

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.1985



*КПСС өлкә комитеты бюросы*
*һәм Татарстан АССР*
*Министрлар Советы карары*

## 1985 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләрен бирү турында





Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитеты тәкъдимен караганнан соң, КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карар бирәләр:

1985 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирергә:

1. АРСЛАНОВ Нури Газизовичка — шагыйрь, «Иделем — илем» исемле шигырьләр һәм поэмалар китабы өчен.

2. НИГЪМӘТҖАНОВ Мәхмүт Нигъмәтҗановичка — музыка белгече, татар халык музыкасы турындагы «Татар халык җырлары» һәм «Идел буе татарларының халык җырлары» дигән хезмәтләре өчен.

**КПССның Татарстан**
**өлкә комитеты**
**секретаре**
**Г. УСМАНОВ.**

**Татарстан АССР**
**Министрлар Советы**
**Председателе**
**И. САДЫЙКОВ.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

7

1985

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*


1985 ЕЛ — ХАЛЫКАРА ЯШЬЛӘР ЕЛЫ

Х. ӘШРӘФҖАНОВ. Фестиваль балкышы . . . . 3

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Н. ГЫЙМАТДИНОВА. Соңгы очрашу. Хикәя . . 6
Ә. МӘХМҮДОВ. Сызлаган җан монологы. 10
Р. ЗАКИРОВ. Сагыну хисе турында баллада. Шигырьләр . . . . . . . . . . . 12
Д. ГЫЙСМЕТДИНОВ. Юмористик хикәяләр . . . 16
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Мәңгелек ут яна мәйданнарда. Шигырьләр . . . . . . . . . . . 20
Р. ГАЗИЗОВ. Безнең яшьлек. Шигырьләр . . . . 24
Г. МОРАТОВ. Мин дөньяны тыңлыйм. Шигырьләр 26
Л. ЛЕРОНОВ. Бүгенгедән — килер көнгә. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 29

ОСТАХАНӘ

Н. ХӘСӘНОВ. Инешемдә — гомер агышы. Хикәя 31
Г. БӘШИРОВ. Яшьләргә өмет. . . . . . . . . 40

М. ЮХМА. Көнгыш — үлемсезлек кошы. Повесть 43
Я. ЧАНЫШЕВ. Мәңге исән Мулланур. . . . . . 110

Г. АФЗАЛ. Муса Акъегет. Шигырьләр . . . . . 112
Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Күяшлы яклар гөле. Хикәя . 117

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

М. ШАБАЕВ. «Калевала»га — 150 ел. Эпостан өзек 125
А. КОНАНБАЕВ. Ак көмештәй... Яңа тәрҗемәләр 129

МУЛЛАНУР ВАХИТОВНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

М. МУЛЮКОВ. Мөселман социалистлар комитетын төзүче . . . . . . . . . . . . . 131

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Т. ХАҖИӘХМӘТОВ. Уральскида Тукай урыннары 136

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

В. СТЕКОЛЬЩИКОВ. Кама суы буенда . . . . . 137

УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

А. ХӘСӘНОВ. Кайсы ысул кулайрак? . . . . . 140
Р. НИЗАМИЕВ. Геройлар — тормышның үзендә . 145

АЭС — ӘДӘБИ ПОСТ

М. ӘМИРХАНОВ. Гаризалар. Очерк . . . . . . 150

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

С. ХАФИЗОВ. Шагыйрьләр һәйкәле . . . . . . 154

СӘНГАТЬ

З. ХӘЙРУЛЛИНА. Җыр да җиңү яулашты . . . 160

Укучыбыз яза . . . . . . . . . . . . . . . . . 164

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Ә. КӘРИМУЛЛИН. Татар китаплары кайда саклана? . . . . . . . . . . . . . . . 165

БИБЛИОГРАФИЯ

М. ГОСМАНОВ. Татар фольклористикасының яңа казанышы . . . . . . . . . . . . . 175

Л. ЕЛЬКОВИЧ. Гүзәллек ничек туа? . . . . . . 178

ШАКИР МӨХӘММӘДЕВНЕҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Р. ӘМИРХАНОВ. Давыллы чор җырчысы . . . . 181

Ш. МӨХӘММӘДЕВ. Максат.— «Карчыга» журналыннан . . . . . . . . . . . . . . . . 182

АЛМАЗ МОНАСЫЙПОВКА 60 ЯШЬ

Н. ШӘРИФУЛЛИНА. Моң тамырсыз булмый . . 185

Габдрахман Әпсәләмов хатлары . . . . . . . 188

Культура тормышы көндәлеге . . . . . . . . 190

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

ӘХӘТ ГАФФАР

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ

МӘДИНӘ МАЛИКОВА

САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*

ТУФАН МИҢНУЛЛИН

ФЛҮН МУСИН

РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*

РӘФЫЙК НӘФИКОВ

НУРИХАН ФӘТТАХ

СИБГАТ ХӘКИМ

РИЗВАН ХӘМИД

НИЛ ЮЗИЕВ

АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

К XII Всемирному фестивалю молодежи и студентов. Статья Х. АШРАФЗЯНОВА «Сияние фестиваля». «Творчество молодых»: рассказ «Последняя встреча» Н. ГИМАТДИНОВОЙ, юмористические рассказы Д. ГИСМЕТДИНОВА. Стихи А. МАХМУДОВА, Р. ЗАКИРОВА, Р. ФАЙЗУЛЛИНА, Р. ГАЗИЗОВА, Г. МУРАТОВА, Л. ЛЕРОНОВА.
Новая рубрика «Мастерская»: рассказ молодого прозаика Н. ХАСАНОВА разбирает писатель Г. БАШИРОВ.
Повесть чувашского писателя М. ЮХМЫ «Кунгош — птица бессмертия» (О Мулланурe Вахитове). Послесловие к повести написал ветеран партии генерал-лейтенант в отставке Я. ЧАНЫШЕВ.
Стихи Г. АФЗАЛА и рассказ Р. ТУХВАТУЛЛИНА «Цветок солнечного края». «Дружба литератур — дружба народов»: «Калевале»—150 лет (Отрывки из эпоса в переводе М. ШАБАЕВА); материалы к 140-летию великого казахского поэта-просветителя Абая. К 100-летию М. Вахитова: статья М. МУЛЮКОВА «Организатор Мусульманско-социалистического комитета».
К 100-летию Тукая: рисунок Т. ХАЗИАХМЕТОВА из серии «Тукаевские места в Уральске». В рубрике «Татарстан — родной мой край» статья первого секретаря Чистопольского РК КПСС В. Д. СТЕКОЛЬЩИКОВА.
«Одиннадцатая пятилетка: люди и дела». Материалы А. ХАСАНОВА и Р. НИЗАМИЕВА.
Очерк М. АМИРХАНОВА с литературного поста журнала — со строительства ТатАЭС.
Статьи С. ХАФИЗОВА и З. ХАЙРУЛЛИНОЙ, посвященные к 40-летию Великой Победы. Фронтовые письма Г. АБСАЛЯМОВА.
К истории культуры: Статья А. КАРИМУЛЛИНА «Где хранятся татарские книги?»
В разделе «Библиография» рецензии на новые книги А. Яхина и Х. Якупова.
В номере отмечаются 120-летие писателя Ш. Мухамедова, 60-летие композитора А. Мунасыпова.
На наших обложках: творчество художника Б. УРМАНЧЕ.

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

Техник редактор Р. Сөләйманова. Корректорлар Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова.

Производствога бирелде 29.04.1985 ел. Басарга кул куелды 17.06.1985 ел. ПФ 05177. Офсет ысулы белән басылды.
Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетно-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 64049. Заказ Ф-190. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1985 ел.

*1985 ел — Халыкара яшьләр елы*

# ФЕСТИВАЛЬ БАЛКЫШЫ

Назым Хикмәт Бөтендөнья яшьләренең III фестиваленнән соң болай язган иде: «Шушы көннәрдә җир шарының төрле нокталарына 26 мең күгәрчен очып китте,— каралар, аклар, сарылар. Барысы да батырлар, куәтлеләр. Алар диңгезтауларны кичәләр. Бу күгәрченнәр үз канатларында тынычлык, азатлык, милли бәйсезлек, дуслык алып киләләр».

Атаклы төрек шагыйре, революционер Н. Хикмәт 1951 елда Берлинда үткән III фестиваль рухын, образлы гына итеп, әнә шул кыска җөмләләргә сыйдырган. Фестивальнең атом сугышына каршы бердәм чыгыш ясаган 26 мең делегатын тынычлык күгәрчене белән чагыштырган.

Бу урында XII фестивальнең эмблемасы авторы Рафаэль Зиннур улы Мәсәгутов белән ел башында булып үткән очрашу хәтергә төшә. Казанга кыска вакытлы командировкага килүеннән файдаланып, без аны «Татарстан яшьләре» газетасы һәм Казан телевидениесенең берләштерелгән «Заман һәм яшьләр» клубына чакырган идек. Әңгәмә танышудан башланды.

— Үзем Волгоград өлкәсендә туып үстем, хәзер Киевта яшим,— диде ул, безнең сорауга җавап итеп.— Әтием рәсем дәресләре биргән, әнием татар теле һәм әдәбияты укытты. Сәнгатькә, туган телемә мәхәббәт дә шулардан күчкәндер.

Украинаның Н. Островский исемендәге комсомол премиясе лауреаты Р. Мәсәгутов безгә фестивальләр тарихыннан кызыклы вакыйгалар сөйләде.

— Халыкара фестиваль хәрәкәтенең традицияләре буенча аның эмблемасы җир шарының кыйтгаларын символлаштырган биш таҗлы чәчәк сурәтендә. Ул таҗлар ак күгәрчен рәсеме төшерелгән җир шарын әйләндереп алган.

Эмблема буларак ромашка 1957 елда гамәлгә керә. VI фестиваль өчен аны Мәскәү рәссамы К. Кузнецов иҗат иткән иде. Ромашка катнашучыларга шулкадәр ошый ки, Халыкара әзерлек комитеты биш континент яшьләренең дуслыгын символлаштырган бу чәчәкне киләчәктә үткәреләчәк фестивальләрнең эмблемаларына да мәҗбүри бер элемент буларак кертергә кирәк дигән карар кабул итә.

Быел расланган эмблема XII фестивальнең «Империализмга каршы теләктәшлек, хезмәттәшлек, тынычлык һәм дуслык өчен» дигән девизын бик ачык гәүдәләндерә. Шуңа да ул йөздән артык рәссамның меңнәрчә әсәрләре арасыннан сайлап алына.

Ромашка чәчәге, тынычлык күгәрчене... Аларның яктылыгы бүген бөтен планетабызны балкыта кебек. Назым Хикмәтчә әйтсәк, җир шарының төрле якларыннан килгән меңнәрчә тынычлык «күгәрченнәре» быел башкалабызның тыныч һавасын сулый, көннәребезгә нур өсти.

Алар арасында минем дустым, илебез вузларының берсендә укучы Никарагуа егете Фердинанда да бар. Без аның белән салкын январь көнендә Мәскәүдә очраклы рәвештә танышып киткән идек. Фестиваль, аңа хәзерлек турында сүз чыккач, ул дулкынлануын яшермичә менә ниләр сөйләде.

—... Безнең «19 июль» исемендәге Сандино яшьләр оешмасы Мәскәүдә фестиваль үткәрү турындагы хәбәрне хуплап каршы алды. Безнең оешмада биш мең член, егерме мең членлыкка кандидат исәпләнә. Фестивальгә хәзерлек, совет яшьләре ишетеп беләдер, Америка империализмы тудырган каты басым астында бара. Илебез җитәкчелеге чакыруы белән 60 меңләп егет һәм кыз төрле провинцияләргә таралдылар. Аларның төп максаты — наданлыкны бетерү. Ә күп яшьләребез ил иминлеге сагында тора.

Без һәр адымда совет яшьләре тормышыннан, алар узган тарихи юлдан үрнәк алабыз. Интернационализм байрагы безгә көрәштә көч өсти. Никарагуа яшьләре күңелләре белән барысы да тынычлык һәм дуслык байрагы астында узучы XII фестиваль сафларында...

Бөтендөнья яшьләренең быелгы форумы Гитлер фашизмын һәм Япония милитаризмын Җиңүгә 40 ел тулган көннәргә туры килә. Бу хәл фестивальнең сугышка, империализмга каршы үткәреләчәк күп санлы чараларына аерым бер мәгънә өсти. Фестиваль программасы 1985 елда Хельсинкида иминлек һәм хезмәттәшлек буенча гомум Европа киңәшмәсенең йомгаклау актына кул куюга ун ел тулуны һәм БМОның быелгы елны Халыкара яшьләр елы дип игълан итүен дә исәпкә алып төзелгән.

Еллар уза тора. Вакыт төрле политик ориентациядәге яшьләр оешмалары арасында хезмәттәшлек һәм үзара аңлашуга ярдәм итүче әһәмиятле фактор буларак фестиваль хәрәкәтенең абруе күтәрелә баруын раслады. Үткән унбер фестивальнең һәркайсы зур политик вакыйга дәрәҗәсенә күтәрелде, дөньяның демократик яшьләренә тынычлык өчен көрәштә тырышлыкларын берләштерергә ярдәм итте.

Мәскәүдәге фестиваль халыкара хәлнең катлаулы бер чорында үтә. Бүген АКШ һәм НАТОның хәрби көчләре ашкынып кораллануны алга сөрәләр. Алар калган бөтен дөнья белән тупас көч позициясеннән чыгып сөйләшмәкчеләр. Ә совет яшьләре фестиваль алдыннан оештырылган тынычлык маршында уртак иминлекне хуплаучы тынычлыкны иң беренче өндәмә итеп күтәрделәр. ВЛКСМ Үзәк Комитетының VIII Пленумы карары нигезендә Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышлап үткәрелгән совет яшьләренең Бөтенсоюз фестивалендә бу лозунг яңа төсмерләр, күркәм эшләр белән баетылды.

Бөтендөнья фестиваленә әзерлек йөзеннән үткәрелгән Бөтенсоюз фестивале безнең ил яшьләренең хезмәттә, укуда, фән һәм техниканы үзләштерүдә, сәнгатьтәге казанышларын барлауда зур роль уйнады. Татарстанның яшьләр оешмалары да һәр егет һәм кызның Бөтенсоюз фестивалендә актив катнашуына ирешү өчен зур масса-политик эш алып бардылар. Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү, материаль, хезмәт һәм финанс ресурсларын экономияләү, фән-техника казанышларын производствога кертүне тизләтү кебек мөһим чараларны тормышка ашыру фестивальгә әзерлекнең иң нәтиҗәле ягы булды. Берничә көн экономияләнгән чимал һәм ягулык исәбенә эшләү, яңа парк-аллеяларга нигез салу, хезмәт коллективларына Бөек Ватан сугышы геройларын кабул итеп, аларның эш хакын тынычлык фондына күчерү кебек яңа башлангычлар барлыкка килде.

XII фестивальгә хәзерлек чоры республикабызның күп санлы комсомол-яшьләр коллективларындагы политик һәм мораль атмосфераны, егетләр һәм кызларыбызның зур эшләргә сәләтлелеген тагын бер кат ачык күрсәтте. Бу чорда фестиваль һәм тынычлык фондларына

йөз меңнәрчә сум акча күчерелде. Менә фестивальгә әзерлек буенча республика комитетына килгән кайбер хәбәрләрдән өзекләр:

«КамАЗдагы кою заводының А. Дубровин җитәкчелегендәге комсомол-яшьләр коллективы беренче квартал планын срогыннан алда үтәде. Бригада социалистик ярышта җиңгән өчен бирелгән 1280 сумлык премияне бертавыштан фестиваль фондына күчерергә булды».

«Яшь композитор, Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Рәшит Абдуллин эшчеләр, колхозчылар белән иҗади очрашулар циклыннан килгән 1600 сумлык керемне фестиваль фондына күчерде».

«Түбән Камада һәр дүрт маршрутның берсендә йөрүче трамвайларга фестиваль символикасы төшерелде. Идарәнең комсомол-яшьләр звенолары үз коллективларына герой якташлары И. К. Катушкин, В. Н. Николаев, Л. А. Говоров, М. Х. Сыртланованы кабул иттеләр. Аларның хезмәт хаклары фестиваль фондына күчерелә».

Ә менә бу хәбәр Балык Бистәсе районы Биектау урта мәктәбеннән: «Тоннадан артык макулатура җыеп, акчасын фестиваль фондына күчердек. Эш дәвам итә»...

Боларга охшаш мисалларны күпләп китерергә мөмкин булыр иде. Иң мөһиме—фестиваль алды көннәрендә яшьләрнең тынычлык һәм дуслык өчен алып барыла торган хәрәкәтеннән берәү дә читтә калмады.

«...Мәскәүдән шулкадәр ерак яшәсәк тә, безне совет яшьләре белән бүген кайнар теләктәшлек, фестиваль рухы берләштерә, дип белдерде Әфганстан студенты Шөкер Абдулла «Татарстан яшьләре» газетасында чыгыш ясап.— Бүген фестивальчеләр сафында республикабызның дистәләгән егет һәм кызлары атлый. Алар төрле һөнәр, төрле милләт вәкилләре булсалар да, фестивальнең бердәм сулышы белән яшиләр: җиргә тынычлык, какшамас дуслык, антиимпериалистик теләктәшлек».

Татарстанның миллионга якын егет-кызлары да шул ук омтылыш белән рухландылар.

— Бүген көн бик хәвефле,— диләр алар, меңнәр авазына кушылып.— Без, планетадагы кешеләрнең биштән берен тәшкил итүче миллионнарча яшьләр, хәлдән килгәнчә, яшәвебез белән дә, хезмәтебез белән дә тынычлык өчен көрәшергә тиешбез!

— Менә шуңа күрә дә Яшьләрнең һәм студентларның XII Бөтендөнья фестивале эмблемасына күгәрчен сурәте ясадым мин,— дигән иде безгә рәссам Рафаэль Мәсәгутов та.

Озак та үтмәс, фестиваль делегатлары шагыйрь Назым Хикмәт телгә алган күгәрченнәр кебек, илләр-җырләр аша үзләренең туган якларына таралырлар. Ул күгәрченнәрнең күңелләрендәге изге теләкләр һәркемнең йөрәгенә үтеп керсен иде.

...Ә бүген башкалабыз күгендә — балкыш. Тыныч балкыш, фестиваль балкышы.

**Харис ӘШРӘФҖАНОВ.**

## Нәбирә Гыйматдинова

# СОҢГЫ ОЧРАШУ

**хикәя**



Бу көннәрдә аның кыланышы бик сәер иде. Ул бер кулы белән авырткан билен тотып, икенчесе белән баскыч иңсәләренә ябышып, тутыгып беткәп мылтыгын чормадан алып төште дә, шуны майлаган-сыйпаган булып, ишегалдына су эчәргә дип төшкән чыпчыкларга төзәп, көнозын утыра бирде. Ауга йөрергә инде соң иде. Картайды шул, күзе дә рәтләп күрми, бармаклары да тыңламый. Моңлы матур күзләрдә күл буйларын урап йөргәндә, аның колаклары камыш арасында чупылдашкан кыр үрдәкләренең тавышын ишетә. Бүген-иртәгә очарга җыеналар. Кыр үрдәкләрен хәзер таз Әнвәре ата. Ул яшь, таза ир. Кайчандыр Сабир хуҗа булган ау биләмәләре сиздермичә генә аңа күчте. Күчсә күчәр, гомер шулай инде ул, моңа артык көенми, аны үкендергән нәрсә — җанның җиденче катына яшеренгән һәм Сабир үзе генә белгән сер. Күпме сагалап та эт-бүрене үтерә алмады бит ул! Язын да, көзен дә, сагалады, тездән кар ерып, кыш буе да урман эчен айкап йөрде, барыбер үтерә алмады... Эт-бүре һаман исән, һаман яши иде.

Картлык гомеренә барышлый Сабир картка ике хәсрәт иярде: берсе бүре, берсе суга батып үлгән малай. Өрәңге яфрагы төсле киң учка салып үчтеки сикерткән беренче бала! Беренче! Аннан соң да малайлар туды, тик, ни хикмәттер, алар кимрәк шатлык китерә иде. Бүреләр белән дә шулай: төннәрен авыл тыныч йокламады. Исәпсез-хисапсыз ау корды Сабир карт, бүренең ниндиен генә каптырмады, ләкин боларның берсе дә чын ау түгел, чын ау беренче дошманы эт-бүре исеме белән канга сеңеп калган иде. Шулай булмаса, бүген ул тутыккан мылтыгын чистартып утырыр идеме соң! Онытылды, бетте дигәндә, өченче көн кибет янында мышный-мышный Әхтәм сөйләп тора:

— Эт-бүрене күрдем, малайлар. Урман кырыенда ята бу, хәл җыеп. Күрүем булды, эчемә кату чыкканчы чаптым, малайлар.

Сабир карт өч кадак шикәр артыннан кибеткә килгән иде. Әхтәмнең сүзләрен ишеткәч, кирә торган җиреннән кире борылып, төркем янына килде.

— Юкны лыгырдап тел генә чарламыйсыңмы, олан?— диде ул, Әхтәмнең җиңеннән тарткалап.

— Чәчрәп китим, мәгәр дә алдашсам, күзләрем якты кояш төсе күрмәсен!

— Колагында нәни генә ак тамга бар идеме?

— Бар, бар, Сабир абзый.

— Һе, алай диген. Ниме соң, койрыгы ала-кола идеме?—Сабир карт бу соравым белән шушы тел бистәсенең ялганын тотармын да, шикшөбһәләрем таралыр дип өмет итте.

— Койрык... койрык,— диде Әхтәм кабатлап.— Койрыкмы? Әллә соры, әллә ала? Тукта әле...

Карт аучының эченә жылы йөгерде. Ул түгел! Эт-бүренең төптән үк койрыгы өзелгән иде.

— Исемә төште, жанваркай койрыксыз иде!— дип кычкырып жибәрде Әхтәм һәм Сабир картны шул сүзләре белән үтереп ташлады. Бүтән сораштырасы да юк. Үзе... Күпме генә төпченсәң дә — үзе!

— Мәйтәм, Сабир абзый, мөртәтнең бәйләнергә исәбе дә булгандыр. Авылдаш дип тормас, мәйтәм.

Сабир картның хәлләре шаяртудан узган, хәзер аңа дөньяда кәмитмәзәкләрдән дә авыррак нәрсә юк иде. Бигрәк тә аның, Әхтәмнең маймыллануыннан тәм табып, бот чаба-чаба көлгән ирләргә ачуы чыкты. «Камырдан әвәләнгән әзмәвер токымы! Мылтык түгел, рәтләп сәнәк сабы да тота белмисез бит, гарьлек»,— диде ул эченнән генә сүгенеп һәм, шикәр алырга да онытып, өенә ашыкты.

Инде көз бакчадагы куакларга сары буявын тамызып йөри, жәйнең гомере әкрен генә кыскара, кыр-басулар шәрә калган, очар кошлар китәр юлга жыена иде. Чакрым ераклыктагы урман гына үзгәрми — куе яшел. Әллә Сабир картның күзләре алдана, әллә урман жәй төсен озаграк сакларга тели. Карт, ниһаять, тәвәккәлләде. Ул явызга бер ядрә житә. Мылтыкны ике ядрә белән корсаң, ышанычлырак булыр иде дә, аучы Әнвәрдән бит ертып теләнәсе килми.

— Кая барасың, алла бәндәсе?— дип өйдән карчыгы Сәкинә чәчрәп чыкты. Картының тикмәгә мылтык сыйпаштырмавын ул белә, әгәр алай-болай ау дия калса, аяк терәп каршы төшмәкче була иде.

— Теге исән ди, әнә.— Карт урман ягына ымлады.

— Кем?

— Алаколакны әйтәм, исән, ди. Атам, бигайбә!

— Кемне атасың, карт жүләр? Саташма!

Байтак сулар акты инде, йортка берәм-берәм бәла-каза ташыган Алаколак та Сәкинәнең хәтер иләгеннән иләнеп ташлангандыр. «Кайткач сөйләрмен, чәй эчкәндә»,— дип уйлады карт.

— Кит әле, читкәрәк китеп бас,— диде ул карчыгын эткәләп.— Сәхрәгә чыгам, эч поша.

— Сәхрәдә кемне атасың, алла бәндәсе? Бир монда мылтыгыңны! Ул сиңа таянырга таяк мәллә, бир!

— Әнвәр сораган иде, илтим булмаса,— дип алдашудан битәр чарасы калмады Сабир картның.

Карчыгыннан жиңел генә котылуына сөенеп, карт урманга табан борылды. Башта чытырманлык эчендәге өнен барып тикшерергә кирәк. Бер ияләшкән жиргә килми калмас. Аңа хәзер аунап хәл жыярдай тыныч урын тансык. Картайган ул. Эткә бирелгән гомерен дә очлап килә. Шәт, этлекнең дә соңгысын эшләр. Балалар ялга кайткач суярбыз дип симерткән бәрәнне алырмы... әллә Сабирның үзенме?..

Сабир карт тигез жирдә сөрлегеп куйды. Үлемгә каршы бармый микән ул? Авыртмаган башына тимер тарак эзләмиме? Бая йөрәкне дулаткан көч-гайрәт инде кими төште. Жилкәдә дылк-дылк селкенеп барган мылтык та гади таяк кына булып тоела иде.

Урман — төпсез дәрья кебек, ерактан ук үзенә тарта. Ләкин бүген Сабир карт аның ымсындыргыч көченә буйсына алмас иде. Сүрелгән йөрәкне яңадан дөрләтәсе бар. Тукта әле, үткән-сүткәннең серен тыңларга яраткан иман ышыгына утырып хәл жыйсын ул. Хәл жыйсын һәм картлыгын онытсын. Титаклаган картлыктан да яман нәрсә юк икән.

һаман тыя, һаман чабудан тарта. Их, бар иде заманалар. Бер төзәүдә өчәр куян аткан чаклар! Ул көннәр Алаколак белән бергәләп кайларда адашып калды икән? Алаколак... Алаколак... Дөньяда бер әйбәт ау эте иде. Кычкырганны яки өндәгәнне дә көтеп тормас, күз карашыннан барсын да аңлар. Хуҗасы белән икесенең даны тирә-якка киң таралды. Сабир дисәләр, Алаколак димичә калмыйлар иде. Әйтерсең, бу икәү ау өчен генә яратылганнар да, урман өчен генә туганнар иде. Әмма ялгышты Сабир-аучы. Мактаулардан башы әйләнеп, фани дөньяның нечкә якларын онытып җибәрде. Ә Алаколак акыллы җанвар иде. Ул кыр бетереп куян эзләп чабулардан, бүре өннәре табудан кала тагын бер изге бурычы барлыгын белә иде. Кемгә нәрсә, аның нәсел озайту вакыты җитеп килә. Монда инде бернинди тоткарлык та була алмый, монда ни хуҗа, ни хуҗабикә каршы килә алмый иде. Чөнки бу Алаколакның үз эше иде.

Нәкъ ау көннәре башланганда эт хуҗаның йортыннан югалды. Хуҗа башта аптырады. Менә-менә кайтырын көтеп көн уздырды, төн уздырды. Эт күренмәгәч, ачудан шартлар дәрәҗәгә житте. Ачу ачу инде, борчак сыман тиз бүртә, бүртә дә, ниһаять, шыта. Шунда күсәкнең башы кемгә тия: хатынгамы, әллә Алаколаккамы? Кешеләрнең ачуы бик хәтәр икәнен каян белсен ди Алаколак, яңа туган баласын ияртеп кайта да керә. Күрегез, янәсе, бераүнең кеме бар! Һәм «әйдә, хуҗа белән исәнләш» дигән сыман йомшак кына бәләкәченә төртә. Хуҗа зәһәр ачуыннан куырылып келәт янында балта кайрый иде, алпан-тилпән атлап үзенә якынлашкан этләр өстенә балтасын тондырды.

— Мә, үләт кыргыры, җәзасын ал!

Нинди генә җәзаларга риза булмас иде Алаколак, тәпиен, колагын бүредән чәйнәтер, «ул» дисәләр, тәгәрәп үләр иде. Ләкин... ләкин мондый җәзаны дошманына да теләмәс иде.

Балта үткен йөзе белән эләгеп аның җан парәсен җиргә сеңдерде. Каян килеп тиде ул вәхши тимер? Этнең күзләре хуҗа кулында ялтыраган тимерне капкадан кергәч тә шәйләп алган иде. Андый әйберләр җансыз була, һавада очмый, аякланмый. Димәк, хуҗа?.. Эт, бәгыренә шырпы кадалгандай, улап җибәрде. Әйе, әйе, авызын күккә күеп улап җибәрде. Хәрәкәтсез яткан баласын иснәде дә кайгысыннан шашып-шашып улады.

Ишегалдындагы шау-шуга хатын да йөгереп чыккан иде, баскычтан төшә алмыйча көл сыман агарынып катып калды. Аннары рәнжеш тулы күзләрен иренә төбәде:

— Нишләдең син, мәртәт? Алаколакның баласын үтергәнсең ич!

— Әнә, Якублар мең тәңкәлек тире тапшырганнар,— дип мыгырданды Сабир.— Безнеке вакытлы-вакытсыз бала таба.

— Их сине, туң күчән!— диде хатыны әрнеп.— Болай да сиңа хезмәт итә-итә хайван картаеп бара иде. Беренчесе бит ичмасам, беренчесе! Кара! Эт хәтере хәтәр була, кара аны!

Алаколак чынлап та, хәтәр хәтерле иде. Аучыны ул бар ерткычлардан да ерткычрак адәм дип уйлады. Хуҗага дигән үч ныклап торып күңеленә кереп урнашты.

Эт йорттан качып урманда яши башлауның алтынчы аенда Сабирның көтүдән буленеп калып басуда чемченергә гадәтләнгән сыеры җәрәхәтеннән озак кына аягына басалмады. Сыртындагы теш эзләре Алаколакныкы иде. Исәп-хисапны өзде дип, моңа әллә ни көенмәде Сабир. Ялгышкан икән, озак та үтмәде, эт абзардагы өч сарыкны буып ташлады. Ярар, диде Сабир, бусына да теш кысып ризалашты. Инде буаз танасы да эт авызына эләккәч, хуҗаның сабыр касәсе тулып ташты. Явызның кылган зыяны йөрәген сикертә иде. Ул бозау хәтле овчарка ияртеп кайтты да, бәйләмичә генә ишегалдына җибәрде. Овчарка өйалды астында йокларга ярата иде. Алаколак аны көпә-көндез, чината-чината өстерәп

чыгарып, чәйнәп ыргытты. Инде эт-бүрегә әверелгән ерткычны атарга кирәк иде.

— Башта атып җәрәхәтлим, аннан соң куакка асам,— дип гайрәт чәчкән Сабир иртәрәк нәтиҗә ясады. Эт-бүре үзен бик оста яшерә, кайчагында Сабирның үзен дә чытырманлыкларда адаштырып калдыра иде. Көрәш айлардан елларга тартылды. Алаколак үзен сиздереп яши иде. Дөрес, ул бүтән Сабирны борчымады, терлек-туар исән-имин кыш чыгып җәйгә керә, аучы йорты бәла-казасыз гына гомер чигә, тик Сабирның ау эшләре бер дә мактарлык түгел, бүресе дә, төлкесе дә аңа элеккечә килеп капмый иде. Әлбәттә, хәзер урманга акыллы хайван хуҗа, анардан Сабирга сыңар куян боты да эләкмәячәк иде.

Бәлкем, Әхтәм теленә салынмаса, Сабир карт эт-бүре белән алышбирешне тәмамлаганга санар һәм карт сөякләрен шыгырдатып урман юлын таптамас та иде. Юк, юк дисәң дә бөтен тән бөйләп шом таралган. Әгәр посып яткан җиреннән өскә сикерсә? Ни атып, ни качып өлгермәссең. Кинәт Сабир картны өркетеп агач ботакларына бәрелә-сугыла ябалак пырхылдады. Җиргә шыбыр-шыбыр имән чикләвеге коелды. «Бу мәхлук кошны атып мәктәп балаларына илтим әле»,— дип калкынды карт, тик мылтыгын күтәргәч кире төшерде. Ядрәсе бер генә иде. Тынычлыгын мәңгегә җуйдырган эттән котылырга кирәк бит Сабир, ашыкмасын әле, ашыкмасын.

Ябалак канатларын шапылдатып һаман чикләвек сибә иде. Әллә төлке-мазар исенә микән? Карт муенын сузып-сузып тирә-якны караштырды. «Юкка-барга чәбәләнмә, туган, урман тыныч»,— димәкче иде ул, тик иреннәре «ю» дип түгәрәкләнде дә калды. Сабир карттан дүрт-биш адымда гына Алаколак утыра иде. Элекке гадәт белән карт гөрселдәтеп һавага атып җибәрде. Ядрә бушлыкка очмады, үлем тоеп бәргәләнгән ябалакка тиде. Бичара кош, канатларын җәйгән килеш, топ итеп аяк очына килеп төште. Эт хәйран тамашага илтифатсыз калды, ичмасам кымшанмады да. Сабир картны үчекләгәндәй, авызыннан бияләй хәтле телен чыгарып ирен читләрендә биетә башлады.

— Бүтән ядрә юк,— диде Сабир карт, имәнгә ныграк сөенеп.— Бар ышаныч кулларда. Я, кил, шайтан токымы. Сикер! Син бу көрәшне көтә идең. Кил, көттермә.

Эт аякларын сузып чирәмгә ятты да арган күзләрен Сабирга төбәде. Ул күзләрдә моң бар, сагыш бар, тик мәкер юк иде.

— Исәнме, Алаколак?!— диде карт аучы, бераздан күңеле йомшарып.— Картайгансың син. Мине әле дә кичермәдеңме? Беренче улым Галимҗаным суга батып үлгәч, минем дә бавырыма кан саугандай булды. Шунда синең хәлеңне аңладым, Алаколак. Дуслашырга иде безгә, ике яралы җанга. Ә син үчләштең дә үчләштең. Йорт-курамда мал-туар асратмадың: килдең-будың, килдең-будың... Озак аўладым сине, тоттырмадың.

Кинәт эт-бүре колакларын торгызды һәм телен тиз генә авызына җыеп алды. Кемдер кипкән ботак-санакларны кыштырдата-кыштырдата бу якка табан атлый иде.

— Картлач! Тагын кемне каптырдың?— дигән тавыш ишетте Сабир карт. Тавыш иясе эткә атап дәшә иде.— Ә-ә, Сабир абзый икән. Нихәл, сау-сәламәтме?

— Ярыйсы әле, олан,— диде Сабир карт, урман каравылчысын танып.— Син Зиннәт малае бит әле, Шәрбән авылыннан. Атаң бик игелекле кеше иде. Ләкин аучыларны җене сөймәс иде.

— Миндә дә эти холкы,— диде каравылчы, кырын-кырын гына атылган ябалакка карап.— хәлемнән килсә, чыпчыгын да аттырмас идем. Сине әйтәм, Сабир абзый, бу кош өчен ничек эт өзгәләмәгән әле. Ул да мылтыклыларны яратмый. Йкенчеләй аң бул, яме.

— Синең этмени?— Сабир картка ялгыш кына эшләнгән гөнаһысы

өчен чамасыз оят иде. Урманга килүнең сәбәбен әйтергә дә ничектер теле әйләнмәде.

— Юк шул. Шәп эт, югыйсә. Үзем белән урман саклый, йортыма күпме ияләштерергә тырыштым, ияләшмәде. Кыргый зат син, шулаймы, дустым?— Каравылчы иелеп этнең башыннан сыйпады.— Ярар, кайтыйк булмаса. Хуш, Сабир абзый.

— Хуш, олан. Син дә хуш, Алаколак. Тәки кеше җылысын тансыклыйсың бугай, каравылчы тирәсендә ураласың икән. Хәер, син бит минем кансызлыгым аркасында гына бүре тиресе ябынган инде. Хуш, Алаколак, хуш!

Ул мылтыгын сөйрәп тузанлы юлга чыкты. Карчыгына сөйләсәң, ышанмас иде. «Саташасың, җүләр. Чәйне куерак ясыйм, миеңдәге чүпчарларны юсын»,— дияр.

Әрәмәлек янына житеп килгәндә, кинәт арттан лерт-лерт итеп нинди дер жанвар юыртканы ишетелде. Карт борылып карарга да өлгермәде, Алаколак аның каршысына чыгып басты. Этнең авызында бая атылган ябалак иде.

— Алаколак?!— дип гаҗәпләнде Сабир-аучы.— Алаколак?!— Икенче мәртәбә очрашу аны аяктан егар сыман: тез буыннары йомшарды, күзләр яшь белән тулды. Эт-бүре аңа ияргән түгелме соң?— Төп йортыңа кайтасыңмы? Сагындыңмы безне? Әйдә, әйдә, туган. Мин дә куаныр Сәкинә, мин дә куаныр,— дип сөйләнде карт.

Алаколак бу чакыруны аңлый иде. Этнең хәтерен яктыртып бәхетле ау көннәре терелде. Гаҗәеп татлы иде бу хәтер! Хуҗаның иркәләп сыйпаган куллары... Хуҗабикәнең тәмле ашлары... Һәм балта... Юк, юк! Бу кеше аның өчен хәзер беркем дә түгел. Җиде ят! Үз юлы белән китә бирсен. Каравылчы кушмаса, артыннан кош күтәреп элдертәсе дә түгел иде.

Эт ябалакны лапылдатып Сабир картның аяк астына ташлады да кире урманга таба чапты.

## Әмир Мәхмүдов

# СЫЗЛАГАН ҖАН МОНОЛОГЫ

Сызлана җан: хәбәр алган
Заман давылларыннан.
Сызлана җан: яра калган
Җиһан ялкыннарыннан...
Бер карасаң, дөнья тыныч:
Ак чәчәктә алмагач.
Су буенда нәни бала
Кояш кебек ялангач.
Күл өсләрендә көймәләр
Тыныч кына киләләр.
Тетрәтеп гүя җир шарын,
Чибәр кызлар көләләр...

Кызыл түбәле кирпеч өй
Утыра яшеллектә,
Торна кыяфәтле кран
Ыргагын элгән күккә:
Тау башында — яңа шәһәр,
Ак кирпечтән — ак өйләр.
Тыныч, горур манаралар
Гүя күкне саклыйлар.
...Карабодай басуы ак,
Бал кортлары бал ала.
Дөнья тыныч... Тирләп-пешеп
Шагыйрь яза баллада.

Бер карасаң, дөнья тыныч,
Талгын судай тын ага.
Күңел генә тыныч түгел,
Күнми «тыныч дөнья»га...
Чиксез күккә күзең төбә!
Зәңгәр күкләр тып-тыныч.
Тып-тыныч күкнең кайчан соң
Булганы бар куркыныч?
...Шагыйрь күзе күпне күрә,
Шуңа да бит ул — шагыйрь.
Зур дөнья гаме, еландай,
Шагыйрь күңелен чагар.

Җаным сызлый, күңел елый,
Дәва табыйм тизерәк.
Дөньяны иңләсен күзләр,
Күргәннәргә түз, йөрәк!

Кешеләрнең фигыле төрле,
Мең халәт мең тарафта.
Яши җирдә тыныч җаннар,
Уйлылар, битарафлар...
Уйланганнар уйлап таба:
Умарта күк калалар,
Гөлбакчаларга әйләнгән
Иксез-чиксез далалар...

Президентны үтергәннәр —
Фаҗигале инцидент!
Гангстерны азат итә
«Кешелекле» президент.

Хәрәкәттә — танкодромнар,
Су астында — көймәләр.
Гүли хәрби аэродромнар...
Тамырда кан төйнәлә...
Хәрби корпорациягә
Башын игән кол да бар.
Кара үлем машинасын
Ясаган ак кул да бар!

Җирдә шулай яши бирә
Тынычлар, уйланганнар,
Һәр нәрсәгә битарафлар,
Тереләй үле җаннар...

Бәхетлеләр дә күп ләкин,
Җирдә бәхет юк димик:
Атомнар белән серләшә
Яңь-яшь бер академик...

Бәхетле — иҗат газабын
Кичергән композитор...
Бала сөйгән анадан да
Бәхетле кеше юктыр.
...Кешегә шатлык өләшә
Бу дөньяда юмор, хис.
Гомеребез шатлыкларга
Бик лаеклы гомер ич!

Тынычлан, җан, тынычлан син,
Тыныч галәм, тыныч таң.
Тынычланмый: отып алган
Сыкрау моңын тарихтан.
Югалтуга ышанмый җан...
Булган нинди алышлар!
Хәтта фашист балтасына
Баш имәгән Алишлар.
Дим буйларында шомыртлар,
Сызландырып бәгырьне,
Көтә — мылтык тütәсенә
Шигырь язган Кәримне.
Меңнәр сөйгәннәрен көтә,
Көтә алар тилмереп.
Йөрәк аша пуля үтә
Хыялларны җимереп.
Ничек сокланмасын җаның
Мусалар куәтенә?!
Кыю ир Җәлил алдында
Баш игән гильотина.

Яруллинны сагынган җан,
Була күр син түземле! —
Кан тамыры киселгәндәй,
Моңлы бер кыл өзелде...
Гөлләр турында яз, шагыйрь,
Зәңгәр күкләрне макта.
Тик күңелең онытмасын
Янганнарны учакта.
...Кешелек аңлы булганда
Илләр уяу булганда,
Дәрьяга төшеп югалмас
Кечкенә бер утрау да.
Кешелек алдында көчсез
Иң көчле кораллар да.
Кешелек көчле булганга
Үлемсез Гренадалар!

...Зур тарихтан тузан гына,
Тузан гына ул кеше.
Кеше булуын раслыйдыр
Бары тик кылган эше.
Кеше гомере бик-бик кыска,
Чәчәк аткан гөл генә.
Сокланып та туялмыйсың,
Гүзәл гөлләр өзелә.
...Толлар гына бәхетсезме?
Мәхәббәтсез — кем, дисез?
Җанда мәхәббәт булмаса,
Хәтта яшәү күңелсез.
«Бу — хакыйкать!» диярсез сез,
Җан килешә: хакыйкать.—
Шул хакыйкать өчен кеше
Утка кергән ничә кат.
...Бәгъзе адәмнең гадәте
Сыймый аек акылга.
Һәр мизгел алтыннан кыйммәт,
Ә ул гашыйк... алтынга!

Тынычлан, ашыкма, Кеше,
Тыныч суларда уйна.
Кулыңа мылтык алганчы
Минем хакта да уйла.

Көзге күктән җыр-моң ява,
Тыныч көзге иртәләр.
Әйтерсең лә, киткәннәрне
Анда сагынып көтәләр...
Мең-мең еллар үткән җирдән...
Кара туфрак күп Кеше.
Ап-ак чәчәк аткан шомырт,
Ул да кеше җимеше.
Күп еллар элек тә җирдә
Булган бит гүзәллекләр.
Безнең күк хыялый затлар,
Гүзәл кызлар, егетләр.

Гуманист та булган җирдә,
Зур йортлар төзүче дә.
Хәтта кешелек җанына
Утлы ук төзәүче дә.
...Аллага табынганнар да...
Онытканнар алланы:
Имеш, утлар янса янсын,—
Ятлар йортын ялмасын...
Ачык алар фәлсәфәсе,
Нинди генә булмасын:
Җирдә сугыш булса булсын,—
Безнең йортта булмасын».
Ак төсләргә гашыйк алар,
Җәймәләр дә ак булсын!
Кеше каны акса аксын,—
Үз каннары акмасын...

...Утларда да янмый кеше,
Суларда да батмый ул.
Иблискә дә башын ими,
Саф сөюен саклый ул.
...Сүзем мәхәббәт турында,
Иң сөйгәнем — Туган ил!
Гүзәл ярны сөйгән кебек
Сөям сине, туган тел.

Дөньяның фигыле нинди?
Нинди эшкә сәләтле?
Кешенең җаны ук шундый:
Ашыгу — бар халәте.
Институтка ашыга
Чал чәчле профессор да.
Базага бара генерал,—
Ашыга агрессор да...

Дамокл кылычы тора!..
Башыңны имә, Кеше!
Бәхет кошың үз кулыңда,
Синдә Алыплар көче!
Йортлар кор, чәчәкләр утырт,
Ул-кызлар үстер, Кеше.
Тезләндер сугыш алласын,—
Танысын синең көчне.
...Тынычлык кына Җиһанда
Бар кораллардан көчле!
Бар шартлауларның көчле!

...Ядрә тигән арысландай
Сызлый яраланган җан.
Яраланган җан, тынычлан,
Синең өчен мин — Җиһан.

## Рифгать Закиров

### Сагыну хисе турында баллада

Диңгез өстендә күренә күптән —
Әллә акчарлак, әллә ак җилкән?
Кыз карый алга үрелеп басып:
Күзләр кысылган, иреннәр ачык...

Инде гел шулай — ничә ел үткән,
Кыз, көтә торгач, олыгаеп беткән.

...Хәтердә әле, һаман хәтердә:
Сөйгәне киткән иде катерда.
Киткән иде ул җилеп катерда,
Явыз дошманны җиңеп кайтырга.

Кыз калган иде шушы урында,
Уңышлар теләп көрәш юлында.
Егет: «Көт!» дигәч, булды көтәргә...
Кыз көтә һаман, һәм ул көтәр дә!

Көтәр ымсынып офыкка карап,
Аһ, нигә кайтмый ул киткән кораб?!

Күптән тынса да туплар тавышы,
Тора тупсада толлар сагышы.
Диңгез кипсә дә... күңелгә сыйган
Сагыну хисе кимемәс сыман.

## Җыр булып түгелермен...

Эчемдә ни — тышымда шул,
Димим мин өзеп кенә;
Күбрәге күңелдә шул —
Бетермим түгеп кенә...

Йөрәктә ут, ә күземдә
Нурлары — очкыннары.
Яшем — дәрья, керфегемдә
Дымнары шуның бары.

Кайгы катыш сагышыма
Күпме гамь аралашкан!..

Үчекмим мин язмышыма,
Шуңа да карамастан.

Моңа, төптән уйлаганда,
Ышанмас күпләр, беләм;
Шуңа, яшен уйнаганда,
Сөйләшәм күкләр белән!

Сөйләшсәм дә күкләр белән,
Мин болыт түгелдермен.
Моң ургылып күкрәгемнән,
Җыр булып түгелермен!..

*

Чуммас идем хәтта бәхет диңгезенә,
Артып-ташып, тулып-ашып китәр булса;
Бар ләззәтне биреп бары бер үземә,
Бүтәннәрнең бәхетен ким итәр булса.

Төшәр идем сикереп сагыш дәрьясына,
Чайпалмыйча, түгелмичә чыдар булса;
Күпме кайгы һәм хәсрәт-зар — барчасы да
Минем генә кочагыма сыяр булса...

*

Тегермәннең тузган олы ташын,
Җылы онның тузан-онтасын,
Авыр еллар инде кичелде дип,
Җиңел генә ничек онытасың?

Тегермәнгә керсәк, без иң башлап,
Ялый идек ташны алмашлап.
Телләр татлы, йөзләр якты безнең,
Үсмәсәк тә алсу алма ашап.

## Аерылышу

Без кайсыбыз болыт булганбыздыр
Сөю дигән сүнмәс кояшка...
Ничәнче кат күктә торганбыздыр —
Җиргә төштек... аерылгач та,
Сыңар канат каерылгач та...

Бер аерылгач инде күрешү юк,
Кавышу юк инде Сак-Сокка.
Ничек болай булдык — белүче юк,
Сылтыйк микән әллә яшьлеккә?
Үпкәликме икән язмышка...

Безне инде аерым сынар кояш,
Аерым-аерым юар яңгырлар;
Ерак күк читендә кыяр-кыймас
Яшен булып өмет ялтырар,
Күкрәүләре озак яңгырар...
Иңрәүләре...

## Син киткәч

*Бүген дә кичәгедәй*
*Шаулады кырда арыш...*

Гәрәй Рәхим

Син киттең дә күмелдең,
Чуалды кырда арыш.
Кинәт тулып күңелем,
Түгелде сары сагыш.

Сыймый кыр кысасына
Чайпалды зәңгәр житен,
Ташыды — күмде моңга
Зәңгәрсу офык читен.

Акты сөт елгасыдай
Ургылып карабодай.
Инде хисләр дә шулай
Куерып бара бугай...

Син киттең дә күмелдең...
Күңел тулды, дөнья буш...
Күмде басу киңлеген
Гүя сары көнбагыш...

## Таулар моңы

Күз төбәсәм күксел үрләр аша
Ак калфаклы таулар ягына,
Томан булып сүзсез моң сарыла
Бар дөньяга ачык җаныма.

Юксындырып туган туфрагым,
Күз алдыма килсә кыр ягым,
Юмарт бөркеп алсу таң нурларын
Гашыйк итә кабат Уралым.

Һәм көч бирә дәшеп бәйгеләргә
Таулар өне — тыйнак, горур моң...
Тау өстендә таулар микән әллә
Баскычлары иҗат юлымның?

●

Соңгы пароход тетене
Сузылды ярдан-ярга:
«Соң инде» дигән шикелле
Озата барганнарга.

Ә моңлы гудок, сулыгып,
Сарылды гүя җанга:
Үкседе гүя кушылып
Ялгызы калганнарга...

●

Җиде ятка калмый торып,
Ят җәберен беләм димә.
Хыянәткә тармый торып,
Хак кадерен беләм димә.

Бәхет кошын җуймый торып,
Асыл кошны таныйм димә.
Үз-үзеңне җиңми торып,
Үз-үземне табыйм димә...

●

Мендәремдә ялгыз яныл-пешеп
Чыккан төннәремдә;
Тәнем генә түгел, җаным өшеп
Йөргән көннәремдә,

Өмет кошы куныл сайрамаса
Гөлдәй хисләремә,
Була идем я боз, я булмаса
Көл дә кисәү генә.

## Озата барсаң

Син озатсаң әгәр, иркәм, мине,
Көнең елдай озын тоелыр,
Татлы төштәй бергә үткән көнне
Уйлап, җаның күпме кыелыр.

Син озатсаң мине зәңгәр кичтә,
Бар бизәге күкнең җуелыр:
Күк камалып кызгылт-кара төскә
Уелыр да, йолдыз коелыр.

Озаталсаң төнлә озат мине —
Аз булса да таңга каршы бар...
Син озатып калсаң елап мине,
Таңда көлеп кояш каршылар!

Дамир Гыйсметдинов

# ЮМОРИСТИК ХИКӘЯЛӘР

## Күз яше



Селектор аша Гарәфи Хәйдәровичның гөбедән чыккандай калын тавышы яңгырады:

— Барлык тәэминатчыларны хәзер үк минем кабинетка!

Кырыс, тәвәккәл тавышына карап, начальникның башында гаять эшлекле фикер туганын абайларга мөмкин иде.

— Гә-әк, конвейер һаман тик торамы? Булырбулмас ике подшипник аркасында! — дип сүз башлады Гарәфи Хәйдәрович. Я, ниш либез, иптәшләр!

Кабинетта үле тынлык урнашты.

— Әйтер сүз юк дисез инде алайса? Ху-уп! Бер-ике җиргә шалтыраттык, бер-ике оешмага сүзебез үтмәде дә — вәссәлам. Шуның белән тынычландыкмы? Ә ел ахыры — борын төбендә!

Шаммасов үзенең тәэминат эшләре буенча урынбасарына кырын карап алды да тавышын чак кына күтәрә төште:

— Тынычландык та баш катырып азапланмаска булдык, шулаймы? Тәвәккәллек кайда, эш өчен яну кайда?! Чын-чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, ди. Мин менә төн йокысы йокламадым һәм бер әмәлен таптым да кебек. Телефон колагын боргалап утырганчы, ул оешмага үзебез барып кайтсак, ничек булыр? Самолетта нибары ике сәгатьлек юл. Идарәдән эш майтарырлык берәр кеше, ягъни мәсәлән, толкач җибәрсәк, ә? Әмма дә ләкин гади вәкил генә түгел, артист кирәк бу эштә. Чын трагедия уйнап күрсәтерлек кеше! Безнең фаҗигане күз яше коеп сөйләрлек сәләтле артист.

Кабинетта утыручыларның иелгән башлары бераз калкына төште.

— Инде килеп, кемне җибәрү турында уйлашырга кирәк безгә,— дип дәвам итте начальник.— Мине дисез икән, турысын әйтим, чыкмый миннән артист. Үзегез беләсез, каешланып каттым бу эштә... Ә менә баш инженерыбыз турында ничегрәк уйлыйсыз?— Шаммасов шунда ук үз соравына үзе җавап бирүне кирәк тапты.— Дөресен генә әйтсәң, ул да скрипкә кылы түгел. Подшипник сорап яшь коя алмас. Теге ни... урынсыз чагыштыру булса — гафу! Мунча ташын кысып, су чыгарып булмый. Урынбасарыбыз да шулай ук...— Директор, аннан да өмет юк дигәндәй, кул селтәп куйды.— Ул инде... ул безнең теләсә кемнән яшь койдыра алыр, әмма үзе — я-а-ак! Андыйлардан түгел... Я, шуннан? Кемне җибәрәбез?

— Мин әйтергә телим,— дип, кысылырга батырчылык итте яшь инженер Җаббаров.— Технология бүлегендә, бәлки беләсездер дә, Хөнҗәмә Харисовна дигән бер чибәр апай эшли. Көненә, кирәксә, ун мәртәбә елый ала... Кирәксә дә, кирәкмәсә дә.

— Вәт-вәт, нәкъ шундый кеше кирәк!— Начальник, чәп итеп, учы белән өстәлгә сугып куйды.— Молодец, Җаббаров! Хәзер үк табып кертегез үзен минем янга!

Өч-дүрт минут та узмады, утыз биш-кырык яшьләрдәге сөйкемле апай директор каршысында утыра иде инде.

— Ми-ин... ми-ин... Булмас миннән, булдыра алма-ам...— дип мышкылдады ул, чишмәдәй аккан күз яшьләрен яулык читенә сөртә-сөртә.

— Була, болай булгач, була!— дип дәртләндерде аны Шаммасов.— Менә шулай, менә шулай! Тырыш инде син анда, кулыңнан килгәнчә тырыш. Һәм шунда ук миңа шалтырат. Көндезме-төнләме, теләсә кайсы сәгатьтә. Хәерле юл сиңа! Онытма, ни... Планыбызның язмышы шушы минуттан синең кулда.

Икенче көнне иртә таңнан ук Шаммасов, зарыгып-зарыгып, Хөнҗәмәнең шалтыратуын көтә башлады. Көн урталарына таба ул борчыла ук башлады, кичкырын исә тәмам чыгырыннан чыкты, кабинет буйлап арлы-бирле йөренде:

— Менә сиңа, ә! Кара син бу шайтан алгырын! Ник бер дә тавыштыны юк соң әле бу хатынның?!

Тәрәзә каршындагы шәрә юкәләрнең яфраклары коелганын күреп, Шаммасов бөтенләй коелып төште.

— Очырырлар, билләһи, очырырлар!— дип кысты ул куллары белән газиз башкаен.— Шушы яфрак кебек очып йөрерсең аннары кунар урын табалмыйча!..

Шулвакыт кабинетка, май кояшыдай балкып, секретарь кыз атылып керде:

— Гарәфи Хәйдәреч, алыгыз тизрәк трубканы. Сезне...

— Мин әле бу, ип... ип... Шаммасов,— дип мышкылдады телефон трубкасында таныш тавыш.— Булмады бит, Гарәфи Хәйдәреч, барып чыкмады... Э-һе... э-һе-м. Әйбәт кенә башланган иде. Директорның үзенә кердем, бер-ике тапкыр яулык чылатып алгач, имзасын да куйдырдым. Аннарысы... аннары бөтен эш харап булды...

— Я, я, рәтләп сөйлә, рәтләп!— дип кычкырды Шаммасов трубкага.

— Аннары склад мөдиренә киттем,— дип дәвам итте Хөнҗәмә үкси-үкси.— Алай-болай кире бормагае дип, анда да каты гына еладым. Әнә шунысы харап итте... Абайламыйрак калдым. Күз яшьләрем директор имзасы өстенә тамды. Э-һе-һем... Имза урынында пычрак тап кына җәелеп калды.

— Соң, яңадан кер үзенә, яңадан кер!— дип кычкырды Гарәфи Хәйдәрович.

— Юк шул инде, булмый...— дип кычкырып еларга кереште Хөнҗәмә.— Ул кичә кичтән үк диңгез буена ялга китеп барган. Э-һе-һем...

Тәмам өнсез калган Шаммасов калтыранган куллары белән трубканы куйды. Шулвакыт аның күзеннән эре-эре ике бөртек яшь сыгылып чыкты һәм юп-юка калган өстәл календаре битенә тамды...

## Атай малы

— Син ахмак белән яшәп, яшь гомеремне заяга уздырдым. Ашаткан ашым харам булсын!— дип җикеренде хатын һәм кул астына эләккән беренче тәлинкәне идәнгә томырды.

— Дөньяда иң зур хатам син кара еланга өйләнүем булды. Күзем күрмәсен!— дип ярсыды ире һәм бер-бер артлы ике стаканны стенага бәрде.

— Беткән баш, ничек телең бара?! Мин булмасам, син мәхлук инде күптән...

Аның соңгы сүзләрен кухня идәнендә чәлпәрәмә килеп ватылган тәлинкәләр авазы күмеп китте.

— Китте! Бетте!— дип кычкырды ире буфеттагы графинны баш өстендә болгап.— Бүгенгесе көннән мин сиңа ир түгел, син миңа хатын түгел!..

Як-якка сибелгән пыяла кыйпылчыклары ирнең балтырын тырнап уздылар.

— Ә-ә, шулаймы? Би-ик шәп, би-ик яхшы! — дип чәрелдәде хатыны. — Бар, дөмек, муеның аякка килсен!..

Янәдән бер өем савыт-саба, чәлпәрәмә килеп, идәнгә сибелде.

Шуннан соң хатын, тузгыган чәчләрен аннан-моннан сыйпаштырып, касса янына ашыкты.

Ире исә тәмам ярсыган күңелен басу өчен тагын бер-ике касәны идәнгә бәрде дә башына ак калфагын, өстенә халатын киеп алды һәм пар бөркеп кайнаган казанны ачып, инде куера башлаган сөтле токмачны болгатырга кереште.

Ашханәне ачар вакыт житеп килә иде...

## Көн кояшлы идеме?

Зур кабинетта бер генә буш урын да юк. Шулай да тып-тын.

— Безнең трест турында газетада фельетон бастырып чыгарганнар, — дип шушы тынлыкны бозды управляющий төшенке тавыш белән. Аннары тәмәкесен ашыкмыйча гына көл савытына басып сүндерде. — Нинди фикерләр булыр?

— Кычкырып укырга кирәк, — дигән тәкъдим ишетелде почмактан. — Ул газетаны укымаучылар да бар бит.

— Дөрес тәкъдим, — дип дәррәү якладылар бу фикерне.

— Башта укырга кирәк.

— Ярар, — дип килеште управляющий һәм газетаны алдыннан этәреп куйды. — Ә кем укый?

Гөр килеп бәхәсләштеләр дә кадрлар бүлеге начальнигыннан укытырга булдылар. Җыелыш саен чыгып сөйли-сөйли, тавышы тәмам шомарып беткән аның. Ул кыстатып тормады, газетаны алып, фельетонны **чатнатып** укырга да тотынды: «Кояшлы бер көндә «Җилбытремповорот» трестының капкасы шыгырдап ачылды да, аннан көчәнә-үкерә авыр йөк төягән автомашина килеп чыкты...»

— Тукта! — дип кычкырып җибәрде управляющий шушы төшкә җиткәч, хәтере калганы тавышыннан ук сизелде. — Ялган! Каян килгән ди ул «кояшлы көн»? Минем хәтерләвемчә, бу хәл үнөче көнне булган иде. Ә ул көнне кояшның кайда икәнлеген телескоп аша да абайлап булмагандыр. Көнозын карлы яңгыр койды. Кирәк икән, без гидрометобсерваториядән белешмә дә алырбыз!..

— Хак сүз! — дип куәтләде управляющийның гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары. — Күкнең төбе тишелгән иде үнөчендә. Моңардан тыш, иптәшләр, фельетонда трестның мин җавап бирә торган тармагына наҳак бәла такканнар. «Капкасы шыгырдап ачылды» диелгәнме? Бу бит сафсата, җәмәгать! Моңа каршы шуны әйтергә тиешмен: шыгырдамый безнең капка! Мөмкин хәл түгел бу! Чөнки без капка күгәннәрен әледән-әле майлап торабыз. Бәлки, корреспондентның үз башында берәр шөребе шыгырдыйдыр!..

— Дөрес әйтә урынбасарыбыз! — дип, завхоз үзенең начальнигын яклады.

— Сез минем сүзләремнең хаклыгын үзегез барып тикшерә аласыз, — дип, тагын да инаныбрак дәвам итте урынбасар. — Һәм капканы барып карау өчен комиссия төзергә тәкъдим кертәм. Хет магнитофонга яздырсыннар, капка ачылганда черт иткән тавыш та ишетелмәс...

Бүлмәдәгеләр дәррәү кубып кул чаптылар.

— Миңа да сүз әйтергә рөхсәт итегез әле, — дип баш механик урыннан кузгалды. — Фельетон авторы безнең автохуҗалык бакчасына да таш аткан бит, җәмәгать. Аның язганына ышансаң, безнең автопаркта

тигез җирдә дә йөкне көчәнеп-үкереп тартучы драндулетлар бар булып чыга. Ничек инде газетада шундый ялган язарга мөмкин?! Барыгызга да билгеле ләбаса: безнең барлык машиналарыбыз да техник карау үзды һәм алар сәгать кебек гөрләп эшлиләр.

— Дөрес әйтә баш механик! Раслый алам! — дип сүз кыстырды гараж мөдире.

— Ә газетада телгә алынган машинаны без,— дип сүзен дәвам итте баш механик,— заводтан бер ай элек кенә алган идек. Шоферы да — тәҗрибәле иптәш. Кыскасы, әлеге машинага шундый ук йөк төяп, теләсә нинди комиссия карап торганда да капкадан выжлатып чыга алабыз...

Бүлмәдә тагын шаулашып алдылар. Ишек төбендәге почмаклардан: «Афәрин! Афәрин!» — дип кычкырдылар.

Управляющий, ниһаять, тавышларны басар өчен ишарә ясарга мәҗбүр булды һәм бүлмәдә тагын тынлык урнашты.

— Инде, иптәшләр, фельетонны кычкырып укуны һәм фикер алышуны туктатырга, дигән фикер бар,— дип, ярып салды управляющий.— Барысы да аңлашылды. Юкка вакыт әрәм итәргә ярамый. Редакциягә җавап язганда: фельетон коллектив җыелышында җентекләп тикшерелде, анда телгә алынган фактлар расланмады, диегез...

## Гармун каешы

Улы Сәлим җыр буенча «икеле» алып кайткач, Сафа Кәбирович үзе дә сизмәстән чалбар каешына үрелде. Әмма кулы подтяжкага килеп төртелгәч, көрсенеп куйды. «Карале,— дип фикер йөртте әти кеше,— малай үсә... Бишенче класста... Ә өйдә ике таңкәлек каеш та юк. Безобразие!..»

Галантерея кибетендә кул сәгате каешыннан гайре берниндн каеш та табылмады. Башка кибетләрдә дә андый товарның инде күптән дефицитка әверелүен әйттеләр.

— Карале, сеңелем,— диде Сафа Кәбирович, соңгы бер кибеттә сатучыны читкә чакырып алып.— Ул каешлар кая китеп беттеләр соң?

— Гаҗәп...— дип елмайды сатучы кыз.— Әти кеше буларак белмисезмени? Чирек ахыры бит, иптәш. Бу вакытта каеш эзләү — җәен кар эзләү белән бер...

Өйгә буш кул белән кайтып кергәч, Сафа Кәбирович уйга чумды. Шундый нәрсә сорап күршегә кереп булмый бит инде! Ә каеш кирәк. Тәрбия әсбабы, акыл-сабакка өйрәтә торган изге нәрсә бит. Тукта әле, бәҗәйның офицер каешы бар иде кебек.

— Юк шул, бәҗәй, теге атнада кайниш алып киткән иде. Малае рәсем буенча рәттән өч «икеле» алып кайткан бугай,— дип аңлатты телефоннан бәҗәсы.

Уйлый-эзләнә торгач, гаилә башлыгы тәки каешка килеп юлыкты бит. Йокы бүлмәсенең карават астында күптән ачылмый яткан баян футлярыннан табылды ул. Чалбар каешыннан бер дә ким түгел. Шул ук кичне әтисе каешны Сәлимнең дәрес әзерли торган өстәле каршына кадакка элеп тә куйды. Янәсе, кара аны, малай актыгы, атаң каешын оныта күрмә!

Шул вакыйгадан соң күп тә үтмәде, Сафа Кәбировичны мәктәпкә чакырдылар.

— Без, ата-аналар, укучылар өчен концерт куярга җыенабыз,— дип игълан итте ата-аналар комитеты председателе Сәмига Сабировна.— Сезнең бик яхшы баянчы икәнегезне беләбез. Бер-ике матур көй уйнап күрсәтерсез инде...

Билгеләнгән сәгатьтә әти кеше баянын күтәреп мәктәпкә килеп керде.

— Һай, рәхмәт килүегез өчен! — дип каршы алды аны Сәмига Сабировна, хур кызыдай елмаеп.— Сезгә концертны алып барырга туры килер. Баянчыбыз кинәт авырып киткән бит. Ничек тә коткарырсыз инде...

Сафа Кәбирович җәһәт кенә сәхнә артына узды. Һәм күз ачып йомганчы футлярдан баянын алды.

— Бәй! — диде гармунчы һәм, баянының каешсыз икәнен күреп, лып итеп урындыкка утырды.

— Нәрсә? Таблетка бирикме?!

— Таблетка түгел, каеш кирәк, каеш.

— Кемгә каеш кирәк?

— Кемгә булсын, миңа!

— Каешыгыз юкмыни?

— Баян каешсыз! Неужели мәктәбегездә бер ир заты да юк?

— Юк шул! — диде Сәмига Сабировна моңсу гына...

«Менә сиңа каеш! Минем үземне каешларга кирәк икән!» — дип Сафа Кәбирович юл буе үз-үзен әрләп кайтты.

## Рөстәм Фәйзуллин

### Мәңгелек ут яна мәйданнарда...

**Мәңгелек ут — ялкыннардан һәйкәл —**
**һәлак булганнарга сугышта.**
**Мәңгелек ут — алар сулышы ул,—**
**тоташ бәлки безнең сулышка.**

**Алар исән безнең күңелләрдә,**
**дәвамнары — безнең яшәүләр.**
**Алар миндә яши!**
**Алар синдә яши!**
**Алар бездә мәңге яшәрләр! —**
**Алар буынына**
**лаек булсак икән**
**алмаш булып килгән**
**без — яшьләр!..**

**Мәңгелек ут яна мәйданнарда —**
**күк йөзенә төшә шәүләсе.**
**Алда тормыш — бөтен барлыгында...**
**Яшәсе дә безгә, яшәсе!..**

### Хикмәтләр

**Эз генә иде,**
**сукмак булды,**
**сукмак иде,**
**керде юл рәвешенә.**

**Диңгез иде,**
**калды күлгә,**
**күл иде,**
**хәзер күз яше генә...**

## Күңелләрдә кырык бишнең мае...

ЖЫР

Кояш сүнде синең күзләреңдә,
иренеңдә сүнде елмаю.
Тишеп үтте күкрәгеңне ярчык —
кырык бишнең иде май ае.

Әткәй, әткәй, кулмадың мине,
күралмадың инде улыңны.
Улың үзе күптән әти булды
кабатланды... кабатланды миндә
буй-сының...

Сугыш алып килгән әрнүләрне
баса алмый вакыт агышы.
Кырык биштә җиргә килгәннәрнең
бәхетләре моңлы-сагышлы...

Менә тагын ямьле язлар килде.
Нинди иркен, матур дөньялар.
Кояш белән тулган күз яшендә
син яулаган Җиңү нуры бар.

## Белми әле

Берәү әнә йолдызына очты,
берәү аңа болгап калды кул...
Нурлар гына килә,
йолдыз күптән сүнгән...
Аны ләкин белми әле ул...

## Яшәү ныклыгы

Ботаклар
өскә чакыра,
тамырлар
аска тарта.
Шушы көчләр тартышканда
яшәү ныклыгы арта.

## Ага болыт

Ага болыт, ага болыт,
сагышны ташый гына...
Мәхәббәте төшкән микән
ялгызлык гашыйгына!

Болыт артында кояш бар —
моны егет уйламый.
Кулларында моңлы гармун —
гармунын да уйнамый.

Уйнар иде, моң чәчелер —
аны ничек җыясың!
Болай да моңлы бала ул,
әнә яңгыр еласын...

Хәл алды ялгыз кыр казы
егетнең күңелендә.
Бер каурыен ташлап китте
офыкка күмелгәндә...

## Сүнгән учак өсләреннән...

Сүнгән учак өсләреннән
җил исә дә җил исә.
Кабынып сыман учаклар,
әгәр бер очкын тисә.

Яктыртырга иде Җирне
бернигә карамыйча...

Янәшә ята утыңнар
ут җанын табалмыйча...

Ут ялкыны — әсирлектә...
Ут-үлән уйный, биеп...
Җилләр йөри очкын көтеп
сабырын җуйган җан кебек...

## Таулар-атаулар

Хәтер булып гүя һәрбер елның
язын су астыннан калка атаулар...

Ә ул авыл инде су астында,
колач җәеп йөзәм өстеннән.
Баш очымда әнә болыт тора
моржалардан чыккан төтендәй.

Хәтфә болын аша менә идем —
биек иде ул чак бу таулар.
Таулыкларын инде югалтканнар,
исемнәре хәзер — атаулар...

## Ай яктысы

Ах, бу яктылык!

Гомере бер көнлек
төнге күбәләк
айга оча,
бернигә карамыйча...

## Күчеп киткәндә

...Сау бул, Казан!
Саубуллашам... күңелем белән:
ул бит синдә кала...

## Озата бар...

Гөрләвекләргә сүтелде
икәү калдырган эзләр,
сулар булып акты инде
карга язылган сүзләр.

Акты сулар, акты сулар
кар-бозларны эретеп,

акты сулар, ташты сулар
ике ярны бер итеп.

Ак болытлар җирдән өскә
чакырса безне әгәр,
озата бар мине хәзер...—
салават күперенә кадәр!

## Әле дә тора кебек...

Әйтергә дип
сүзләр эзләдем мин.
Әйтә алмадым...
Ә аннары
кирәк тапмадым...

Еллар үтте.
буш перронда
бер кыз
әле дә тора кебек
шул урында һаман таптанып...

## Урамнарда буран дулый иде...

Урамнарда буран дулый иде
чәчләреңне чакырып җиленә.
Ә мин сине җибәрмәдем барыбер,
баралмадың барыр җиреңә...
Син утырдың шәмгә кулың сузып
(бүгенгедәй истә ул чаклар),
якыная барды әкрен генә
күзеңдәге ерак учаклар.
Иркенәеп бүлмә, офык тулды,
шәфәкъ төсе кунды алмага,
тәрәзәнең зәңгәр төшендәме
ап-ак чәчәк атты абага.
Ай калыкты күңел күкләрендә,
син кояштай балкып утырдың.
Ә урамда һаман буран иде,
юлларны кар белән тутырды...
Хәтеремдә матур, якты булып
һәр мизгеле калды бу кичнең.
Ул чак мин яшь идем,
белми идем ничек аталганын
йөрәк тулы
сөер бу хиснең...

## Сәлам әйт, җил...

Тугайларга сәлам әйт, җил,
урманнарга сәлам әйт,
тау башыннан Ай калыкса,
син аңа да сәлам әйт.

Әйт син сәлам җәйләр буе
кош сайраган талларга,
Канатың белән кагыл син
керәшәле ярларга.

Сәлам әйт, җил, болындагы
сабантуй колгасына,
бәлки ярымның яулыгы
җилферди һаман шунда...

## Карап торам...

Учак яна,
ялкын теленә
әйләнә бара барсы:
имәне дә, усагы да,
каены, карамасы...
Карап торам,
сихерләп тарта күңелне
көл булу тантанасы...

## Тагын соңга калып...

*Зиратка керел*
*югала бара,*
*югала бара юллар...*

Соң керде акыл —
гамьсез итте
дөнья рәхәте.
Беренче укытучым,
бүген килдем

Сезнең янга...
инде соңга калып...
Иреннәрдә
әллә ничә еллар элек
әйтә алмыйча калган рәхмәтем...

...Югалтуның бар үз табышы...

Сәгать җуйдым —
аптырамадым.
Мин бит вакыт югалтмадым...

Кояш батты,
моңа да шат —
ай чыгарга үзе бер шарт!

# Рафаил Газизов

## Безнең яшьлек

Чакырылмаган кунак булып килә,
Төшкә кереп борчый ул еллар:
Безнең яшьлек аша авыр мышнап
Җир тырмалап узды сыерлар.
Җир сөргәндә үгез киреләнгәч,
Асларында учак яндырдык,
Кайгыларны әниләрдән яшереп
Буразнага күмеп калдырдык.
Оныттылар атлар кешнәүләрне,
Күтәрәмгә калды малкайлар,
Алар һаман аяклана алмый
Хәтер чоңгылында яталар.
Күзләрендә мөлдерәмә яшьләр,
Агып китсә — җанны уярлык,
Атлар бераз җылынсыннар өчен
Йөрәгеңә ябып куярлык.
Егылып үлде алар, сынды тимер,
Алмагачлар китте бакчадан,
Сынмады тик өмет, аяк өшеп
Чабатага ябышып катса да.
Сынмады тик өмет, яшьлек, сине
Чабаталар итеп үрдек без,
Тубаллардан орлык итеп чәчтек,
Илгә икмәк итеп бирдек без.

## Чирәм ерта көчле тракторлар

Сука гасырлары — ерак тарих...
Чирәм ерта көчле тракторлар,
Буразналар — кино тасмалары,
Буразнада уятылган чорлар.
Кәсләр ята — ерак гасырларның
Чәрдәкләнгән кабыргасы сыман,
Бу туфракны тоякларда чайкап
Ничә буын атта җырлап узган.
Аяз күкне, язны бүләк итеп
Болгар атлылары моннан очкан,
Кол Галинең угы төшкән җирдә
Шигырь чишмәләре бәреп чыккан.
Буразнада нидер ялтырады.
Бәхтиярнең көмеш эзе мәллә,
Ул бит монда туган, монда үскән,
Шәһит булган — бәхет эзләгәндә...
Тарих ята буразналар булып,
Халкыбызның данлы юлы ята.
Сабан тәрәннәре күзгесендә
Гасырларны җиңгән таңнар калка.

## Көзге моңнар

Печән чаптык монда... Җәйнең соңгы
Елмаюы булып курпы чыккан.
Сабый үлән сыена яфракларга —
Яфрак үзе туңа җылы юктан.
Яфрак өермәсе — көзге учак —
Очкыннары болытларга менә,
Бакчадагы шәрә алмагачның
Туй күлмәге керә төшләренә.
Ә хәзергә — җылы җитми җанга
Учагында шатлык әретергә.
Шул юаныч бирә: чәчәкле җәй
Кызыл алма булып төшкә керә...

## Мин сәламнәр илтәм...

Су буена төштем: җырлар җыям
Инешләрдән, җилдән, таллардан.
Чишмәләргә дәшәм: — Исәнмесез!
Сихри моңнар Сездә кайлардан?
Һәм чишмәләр җавап бирә миңа:
— Асыл егет, син бит бу җирдә
Аз яшисең әле, тик шулай да
Җырлар шыта синең күңелдә.
Без кешеләр идек, сихерләде
Матурлыгы белән җиребез,
Чишмә булдык шуннан, без синең дә
Чишмә булуыңны телибез!

...Җырламыйча кара, теләкләрен
Чишмәләрем җырдан үргәндә,
Туган җирем җыр яктысы итеп
Каеннарын юлга тезгәндә!
Мин сәламнәр илтәм чишмәләргә,
Саф төннәрдән, көннәр, таңнардан...
Су буена төшәм... Җырлар килә
Инешләрдән, җилләр, таллардан.

## Сөйләшәсе килә...

Яшел хәтфә белән каймаланган
Сукмаклардан үтә юлларым,
И түгә соң урман куенына
Якты кояш шәфкать нурларын.

Яфраклардан таң шәрабе тама,
Вакыт саный тамчы тып та тып...
Сөйләшәсе килә заман белән —
Барлык сәгатьләрне туктатып.

## Газинур Моратов

## МИН ДӨНЬЯНЫ ТЫҢЛЫЙМ

●

Түм-түгәрәк планетамның
Кыйбла миңа һәр ягы...
Ультракыска дулкыннарда
Тыңлап ятам дөньяны.

Тыңлап ятам: кай халыклар
Бәйсезлеген җуйганнар?!—
Революция портына
Тагын мина куйганнар...

Кай дәүләттә, хаким булып,
Тәхеткә менгән ялган?..
Ак йортның кара дивары
Тагын канга буялган.

Кара күзлек кигән хунта
Пьедесталгамы менгән?!—
Тагын җинаять кылынган
Халык исеме белән.

Нәни Гаврош күк малайны
(О тиран, шулмы үчең?)
Терелэй күмгәннәр — фәкать
Иманы булган өчен.

Ультракыска дулкыннарда
Тыңлыйм бүген дөньяны —
Бу хәвефле планетамның
Газиз миңа һәр ягы.

## Ирек уты

*Ирекле, ирекле һәм, ниһаять, ирекле.*

М. Л. Кингның кабер ташындагы язу

Чынлык булган җирдә ялган да бар,
Хөрлек булган җирдә — богаулар.
Шул богауны йолкып өзәр өчен
Яралгандыр көрәш, дау-яулар.
Көннәр белән мени, көрәш белән
Үлчи Вакыт Кеше гомерен...
Петропавел сөйләр —
Кибальчичның
Әйтелмичә калган гозерен.

Тарих әманәтен, Ирек утын
Яшермәсен палач хет кая —
Я Лоркалар булып кабына ул,
Я Җәлилләр булып елмая.

Килеп керә хөкем залларына,
Антлар эчми генә сүз ала.
Ә үзенең күкрәгеннән саркып
Трибунага кайнар кан тама...

Рөхсәтсез ул, шакымыйча гына,
Килеп керә парламентларга...
Һәм көрәшкә ташлана ул бүген,
Кызыл байрак булып — иң алда!

## Васыять

*Соңгы җырым палач балтасына*
*Башны тоткан килеш языла.*

Муса Җәлил

Баш очымда Кояш түгел,—
гильотина!

Җырларым бит әле —
читлектәге лачын!

...Соңгы сүзем, әманәтем —
сиңа, халкым!
Беркайчан да сатмадык без
яманатың.

Ирекле бул мәңге!—
Васыятем сиңа!
...Баш очыңда Кояш булсын мәңге!..
Җирдә —
юкка чыксын
гильотина!

## Teләктәшлек турында җыр

*Россиягә ярдәм итегез!*

Бернард Шоу

Европаның җейле йөзен
кабат
Таптаганда тиран итеге,
Ил агасы дәште эфир аша:
— Россиягә ярдәм итегез!

Хәвеф иңде Ирек Ватанына,
Көн күзен көл, сөрем каплады.
Халык күңеледәй каеннарның
Күкрәгендә үлем таплары.

Кызыл мәйдан, сабыр аналар күк,
Озатканда сыкрап улларын,
Ил агасы дәште кыйтгаларга,
Җан ачысы булып толларның.

Мәскәүдә кыш. Зоя — яланаяк.
Эшафотның канлы күзләре
Капшый тәнен, күкрәкләрен аның...
Карда кайнар нәфрәт эзләре.

...Парламентлар!
Дар элмәге өчен
Без һәммәбез — муен. Бертигез!
Россиягә ярдәм итегез сез,
Азатлыкка ярдәм итегез!

...Ә Азатлык һаман камалышта,—
Я крепость ул, я тоткын әле...
Сыкрап-сыкрап чорлар кабатлана:
Ольстерда — «Канлы якшәмбе».

## Мигель Эрнандеска — көтүчегә һәм шагыйрьгә

Болыныңнан кем аерды [1],
Кем каерды канатың?..
Тиран мушкасында бүген —
Хөрлекнең тулпар аты.

«Кәҗә көтүчесенә дә
Кирәк булган, имеш, дан»...—
Яраладыр шагыйрь җаны
Туган җир туфрагыннан.

Ватаның зинданда ауный,
Чиркәүләр яза деннән:
Яраладыр шагыйрь җаны
Халыкның нәфрәтеннән.

Илдә — яңа инквизиция...
Вакыт — матадор сыман:
Яраладыр шагыйрь җаны
Халыкның кайгысыннан.

...Көтүеңнән кем аерды,
Кем каерды канатың?
Тиран мушкасында — шагыйрь,—
Хөрлекнең тулпар аты.

## Нәфрәт турында җыр

*Җир әйләнә барыбер, инквизитор.*
*Коммунизм ягына әйләнә.*

Хәсән Туфан

Мәйданнарда дарга асылды ул,
Диварларга терәп атылды...
Канлы кулын юган чакта, палач
Уйлагандыр, чыкмас, дип, тыны.

Тик ялгышты:
Күрми калды палач
Йодрыкларын аның — төйнәлгән!
Хәер, нигә фәлсәфәләр аңа,
Эш бит бара, эш бит көйләнгән.

[1] Атаклы испан шагыйре М. Эрнандес башта көтүче, аннан гражданнар сугышы чорында республика тарафдары — комиссар була. Франко төрмәсендә үлә.

Йомылды куз. Ә йодрык калды,
Ә йодрык калды... сугарга.
Планетага якты җитми иде,
Һава җитми иде суларга.

Ә йодрык кабат күтәрелде,
Һәм кизәнде Пугачев булып.
Богау чыңы яңгырады күктә.
...Таралмады болыт.

Ә йодрык тагын күтәрелде,
Утлы йөрәгедәй титанның —
Байрон булып сукты яңагына
Леди-политиканның...

Чабаталы Рәсәй булып сукты,
Тантанасы булып халыкның.
Күмәк җыры яңгырый кебек күктә
Муромецның, Манас, Алыпның.
...Танк эчләрендә янды Нәфрәт,
Һаман исән чыкты ул уттан...

Көрәш бара җирдә —
Явызлыкка
Континентлар булып сугар йодрык —
Биш бармагы аның —
Биш кыйтга!

# Лэбиб Леронов

## Бүгенгедән — килер көнгә

Беркем белми аның төгәл яшен
(Яшендәй тиз уза ел-гасыр!).
Борынгыдан бүгенгегә ага
Яшел елга — Урман елгасы!..

Ага... ага... Тып-тын гына ага...
Дулап ала кайчак дулкыннар,—
Шул чагында агачларның шәрә
Тамырлары куя сулкылдап.

Ага... ага... Язгы бозлар сыман,
Кайнап-кайнап, ярга моң таша!

А, сукмаклар — урман урамнары,—
Шул моңнарга барып тоташа.

Җилләр киереп ача изүләрне —
Чәчрәп оча ярык төймәләр...
Су өстендә көз шәүләсе йөзә
Һәм уйнаклый яфрак-көймәләр.

Ага... ага... табигатьнең шашып
Бер көләсе килә, еласы...
Бүгенгедән килер көнгә ага
Яшел елга — Урман елгасы!..

## Малайчактан хат

Хат алдым малайчагымнан,
Көтмәгәндә, бүген мин:
«Ни үзең юк, ни хәбәрең, —
Сиңа оят түгелме?..
Әгәр сагынсаң, эшеңнән
Сорап кайт бер өч көнгә.
...Болытлар тукталыш ясый
Безнең авыл өстендә...»

Хатка тәгәрәгән яшем
Пышылдады: «Сагына-ам!» —
Ничек аңлатырга икән
Шуны малайчагыма?

Торган саен сагынуым
Арта гына отыры...

Бер кайтып килермен, ахры,
Болытларга утырып.

## Шәһәрдә йокысыз төн

Йокы алмый,
йокы алмый,
йоклый алмыйм һич менә:
казлар каңгылдашкан тавыш
килә мендәр эченнән!

## Таң алдыннан

Җитми мәллә яктылык? —
Кемдер җиргә абынды.
Шырпы сыздым офыкка —
Кояш кабынды.

## Кышка кералмый торам...

Кыш ишеге шып-шыр ачык —
Атлый түргә пар туннар.
Туңган көлү авазлары
Ияра алар артыннан.

Шып-шыр ачык кыш ишеге! —
Түргә уза ак буран...
Мин торам ишек катында
Җилне муенга урап.

Карашыма көн сарыла, —
Төсләр туңган, оешкан...
Күздә син калганга әллә
Кералмый торам кышка?!

●

Җир — шыгырдап торган идән,
Галәм — зәңгәр түбәдер.
Төнге тиле карлар шашып
Учларымны үбәдер...

Кичәге ай, танышым, дип,
Карыйдыр, шәт, текәлеп.
...Ботинкамның моңсу җырын
Тыңлап ята декабрь.

## Нурислам Хәсәнов

# ИНЕШЕМДӘ — ГОМЕР АГЫШЫ

**хикәя**

Бүген без шактый кырыс солдат юлын кичтек — походта булдык. Илнең ком-далалары, чүлләре буйлап уздык. Ләкин кайда гына булмыйм, син истән чыкмыйсың, әни... Сагынудан бөтен дала иркенә бик кычкырасым килде... Шадраланган алтын чүл өстеннән атлыйбыз. Баш очында янган кояш мәңге сүрелмәстер кебек. Тирә-як киңлекләрендә рәшә дулкыннары тирбәлеп йөзә. Кызган комнан бөркелгән һава йөзләрне юа. Гимнастерка җилкәләренә бәреп чыккан аксыл тир эзләре — әйтерсең, чүл уйсулыклары төшерелгән карта. Иреннәр кипши. Маңгайлардан тамган тир бөртекләре комга сеңеп өлгерә алмый, парга әйләнә. Комга иңеп кергән аякларга гөч өстәргә теләгәндәй, авыз эчемнән генә адымнарны саныйм: «Бер, ике, өч...»

Күктә кояш. Аңа карап бара-бара сүзгә киләм:

— Кояш! Зинһар әниемдәй мәрхәмәтле бул! Сусатма артык. Беләм, синдә — тиңсез яну көче! Яну көче йөрәгемә гүя синнән күчкән, алсу нурларыңның төсе каныма сеңгән. Сиңа туры карап барырга тырышсам да, керфекләремне йомдырасың, серләреңне яшерәсең кебек. Ә үзең һаман көләч, һаман елмаясың. «Яшәү ул — яну, янып яшә, энем!»— диясең шикелле.

Походта без, ялга тукталгач, учак яктык. Учак әйләнәсендәге солдатларның кояшта янган йөзләрендә алтынланып ялкын шәүләләре уйный. Бер мәлгә бар да сүзсез калганнар. Һәркемнең күңелендә үз уе. Ялкынланып янган учак миңа әткәйләр истәлегенә кабынган мәңгелек ут сыман тоелды. Ялкын шәүләләрендә аларның да йөзләре алтынлана, ал байраклар җилферди кебек. Гүя мин аларның җир күкрәгеннән безгә дәшкән тавышларын ишетәм: «Җир шары әле һаман да тынгысыз. Уяу булыгыз! Җир астыннан мәңгелек ут булып чыккан безнең йөрәкләр ялкыны сезгә шул турыда искәртеп торсын!»

Учак янынан купкач, без янә походыбызны дәвам иттердек. Хәерле юл теләгәндәй, хушлашып, дала уртасында ялгыз учак янып калды. Аңар карый-карый, ераклаша-ераклаша мин, әнкәй, сине уйладым. Йөрәгемдә яңарган сагыну хисләрем, еракта — Татарстанда, кечкенә генә инеш буена урнашкан Шәтке төбәгендә...

Солдат улың инде кайтырга чыкты, әни. Хезмәтен үтәп, бөтенләйгә! Сагынуларым тулып ташый. Уйларым тук та тук тыкылдап барган поезд тәгәрмәчләреннән дә алда йөгерә. Корыч «аргамак», дала киңлеклә-

рен урталай ярып, пошкыра-пошкыра чаба. Артыннан иярген вагоннар тезмәсе борылышларда яшел еландай шуышып уза. Дулкынлануымны тыярга тырышып, тәрәзәдән дала киңлекләрен, юл буйларын күзәтеп барам. Юл читендә үскән агачлар, безнең тизлеккә көнләшкәндәй, егыла-егыла артка чаба. Мин әле бер, әле икенче хатирәләр дулкынында тирбәләм... Кайтып килүемне алдан хәбәр итмәсәм дә, көтүеңне беләм, әни. Аналар йөрәге сизгер була, тик мин моны соңрак аңладым. Тормышыңда сагынып-өзгәләнеп көтүләрең күп булды синең. Яшьтән үк сеңелең белән ятимә калгансың. Язмыш сезне чит җирләрдә бер-берегездән аерган. Житмәсә, әтинең сугышта һәлак булуы... Үлгән хәбәрен алгач та ни гомер көттең син аны! Барсына да түзә белгәнсең, әни...

Кышкы кичләрдә безгә еш кына, бәйләвен алып, күрше Зәлия апа кереп утыра иде. Ул чагында миңа тугыз яшьләр чамасы булгандыр. Берсендә шулай, мин дәрес хәзерлим, Зәлия апа шәл бәйли, син урындыктагы каба өстенә утырып йон эрлисең. Сары сагыз кебек сузылып килгән йон нәзек, сөякчел бармак араларында нечкәреп бөтерелә-бөтерелә дә алъяпкыч итәгендә зырылдап әйләнгән орчыгыңа чорнала бара. Зәлия апа сүзчән түгел. Күбрәк син сөйләгәнне тыңлап, җөпләп утырырга ярата. Шулай да бервакыт сорап куйды:

— Сәүдә апа! Әйдәле, бер үз тормышыңны сөйләп җибәр булмаса? Безнең авылга килен булып кайлардан килгәнсең бит син...

Башта, сүзне нәрсәдән башлыйм икән дигәндәй, уңайсызланып куйдың, урыныңа җайлабрак утырдың һәм:

— Сөйләмә дә инде, Зәлия,— дидең.— Кыз баланың язмышы очар кошныкына тиң, дип белми әйтмәгәннәрдер.

Орчыгың алъяпкыч итәгендә янә бөтерелеп уйнап алды. Йөзең ниндидер сагыш кичергәндәй уйчанланып китте. Тавышың, әйтерсең, йөрәк түреннән саркып чыкты:

— И-и Зәлия, ул елларны искә төшерсәм, күңелләр әллә нишләп китә, йөрәк жылый. Егерме беренче елгы ачлык безнең бәхетсезлеккә каршы булгандыр инде ул...— Авыр гына сулап куйдың. Үткәннәреңне хәтерләү иңеңә авыр йөк булып ятты булса кирәк.

— Безнең якларны Тау ягы диләр бит. Без шунда тау итәкләренә җиләккә йөри торган идек. Бер дә бер көнне, шул читкә китәр алдыннан инде, сеңелем Мәсрүрә белән җиләккә киттек. Әти белән әни, иртән чыгып киткәндә, өйдә генә утырыгыз, дип кисәтеп куйганнар иде, югыйсә. Кая инде ул безгә, бала-чагага, өйдә генә утыру! Башта ишегалдына, аннары урамга чыгып уйнадык. Бераз юангач, тамаклар ачыга төште. Безнең күңел җиләккә барырга иләсләнеп куйды. Киттек җитәкләшеп тау итәгенә. Ялан тәпи килеш йөрибез җиләк эзләп. Әле тегендә, әле монда сугылабыз. Агач төбендәрәк күләгәдә үскән берничә каен җиләге табып ашадык. Көн кыздыра инде. Күктә ник бер болыт әсәре күренсен! Ичмасам, әзрәк җил дә исми. Сулышларга җиңел булыры бераз. Юк шул. Күп тә үтмәде, берзаман сеңелем Мәсрүрә: «Апай! Минем тамагым ачты»,— дип аваз салды. Мескенем, миңа күзләрен мөлдерәтеп караган. Учымдагы пар җиләкне аңа бирдем, өзгән чәчәкләрне кулына тоттырдым. Еламасын, янәсе.

Җиләккә алгысынып йөри торгач, Мәсрүрә авызын бөгеп елап ук җибәрде: «Апай! Әллә кайтабызмы? Җиләкләр дә күренмиләр»,— ди. Анның арыган, талчыккан кыяфәтеннән ачыкканлыгы сизелеп тора. Нишлисең? Ашарга юк. Мин, төш җиткәнлеген чамаларга тырышып, үкчәләремне аяк бармакларына тери-тери күләгәм озынлыгын саный башладым. Сеңелем күләгә очына чыгып җиткәнне дә көтмичә:

— Ничәү? Төш җитәме әле?— ди.

Чөнки әбәткә кайткан әнинең я әтинең ашарга ни дә булса алып кайтасын белеп тора. Мин шундук, күземне чагылдырып кояшка карап алган булдым да, этидән күреп калганча, белдекле кешедәй: «Житеп

килә... Алты ярым булган»,— дидем. Каз бәбкәседәй тезелеп кайтырга чыктык. Кулыннан чәчәген ычкындырмаган Мәсрүрәнең, арттан калышмаска тырышып, терт-терт атлый-йөгерә барганы һаман да күз алдымнан китми. «Әни бүген дә тәмле әп-пи алып кайтыр микән?»— дип сорый. «Кайтыр, кайтыр!»— дип юатам аны. Өйгә кергәч, чәчәкләрен сулы савытка утыртып тәрәз төбенә куйдым. Әни дә кайтып житте. Без инде аякларыбызны сәкегә салындырып кунаклаган идек. Әни тәрәз төбендәге чәчәкләрне күреп алды да орышырга тотынды. «Нәрсә дидем мин сезгә. Шушы эсседә өйдә генә утырмыйча тау итәгенә кадәр барып йөрмәсәгез ни булган?»— ди. Авызга су капкандай дәшми утырабыз. Сүзен зурга сузмады. Күзләребез аңарда. Сыерчык балалары оя тишегеннән башларын тыгып жим көткәндәй утырабыз. Менә аның куллары түшенә — алъяпкыч астыннан кабарып торган төенчеккә үрелде. Без, жанланып, селкенешеп куйдык. Ул тастымалга төргән паек икмәген, саклык белән генә кискәләп бүлде дә безгә өләшеп чыкты. «Валчыгын коеп ашамагыз!»— дип кисәтте. Мич ягына үткәндә, капканың шыгырдап ачылганын ишетеп, идән уртасында тукталып калды. «Атагыз кайтты бугай!»— диде дә аны каршыларга ишегалдына чыгып китте.

Әти белән әни өй түрендәге бүрәнәгә килеп утырдылар. Әти соңгы көннәрдә кайта-керә, күңелсез генә йөри. Сөйләшкәннәре тәрәзә аша ишетелеп тора. Әти, бераз тын гына утыргач, авыр көрсенеп куйды: «Бүген мин Сабиржан энемнәрдә булган идем,— дип сүз башлады.— Алар Барыйлар, Тимергалиләр белән Грузныйга, нефть промысласына китмәкчеләр. Әллә соң без дә тәвәккәлләп карыйбызмы?»— ди. Әни бик аптырап кына: «Үзең беләсеңдер инде»,— диде дә башын түбән иде.

Ике көннән соң без дә, Грузныйга китүчеләр белән жыенып, станцага килдек. Килүчеләрнең күплеген күрсәң — мәхшәр көне диярсең. Ыгы да зыгы. Бер-берләренә киңәш-фатиха бирешәләр. Нишләсен халык, ачлыкка түзәрлек булмаган шул, Зәлия...

Вагоннарга кереп утырдык. Поезд авыр ыңгырашып кына кузгалып китте. Кешеләрнең күбесе сәләмә киемле, ярты ялангач. Шунда ук хәер сорашулар. Кайсы, бер телем икмәк сорап, калтыранган хәлсез кулына соңгы киемен салып тоткан. Эчкә батып кергән күзләренә сагыш сеңгән. Гозерләп ялваруларыннан йөрәк сыкрый. «Зинһар өчен балам хакына бер телем икмәк бирсәгезче?»— диләр. Хәлсезләнгәннәр утырып та, ятып та торалар. И Зәлия, адәм баласына ачлык ниләр генә күрсәтми икән ул. Кемнәрнең генә башын түбән идерми? Аны ходай күрсәтмәсен, ярабби...

— Әйтмә инде.

— Сугыш чорын ал тагы. Бөтен авырлыкларын бергә кичердек. Урманнардан, чана тартып, утын кисеп ташуларны ал. Салкын кичләрдә, шыгырдап, ай нурында ялтырап калган ул чана эзләрен гомер онытa алмассың...

Зәлия апа, сүзеңнең дәвамын ишетергә теләп, сорап куйды.

— Сәүдә апа, шуннан Грузныйга ничек барып життегез инде?

— Барганда ук, безнең бәхетсезлеккә каршы, ач адәмнәр арасында төрле чир таралды. Алда ниләр көткәнен белми, бер-беребезгә сыенышып, вагон тәрәзәләреннән карап барабыз. Ул чагында поездлар әкрен йөри иде. Икенче тәүлектән соң әтиебез иртәнге йокыдан тормый да тормый. Әни: «Әтиегезнең йокысы туймаган әле», ди. Үзе борчыла. Безне шунда авылдашлар янына — икенче якка күчереп утыртты. «Монда әтиегезгә комачаулыйсыз»,— ди. Төш вакыты да житте. Әтиебез һаман кузгалмый. Аның янына Сабиржан абый да, авылдашлар да баргалап килә башлады. Безгә рөхсәт юк. «Әти нишләп озак йоклый ул?»— дип әнидән сорыйбыз. Ул иреннәрен тешли. Сулкылдап еларга житешкән. Бездән күзләрен яшерә. Йөзе пошаманлы. Сабырлыгын жыеп безне тынычландырырга тырыша, тагын тиз генә әти янына китеп югала.

Без, шулай, үз гамебезгә бирелеп, тәрәзәдән карап бара идек. Кинәт, әниебез йөгереп килеп, Сабирҗан абыйны чакырып алды. Без дә, куркышып, артларыннан иярдек. Барып карасак, сырхавы әтине тәмам чигенә җиткергән... Шунда ул күзләрен ачып безгә төбәлде. Куркыныч барын сизенгән җаныбыз соңгы сүзеннән сискәнеп китте: «Бәгырьләрем!.. Каласыз бит...»— диде дә күзләрен йомды. Әни: «Шакирҗаным!..»— дип сулкылдый-сулкылдый үрсәләнде. Без дә елашырга тотындык... Ул чагында поездда мәет тотарга рөхсәт итмиләр иде. Йогышлы чирдән үлүчеләр күп. Станцаларда каберне алдан казып торалар. Әтине, үзебезчә кумәр өчен, нинди дер зуррак станцага җиткәнче, өстен каплап алып бардык. Аннары шунда җирләп калдырдык...

Зәлия апа дәшми генә янә сөйләп китүеңне көтте.

— Кара кайгыда Грузныйга барып җиттек,— дип сүзеңне дәвам иттең.— Ары китеп, таулы-ташлы җирләргә, нефть промыслалары янына — агач баракларга барып урнаштык. Бер атна дигәндә әниебез авырып вафат булды. Икәүләп ятимә булып калдык. Инде нишләргә? Сабирҗан абыйлар белән киңәшеп, сеңелем Мәсрүрәне Грузныйдагы приютка бирергә булдык. Ул болганчык сулы Терек елгасы буена урнашкан балалар йортында елап калды...

Яшәгән җиребезне, промысла номеры белән, утыз тугызынчы квартал дип йөртәләр иде. Бараклардан ерак та түгел, сиртмәле кое кебек көянтәле нефть суырткычлар эшләп тора. Шул тикле җирләрдән монда кайтырмын дип уйламаган идем. Ашыйсы ризыкларым, күрәчәкләрем шушында булгандыр инде. И, гомерләр...

— Габдулла абый белән ничек таныштыгыз соң?

— Ул чакта Габдуллам Сабирҗан абый белән кәчәгәрдә бергә эшләгәннәр ие. Ул да туган җиреннән ачлык нужасына түзмәгәнгә чыгып киткән. Безнең баракка, Сабирҗан абыйларга килгәләп-киткәләп йөри иде. Мине дә шунда күргәләп калган булса кирәк. Абый аны төпле егет дип тапкандыр, күрәмсең. Олы кеше кемнең кемлеген тиз тоя бит ул. Араларында минем турыда сүз дә булгандыр дип беләм. Беркөнне без шул тирә кызлар белән аулак өйгә җыелдык. Моны егетләр дә сизенгән. Бу да килде. Киенгән, ясанган. Өстендә кәчтүн-чалбар. Минем һаман да бер шакмаклы күлмәк. Ул да тәнемә кечерәеп, тартылып калганые инде. Ярый әле ходай миннән матурлыкны кызганмаган. Яшь чакта анысы да кирәк бит. Егетләрне үзең беләсең, буйлы-сынлыны яраталар. Хәер, ошамаган булсам, ул мине шул тикле җирләрдән алып кайтмаган да булыр иде.

Зәлия апа көлемсерәп җанлана төште.

— Әйе, әйе. Шуннан?

— Шуннан шул. Йөзек салышлар уйнаганнан соң, кухня ягында аулакта калгач, кыяр-кыймас кына сүз башлады.

— Менәтерә...

— Мин күтәрелеп туры карарга да оялам инде. Ике битем ут кебек яна. Ул да, уңайсызланып, боргалана-сыргалана. Я аны, я моны сорап куйган була, тагын тынып кала. Мин дә — авызыма су капканмыни... Әллә ничек, читенсенәм. Башымны аска иеп тора идем, бу миңа болай дип әйтте дә салды: «Син миңа кияүгә чыгарга риза булырсыңмы?»— ди. Мин: «Каян белим»,— дим. Бөтен битем комач кебек. Һаман да сүзсез тору кыен, уңайсыз. «Я, әйт инде?»— ди. «Сабирҗан абый белән сөйләшми торып... мин бернәрсә дә белмим әле»,— дим. Шунда ул үз-үзенә көлемсерәп куйды, кыюланыбрак киткән күк тә булды һәм: «Сабирҗан абый каршы килмәс, ул мине белә ич»,— ди. Кесәсеннән кызыл билле прәнник чыгарып миңа суза. Алырга да, алмаска да белмим. Ашап карыйсы да килә... Кулларым тартышып китте. Шунда ул минем кыюсызлыгымны сизеп, прәнникләрне көчләп тоттыргандай итте. «Аша, оялма!»— дигән була. Барыбер сөйләшергә телем әйләнми. Тынып тик торам. «Я, әйт инде? Ризамы?»— ди. Билләһи газим, ни дип тә җавап бирергә белмим бит.

Тәнемнең әллә кай җирләрен ниндидер вак энәләр чәнчештереп торамыни. Аякларым да кыбырҗый, үзеннән-үзе идәндә ышкыла башлады. Шунда үзем дә сизмәстән: «Кыйнамасаң, сукмасаң...»— дип әйтеп ташлаганмын. Шулай диюгә, моның йөзе ачылып китте, кабарынкы калын, кара кашлары селкенеп алды. Коңгырт күзләрен тутырып миңа елмая. «Нишләп тиим мин сиңа, булмаганны»,— ди. Көлә. «Яннарымда син генә булсаң иде»,— ди. Әкрен-әкрен миңа якыная. Шунда, ничектер, туры китереп, кулымнан тотып алды бу, бармакларымны учына кысты... Менә шуннан сөйләшеп киттек.

— Язмыш насыйп иткән инде.

— Үзем дә шулай уйлыйм, Зәлия. Әйтергә дә оят, кияүгә чыкканда миңа әле күкрәк тә чыгып бетмәгән иде. Яшь булганбыз инде... Ул чагында төрлесен уйлап торырга вакыты ул булганмыни... Мин кияүгә чыккач, озак та тормыйча, Сабирҗан абый үлеп китте.

— Һе-е. Бер килгәнгә килеп торуын кара син аның.

— Нишлисең инде... Шунысы үкенечле, шунысы йөрәктән китми, Мәсрүрәләр приютындагы балаларны бүтән шәһәргә күчерәсе иткәннәр. Шулчак сеңелем, күрешеп калырга дип нянкасы белән, безнең торган җиребезгә килгәннәр. Нефть промыслалары шәһәргә шактый ерак иде. Поездлар әкрен йөри. Күрәсе килеп озак көткәннәр. Беребез дә өйдә булмаган. Габдулла тәүлекле эштә кәчәгәрдә, мин беренче бала белән больнискә кергән идем. Күршеләр дә кайда икәнебезне белмәгәннәр. Болар көткәннәр-көткәннәр дә күңелсезләнеп китеп барганнар. Сеңелемне күрә алмый калуыма һаман да йөрәкләрем сызлый... И Зәлия, ул чагында яшьлек белән бернәрсә белмәгән инде без. Русчаны аңламаган. Шул сеңелемнең кайларга киткәнен дә белешә алмадым. Хат яза белмәдем. Ни үкенеч!.. Аннары бирегә кайттык.

И Зәлия, үзең дә күреп-аңлап торасың, безнең җилкәгә тормышның күпме мәшәкатьләре берсе артыннан икенчесе өелә генә торды. Аның өстенә балаларым өч-дүрт тәүлек эчендә берсе артыннан икенчесе, тамаклары шешеп, сулый алмыйча үлеп киттеләр... Духтыр юк, дарулар юк. Кайларга барып бәрелергә урын тапмадым. Инде менә сугыш алдыннан туган улым — Илбатырым исән-сау була күрсен,— дигән идек.

Тырмаша-тырмаша яшәп киттем мин, әни. Болыннарда ат кузгалаклары җыеп тукландым. Безне исән калдырган үләннәрне, кычыткан ашларын гомеремә онытасым юк! «Кайчан күкрәкләргә терәп ипиләр кисәрбез икән?»— дигәннәрең әле дә истән чыкмый. Бер таңнан икенче таңга кадәр колхоз эшеннән бушамадың... Вакытлар үтте. Көттерепкөттереп булса да, ипине күкрәккә терәп кисәр көннәр килде. Ул чакта мин вак-төяк эшләреңә ярый башлаган идем...

Вагон проводницасы пассажирларны йокларга өнди. Инде соң, тышта караңгы. Әнә, каршы яктан килгән поезд ыжгырып үтә. Вагон тәрәзәләре артында төнге табигать кино кадрларыдай йөгерешә. Тәрәз-кадрлар миңа, әйтерсең, узган тормышыңны сөйләп ашыгалар. Мин аларда чагылганнарның һәммәсен күреп калырга тырышам...

* * *

Казан автобусы Теләчәгә өч сәгать дигәндә кайтарып җиткерде. Аннан авылга җәяүләп кенә киттем. Без, әни, кайчандыр шаулап торган Теләчә базарына синең белән икәү шушы юлдан чыккан идек. Сугыштан соңгы еллар иде ул. Әтинең үзе теккән тунын пот ярым онга саттык. Шунда син миңа сары сагыз алып биргән идең. Аны юл буе чәйнәп кайттым. Үзем кичләрен авыл яшьләренең «наза» уеннарында Теләчә-

чәгә багышлап җырлаган җырын такмаклап алам:

...Уйныйлар Теләчәдә.
Насыйп булмаган яр кала
Җаннарың теләсә дә.

Кайта-кайта шактый арылды. Җилкәңә күтәргән йөк авыр иде. Күпмедер ара узган саен утырып ял итәбез. Шулай үзебезнең тау башына килеп җиткәч тә ял итәргә утырдык. Син шунда әтине искә төшердең дә болай дип сөйләп киттең. «Атаң, мәрхүм, Грузныйдан кайтышлый, шушы тау башына җиткәч, бер утырып җырлаган иде:

Бара торгач мин утырдым
Биек тау билләренә.
Сандугачлар да сайрыйлар
Кайтам дип илләренә.

Аш-сулар уздырган саен гел дә җырлап, күңелле утыра торган иде...» Шулай дигәч, уфтанып куйдың. Аннары без янә кузгалып киттек. Бүре елгасы кырыйларыннан дулкын-дулкын булып сузылган, сыер көтүләре таптап салган тар сукмаклардан атладык. Берсендә, әнә теге текә яр юлыннан үләннән кайтышлый, безнең «уфалла» арбабыз Бүре елгасының «йотам» дип торган тирән чокырына тәгәрәгән иде.

Ул елны җәй коры килде. Терлеккә азык яклары, безнең тирә-юньдә печәнле болын һәм елгалар аз булганлыктан, кыенрак иде. Көтү йөртер җирләр аз. Ә мал-туарны асрарга кирәк. Башкача ничек көн күрәсең. Сыерсыз, суган суы суырып кына, ерак китеп булмый. Кешеләр, көнозын колхоз эшендә эшләп кайткач, тиз генә чалгыларын «уфалла» арбасына сала да печән кыркырга йөгерә. Елгага ауган көнне без дә шулай икәү печән чабарга чыгып киткән идек. Мин әле яшьрәк.

Дыңгыр-дыңгыр тәгәрәгән буш арбага ябышып артыннан этеп барам. Бауга бәйләп салынган чалгы кояшта ялтыр-йолтыр килә. Тәгәрмәч бүкәне күчәр башындагы чәкүшкә тимеренә дык-дык бәрелә. Бер-берсен куыша-куыша әйләнгән агач тырнаклар мине артларыннан йөгертә.

Бара торгач, без тау артындагы урман полосасына чыгып җиттек. Син, көттермичә, чалгыңны кайрак белән кайрап алдың да, кояшта елкылдаган карасу-коңгырт толымнарыңны яулыгың астында качыш уйнатып, үләннәрне кырт-кырт кистереп чаба башладың. Ә мин чабылган үләннәрне җыеп, арба янына ташыйм...

Йөкне төяп бетергәч, кайтырга чыктык. Мин арба артыннан этеп барам. Түбәнгә таба тәгәрмәчләр үзеннән-үзе тәгәри. Каты үлән сабаклары, шайтан таягыдай, тәгәрмәч тырнакларына кереп, сыдырыла-сыдырыла тырылдап баралар. Арттан тузан куба. Битләргә сара, колак эчләренә кереп тула. Юлдагы җылы, йомшак тузанга ялан тәпи эзләре чылбырдай батып-уелып кала. Үрләргә җиткәч: «Улым! Арурак этә төш!»— дисең. Үрне менә-менә арба тукталыр дәрәҗәгә җитә. Тешләр тешкә кысыла, аякларым җиргә ныграк терәлә: арба бармый, аякларым гүя җир шарын бушка әйләндереп торалар. Тәгәрмәч тырнакларыннан тотып каерырдай булам, кулларымның хәле беткәч, иңнәремне терәп этәм, җаным сине кызгана. Маңгай чәчләрең юешләнеп чигәләреңә ябышкан. Маңгай тирең тузанлы битләреңә юл салып ага да ага. Ничек кенә булмасын, түзим, түзим, дисең. Чөнки сөт, сөт кирәк! Ул күзгә кергән тир әчеләре белән тагы да тәмлерәк икән шул. Моны миңа синең әнә шул сабыр карашларың сөйли... Этә-этә хәлем бетте,башым кояш кызуы каккандай, әйләнеп-әйләнеп китә. Күз карашларым рәшә дулкыннарын кыр өсләреннән бер ары куа, бер якынайта. Шул зәңгәр дулкыннар эченнән гүя миңа ак кашлы сыерыбыз карап тора. Ул кышкы салкын көннәрдәгечә бер култык печән көтеп, дымлы моңсу күзләрен төбәгән дә, ачтан суырылып иңгән эчен тибрәтә-тибрәтә җанны тинтерәтеп мөгри...

Үрне менгәч тә тәртәне җиргә куйдың. Ялга тукталдык. Атлый-чайкала килеп арбадагы печәнгә сөялдең. «Уф алла!» дидең, кипшенгән иреннәреңне ялап алдың. Шунда син йөк үләне арасыннан бер тармак җир җиләге табып алдың. Берсен миңа суздың, икенчесен үзең каптың. Эх, нинди тәмле иде ул җир җиләге!

Хәл алгач, тагын кузгалдык. Инде юл түбән таба иде. Әнә шул Бүре елгасы тавын төшәр алдыннан, тәгәрәмәскә дип, бер як арба тәгәрмәчен бау белән бәйләп куйдың. Йөкне таудан тыеп төшү өчен бу шулай кирәк иде. Баскан урыныңнан «Аллага тапшырдык!» — дидең дә кузгалдың. Таудан әкрен генә төшәбез. Син тәртә эченнән барасың, мин йөк бәйләгән бауга ябышып, арбаны арттан тыям, үземә таба тартам. Бәйләнгән тәгәрмәч җиргә, вак ташларга ышкыла-ышкыла, дырк-дырк бара, тәртәне һаман да үз ягына каерырга чамалый. Син аңа ирек бирмәскә тырышып, тәртәне юл уртасыннан тоткансың. Сул ягында — тирән Бүре елгасы, йотырга дип торган ачык авызы йөрәкне җу иттерә. Тауның кыл урта бер җиренә җитүебез булды, кинәт бау шытырдап өзелде! Кызулап киткән арба артыннан, йолкынып, җиргә сөрлектем. Куркү катыш кычкырган тавышың колагымда чыңлады:

— Балам! Беттек, беттек...

Өстерәп чапкан арба, ярга кыйгаеп, мине бер читкә атты. «Ән-ни!» дип кычкырып җибәрдем. Тузан өермәсе эчендә җирнең асты-өскә әйләнгән кук булды. Шунда ук сиңа ни булганын белергә теләп, торып бастым. Синең дә, минем дә терсәк һәм битләр сыдырылган иде... Арба мәтәлә-мәтәлә, йөккә кадалган чалгыны бер якка очыртып, тәртә-урәчәләрне сындыра-сындыра елга үзәненә төшеп бара. Менә ул «доңк» итеп ташка килеп бәрелде дә елга үзәнендә кырынаеп туктап калды. Сыңар тәгәрмәче әйләнүен дәвам итә бирде. Син: «Күрәчәк,— дидең.— Ярый әле таптап китмәде... Башка вакытны да шул ук бау белән бәйли идем юкса»,— дип кулмәк итәкләреңнән тузаннарыңны кактың. Аска төшеп җиткәндә сыңар тәгәрмәч әйләнүеннән тукталган иде инде...

Әй, әни, тормышта язмышың арбасы әнә шулай ярдан тәгәрәмәсен икән. Аның өчен син өйрәткәнчә гадел, игелекле булып, хезмәт сөеп үсү дә кирәк икән шул.

Инеш яры!.. Әти утырткан таллар! Әйтерсең алар минем кайтуымны көтеп, исән-сау кайттыңмы дигәндәй, башларын суга иялэр. Бу талларга сөялеп син, әни, кайтып килүләремне күп тапкырлар көткәнсең. Бу минутта нигәдер күренмисең. Күрсәң, каршыма йөгереп чыгар идең. Мөгаен, эштәдерсең. Кечкенә генә такта түбәле өебезнең зәңгәр буяулары кояш нурларыннан уңа төшкән... «Быел язгы ташу ярны күп ишти»,— дип хатыңда язган идең аны. Чыннан да шулай икән. Суган бакчасындагы карлыган куакларына кадәр җимереп алып киткән. Ел да болай ишелсә, нигезгә дә барып җитәргә күп сорамас. Тал тамырлары ярга пәрәвездәй ябышып калган. Кырый талның тамырлары язгы бозлардан телгәләнгән. Инеш суын бөямәгәннәр икән. Болай булгач, ерып кына чыгам.

Ишектә — йозак. Балалар бакчасыннан кайтып җитә алмагансыңдыр. Сәгать алтынчы гына шул. Абзар читеннән бәрәңге сабакларын чабарга да керешкәнсең. Бакча безнең икәүдән-икәү сөйләшкәннәрне әле дә саклый кебек. Талгын җил миңа гүя шул тавышларны алып килә:

— Әни! Нигә чыктың инде? Үзем дә казып бетергән булыр идем.

— Бәрәңге алу көнелле бит ул, улым.

Казып чыгарган бәрәңгеләрне, сабакларыннан кага-кага, бер күчкәрәк өяргә керештем. Миңа карап, син үз фикереңне белдерәсең:

— Иске «ана» бәрәңге беркемгә дә кирәк түгел, калдырып чүплиләр. Картайгач, кешенең дә хаҗәте калмый башлый икән.

— Нишләп алай дисең, әни? Сиңа әле картаерга...

— Һи, ышанып булмый гомергә.

— Кешеләр йөзгә кадәр дә яшиләр. Син дә яшәрсең.

— И-и, тиле. Безгәме соң йөзгә житү?! Ни нужалар күреп...— Муенына салынып төшкән яулыгыңны, жилкәңә шудырып, төзәтеп алдың.— Тигез гомер рәхәт икән... Әтиеңнең шушы бакчаларда кыбыр-кыбыр эшләп йөргәнен күрәм. Берсендә шулай, жылык-жылык өйгә кереп килә. «Аягың пычрак, салмагансың да»,— дим. «Әле моржаңны да агартмагансың»,— диде дә китеп югалды. Аннары моржам ишелде дә төште. Кайтмаска булган икән... Аны көтүләремне үзем генә беләм... Төннәрен уянып китә идем дә (син йоклыйсың) тәрәзәгә килеп, аяз күктәге айга карыйм, айдан сорыйм: «Габдулла! Син дә бу айны күрәсеңме икән?!»— дим. Атаңмы? Сабыр, түзем кеше иде. Кулыннан килде. Теккән киемнәре көлеп торыр иде. Коеп куйган диярсең. — Йөзең кинәт болытлар арасыннан елмаеп чыккан кояштай яктырып китте. — Хатын-кызлар кием үлчәткәндә, миннән кыенсынмасын дип, яныннан берәр эш табып юри чыгып киткән була идем... Бергә яшәгән көннәр күңелле булган икән...

Әни! Менә шушы салына төшкән капкаңны ачып, үзең дә кайтып керерсең инде. Әнә, кара тавыгың, кетәгенә менәргә чамалап, кырынкырын йөгерә. Миннән өркә булса кирәк. Утынлыккарак узыйм әле. Ярылмый калган ботаклы утыннарың шактый жыелган... булмаса, шуларны ваткалый торыйм, яхшы физзарядка булыр. Балта кайда? Баз шалашы авызында түгелме? Әһә, сарай буенда икән. Әтидән калган имән бүкән һаман үз вазифасын үти әле. Шушы бүкәнгә утын ярырга иелгәч, ихтыярсыздан, теге Кәрим мулла малае Дибай искә төшә. Ул, алтыннарын яшереп йөрткән әтисе кинәт кенә үлеп киткәч, хәзинәне күпме генә эзләп караса да табалмый. Вакытлар үткәч, беркөнне баскыч төбенә чыгып баса. Нәрсәгәдер бик тә ачуы килә. Һәм кулына балта алып ишегалды уртасында торган бүкәнне ярып ташлый. Бүкән эче куышыннан яшерелгән алтыннар чәчелеп китә... Бүкәнгә иелгәч, минем дә бүкәнне ярып карыйсым килә. Юкса беләм: минем «байлык»ның бер өлеше — балачак илендә калган, башкалары — киләр көннәрем эргәсендә көтеп тора... Кара бу кәкре ботакны, ярылмаска чамалый. Балтаны «тешләп» авызын ыржайткан... Солдат абыйсы белән көрәшмәкче! Баш аркылы томырыйк әле. Оп-па!.. Ике якка очтыңмы?.. Әни кайткан ич! Капка ачылганны да сизми калганмын!

* * *

Инде менә ничәнче көн, кич йөреп кайтышлый, мин шушы инеш ярында тукталып калам. Тиз генә өйгә керәсем килми. Язгы ташкыннардан ишелә барган яр жанымны тынгысызлый, йөрәкне тырнап тора. Яр ишелүен эткәй таллары гына саклый алмаячак. Менә мондагы кырый тал авып, өч метр жирне умырып алган. Киселгән төбе кызыл яр читендә, судан башын калкыткан крокодилдай, тырпаеп тора. Юк бу ярны ничек тә ныгытасы иде. Я булмаса инеш суын әнә теге дугаланган болын почмагыннан бульдозер белән ердыртып жибәрергә кирәк. Болай эшләсәң шәбрәк. Председатель рөхсәт итсә? Син сорап караган булгансың да... гозереңне кире каккан. «Болын бит ул, көтүлек жирләре»,— диган. Юкса, бу болын почмагы егерме биш сутыйдан да артмый. Моннан тик алты-жиде хужалык бакчасы ишелүдән котылыр иде. Ярар, мин үзем, колхоз эшенә керешкәнче, сорап карармын әле...

Су буйлары тын. Нигәдер минем жан гына тынгысыз. Үз-үземә урын табалмагандай, айлы кичтә ялгызым каңгырып йөрим. Төрлесен уйланам. Сез дә, эти белән икегез, кичләрен шушы инеш буйларыннан серләшә-серләшә парлашып йөргәнсез, киңәшләр коргансыз. Әнә шулай каршыгыздан гына яркanатлар пырылдап очкандыр. Аяк тавышларыгыздан инеш буенда кунып калган казлар тын гына, әчкәрәк йөзеп талпынгандыр. Көмеш су өстенә иелгән тал ботаклары йокы аралаш

аларның йомшак йонлы башкайларыннан сыйпап калгандыр. Бу зифа талларга сөялеп сез күңелегездән нинди уйлар кичердегез икән?.. «Атаң вакыт-вакыт утырткан таллары белән сөйләшеп йөрер иде»,— дисең. Юкка түгел, берәр хикмәте булгандыр аның, әни. Бәлки ул җир кешесенең үз хезмәтен күрә белүдән, маңгай тире тамган туфрагына мәхәббәте арта барудандыр. Алай булмаса, туган илен сагынып, бер киткән Грозный шәһәреннән ул бәлкем әйләнеп кайтмаган да булыр иде. Мин дә шәһәр кешесе булып йөргән булыр идем. Юк шул... Сагындыра-сагындыра үзенә тарта икән ул Туган җир!

Әти нигез урынын инеш буеннан алып дөрес эшләгән. Су кадерен белгән ул. Алай гына да түгел, аккан суларга карап, синең белән бергә-бергә озын гомерләр кичерергә теләгәндер. Гомер дигәнең дә аккан сулар кебек. Тукталып тормый, үтә дә китә. Уйларым да шушы инешләргә кушылып ага сыман... Инеш буйларында ялгызым калгач, мин дә әти кебек, уйларымда үз-үземә сөйләшеп киткәлим. Сорауларымның я берсенә, я икенчесенә җавап эзлим, карашларымны ачыкларга тырышам.

...Ишелмәсәң иде син, яр! Болай чиләнеп, имән казыкларны тукмак белән чәкәләштермәгән дә булыр идем. Берегез кыйный, икенчегез түзеп кыйнала. (Нишләмәк кирәк? Тормышта да андый гыйбрәтләр очрап куя.) Миңа тик, сезнең инеш буена яңгыраган аһ-зарларыгызны тыңларга кала. Нәрсә, имән казык? Киреләнергә чамалыйсыңмы? «Пеләшләнгән машина баллоннарына арка терәп, ярга билдән чумып калырга теләмим, һич югында күмер булып янар идем, җылым белән кешеләргә файда кылыр идем»,— дисеңме? Юк, казык, офтанма. Мин сине юкка кыйнамыйм: мин түзим! Син, нигез бүрәнәсе булып ята алмасаң да, барыбер ата нигезен саклап калырга булышасың. Бу очракта син — нигез терәге. Бу өй түрендәге ялгыз каен, вакытлар узу белән, моңаеп калырга тиеш түгел. Бу нигез урынын алабута, кычыткан басып китмәс. Хуҗасының малае солдаттан бөтенләйгә дип кайткан... Аның өчен туган җир ата нигезеннән башлана. Аның монда иң тәүге, иң садә хисләре бөреләнеп чәчәк аткан. Җир шарындагы без басып торган шушы нокта — аның туган авылы — тормышында таяну ноктасы да. Ул шушы туфракка басып, үз биеклегеннән дөньяга фикер кыла. Дөрес, Илбатырның да: «Китәр идем моннан...»— дигән минутлары булмады түгел, булды. Һәм ул әлеге уенңан кире кайтып: «Нигез дигән нәрсә бар... Әни! Син бар...»— дип исәп тотты.

Җитәр, тынып тор, тукмак! Утырып бер ял итәргә кирәк. Солдат абыең да кеше... Чү! Тукта! Бу кош нигә әле каршыдан гына очына-очына йөри? Я теге, я бу инеш ярына куна да озынча койрыгын тибрәтә-тибрәтә, кара-аксыл түшләрен елтыратып, чикләвектәй башкайларын як-якка бора. Аннан янә очып китә, тагын килеп куна, монда карый. Су кошы бу, чәпчек. Әллә ярга оясын корган инде? Карыйм әле... Әй-йе. Менә ич. Ярга ятьмәдәй җәелеп ябышкан тамырлар арасына кереп оялаган. Күкәйләре дә бар. Бишәү. Димәк, ул оясын шулай сагалый. Нәни йөрәге күкрәк читлегеннән чыгардай булып тибенәдер. Курыкма, кошкай! Мин синең ояңны җимерми генә узармын.

Әйе, кошлар да үз оялары өчен борчылалар шул...

Әни! Тагын борчылып яныма чыгып киләсең инде. Өзелеп эшләмә, торган яр торыр иде әле, диярсең инде. Юк, әни, аны хәзер солдат ялы узып киткәнче эшләп калырга кирәк. Председатель теге көнне үк: «Кайчан эшкә чыгасың инде, кайтканыңа ике атна булды»,— дип белдерде. «Кая кушасыз?»— дигәч, «Хәзергә тимерче Әсгать янына төшеп торырга туры килер»,— диде. Аннары кая куяргадыр исәбе.

— Юк эшкә керештең бугай син, улым. Авыр да үзеңә. Агачлар гына утырткан булыр идек, торыр иде әле шунда.

— Юк, әни, булгач булсын инде.

— Әйдә, суынганчы ашарга кер. Бәрәңге өчпочмагы пешергән идем.

— Хәзер, әни. Менә бу ике казыкны гына кагып бетерим дә...

Әйдә, тукмак, җитәр! Җырыңны көйләргә әзерлән! Һоп-па! Монысы бер булыр, бу ике... Ир-егетләр без, казык. Авырлыкларга бирешмәскә дип килдек. Бу урынны туган җиремнең үзәге дип бел. Без аны гөлбакча итәрбез. Менә күрерсең, озак та үтмәс, шушы суган бакчасында язларын алмагачлар, чияләр, сиреньнәр чәчәк атып, хуш исләр таратырлар. Ышан, Габдулла Камалов нигезендә тормыш дәвам итәр! Бу инеш сулары гомер агышларымны хәтерләтеп агар да агар.

# ЯШЬЛӘРГӘ ӨМЕТ

Бу әсәрнең кульъязмасын укыр-укымас төрле урыннарына күз салгалап утырганда иң башта араларның чамасыз ераклыгы күзгә чалынды: әллә кайлардагы ком чүле, меңнәрчә километрларга сузылган тимер юллар, Казан, үзебезнең якның Теләчәсе, авылның инеш яры... Ә хикәя бер табакка да тулмаган. Шундый кеп-кечкенә әсәрне меңнәрчә километрларга сузу шулкадәр үк кирәк булдымы икән?..

Укыргамы, әллә кирәкмиме, берәр «өмет» бармы?

Әмма, ни гаҗәптер, хикәя үзен «укыта» иде. Башта бер бите, аннары башка битләре... Болайга киткәч, әсәрнең бу сыйфаты белән исәпләшмичә ярамый, аңа игътибар итмичә һич тә мөмкин түгел иде. Чөнки, ахыр чиктә, әдәби әсәр укылсын өчен языла, аның укучыны үзенә җәлеп итә алуы — төп сыйфатларыннан берсе ләбаса.

Нәрсәсе үзенә тарта, әсәрнең нинди «сөйкемле сөяге» бар?

Укый торгач, хикәядән күңел түренә үтеп кереп рухи дөньяның нечкә кылларын чиертә торган ниндидер бер ягымлы, йомшак җылылык сирпелә башлавын сизәсең. Ком чүлендә кырыс солдат хезмәтендәме ул, поездда иксез-чиксез далалар кичәме, туган йортына кайтып төшкәч, язгы ташу җимереп киткән яр буйларын ныгытамы — кайда гына булмасын, солдат егет һәрдаим күңеленнән әнисе белән сөйләшә, уйларын-тойгыларын аның белән уртаклаша, киңәшә, сугышта үлеп калган атасының, кыен тормыш юллары үткән әнисенең башларыннан узган гыйбрәтле хәлләрне, үзе яшәгәндәй, күңеле аша уздырып эчке дөньясын баета. Солдат егетнең атаанасына булган кайнар мәхәббәте, аның йөрәк җылысы булып укучыга да килеп җитә. Улының хыялында күптән вафат булган атасы да телгә килә. Ул мәңгелек ут ялкыныннан улына васыять сүзләре белән дәшә:

— Җир шары әле һаман да тыныч түгел. Уяу булыгыз! Җир астыннан мәңгелек ут булып бәреп чыккан безнең йөрәгебез ялкыны сезгә шул турыда искәртеп торсын! — ди.

Билгеле инде, мондый авазны ишетә белгән егетне буш кешегә санап булмый, ул иске нигезгә яңа хуҗа булып кына да кайтмый. Юк, ул туган иленең иминлеген саклап калу өчен җанын да кызганмаган солдат әтисенең лаеклы варисы булып, ата-бабадан калган бай рухи хәзинәне үз күңеленә кадерле мирас итеп сеңдергән киң карашлы, батыр йөрәкле замана егете булып гәүдәләнә.

Бу хикәя әйтеп бирергә теләгән фикеренең әһәмиятле булуы, үзенә җәлеп итәрдәй әдәби кыйммәте булуы белән укучыда уңай караш тудырса кирәк. Әмма шул ук вакытта хикәя яшь авторның әсәрне язганда нинди кыенлыклар кичерүен күз алдына китерү ягыннан да игътибарга лаеклы.

Аларның берсе — авторның хикәяне иҗат итү өчен кирәкле булган «төзү материалына» — тормыш вакыйгаларына мөнәсәбәте, дөресрәге, алар белән «тартышуы». Әдәбиятчылар арасында: «Бер роман язу өчен ун романлык тормыш материалы кирәк була»,— дигән күптәнге тәгъбир йөри. Әнә шул ун өлештән бер генә өлешен, иң кирәген генә сайлап алу автордан шактый ук осталык таләп итә. Бу әсәрне язганда да автор әнә шундый кыенлыклар кичергән. Аңа хикәяне язу уңае белән күңеленә килгән һәммә вакыйга һәм күренешләр дә: ком чүлендә походта йөрү дә, уйлана-уйлана поездда кайту да, әнисенең бала чагында сеңелесе белән җиләккә барулары да (дөресен генә әйткәндә, монысы, А. Чехов әйткәнчә, атарга тиешле булып та атмый калган мылтык булып чыга), ачлык ел да, әнисенең ничек кияүгә чыгуы да һәм башка бик күпләр — һәммәсе дә бик кирәкле, бик әһәмиятле, аларсыз хикәяне һич тә язып булмый кебек тоела. Әйе, шулай тоела.

Әдәбиятка беренче аяк басканда күпләрнең башыннан узган хәл бу. Шунлыктан, хикәя авторының вакыйгалар, истәлекләр басымына каршы тора алмавын вакытлы бер хәл дип,

осталык үренә менеп барганда узыла торган бер баскыч кына дип карарга кирәктер. Килер бер вакыт, тәҗрибә туплый төшкәч, мондый хикәя язып өчен авторга ком чүлләре дә, кырык-илле елга артка чигенүләр дә кирәк булып чыкмас, бу хикәядә укучыга җиткерәсе фикерен ул җыйнак кына, үтемле генә итеп яр буена казык каккан арада да әйтеп бирергә өйрәнер. Әнә бит талантлы драматург булу, романнар авторы булу өстенә новеллалар остасы буларак та танылган зур әдип — Шәриф ага Камал нинди җан тетрәткеч зур фаҗигане дә кечерәк кенә бер өй эченә, хәтта идәндә аунап яткан бер төймәгә дә сыйдыра алган.


Паровозны корыч аргамакка, узып баручы поезд тәрәзәләреннән чагылып калган күренешләрне кинокадрларына охшатуны мин матур әдәбиятта яңалык дип әйтмәс идем. Андыйлар еш кабатланып тора. Хәер, әдәбиятка яңа килгәндә — язганда булгалый андый хәлләр. Тапкыр сүзләрне, отышлы чагыштыруларны һәммәсен дә үзең уйлап таптың кебек хис итәсең. Бер әсәремне язганда мин, бик тә отышлы күренеш табуыма куанып, бер карчыкның кул аркасына төшкән кояш шәүләсен икенче кулы белән бик рәхәтләнеп сыйпап утыруын язган идем. Ләкин шунда ук бу күренешнең каләм очына ничектер бик ансат килеп төшүе, шуның өстенә, бик кыйммәтле «табыш» булуы күңелгә шик салды. Ай-һай, үземнекеме икән? Бүтән берәр әсәрдән килеп кергән булса? Эзләнә, искә төшерергә тырыша торгач, ачыкланды: бу образ минем алдымдагы кәгазьгә М. Горькийның әллә кайчан ук укылган бер әсәреннән килеп «кунган», имеш. Билгеле, бу куанычны сызып ташлавы бик кыен булды. Ләкин нихәл итмәк кирәк? Иҗат сүзенең төп мәгънәсе яңаны тудыру бит, башкаларны кабатлау түгел.

Нурислам Хәсәнов әсәренең тәҗрибә җитеп бетмәүдән килә торган кайбер җитешсезлекләре янында уңышлы яклары да аз түгел. Мәсәлән, миңа аның башта әйткәннәрдән тыш тагын ягымлы, йомшак тел белән язуы ошый. Ул сүзгә дә саран түгел. Яшь автор моңарчы халык телендә сакланып килгән, хәзергә әле еш кулланудан шомарырга өлгермәгән аерым сүз һәм гыйбарәләрне дә тәмен, кадерен белеп нәкъ үз урынында куллана, тормыш детальләрен күрә белә, аларны укучы күңеленә үтеп керердәй итеп әйтеп тә бирә. Мәсәлән, күңеленнән әнисе белән сөйләшкән бер урынны ул болай тасвир итә: «Мин арба артыннан этеп барам... Үрләргә җиткәч син: «Улым, арурак этә төш!» дисең...»

Телгә бай булу, телнең мөмкинлекләреннән дөрес файдалана белү — язучыга иң кирәкле сыйфатларның берсе. Мәгълүм булганча, шундый бер хакыйкать яшәп килә: ярлы, начар тел белән яхшы әсәр язу мөмкин түгел.

Бу хикәя турындагы фикерләрне йомгаклап әйтәсе сүз шул: без, өлкән буын кешеләр, яшьләр иҗатына зур өметләр баглыйбыз, киләчәктә алардан берсеннән-берсе уңышлырак яңа әсәрләр көтәбез.

**Гомәр БӘШИРОВ.**



Мулланур Вахитов.

*М. Юхманың «Көнгыш — үлемсезлек кошы» повестена.*

Т. Хажиәхмәтов рәсеме.

**Михаил Юхма**

# КӨНГЫШ — ҮЛЕМСЕЗЛЕК КОШЫ

## ПОВЕСТЬ

*Хәзерге буын гына түгел, киләчәк көн дә, һәрнәрсәгә тиешле хак бирәчәк тарих та аның хакында:*
*— ...Шәрыкның азатлык таңында вакытсыз һәлак булган бөек революционеры, бөек корбаны! — дип әйтәчәгенә тирән бер ышану белән ышанамыз!*

Галимҗан Ибраһимов.

Җир шары кызурак әйләнә башлаган кебек иде. Көннең, сәгатьнең кадере артты. Хәтта поездлар да, вакыт рельсларына сыеша алмыйча, расписаниедән соңга калып йөриләр иде. Байтактан бирле инде шулай.

Бөтен Россияне уяткан, хәрәкәткә китергән Революция туфаны, иске ярларына кайтырга теләмичә, үзенә яңа үзән салган давыллы дәрьяны хәтерләтте. Революция дулкынында халык үзенә алдан юл ярып барырлык, кайнар йөрәкле, зирәк акыллы улларын күтәрде. Аларга ышаныч баглады. Аларның сүзенә колак салды.

Татар халкының каһарман улы, ялкынлы революционер Мулланур Вахитов әнә шундыйларның берсе иде.

...— Безнең язмышыбыз үзебезнең кулларда! — диде ул. — Әгәр без, мөселманнар, Европа буржуйлары кулында бер уенчык булып калырга теләмәсәк, мөселман эшләрен үз кулыбызга алырга тиешбез!

— Рас әйттең!— дип хуплады аны гавам. Хәтта милләтче агайлар шашынып кул чапты, майлы иреннәрен ялап:

— Мотлака дөресен сөйли, афәрин!— дип кычкырдылар.

— Февраль революциясе әле чын инкыйлап түгел иде,— дип дәвам итте Мулланур.— Үткән елның октябрендә генә рус капитализмының тәхете йөзтүбән килде, һәм хас халык революциясе — ярлы һәм мазлум хезмәт ияләре революциясе тантана итте. Мөселман эшләрен дә мөселман эшчеләре, крестьяннары һәм солдатлары хәл кылырга тиеш, кардәшләр!

— Әй... Ялгышты!.. Хилаф юлдан китте. Гидайлар сүзен сөйли ләбаса...— дип чыраен сытты агай-эне.

---

Журнал варианты. Мөдәррис Вәлиев тәрҗемәсе.
© Михаил Юхма. Кунгош — птица бессмертия. М., «Политиздат», 1984.

— Бары тик хезмәт ияләре генә, әлегәчә бәхеттән мәхрүм итеп киленгән юксыллар гына бер йодрыкка берләшеп, мөселман дөньясын азат һәм бәйсез итәргә сәләтле!

— Сафсата! Кызыл авыз!.. Карале, моның башында нинди җилләр исә? Әллә соң бер-бер хәйлә корамы — ярлы-ябагайны үзенә каратмакчы буламы?!— диештеләр затлы туннарга төренгән төркемдә.— Һәрхәлдә, башы йомры күренә егетнең. Еракка китәр бу...

— Әйе! Петроградның үзенә барып җиткәнче!— дип җавап кайтарды аларга кемдер.

Халык диңгезе чайкалып куйды, аның өстендә җилкән булып кызыл байраклар җилфердәп ачылды. Тыелгысыз булып агылган бу ташкын, тимер юл вокзалына якынлашкан саен, зурая, көчәя барды. Чуен юлга ук терәлеп, тыгыз, матур сафлар булып милли гаскәрләр тезелгән иде: шинельләрдә ал бантлар, бүрекләрдә — ярым ай төшерелгән яшел тасмалар...

— Мөгаен, әле кемдер халык бәхете, хезмәт ияләре хакимияте төшенчәләрен кызыл сүз, коры вәгъдә генә булып калыр дип өметләнәдер.— Вахитов кинәт кенә бөтен гәүдәсе белән әлеге «затлылар» төркеменә таба борылды. Тегеләр күз алдында бөрешеп куйдылар. Әйтерсең лә ул аларның күңелендәге үтәли күреп, иң яшертен уйларын укып тора иде.— Ләкин, юк, өметләнмәсеннәр! Безнең сүзләребез гамәлдән аерылмый! Без Петроградка эшче, крестьян һәм солдат туганнарыбызның мәнфәгатен кайгыртып барабыз һәм шул мәсләгебездән бер адым да читкә тайпылмабыз.

Аның сүзләрен хуплагандай, әкрен генә паровоз сызгыртып куйды.

— Менә, паровоз да бирделәр. Тиздән бу тамаша тәгәлләнә, җәмәгать!— җиңел сулап куйды тук чырайлы, кондыз якалы адәм.

Аның янында торучыларның чырае ачылмады. Арадан берсе:

— Ах, шулай булсачы, кәбәм! Тик куркамын: бу әле башланып килүе генә булмагае!— диде.

Учредительное собрание депутаты Мулланур Вахитовны Казан, әнә шулай сагаеп һәм шөбһәләнеп тә, үз итеп һәм зурлап та озатты.

Бу — 1918 елның 2 нче гыйнвары иде.

## Беренче бүлек

### 1

Вакыт үзе шулай ашыга идеме, әллә башка сәбәпләре дә булдымы икән... Поездлар инде күптән расписание буенча йөрмиләр иде. Мулланур утырган состав та Петроградка төгәл бер тәүлеккә соңгарып килде.

Перронга чыккач, Мулланур бермәлгә югалып калгандай булды. Шау-шудан, кеше күплегеннән, сәер бер ыгы-зыгыдан башлар әйләнеп китәрлек иде! Әмма ләкин берәүнең дә йөзендә шатлык әсәре сизелми, бәйрәм рухының эзе дә юк. Берәүләр аптырап калган, борчулы, хәтта хафага төшкән кебек. Икенчеләренең йөзендә — бернигә дә ис китмәү галәмәте. Дөрес, ара-тирә көлеп куйган тавышлар да ишетелеп ала, егетләр-кызлар гөрләшеп узып китә. Тик кызыл әләмнәр дә, плакат-мазарлар да күренми...

Юк, бер дә бәйрәмгә охшамаган шул бу. Ә бит карт Рәсәй ничәмә еллар буе көткән иде бу көнне! Хәер... Бүгенге көнне түгел, кичәгесен көтте Россия. Учредительное собрание кичә, 5 нче гыйнварда ачылырга тиеш иде. Бүген инде 6 сы... чынлап та, бик сәер бит әле. Нидер булган, көтелмәгән бер хәл, фаҗига килеп чыккандыр шикелле.

Искәрмәстән кемдер аның җилкәсенә шапылдатып сукты. Мулланур теләр-теләмәс кенә борылып карады. Берәрсе ялгышып, кем беләндер буташтырып шаяртамы соң?.. Күр әле: ап-ак тешләрен күрсәтеп, авызын колагына җиткәнче ерып тора бит! Шадрасына хәтле таныш!

— Шәриф!..— дип сөенеченнән кычкырып җибәрде Мулланур.— Һай, егет икәнсең! Һай, шәп иткәнсең әле мине каршыларга төшеп.

Бу — Шәриф Манатов, башкорт егете, аның күптәнге дусты, ул да Учредительное собрание депутаты иде. Шәриф Петроградка алданрак килеп җитешкән дә, менә бүген вокзалга, соңга калган дустын каршыларга, аңа бөтен хәл-әхвәлне аңлатырга йөгергән дип уйлады Мулланур.

Әмма Манатов үзе дә әле генә килеп төшкән булып чыкты: Оренбург поезды да, Казанныкы кебек үк, бер тәүлеккә соңга калган икән.

Алар икәү вокзал алдындагы мәйданга чыктылар. Монда да ниндидер киеренкелек сизелә иде. Халык күп, ләкин кешеләр үзләрен бик сәер тоталар: митинглар, җыеннар вакытындагы кебек тоташ дулкын юк, бөтен мәйдан, язгы ташудан соң калган чүп утраучыклары кебек, кечкенә-кечкенә төркемнәргә таркалып беткән.

Мулланур белән Шәриф, шундый төркемнәрнең берсенә килеп, уртагарак үтәргә — тавышы өзелә-өзелә нидер кычкырган бәндәне күрергә тырыштылар. Үзе әле күренмәсә дә, аның:

— Юкка гаҗәпләнәсез, әфәнделәр!— дигән сүзләре ачык ишетелде.— Ул юлбасарлардан бүтән игелек көтеп буламыни!..

— Нәрсә дисең син?! Яле, кабатла!— Мулланурның алдында торган таза гына гәүдәле матрос уртага ыргылып, теге бәндәнең якасыннан умырып алды...

— Туктале, туган,— дип, матросның иңенә кагылды Мулланур.— Сугышырга җитешерсең. Ичмасам, аңлатып бир әле: нәрсә булды соң сездә?

Матрос каш астыннан гына сөзеп карады:

— Ә син кем тагын?

— Безме? Учредительное собрание депутатлары без!— дип елмайды Шәриф.— Әле генә поездан төштек...

— Ә-ә-ә, депутатла-а-ар... Соңга калдыгыз шул, әфәнделәрем!— Матросның әле генә ачулы тавышы күз ачып йомганчы мыскыллауга әверелде.

— Әйе, без ачылышка соңгардык шул,— диде Мулланур.— Тик шулай да...

— Ачылышка гына түгел, гүпчи соңга калдыгыз сез. Чәпчим! Я, барып җиттеме инде?.. Юк хәзер сезнең Учредительное собраниегез. Кабарган иде — шартлады... Исе генә калды. Фу-у!

— Бу нинди мәгънәсез шаярту?— дип кашын җыерды Мулланур.

— Тәәссефкә каршы, гражданин депутат, шаярту түгел бу, чын хакыйкать үзе,— дип, Мулланурга таба борылды озын, арык гәүдәле әфәнде. Аннары ашыкмыйча гына тун төймәләрен ычкындырып, эчке кесәсеннән күзне камаштырырлык чиста ак кулъяулык алды, алтын кысалы күзлек пыялаларын сөртергә кереште. Әфәнденең күзләренә яшь килгән иде.

— Бөтен Россия өметләнеп көткән иде бит! Шуны куып таратырга батырчылык иттеләр!— диде ул үксегән тавыш белән.

— Булмас ла!— дип кычкырып куйды Шәриф.

— Ничек? Кем тараткан?— диде Мулланур.

— Большевиклар!

Кинәт бөтен дөнья тынып калган кебек булды,— Мулланурның хәтта колаклары чыңлап куйды. Бу хәбәр әле акылга барып җитми, шуңа күрәдер, бер мәлгә саңгыраулатып калдырган иде. Ләкин әлеге халәт бик тиз узып, зиһен элеккегедән дә ныграк ачылып китте.

Ах, менә кая таба юл алган икән эшләр! Ә бит нәкъ шулай буласын көтәргә кирәк тә иде. Русия — зур мәмләкәт, азмы әле анда томаналык, караңгылык азмы! Күпме төбәкләрдә гади халык мәңгелек йокыдан уянып кына килә. Һичнинди сәяси тәҗрибәләре дә юк, әлбәттә. Учредительное собраниегә сайлаулар дөньялар болганган чакта, киеренке шартларда узды. Депутатлар арасында кызыл авыз либераллар, ачык кыйблася-

иманы булмаган бушкуыклар күп булса да гаҗәп түгел. Буржуаз партия вәкилләре дә шактый үтеп кергәндер әле.

Учредительное собрание шома гына үтмәс, дип Мулланур элегрәк тә уйлана иде. Уң партияләр гади хезмәт халкының мәнфәгатьләрен аяк астына салырга тырышачаклар. Көрәш каты, рәхимсез булачак. Әмма барыбер дошманнарның тарих тәгәрмәчен кирегә бора алмасына, гаделлекнең җиңеп чыгасына шикләнми иде Мулланур.

— Тараттылар дисез алайса... Шулай кирәк булган, күрәсең,— диде Мулланур әкрен генә.

— Менә дөрес әйттең, брат! Шул кирәк иде Учредилкага!— дип җөпләп куйды матрос. Бәхәстән файдаланып, баягы «оратор» аның кулыннан ычкынган, янә нәрсәдер әйтмәкче булып очына башлаган иде.

— Әйдәле, Шәриф, китик без моннан,— диде Мулланур.— Урамда якалашып торудан мәгънә юк. Безгә аннан мөһимрәк эшләр дә бардыр әле!

— Кая барабыз соң? Таврида сараенамыни?— дип аптырады Шәриф.

— Юк! Учредительное собраниенең таратылуы хак икән, Таврическийда безгә эш калмаган, дустым. Минемчә, хәзер иң дөрес юнәлеш — Смольный...

## 2

Петроград — Мулланурның студентлык пайтәхете. Ул аның күңеленә яшьлек хатирәләре белән һәм, ахрысы, барыннан да бигрәк хозурлану, соклану хисе белән кереп калгандыр. Хәтернең кайсыдыр бер почмагында әнә шул соклану нурына өртелеп Смольный бинасы яктырып тора...

Ләкин хәзер Смольныйга бөтенләй үзгә төс кергән. Рәшәткәле капкасы шыр ачык, аңа каршы броневик килеп туктаган. Бина тирәсе утын әрдәнәләре белән бөҗралап алынган: күрәсең, коралллы һөҗүм булa-нитә калса, ышыклану өчендер инде. Колонналар яныннан алты дюймлы ике орудие кара көпшәләре белән күзгә карап тора. Шунда ук берничә пулемет расчеты урнашкан.

— Пропуск!

Кызыл бәйләвечле сакчы депутатлык мандатларын, иҗекләп укыгандай, иреннәрен кыймылдата-кыймылдата бик озаклап карады. Ниһаять, юлны кискән винтовка, түтәсе белән таш идәнгә бәрелеп, «чырк» итеп куйды.

— Узыгыз!

Әле күптәнме бу озын коридорларны тәкәббер-текә күкрәкле ханымнар һәм горур-көяз килешле туташлар яктысы балкытып торгандыр. Күз алдына китерүе дә кыен! Затлы нәселдән чыккан кызлар институтыннан хәзер нәрсә генә калды икән?.. Бөтен тирә-якта — соры шинельле солдатлар, кара бишмәтле матрослар, беләкләрендә — кызыл җиңтасма. Бүлмәләрдән — «ундервуд»лар шытырдавы ишетелә. Баш өстендә махорка төтененнән җыелган күксел болыт эленеп тора.

Смольный эче нәкъ кырмыска оясы кебек кайнаса да, күрәсең, монда барысы да ниндидер бер эчке тәртипкә, системага буйсынган. Игътибарлабрәк карасаң, беркемнең дә болай гына буталып йөрмәвен, һәркайсының үзенә ачык билгеле эш-максат белән ашыгуын аңлыйсың. Мулланур белән Шәриф тә моны бик тиз абайлап алдылар. Алар икесе генә көчле агым уртасында калып, кайсы ярга чыгарга икәнен белми торалар кебек иде.

— Әй, ашыкма!— дип туктатты Шәриф Мулланурны.— Болай бит адашып китүең дә бар. Берәрсеннән сораек! Хәер, кемнән сорайсың? Нәмә кирәген әле үзебез дә белмәйбез бугай...

— Безгә Ленинны табарга кирәк,— диде Мулланур.

— Әйттең сүз...— дип көлеп җибәрде Шәриф.— Безне генә көтеп торадыр, бездән башка мәшәкате беткәндер аның.

Ул чынлап та, Мулланур шаяртадыр гына, дип уйлады. Ә Мулланур-

ның шаяртырга исәбендә дә юк. Әле тегендә, вокзал мәйданында ук тикмәгә мени Смольныйга барырга тәкъдим ясады ул. Карары нык иде: бернигә дә карамастан, Ленин белән очрашырга кирәк. Дөрес, Смольныйга керү белән, бераз икеләнебрәк калган иде: кинәт кузгалган бу ташкында ул үзен бер тамчы гына итеп тойды. Әмма дустының чыраена чыккан аптырау, югалып калу Мулланурга баштагы ныклык-ышанычны яңа көч белән кире кайтарды.

— Әйдә, җәһәтрәк бул әле,— дип ашыктырды ул Шәрифне, кая барасын бик яхшы белгәндәй.

— Бәлки, башта бераз капкалап алырбыз?— диде Шәриф уңайсызланып кына.— Кичәдән бирле авызга локма ризык капкан юк...

Ул шундый юашланып, мескенләнеп калган иде, Мулланур бер шаркылдап көлмичә түзә алмады. Мәгәр Шәрифнең сүзләрендә хаклык зур иде: кинәт кенә өздереп ашыйсы килеп китте.

— Ярар, синеңчә булсын. Ач карында ачу бар дигәндәй...

Ашханәне табу читен булмады. Аның ишеге берөзлексез ачыла һәм шапылдап ябыла, шул ишектән бөтен тирә-юньгә хуш исле кәбестә һәм арыш ипие исе тарала иде.

— Бәлки, безне әле монда ашатмаслар да?— дип икеләнеп куйды Мулланур.

— Ашатырла-а-ар!— диде Шәриф. Аның тавышы көр, аш исеннән ул тәмам рухланып, дәртләнеп киткән иде. Каракучкыл йөзе яктырып, коңгырт күзләре шаян елтырый ук башлады. Шунда ук ашау мәсьәләсендә тулы информация дә алып килде:

— Кайсыдыр полктан поход кухнясы китергәннәр, малай. Өч тәңкәгә теләсә кемне сыйлайлар!

Щи, ботка, шуның өстенә калын гына ипи телеме. Сый дигәне менә шундый гадәти иде. Мәгәр савыт-аяк дигәндә... Ниләр генә юк икән монда! Калай җамаяклар да, солдат котелоклары һәм фаянс, фарфор тәлинкәләр дә... Каршыда утырган җирән солдат, әнә, тирән балчык чүлмәктән көмеш кашык белән щи чөмерә. Аның күршесендәге матросның кулында агач кашык, алдында — бик нәфис, юка, кашык тигән саен чыңлап китәргә торган тәлинкә. Бик затлы фарфордан эшләнгән булса кирәк...

— Ачыктыгызмы, иптәш?

Мулланур, бу сорауның үзенә бирелүен әле төшенә алмыйча, әкрен генә башын борды. Уң ягында утырган гаҗәп җете-шаян күзле бер кеше елмаеп аңа карап тора иде.

— Сезгә тагын бер өлеш ботка алырга киңәш итәм. Алыгыз, ал, зинһар, уңайсызланмагыз!— дип кыстый башлады ул Мулланурны. Юк, бу — башта тоелганча, артык яшь кеше түгел икән. Тик карт та түгел! Киң маңгай, җыйнак кына сакал... Күз төпләрендәге күләгәләр генә йокысыз төннәр, алны-ялны белми эшләү галәмәте бугай. Бар килеш-килбәтеннән ныклык, сабырлык, көч-җегәр бөркелеп тора. Ә күзләре! Алар чиксез игътибар һәм кызыксыну белән тулы.

Мулланур ашаган арада, күршесе инде тәлинкәсен читкәрәк этеп куйган да, кечкенә кәгазь кисәкләренә кызу-кызу гына нидер язып утыра иде. Менә ул язуыннан туктап, бөтен гәүдәсе белән Мулланурга таба борылды.

— Еракан килдегезме?— дип сорады.

— Казаннан,— диде Мулланур.— Мин Казаннан, ә менә иптәшем Оренбурдан.

— Я соң, ничек каршылады сезне Питер?

Сүз юктан сүз булсын дип кенә кызыксыну түгел иде бу. Мулланур шуны сизеп, бермәл уйга калды. Аңлатып булырмы?

— Ничек дип, балта түтәсе белән башка суккандай булды инде. Учредительное собраниегә дип килгән идек. Депутатлар бит без. Килдек тә менә...

Мулланур сүзен әйтеп өлгермәде.

— ...Үз күзләрегез белән күрдегез инде, шулаймы?— дип бүлдерде аны гәптәше.— Кызык бит әле бу! Гаҗәп кызык... Ә каян белдегез Учредилканың таратылганын? Кайда ишеттегез?

— Поездан төшү белән...— дип, әкренләп сүзгә Шәриф тә кушылды.

— Димәк, поездан төшү белән! Ә кем әйтте аны сезгә? Зинһар, иркенләп сөйләгез әле. Бик тә кызык ич бу.

— Вокзал мәйданында... Безгә бер матрос аңлатты...— дип икесе берьюлы искә төшерә башладылар.

— Шулаймы? Ничек итеп аңлатты инде ул? Нинди сүзләр белән?— дип төпченүен дәвам итте яңа танышлары.

— Ул безгә: «Соңардыгыз шул, әфәнделәр! Кабарган иде дә шартлады... Исе генә калды... Фу!»— диде.

— Карале, шәп әйткән бит, ә! Чынлап та шулай дидеме?.. Ярый, рәхмәт сезгә, зур рәхмәт. Без сезнең белән күрешербез әле. Һичшиксез, күрешербез! Ә шулай да тагын бер тәлинкә ботка алыгыз. Ихлас әйтәм!

Ул җиңел генә торды, икесе белән дә кул биреп саубуллашты һәм, кәгазь кисәкләрен кесәсенә сала-сала, кызу атлап ишеккә таба китте.

— Булдырдык бит, әй!— диде Мулланур, өстәмә берәр өлеш ботканы да «сугып» салгач.— Инде юлны дәвам итсәк тә була.

Алар яңадан шул ук очсыз-кырыйсыз коридор буйлап киттеләр. Дулкын кочагында калган кебек, бер яктан икенче якка сугылдылар. Тик хәзер инде аларның адымы ышанычлырак иде, чөнки максатлары ачык — ничек тә булса Ленинны табарга кирәк.

«Ундервуд»лар аеруча үҗәтләнеп шатыр-шотыр килгән бер бүлмә каршында туктап, икеләнебрәк калганнар иде,— искәрмәстән биек ак ишек ачылып, аннан җәлт кенә килеп чыккан күн курткалы адәм Мулланурны бәреп ега язды. Ә үзе авыз эченнән генә:

— Гафу,— дип китеп барган җиреннән, кинәт нәрсәдер исенә төшкәндәй, борылып, туктап калды.— Мулланур! Син түгелме соң?!

— Галимҗан?!

— Мулланур...

— Бирәем дигән колына чыгарып куяр юлына, дип әйтеп-әйтеп әйткән ди...— Шәриф куанычыннан такмаклап китте.— Болай булгач булды, әттәгенәсе!

Галимҗан Ибраһимов та алар кебек үк депутат, Учредительное собраниегә ул Уфа губернасыннан сайланган иде. Мулланур бу җегәрле, кыю кешене электән үк яхшы белә. Сул эсерлар ягында иде Ибраһимов, шуңа күрә арада еш кына бәхәсләр дә килеп чыккалады, революцион тактиканың бик мөһим мәсьәләләрендә капма-каршы якка китә язган чаклары да булды. Ләкин хәзерге очрашуга аларның икесе дә шат иде.

— Сезнең килүегез бик әйбәт булды бит әле, егетләр!— диде Галимҗан, Шәриф белән Мулланурның икесен берьюлы кочагына алып.

Әле генә шатлыктан тыпырдаган Шәриф:

— Нәрсәсе әйбәт инде? Болай килеп чыгасын белсәкме! Өйдә генә утырган булыр идек,— диде.

— Юк, алай димә, Шәриф туган. Ярый әле килгәнсез. Син бит әле күз алдына да китерә алмыйсың: сезнең кебек кешеләргә мохтаҗлык бик зур хәзер.

Галимҗан аларны әле генә үзе килеп чыккан бүлмәгә алып керде. Монда да халык күп-күбен, ләкин коридордагы кебек үк мәхшәр түгел икән. Берәр тәрәзә төбенә җайлашып, рәхәтләнеп сайрашырга була. Мондый мөмкинлек чыгудан Мулланур хәтта каушап калды.

— Я инде, сөйләп җибәр. Син бит анда булгансыңдыр,— дип каядыр ашыккандай каударлана ук башлады.

— Башыннан ахырына кадәр булдым... Үз күзләрем белән күрдем...— дигән булып сөйләнсә дә, Галимҗан сүзне юри суза,— тегеләрнең тә-

катьсезләнүеннән бераз гына тәм табып тора кебек иде.
— Безне дә зарыктырма, үзең дә онытканчы сөйләп кал!— диде Мулланур.

— Онытырлык булдымыни ул, егетләр...— дип куйды Галимҗан.— Кичә иртәдән үк ниндидер киеренкелек сизелә иде. Нәкъ менә яшенле яңгыр якынлашкан төсле. Буржуаз гәзитләрнең барысы да: «Бөтен хакимият — Учредительное собраниегә!» дигән баш белән чыкты. Невский проспектында үткән-сүткәннең авызында бер сүз: «Ниһаять!.. Аллага шөкер!.. Советларны чәнчелдерәчәкләр! Большевикларның муенын борачаклар!..» Таврида сараена якын урамнарда төркем-төркем булып көяз егетләр таптанып торалар иде. Штатский тун ябынган офицерлар булса кирәк. Кулларында әлегә төреп куелган әләмнәр. Арада сирәк-мирәк кенә кызыллары да бар, тик күренеп тора: күбесе ак. Бу төркемнәр дә куанычтан тыпырдап торалар: «Советларга — кабер! Большевикларга — ясин!»— диешәләр.
— Ничек алар шулай тиктомалдан җанланып киттеләр соң? Һич аңламаем,— диде Шәриф.
— Нәрсәсен аңламыйсың?— дип йөзен чытты Ибраһимов.— Депутатлар арасында күпчелекне уң эсерлар алды бит... Болай булгач, большевиклар властена көн калмады, дип өметләнделәр... Бөтен хикмәт тә әнә шунда. Әле син аларның залда ничек пәйда булуларын күрсәң иде...
— Кемнәрнең?
— Шул, эсерларны әйтәм. Хуҗа булып, шау-гөр килеп керделәр. Уң якка җәелеп утырдылар. Алардан да уңдарак бер-ике бөртек кадет кына, ә сул кулда — меньшевиклар фракциясе урнашты. Арырак — сул эсерлар. Иң соңыннан большевиклар кереп утырды. Иң сул канатка. Күз алдына китерәсезме? Зал нәкъ дага кебек дугаланып килә, һәр партиянең күпме урын алуы бер күз ташлау белән күренә. Уч төбендәге кебек менә! Минем хәтта йөрәк дөп-дөп тибә башлады. Көчләр күрер күзгә үк тигез түгел. Хәзер башлана мин әйтәм... Менә уң яктан эсер Лордкипанидзе сикереп тә торды, Учредительное собраниене иң карт депутат ачсын, дип кычкырды.
— Кем була инде анысы?— дип бүлдерде Шәриф.
— Кем булсын — Швецов, әлбәттә. Уң эсер. Авыр гәүдәле, чал чәчле... Председатель урынына үрмәли дә башлады. И шуннан башланып китте... Сулдан аяк тибәләр: «Долой! Самозванец!»— диләр. Уң яктан: «Тимәгез! Сөйләсен!»— дип кычкыралар. Швецов өстәлдәге кыңгырауны әләктереп алды да шылтырата башлады. Карасам, ул арада баскычтан Яков Михайлович Свердлов күтәрелеп килә! Йөзе шундый тыныч, адымнары шундый нык,— әйтерсең лә, каршында мең бугазын киереп мәхшәр уйнавын сизми дә. Тиздән ул Швецов янына менеп җитте, тегене җилкәсе белән... менә шулай, тыныч кына этәреп куйды һәм... Их, туганнар! Андый көчле тавышны минем гомеремдә дә ишеткәнем юк иде! Нинди җиңел, какча гәүдәле, буйга да әллә ни озын түгел бит ул үзе,— һич тә алып батыр димәссең. Ә тавышы... Сур мөгезеннән чыгамыни! Бүтәнчә чагыштырып та булмый. «Эшче, солдат һәм крестьян депутатлары Советларының Үзәк Башкарма Комитеты Учредительное собраниене ачуны миңа тапшырды...»— диде ул сабыр гына. Зал шунда ук тынычланып калды...
— Эсерлар да тындымы?— диде Мулланур.
— Юк, бәгъзеләре әле тагын кайнап маташтылар. Тик берни дә майтара алмадылар. Свердлов баштагыча ук тыныч-саллы тавыш белән сүзен дәвам итеп, Учредительное собраниегә менә шундый декларация кабул итәргә тәкъдим кертте: Россия азат милләтләрнең ирекле берләшүе нигезендә төзелгән Советлар Җөмһүрияте дип игълан ителә... Җир алпавытлардан алынып крәстияннарга бирелә, банклар дәүләт кулына күчә, завод һәм фабрикаларда эшчеләр контроле кертелә... «Әгәр Учредительное собрание халык мәнфәгатьләрен дөрес чагылдырса, шушы декларациягә кушылыр,— диде Свердлов.— Учредительное собраниене ачык дип белдерәм һәм председатель сайларга тәкъдим итәм...»

Шәриф яңадан түземсезләнеп сорау бирде:
— Я, я, кемне рәис итеп сайладылар соң?— диде.
— Билгеле инде, залда янә зилзилә купты. Янә шул Лордкипанидзе чәчрәп чыкты. Рәислеккә Виктор Черновны сайлауны таләп итте.
— Черновны? Уң эсерлар башлыгын?..
— Шул үзе... Күпчелек тавышны да ул алды. Аннары, председатель мөнбәренә кунаклап, өч сәгать тоташ ләчтит сатты. Дөньядагы бөтен нәрсә турында сөйләгәндер мөгаен, әмма Яков Михайлович тәкъдим иткән декларация хакында ләм-мим сүз әйтмәде. Шуннан соң инде мәсьәлә кабыргасы белән куелды: Учредительное собрание хезмәт халкы өчен нәрсә дә булса эшләргә җыенамы? Совет власте декретларын кабул итәргә телиме? Андый теләк һич тә сизелмәгәч, большевиклар фракциясе Учредительное собраниене ташлап китүен белдерде. Большевиклар артыннан сул эсерлар кузгалды. Мин дә аларга иярдем.
— Син алайса азакка кадәр күрмәгәнсең инде?— диде Мулланур.
— Соңыннан ниләр булганын бер иптәшем сөйләде миңа. Юк, ул делегат түгел, кунаклар урындыгында утырган иде. Чын-чынлап тамашачы инде, шул «спектакль»не ахыргача карарга түземлеге җиткән.
— Шуннан ни булган соң?
— Яңадан сүз боткасы куерган. Төн уртасы җиткәнен дә сизмәгәннәр. Сәгать бер тулган, ике... дүрт... һаман сөйлиләр дә сөйлиләр икән... Менә бервакыт Черновның артында нииндидер матрос пәйда булган. «Каравыл арыды. Барыгызга да залны бушатырга киңәш итәм!»— дигән ул. «Сез кем соң әле?»— дигән Чернов. «Мин,— дигән матрос,— Таврида сараеның каравыл башы». Шуннан соң Чернов түшен киерә төшеп җавап биргән: «Учредительное собрание таралмаячак. Тәндә җан бар чагында!..»— дигән. Ләкин шулчак әкренләп утлар сүнә башлаган. Озакламый зал бөтенләй караңгылыкка чумган. Әле дөм караңгыда да Черновның тавышы тагын бераз ишетелеп торган...
— Шул төс аларга!— диде Мулланур.— Һәй, төкерик әле шуларга, ник искә төшереп торабыз тагын.
— Менә сиңа мә!— дип үпкәләгән булды Ибраһимов.— Ни тырышып мин сөйләгән булам боларга...
— Юк, Галимҗан. Сөйләвең өчен рәхмәттән гайре сүз юк! Син мине аңлап җиткермәдең бугай. Әле генә син сөйләгән хәлләр барысы да безнең революциянең кичәге көне... Әйт әле менә, син хәзер монда, Смольныйда нишләп йөрисең?
— Көрәштәшләр эзлим,— дип елмайды Галимҗан.
— Соң алай булгач, икесен таптым дип уйла инде!
— Шуңа күрә сезнең килүегезгә сөендем дә, Мулланур. Беләсеңме, кичә кич мөселман депутатлар группасы милли эшләр халык комиссары белән сөйләшкән иде. Иптәш Сталин әйтте, сезгә хәзер мәркәз мөселман учреждениесе оештыру турында уйларга кирәк, диде. Ә ул идеяне беләсезме, кем? — Ленин үзе биргән!..
— Ә син ни дип җавап кайтардың инде?
— Мин дүрт куллап риза дидем.
— Ә башкалар?
— Бөтен бәла да шунда шул... Башка мөселман депутатлар миңа кушылмадылар. Ык-мык итеп тордылар-тордылар да, турыдан-туры ярып салдылар: бәлшәвикләр кулында курчак буласыбыз килми, диделәр.
— Шулай булмыйни!— Мулланурның йөзенә мыскыллы елмаю чыкты.— Туктаровлар кулында курчак булу килешәрәк төшә аларга...
— Һәрхәлдә, кичә мин бер ялгызым гына идем. Бүген инде без өчәү...
— Хуш, инде нишләргә карар кылдың? Бу идеянең кайсы башыннан күтәрә башларга була соң?
— Мин болай уйлыйм. Иң элек безгә арабыздан бер кеше табарга кирәк. Бер кеше! Мөселман хезмәт ияләре бөтен күңелләре белән ыша-

нырлык, хәтта пәйгамбәргә табынган кебек табынырлык булсын ул. Без төзисе учреждениене әнә шундый чын абруйлы кеше генә житәкли алыр...

— Андый кешене табуы жиңел булмаячак шул,— диде Мулланур көрсенеп.

— Шулай ук дисеңме? Ә бит без монда тик ятмыйбыз... Без андый кешене таптык инде.

— Чынлапмы? Кем ул?

— Син.

Мулланур тәрәзә төбеннән үк сикереп төште.

— Шулай, Мулланур. Бу эшне башкарып чыга алырдай кеше син генә. Сиңа ышанырлар, сиңа иярерләр.

— Хак әйттең, Галимьян,— диде Шәриф.— Мин дә шулай уйлаем. Мондай зур эшнең башында Мулланур Вахитов торырга тиеш.

— Алайса мин чынлап та ялгышмаганмын икән.— Ибраһимовка кырыс, тәвәккәл төс керде.— Без хәзер моны ярты юлда калдырмыйк инде, туганнар. Изге эшне ашыктырырга кушканнар. Киттек!

— Кая?— диде Мулланур, аңышып житмичә.

— Ленин янына!

Йөрәгенең күкрәк читлегенә сыеша алмый тибүен тойды Мулланур. Югыйсә әле генә үзе Ленинны күрергә ашкынып килә иде бит. Инде хәзер, бу очрашуның чыннан да буласын белгәч, кинәт икеләнеп-каушап калды.

— Ярармы, килешерме соң?..

— Нинди килешмәү ди ул. Шунсыз һич мөмкин түгел,— диде Ибраһимов һәм алдан юл ярып үзе атлады.

Ак мәрмәр баскычтан алар икенче катка күтәрелделәр, шундый ук киң, якты коридор буйлап киттеләр. Монда кеше ул кадәр үк күп түгел икән. Тыз-быз килүчеләр дә күренми.

Әле дә булса алдан баручы Галимжан бер ишек каршында туктап калды, аның сырлап эшләнгән бакыр тоткасын җайлы гына борып, эчкә кереп тә китте. Мулланур белән Шәриф бу биек ак ишеккә җитеп, бераз сулу алырга да өлгермәделәр, Ибраһимов яңадан килеп чыкты, кулы белән алга әйдәүче ишарә ясады:

— Узыгыз!

Мулланур, керү белән, Ленинны күрергә теләп, як-ягына карап алды. Тик бу әле кабул итү бүлмәсе генә икән. Талчыккан кыяфәтле бер хатын машинкада нидер тукылдатып утыра. Икенче өстәл артыннан өстенә гимнастерка кигән яшь егет күтәрелде. Бүлмәдә тагын бер кеше бар иде. «Максимка»сы белән тәрәзә төбенә үк менеп кунаклаган. Ул ишектән керүчеләргә күз генә ташлап алды да яңадан үзенең пулемет көпшәсе караган якка — урамга таба борылды.

Эчке ишектән кереп югалган гимнастеркалы егет яңадан пәйда булды:

— Әйдәгез, иптәшләр, рәхим итегез. Владимир Ильич сезне көтә,— диде.

«Күңелгә килгән алга килә...— дип уйлап куйды Мулланур.— Бигрәк тиз булды. Нәкъ әкияттәге шикелле». Ул әле ничектер һаман Ленинның үзен күрми, колагына Ибраһимовның тавышы гына төштәге кебек тоныкбулып ишетелә:

— Владимир Ильич... Сезне Учредительное собрание депутатлары белән таныштырырга рөхсәт итегез. Иптәш Вахитов — Казан губернасыннан депутат. Иптәш Манатов — Оренбург губернасыннан...

Өстәл артында кызу-кызу гына нидер язып утыручы кеше башын күтәрде:

— Хәтерем ялгышмаса, мин бу иптәшләр белән инде таныш,— диде.

Мулланур аптырап калды. Иң әүвәл аны тавышыннан таныды. Аннары күзләреннән, йөзеннән, маңгаеннан... Бу бит шул үзе — ашханәдә бер өстәл янында утырган, бик җентекләп хәл-әхвәл сорашкан кеше! Менә хәзер кулын сузып күрешергә килә...

— Исәнмесез, иптәшләр! Сезне кабат күрүемә бик шатмын. Мин бит кисәткән идем сезне, хәтерлисезме. Һичшиксез күрешербез әле, дигән идем... Ничек әйткән әле ул сезгә: «Соңгардыгыз, әфәнделәрем!.. Кабарды да — шартлады!..»— дигәнме?— Ленин, Ибраһимовка таба борылып, аңлатып бирде.— Бүген аларны вокзалда бер матрос шулай каршылаган...

Мулланурның колагында: «Гүпчи соңга калдыгыз, әфәнделәрем! Юк хәзер сезнең Учредительное собраниегез...»— дигән сүзләр кабат яңгырагандай булды.

— Димәк ки, сез дә «Учредилка»ны тарату дөрес эш булган дип саныйсыз?— дип сүзен дәвам итте Ленин.

— Без әле генә нәкъ шул турыда сөйләшеп торган идек,— диде Шәриф.— Иптәш Вахитов ул хәлне, минемчә, бик дөрес бәяләп, бу — безнең революциянең кичәге көне, диде. Бүтән телгә дә алып торасы юк аны, диде.

— Һм... революциянең кичәге көне...— дип кабатлады Ленин.— Шулай, дөрес... Әмма тарихта мондый мисаллар да бик күп: кичәге көн еш кына бүгенге, хәтта әле иртәгәсе көн белән дә тоташкан була...

Ленин уйга бирелеп, тынып калды.

Мулланур белән Шәриф менә хәзер Владимир Ильич үз фикерен ачыклап бирер дип көттеләр. Тик Ленин әйтерсең лә сүзнең кайдан башланганын бөтенләй онытты.

— Карагыз әле, иптәш Вахитов... Менә сез Казаннан Питерга, Учредительное собраниегә дип чыгып киттегез. Сезне бит, мөгаен озатып калганнардыр инде? Фатиха биргәннәрдер?

— Шулай булмыйча,— диде Мулланур.— Ярты шәһәр җыелгандыр, шәт.

— Миңа калса, буржуйлар гына килмәгәндер бит инде сезне озатырга? Гади кешеләр дә булгандыр, мөгаен? Эшчеләр? Крестьяннар? Солдатлар?..

— Шулай булмыйча,— дип кабатлады Мулланур.

— Димәк, алар сезгә ышаналар? Өметләнәләр? Учредительное собрание депутаты буларак, сез аларның мәнфәгатьләрен кайгыртырсыз дип исәп тоталар? Шулай бит?

— Шулай дип уйлыйм, Владимир Ильич. Яхшыга үзгәрешләрне өмет итә халык. Бер бабай хәтта миңа юл күчтәнәче кыстырып килгән иде...

— Менә күрдегезме!— дип эләктереп алды Ленин.— Үз депутатының юлда ничек барасын да кайгырта халык. Һәм инде хәзер күз алдыгызга китерегез: сезне озатып калган әлеге кешеләргә кинәт кенә шундый хәбәр кайта... Учредительное собраниедән йоннар гына тузгып калган... «Кабарган да — шартлаган...» Бу хәлгә ничек карарлар алар? Уйладыгызмы шул хакта?

— Ни өчен шулай килеп чыкканын төшенерләр дип уйлыйм,— диде Мулланур һәм Ленинның үткен карашыннан акрын-акрын кызара барып:— Һәммәсе дә түгел, әлбәттә...— дип өстәде.

— Шул-шул!— диде Ленин, сул кулы белән кискен хәрәкәт ясап.— Менә мин дә шулай уйлыйм. Барысы да булмас... Әлбәттә, без башкача эшли алмый идек, башкача эшләргә хакыбыз юк иде. Әмма безнең фикердәшләребез, хәтта дусларыбыз да моны тиз генә аңлый алмаслар әле. Һәрхәлдә, шактый вакыт узар... Менә шуңа күрә, бу хакта бөтенләй онытырга кирәк дигәндә, сез бераз... кызыбрак киткәнсез шикелле, иптәш Вахитов.

Мулланур нәрсәдер аңлатырга, мин бит аның бүтән якларын күздә тотып әйттем, дип акланырга талпынган иде. Ләкин Ленин сүзне шунда ук башкага борып җибәрде.

— Берегез — Казаннан, икенчегез — Оренбургтан, дисез... Болай булгач, сез, иптәшләр, эчке Россия мөселманнарының төп өлеше яши торган өч губерна исеменнән эш итәсез икән ләбаса!

Ибраһимов бу сүзләрне раслагандай баш кагып куйды.

— Сез менә Питерга ук килеп җиткәнсез,— дип дәвам итте Ленин.—

Аңлавымча, иң беренче нәүбәттә сез хезмәт ияләренең мәнфәгатен кайгыртып йөрисез. Шулай түгелме?

— Шулай,— диде Мулланур.

— Беләсезме, без әле бүген генә шул хакта киңәшеп торган идек. Һәм шундый карарга килдек: мөселман хезмәт ияләренә кагылышлы эшләрне аларның үз вәкилләре алып барырга тиеш. Әлбәттә, Советлар платформасында торучы вәкилләре. Эчке Россиядәге бөтен мөселманнарның мәнфәгатьләренә туры килерлек бер үзәк оешма төзергә иде исәп. Сез ничек уйлыйсыз, ә?

— Без... Сезнең фикергә без тулысынча кушылабыз,— дип күз алдында кабынып-ялкынланып китте Мулланур.

— Хуш. Алайса тагын кайбер нәрсәләрне ачыклап бетерик,— диде Ленин.— Барыннан да бигрәк, буржуаз партияләрнең йогынтысы ничек икән сездә? Мөселман буржуазиясе, миңа калса, бу араларда шактый көчле позиция яулап алырга өлгергән булырга тиеш.

Ленин бу сорауны Манатовка төбәбрәк әйтте. Аның әлегә гел күләгәдәрәк тотырга тырышкан Оренбург делегатын да сынап карыйсы килә иде шикелле. Ләкин Шәриф: «Үзең әйт инде булмаса! Синең сүзең иплерәк килеп чыга бит...» дигән кебек, күзләрен мөлдерәтеп Мулланурга карады.

— Безнең якларда буржуйларның йогынтысы, чынлап та, әле́ аз түгел...— дип яңадан телгә килде Вахитов.— Хикмәт шунда... Алар хәзер адым саен революцион гыйбарәләр белән ялтырарга өйрәнеп киттеләр. Туктаров кебек җыен бушкуык «халык», «революция» дигән сүзләрне уңга-сулга сибеп, хезмәт ияләре өчен янган-көйгән булып кыланалар. Аяныч-ка каршы, кайберәүләр шуңа ышанып та куя... Ә бит алар нибары сәяси базардагы шомарып беткән маклерлар гына!

— Ничек, ничек? Политик базар маклерлары дидегезме?— Ленин рәхәтләнеп көлеп җибәрде.— Бик үткен характеристика бит бу!

Мондый хуплау сүзен ишетү Мулланурны дәртләндереп җибәрде, аның бөтен тәнен богаулап торган киеренкелек язылды, теле ачыла төште. Ул Казан буржуазиясе төзегән «Мөселманнар комитеты» дигән нәрсә һәм аңа каршы торучы демократик көчләр турында сөйли башлады. Мөселман социалистлар комитетының беренче көннәрдән үк пантюркистлар, панисламистлар ише үтә милләтчел хәрәкәтләрне фаш итүе, барлык мөселман хезмәт ияләренең бердәмлеге өчен көрәшүе хакында Ленинның үзенә сөйләү рәхәт иде аңа. Мулланур шулай ук Казанда эшчеләр клубы төзелүен, большевиклар партиясе Үзәк Комитеты белән хат-хәбәр алышып торуларын, Мөселман социалистлар комитеты (МСК) әгъзаларының татар крестьяннары корылтаенда чыгыш ясавын һәм «Кызыл байрак» газетасына нигез салуларын да әйтми кала алмады.

— Ә Шейнкман һәм Ольkeницкий иптәшләр ничек?— дип сорады Ленин.— Алар сезгә булыша алдылармы соң?

— Без һәрвакыт аларга таяна ала идек. Кайбер очракларда алар, иплe генә итеп, безнең хаталарны да төзәткәләделәр,— дип җавап бирде Вахитов.

Владимир Ильич исә сорау арты сорауны яудырды гына. Аның шулкадәр буталчык мәсьәләләрдә үзен иркен тотуы, һәр күренешнең асылын җиңел билгели алуы Мулланурны шаккатырды. Ленин шул арада Башкортстан турында да, Оренбургка кереп оялаган атаман Дутовның позициясе һәм Урал казакларының үз-үзләрен тотышы хакында да сорашырга өлгерде. Мулланурның Хәрби шура турында сөйләвен ул аеруча кызыксынып тыңлады шикелле.

— Хәрби шура ике яклы пәке кебек кылана,— диде Мулланур.— Болай, тыштан ул Совет властен таныган кыяфәт ясый. Ә асылда итәк астыннан ут йөртә,— мөселман хәрби частьлары Мөселманнар комитетына, ягъни мәсәлән, буржуазиягә һәм милләтчеләргә буйсынсын өчен ул барысын да эшли. Providing Бездә тагын кайбер мәгълүматлар бар... Хәрби шура хә-

зер яшертен рәвештә үз гаскәри берләшмәләрен төзи, алар исә иртәмесоңмы революциягә каршы күтәреләчәк. Шуңа күрә безнең Мөселман социалистлар комитеты Хәрби шураның астыртын эшчәнлеген фаш итү, монафикъльлыгын, дошманлыгын халыкка төшендерү максатын куйды.

Ленин бу сүзләрне хуплап башын иде һәм үзенең блокнотына тиз-тиз генә нидер сызгалап алды.

Башкорт милли хәрәкәте турында сүз чыккач, Шәриф агарынып китте. Монда, Петроградта, әлеге хәрәкәткә ничектер сагаеп, хәтта Советка каршы көч дип карыйлардыр шикелле тоелды аңа. Һәм оялчанлыгын да онытып, бәхәс уртасына ташланды:

— Бәлки сезгә кем дә булса башкорт хәрәкәтен контр дип күрсәтергә тырышкандыр... Ышанмагыз, иптәш Ленин! Алай дип провокатор гына әйтергә мөмкин! Чып-чын провокатор!.. Дөрес анысы, бездә башкорт автономиясен даулау хәрәкәте бик көчле. Тик шунысын да онытмаек: башкортның бит капиталистлары юк, татардагы кебек оешкан көч рәвешендәге эре буржуазиясе дә юк. Әгәр башкорт автономиясе Үзәк хакимият тарафыннан таныла икән, һич тә шикләнмәгез: башкортлар Советка каршы чыкмау гына түгел, үзләре Дутовка һәм Урал-Оренбург тирәләрендәге контрреволюциягә каршы төп көч булып әвереләчәкләр.

— Урыннардагы хәлне без шулайрактыр дип күз алдына китерә дә идек, иптәш Манатов,— диде Ленин.— Теләсә нинди милли хәрәкәтне бәяләүгә бик игътибар белән якын килергә кирәк. Без шундый фикердә торабыз. Һәм, әйтик, башкорт хәрәкәтен дә революциягә каршы юнәлгән дип уйламыйбыз. Һич юк! Ләкин шулай ук артык мавыгырга да ярамый. Җирле Советлар белән үзәктәге власть арасына чөй кагарга җай гына көтеп тора дошманнарыбыз. Моны һәрвакыт истә тотыйк.

— Аңлыйбыз, иптәш Ленин,— диде Шәриф.— Бу яктан безгә иң яхшы үрнәк — Казан Мөселман социалистлар комитеты.

— Инде сезнең комитетка килгәндә...— Ленин яңадан Муллануpга таба борылды.— Аңлавымча, ул — сәяси яктан шактый төрле агымнарны берләштергән массовый оешма. Мөселман хезмәт ияләренең аз гына өлешен булса да үз артыннан ияртә алган кешеләрне читкә тибәрә күрмәгез,— диде Владимир Ильич.— Большевиклар партиясенең төп тактик принцибын онытмагыз: безнең лозунгларның хаклыгына халык үз сәяси тәҗрибәсе аша ышанырга тиеш. Ә меньшевик һәм эсер әфәнделәр... Иртәме-соңмы, алар үзләренә суҗырларча ияреп киткән кешеләр алдында фаш булачаклар. Һәм тагын бер нәрсә: кайсыдыр мәсьәләләрдә безнең белән килешеп үк бетми торган һәр кешегә гомерлек дошман итеп карарга ашыкмагыз. Ялгыш юлдан китүчеләргә хаталарын аңлатырга кирәк. Аларны үз ягыбызга тартырга тырышыйк. Бары тик шулай гына — башкача һич тә мөмкин түгел. Сез мине аңлыйсызмы?

— Аңлашылды, иптәш Ленин,— дип баш какты Мулланур.— Яхшы киңәшегезгә рәхмәт.

— Я, ярый,— диде Ленин.— Димәк, Россиядә хәзер мөселманнарның үзәк учреждениесе булачак. Үзегезне аның беренче хезмәткәрләре дип санагыз. Өчегез дә! Эшкә тотыныгыз, иптәшләр!

Ленин урыныннан торды.

— Тирәгезгә үзегез таяна алырдай кешеләрне җыегыз, фикер алышыгыз, тәкъдимнәрегезне тиешенчә уйлап бетерегез һәм безгә хәбәр итегез.

— Без хәзер үк эшкә керешербез, Владимир Ильич,— диде Мулланур. Ленинның хушлашырга дип сузылган кулындагы ныклык аңа да күчте сыман.

Смольныйдан чыгу белән, Мулланур башын артка чөеп, тирән итеп сулыш алды. Хуш исле салкын һава тамак төпләрен көйдереп үтте. Сулышка иркен, аяк атлаулары рәхәт иде!

— Егетләр! Менә бу — кеше дисәң дә кеше!— дип хәйран калуын яшермичә әйтеп куйды Шәриф.— Ну баш үзендә! Бөтенесен ничек исендә тота икән ул, ә? Үзе шундый ихлас, шундый кече күңелле...

Ленин белән очрашу Мулланурны да нык әсәрләндерде. Моңа кадәр ул революция юлбашчысын гайре табигый, илаһи бер зат итеп күз алдына китерә иде. Ленинның үзен шулкадәр гади тотуы, кеше хәленә кереп сөйләшүе аны сөендерде дә, канатландырды да.

### 3

Беренче киңәшмәне өчәү уздырдылар.

— Я, нәрсәдән башлыйбыз?— диде Мулланур.

— Минемчә, ат кушудан!

— Юри әйтүеңме, Шәриф? Тотасың да, нәкъ менә иң соңгы, иң юк эшне беренче итеп куясың...

— Алай димә әле син...— Нигәдер уйга калып утырган Галимҗан Мулланурны сак кына бүлдерде.— Әүвәл — «бисмилла», ягъни исем белән башлана, дигәннәр бит... Бик күп нәрсә нинди исем кушудан да торачак.

— Ә миңа иң мөһиме — ат булсын, арба булсын,— җик тә бер сызгыр! Барганда сөйләмә, кайтканда сөйләрсең, дип тә әйтәләр... Маңгаена мөһер кирәк дисез икән, ярар соң, сезнеңчә булсын,— дип күнде Мулланур.

— Эш маңгайда түгел. Төгәл, дөрес исемгә бәйле булачак халыкның безне аңлау-аңламавы, безнең арттан бару-бармавы. Шуңа күрә исемдә без башлаган эшнең асылы, киләчәге күренергә тиеш.— диде Галимҗан.

— Килешәм дидем ич инде! Ышандырдыгыз! Бирелэм!— Мулланур елмаеп, ике кулын да өскә күтәрде.— Сездә нindiрәк фикерләр бар соң?

Шәриф инде бу хакта күпмедер уйланган иде, күрәсең, шунда ук үз тәкъдимен кертте:

— Мөселман эшләре буенча комитет!— диде.

— Комитет... Мөселман эшләре буенча комитет... Юк, барыбер нәрсәдер җитми кебек. Өе биек, өйрәсе сыек дигәндәйрәк килеп чыга. Нindiдер саллырак сүзләр кирәк. Ерактан ук, исемнән ук совет власте рухы бәреп торырга тиеш.

— Бәлки, мөселман эшләре буенча Шура дип...— Шәриф инде икеләнебрәк калган иде.

— Бу очракта, мөгаен, комиссариат сүзе кулайрак булыр,— диде Мулланур.— Революция исе килә шул сүздән. Бөтенрусия мөселман эшләре комиссариаты! Шәп яңгырый бит, егетләр, ә!

Үз тәкъдиме астарак калугамы, әллә башка нәрсәгәме хәтере калып, кинәт Шәриф чыгымчылый башлады.

— Бөтенрусия дигәнегезгә каршы килмәем. Әмма башкорт исеме кермәсә, мин разый түгел. Һич югы «Татар-башкорт комиссариаты» булырга тиеш,— дип, мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

Бу хәлне күреп, Мулланур да ярсып китте:

— Һәркем үз төбәгенә тарткалый башласа, безгә бергә эшләү мөмкин түгел дип саныйм. Зур эшне ваклау минем инануыма, максатыма каршы килә.

Ибраһимов, ирексездән, урталыкны табарга, килештерергә мәҗбүр иде.

— Бөтенрусия мөселманы бигүк дөрес булмас, Мулланур,— диде ул.— Безнең ул сүзгә хокукыбыз юк. Без Идел-Уралдан сайланган. Шулай ук «Татар-башкорт» та мәркәздәге оешманың колачын тарайтып кую булыр, Шәриф. Әгәр эчке Русия һәм Сибирия мөселман эшләре комиссариаты, яисә Мәркәз мөселман комиссариаты дисәк, уртак фикергә якынрак булмасмы?

— Мәркәз мөселман комиссариаты...— дип, һәр сүзнең тәмен татып карагандай, әкрен генә кабатлады Мулланур...— Ярыйсы гына ич бу. «Мө-

селман эшләре» дигән сүзнең «мөселман» булып кына калуы да мәгънәне көчәйтә.

Шәриф, әлбәттә, мондый компромисстан канәгать иде. Ләкин Мулланурның соңгы сүзләрендә тагын нииндидер өстенлеккә ирешергә омтылу күреп:

— Ягъни мәсәлән, ничек итеп көчәйтә инде ул?— дип куйды.

— «Мөселман» сүзе белән без аерым-аерым атап тормыйча гына берничә этник төркемне күздә тотабыз. Ә «Мөселман эшләре» дигәч, бу оешма үз тарафдарларын диненә, өмматенә карап берләштерә икән, дип уйларга мөмкин. Хәтта әле ниндидер дин эшләрен хәл итүче учреждение дип тә аңларга була... Безнең бит мәзһәб ул түгел. Без, революционерлар, гомумән, дин сөременнән азат кешеләр...

— Ә монда дин сөременең ниндәй катнашы бар?— дип кыза башлады Шәриф.— Мин һич тә алай уйламаем. Безнең Мәркәз комиссариатын дини оешма дип кем генә кабул итәр икән?! Ә инде адым саен «без — дингә каршы!» дип кычкыра башласак, бик күп намуслы кешеләрне тәгаен үзебездән читләштерәчәкбез.

— Ю-ук, эш аңа ук барып җитмәс,— диде Галимҗан.— Безнең олуг рәисебезнең исеме генә дә андый бәлаләрдән саклар.

— Моның белән ни әйтергә телисең?— диде Мулланур.

— Ничек инде! Мөселман комиссариатының башында Мулланур дигән могтәбәр вә изге исемле кеше утырганын белсә, мөэмин-мөселман агайлар берсен-берсе таптый-таптый безнең байраклар астына ыргылачак!

Өчесе дә рәхәтләнеп, күзләрдән яшь атылып чыкканчы көлештеләр.

Киңәш-уңаш итү әзсез калмады: комиссариатның эш планы инде беркадәр күз алдына килә башлады. Хәзер фикердәшләр, тарафдарлар, юлдашлар тупларга вакыт җитте. Хәтта ашыгырга, таралышып өлгергәнче, Учредительное собраниенең мөселман фракциясендәге зуррак йогынтылы кешеләр белән очрашып калырга кирәк иде.

Иң эре ике «кош»тан — Әлим Хәкимов белән Әхмәт Цаликовтан башларга булдылар. Мондый хәлдә хосусән Цаликов белән элемтәгә керү мөһим тоелды. Ник дигәндә, татар зыялылары арасында да аның сүзе ныграк үтәчәк. Аннары, әйтерең бармы: Әхмәт мирза хәзер — Бөтенрусия милли шурасының башкарма комитеты рәисе бит әле! Әлеге оешма Октябрьга кадәр ифрат абруйлы иде, әле дә, мөгаен, дилбегәне кулында шактый нык тотадыр. Бигрәк тә Русиянең эчке губерналарындагы таза тормышлы мөселманнар өчен һаман да икенче Мәккә төсле булып кала шикелле ул. Әгәр дә Цаликовны комиссариат эшенә тартып булса, асылда Милли шураның йогынтысы сәнәк белән суга язган кебек кенә калачак.

Әхмәт мирза янына Галимҗан барыр дип карар кылдылар. Мулланур исә Әлим Хәкимов белән очрашырга булды. Болай бүлешүнең әллә ни хикмәте юк иде. Мулланурның әлеге шул Хәкимовка бернчә тапкыр юлыкканы гына бар. Янә бервакыт тегесенең Мулланур язган бер мәкаләне бик хуплап чыгуы хәтердә. Ул мәкаләдә Туктаров һәм аның иярченнәрен утлы табага бастырган иде Мулланур. Дөресен әйтергә кирәк, Әлимне уң эсер Фуад Туктаров тарафдарларына ук кертеп булмый. Киресенчә, ул, җае чыккан саен, Туктаровка очып кунарга тора, хәтта аның тирәсенә җыелганнарга да татар буржуасының ялчылары дип мөһер суга иде.

«Дөньяда ниләр булмый,— дип уйлады Мулланур.— Бәлки, миңа да еланның тел ачкычларын табарга насыйптыр?!»

Әлим шәһәр читендәге бәләкәй генә мосафирханәдә яшәп ята иде. Мулланурның килүенә ул хәтта сөенгән кебек булды. Шатлыгы эченә сыймаган булып кылана гына идеме икән әллә Хәкимов? Төптәнрәк уйлаганда, вакыйгаларның нинди борылыш алуын истә тотканда, ул күбрәк тыштан ялтырый иде бугай. Ә бәлки, чынлап та, Мулланурны күрү белән эченә җы-

лы кергәндер? Аны үзенең каршына баш иеп килде дип уйлагандыр?

— Уз, кардәш! Утыр... Сине күрүемә бик шатмын!— дип тезеп китте Әлим.— Милләтебездән синең йөз чөермәсеңне беләдер идем, өмидләнәдер идем...

Хәкимов озын буйлы, күркәм кыяфәтле кеше иде. Кара көрәк сакалы аның кәкре борынлы зур чыраена төс бирә, хәтта мәһабәтлек өсти сыман. Ошбу һавалы, тәкәббер затның, әле күптән түгел генә үзен шәех итеп күрәсе килгән бер адәмнең фәкыйрь кунакханәдә, тыгыз, ямьсез бүлмәдә, көтелмәгән кунак алдында йөз суын түгүе, хәтта ялагайлана башлавы бик сәер иде.

Хуҗаның тел төбен әле төшенеп җитмәстән, Мулланур тәкъдим ителгән урындыкка килеп утырды.

— Һай, ничек ялгыштык, нинди коточкыч гафиллек күрсәттек без Мулланур әфәнде!— Хәкимов зур сәхнәдә басып торган кебек кулларын бутап, тавышын калтыратып кычкырды. Әйтерсең лә бер Мулланурга гына түгел, биек мөнбәрдән бөтен милләткә мөрәҗәгать итә иде ул.— Вәйля! Дәригъ!.. Күзләребез ачылды. Большевикларның изге ниятенә ышанып хаталандык без. Тик хәзер... Хәзер алар, хәсисләр, ниһаять, чын йөзләрен ачтылар!.. Учредительное собраниене вәхшиләрчә куып тарату... Инкыйлапка өмид баглаган гаммәнең бугазыннан алу... Халык моңа түзеп торырмы!..

«Юкка гына килдем, ахры»,— дип уйлады Мулланур, авыз читләре күбекләнә башлаган Хәкимовны күзәтеп. Шулай да сүзне үз җаена борырга тырышып карады.

— Туктале, Әлим,— диде ул, «оратор»ны бүлдереп.— Без синең белән халык җыенында түгел ләбаса. Сабыр гына сөйләшик әле...

— Дөрес әйтәсең, Мулланур әфәнде. Сүз белән бозау имезмик. Хәрәкәт итү лазем... Тик минем бөтен эчем-тышым яна. Шуңа гасабиланам.

— Миңа калса, хәзер килеп туган хәлне син бигүк дөрес бәяләмисең шикелле...

— Ничек? Бигүк... дөрес түгелмени? Монда ике төрле уйларга мөмкинме соң?.. Ә син... Син бу закон бозуны яклыйсыңмы? Түзеп тора алмаслык зобанилыкка разыймы син?

Мулланур бүленеп калган сүзен тыныч кына дәвам итте.

— Хәтерлисеңме... Былтыр декабрь аенда Казанда, крестьян депутатлары Советларының губерна съездында мин ничек әйткән идем? Учредительное собрание халыкның революцион казанышларын закон белән беркетергә тиеш, дигән идем түгелме? Исеңдәме шул?

— Исемдә булса ни...

— Кызганычка каршы, Учредительное собрание революцион халыкка иярмәде, аның теләкләрен искә алырга теләмәде.

— Сабыр ит, Мулланур, син миңа турысын әйт әле, син үзең Учредительное собраниене шушылай вәхшиләрчә куып таратуны хуп күрәсеңмени?

— Мин Петроградка алтысында гына килеп төштем. Ә буласы эшләр бишендә булып узган. Син аны үз күзләрең белән күргәнсең. Димәк, ни өчен шулай килеп чыгуын да миннән яхшырак беләсең. Свердлов тәкъдим иткән декларацияне кабул итүдән нишләп баш тарттыгыз? Солых турында, җир турында декретларны нигә расламадыгыз?

— Нинди декларация, нинди декрет ди ул! Ил тәхетен тартып алган бер төркем юлбасардан рәхим-шәфкать, имеш! Авыл ярлылары җирне закон тәртибендә алырга тиеш. Бу олуг мәсьәләне халык бары тик үзенең тулы вәкаләтле...

— Я, җитте, Әлим! Халыкның хәзер ни көткәнен син бик яхшы беләсең. Сугышка мөнәсәбәтен ул шактый ачык сиздерде: большевиклардан башка да, фронт, иске мендәр сүрүе кебек, үзеннән-үзе ертылып-сүтелеп

китте. Үзенең җиргә хокукын да халык шулай ук ачык белдерде: крестьяннар, сезнең закон чыгарганыгызны көтеп тормастан, алпавытлардан җирне тартып алдылар.

— Син шушы башбаштаклыкны мактыйсың! Миңа башбаштаклык идеяләре күтәреп килгәнсең!..

— Ашыкма,— диде Мулланур тавышын баса төшеп.— Мин сиңа бер тәкъдим белән килдем. Яңа гына төзелгән мөселман оешмасына керергә чакырам. Мөселман Мәркәз комиссариатына.

Әлимнең йөзеннән беленер-беленмәс кенә булып кызыксыну күләгәсе узды.

— Беренче тапкыр ишетәм! Кем төзегән аны?..

— Мөселман фракциясенең сул төркеме.

— Большевиклар кушуы буенчамыни? Нинди максат белән?

Мулланур кисеп җавап бирде:

— Социалистик революциянең иң якында торган бурычларын Совет хөкүмәте ярдәмендә хәл итү өчен.

— Юк!— дип буылып кычкырды Әлим.— Большевиклар кубызына биемәячәкмен! Сезнең Совет хөкүмәте дигән нәрсәгезне үлгәндә дә танымаячакмын. Юк!

— Алай булгач...— Мулланур урыныннан торды.— Безнең сөйләшер сүз беткән икән, Әлим әфәнде.

— Туктале,— диде Әлим, аның кулыннан тотып.— Сиңа, киткәнче, сүземне әйтеп калыйм. Исеңдәме, әле кайчан гына — аннан соң ярты ел да узмагандыр — большевиклар үзләре бугаз ерткан иделәр: янәсе, кичекмәстән Учредительное собраниене чакырырга! Янәсе, гомуми амнистия; стачкалар вә җыелышлар иреге! Нәкъ шулай эшләнде дә. Барысы да алар теләгәнчә булды. Учредительное собрание дә большевиклар таләп иткәнчә чакырылды. Соң эш нәрсәдә?! Ни өчен аны куып тараттылар? Ярты ел эчендә ни өчен аларның фикере үзгәрде?.. Әйтимме ни өчен икәнен?!— Әлим ярсыганнан-ярсый бара иде.— Бу вакыт эчендә большевиклар хакимиятне тартып алырга өлгерделәр. Менә хикмәт нәрсәдә! Алар инде дилбегәне кулга алдылар. Хәзер без аларга кирәк түгел. Хәзер безне үләт чокырына ташларга да була. Алар бездән башка да идарә итәләр.

— Ах, әнә сине нәрсә кытыклый икән,— диде Мулланур.— Дилбегәнең кулдан китүе борчый сине. Сез инде җирне үзегездән килеп сорарлар дип өметләнеп торгансыз, ә алай булып чыкмады... Җирне хәзер большевиклар бирәсе икән... Тик син, Әлим, әгәр дә чын революционер булсаң, эшнең асылына карар идең. Авыл ярлыларының җирне кем кулыннан алулары түгел, гомумән җирле-сулы булулары мөһим ич!

— Син... син сүзне алай борма!— Әлим бермәлгә каушап калды шикелле. Яңадан Мулланурның каршына ук килеп, күзләренә карады.— Турысын әйт: төтен җибәрәсеңме, әллә чын күңелеңнән сөйлисеңме?

— Күңелемдәгесен әйтәм, Әлим.

— Ярар, анысын тора-бара күрербез. Тормыш күрсәтер... Тик миңа шуны әйт әле: сезнең ул комиссариатның мәсләге нинди? Эше нидән гыйбарәт?

Әлим белән ботка пешмәсен Мулланур бая ук аңлаган иде инде. Шулай да тагын бер талпынып карарга булды, Шәриф һәм Галимҗан белән төзегән программаны кабат күз алдыннан кичерде.

— Русиядәге бөтен мөселманнарның хаҗәтләре хакында Совет властена хәбәр итеп тору...— дип санап китте Мулланур.— Совет властеның барлык чараларын, максатларын, идеяләрен мөселман халыкларына җиткерү, аңлату... Мөселман хезмәт ияләренең мәдәният һәм мәгърифәт ихтыяҗларын канәгатьләндерү... Төрле төбәкләрдә Совет власте белән мөселманнар арасында килеп чыгуы ихтимал булган һәртөрле аңлашылмаучылыкларны җайга салу...

— Ягъни мәсәлән, Советлардан башка бер адым да атламыйсыз булып

чыга? Советлар дилбегәне кайсы якка тартса — шул тарафка сәҗдә кылырга булып чыга?..

— Син яңадан дилбегә турында сөйли башладың, Әлим. Без син уйлаганча, кемнеңдер кубызына биючеләр түгел. Комиссариат Совет властеның тулы вәкаләтле үзәк оешмасы булачак.

— Аңлашыла! Бер сүз белән әйткәндә, син мине большевиклар тәртәсенә җигелергә кыстыйсың, Мулланур. Юк инде, дустым, барып чыкмас.— Әлим башын чайкап куйды.— Иман яңартучыларны син башка җирдән эзлә.

— Бәс шулай булгач, сүз көрәштереп, төче сүзләр сөйләшеп маташу нигә кирәк?— диде Мулланур.— Хуш иттек, Әлим. Бигайбә!

— Нишләп алай бик тиз бәхилләшәсең?— Әлимнең күзеннән усал очкыннар чәчрәде.— Без әле очрашырбыз дип уйлыйм. Хәзер без баррикаданың икебез ике ягында. Ә икесе ике якта булган кешеләр, иртәмесоңмы, очрашмый калмыйлар.

— Мин ул очракта да читкә тайпылмам.

— Андай очрашулар, гадәттә, кулга корал тоткан килеш була...— Әлим вәкарь белән генә кулын сузды. Ләкин Мулланур инде бусаганы атлап чыгарга өлгергән иде.

— Корал бездә дә табылыр, Хәкимов әфәнде!— диде ул артына да борылып карамыйча.

Әлим, саубуллашырга дип сузылган кулы белән нәрсәгәдер тотына алмый калгандай, чайкалып китте.



## 4

Үзенең шактый күңелсез визиты турында сөйләгәч, Мулланур дусларының хәл-әхвәлен сорашты.

— Минем дә мактанырлык эшем юк,— дип йөзен чытты Шәриф.— Ике козгын янында булдым. Авызларын күбекләндереп акыралар. Сатлык җаннар, дип безне сүгәләр. Берсе шундый бүртенде, күзләрен кан басты, шул мәлдә «үз чире» тота башлар дип курыктым...

— Галимҗан... Әллә синең дә юл уңмаган инде?— дип, борчылып, Ибраһимовның күзләренә карады Мулланур.

Яшерен-батырын түгел, Әхмәт Цаликов белән очрашуга азмы-күпме өмет багларга мөмкин иде әле. Бер яктан, Галимҗан бу мәсьәләләрдә тәҗрибәлерәк булуы белән иптәшләреннән аерылып тора: аңа элегрәк тә төрле дипломатик миссияләр башкарырга туры килгәләгән. Ә икенче яктан, Цаликов та, ни генә әйтмә, үзенең ишләре арасында бер ун башка югарырак тора.

— Цаликов мине әйбәт каршылады,— диде Галимҗан.— Итагать белән тыңлады. Бүлдермәде... Ә миңа турыдан-туры сорагач, безнең белән хезмәттәшлек итәсеңме дигәч, ни дип тә җавап бирмәде. Башта уйлыйм әле, аннары нинди карарга килүемне хәбәр итәрмен, диде.

— Минемчә, алай ук начар нәтиҗә түгел бит бу, егетләр!— дип шатлыгын йөзенә чыгарды Шәриф.— Ходайның кодрәте бик киң, кяферне әйләсә мөэмин... Ул карт алаша безнең тәртәгә дә җигелергә мөмкин, димәк!

— Әхмәт мирза кебек кешене үз ягыңа аудару җиңел булмас... Ләкин Хәкимов кебек лыгырдык һәм демагогларның дистәсен кулга ияләштерүгә караганда да мөһимрәк эш бу — дип уйчан гына әйтеп куйды Мулланур.— Тимерне кызуында сугарга кирәк... Янә бер сөйләшеп карыйк аның белән.

— Галимҗанны тагын җибәрәбезме?— диде Шәриф.

— Юк инде, туганнар,— дип кулын селтәде Галимҗан.— Бу юлы андый рәхәтне сезнең берәрегез татып карасын.

Мулланур Шәрифкә сынап карады:

— Бәлки, син барырсың?

— Минемчә, син барсаң әйбәтрәк булыр, Мулланур,— диде Шәриф ипле генә итеп.

Мулланур исәпкә калды. Галимҗан инде бу баруда дипломатик мөмкинлекләрен тулысынча сарыф итеп бетергән булса кирәк. Шәриф исә артык кискен, мавыгып китүчән, кызган чагында артыгын сөйләп ташларга да мөмкин. Әйе, башка чара юк — Цаликов янына ул үзе барырга тиеш...

Әхмәт мирза Исаакий соборыннан ерак түгел яшәүче чыбык очы бер кардәшендә тукталган иде. Ишекне ул үзе ачты, болын кебек иркен квартира буйлап кунакны алдан уздырып, бик кунакчыл төс белән иң әчке бүлмәләрнең берсенә алып керде.

Тирән кәнәфиләргә җайлап кына утырышкач, Әхмәт сүзне мөгезеннән алырга тырышты:

— Күңелем сизә, сез инде болай гына килмәгәнсез, юкны бушка авыштырып кына йөрмисез булса кирәк.

— Әйе, дөрес чамалап алдыгыз. Мин — кичә сезнең белән Учредительное собраниенең элеккеге депутаты Галимҗан Ибраһимов кузгаткан мәсьәлә уңаеннан...

— Һм... «элеккеге» дисезме?.. Бу бик төгәл билгеләмә дип әйтмәс идем. Дөрес, Учредительное собрание таратылды. Әмма, ни генә булса да, депутат депутат булып кала. Үзен сайлаган кешеләр кире чакырып алганга кадәр... Сез инде без фәкыйрегезне кичерегез, мәгәр мин үземне элеккеге депутат дип санамыйм.

— Сүзләр турында сүз куертмыйк әле.

— Ярар, бәхәсләшмик бу хакта. Хәтерем ялгышмаса, сез ниндидер комиссариат төзергә ниятләнәсез...

— Мәркәз мөселман комиссариаты.

— Шул, шул... Мәркәз... Үзәк... Бу инде Югары, яисә, әйтик, Баш комиссариат дигән мәгънәдә бит. Болай булгач, сез Рәсәйнең бөтен мөселман өммәте исеменнән хәрәкәт итәргә җыенасыз булып чыга. Шулай түгелмени? Ә, турысын әйткәндә, сезгә мондый вәкаләтне кем бирде?

— Совет власте,— дип тыныч кына җавап бирде Мулланур.

— «Власть, хакимият» — берәгәйле, көчле сүз. Әйтерең бармы... Хуш, сезгә вәкаләтне Совет хакимияте биргән. Ә халык кайда? Халыктан сорадыгызмы соң?

— Совет власте үзе үк халык власте инде ул. Совет власте Россия халыкларының иң асыл, иң мөһим мәнфәгатьләрен гәүдәләндерә.

— Ул мәнфәгатьләрне ничек яклый соң Совет хакимияте? Халык вәкилләренең законлы җыелышын куып тарату юлы беләнме?

— Әйдәгез, дөреслекнең күзенә карап сөйләшик,— диде Мулланур. Халык сугыштан туйган, тынычлыкта яшәргә тели иде — Совет власте аңа солых алып бирде. Авыл ярлылары җиргә мохтаҗ иде — Совет власте үзенең беренче көнендә үк Җир турында декрет кабул итте. Кайсы хакимнең, нинди хакимиятнең боларны эшләргә көченнән килде?

— Һм... Әйтерең бармы...— дип пошынып куйды Цаликов.

— Сез бит күреп торасыз, халык Ленинга иярде. Бу — хакыйкать. Ә хакыйкать белән исәпләшергә кирәк.— Мулланур хәзер һөҗүмгә күчте шикелле.— Россиянең сезгә иярмәве дә ап-ачык хакыйкать. Күзләрегезне ачыбрак карагыз!

Бу сүзләр Әхмәткә шактый нык тәэсир итте. Һәрхәлдә, ул бермәл телен тешләп уйга калды.

— Мулланур әфәнде,— дип, ниһаять, телгә килде ул.— Мине дә игътибар белән тыңлагыз әле һәм кул селтәмәскә тырышыгыз... Һәр адәм өчен иң олы бүләк, иң олы байлык — азатлык. Бу нәрсә аерым кешеләргә генә түгел, бөтен бер халыкка да кагыла. Зурмы ул халык, әллә кечкенәме, кешелек культурасының биек үрләрен яулаганмы, яки бу авыр юлда әле беренче адымнарын гына ясаганмы — анысы мөһим түгел. Һәр халык

үзенең язмышын үзе хәл итәргә, үз кануннары һәм гореф-гадәтләре буенча яшәргә хаклы, туган-үскән җирендә үзе хуҗа булырга хокуклы... Аның туфрагында чит-ят сүзләр, илбасарлар авазы ишетелмәскә, ул бары тик газиз туган теле бишегендә генә тирбәлергә тиеш...

— Без дә шуны телибез бит!— диде Мулланур.

— Кем соң ул «без»?

— Ленинчы большевиклар дигәнем. Безнең мәслэгебез нәкъ шул. Тулы азатлык, халыкларның тигез хокуклыгы һәм үзбилгеләнүе. Ленинның милли мәсьәләдәге төп фикере шундый.

— Әх, сез...— Әхмәт мирза авыр сулап куйды.— Сезгә әле бер иске солдат җырын ишетергә туры килгәне юктыр, күрәсең. Аны, Севастополь кампаниясе вакытында Лев Николаевич Толстой чыгарган җыр, диләр. «Гладко писано в бумаге, да забыли про овраги, а по ним ходить...» Бөтен бәла да шунда, Мулланур әфәнде, сезгә чокыр-чакыр өстеннән йөрергә туры киләчәк.

— Ярар, безне чокырлар белән куркытмагыз...— диде Мулланур, ярсуын басарга тырышып: Әхмәтбәкнең икеле-микеле сөйләшүләре аны туйдыра башлаган иде инде.— Сездән мин бер генә сорауга ачык җавап алырга теләр идем: безнең комиссариат эшендә катнашырга ризамы сез, әллә түгелме?

Цаликов тагын уйга чумды.

— Мин әлегә ни дип тә әйтә алмам сезгә,— диде ул, уйларыннан арына алмаган бер кыяфәттә.— Миңа барысын да исәпләргә кирәк. Нинди генә карарга килсәм дә, сезгә хәбәр итәрмен...

— Без көтәрбез.

«Мирза әгәр безнең белән эшләүдән баш тартса, шактый кызганыч булачак!»— дип уйлап куйды Мулланур.

Шулай да күңел сизә: мәсьәлә инде бик ачык хәл кылынган. Юллар кушылмаслык булып аерылган. Арада — үтеп чыга алмаслык упкын...

5

Владимир Ильич белән очрашу көнен Мулланур түземсезләнеп көтте. Бу арада ул көн саен төрле мөселман әһелләре белән уртак тел табарга тырышты. Нужа бабай башкалага кадәр үк куып китергән татар, башкорт, кыргыз йөргеннәре, тау халыклары вәкилләрен кабул итте. Һәркайсының гозерен, теләген игътибар белән тыңлады, язып куйды, кулдан килгәнчә булышырга вәгъдә итте.

Менә ул яңадан әлеге таныш кабинетта. Ике гади өстәл, бернichә урындык — бүлмәдәге бөтен җиһаз шуннан гыйбарәт. Владимир Ильич сүзне гадәтенчә тиз һәм эшлекле итеп алып бара. Бу юлы инде кабинетта якын танышлар, фикердәшләрнең очрашуы әллә каян күренеп тора.

Ленин тартмадан ниндидер кәгазь кисәге алып, аны өстәл өстеннән генә Мулланурга таба шудырды. Вахитов әлеге кәгазьне сак кына кулына алып, кычкырып укый башлады. Күз алдында сыек шәмәхә хәрефләр биеште, йөзенә шаулап кан йөгерде:

Милли эшләр буенча Халык комиссариаты каршында эчке Россия мөселман эшләре буенча Комиссариат оештырыла.

Мөселман эшләре буенча комиссар итеп — Казан губернасыннан элеккеге Учредительное собрание члены Мулланур Вахитов, аның иптәшләре итеп — Уфа губернасыннан элеккеге Учредительное собрание члены Галимҗан Ибраһимов һәм Оренбург губернасыннан Шәриф Манатов билгеләнә.

Халык Комиссарлары Советы Председателе
*Вл. Ульянов (Ленин)*
Милләтләр эше буенча Халык комиссары
*Джугашвили-Сталин...*

— Я, сезнең эшләр ничек бара, иптәш Вахитов?— дип сорады Ленин.— Мөселман фракциясенең калган членнары үзләрен ничек хис итә

анда? Сез алар белән очраштыгызмы инде? Яле-яле... Нәтиҗәсе булдымы соң? Сезнең белән бергә эшләргә ризамы алар?

— Кызганычка каршы, әлегә берни дә барып чыкмый, Владимир Ильич,— диде Мулланур.— Петроградта калганнарның һәркайсы белән диярлек сөйләшеп карадык. Берәүләре Совет властен танудан ачыктан-ачык баш тарта, икенчеләре җүләргә сабыша, өченчеләре ык-мык килә, икеләнә, ачык җавап бирми, суза.

Ленин кашын җыерды.

— Тагын нинди дә булса сораулар килеп чыкмадымы?— диде.

— Юк... Бары... ни...— дип башласа да, сүз таба алмый туктап калды Мулланур.

— Тыңлыйм сезне, иптәш Вахитов...— диде Владимир Ильич.

— Без әлегә кайда төпләнергә дә белмибез.

— Һич тә борчылмагыз. Бу хакта без уйлаштык. Бүген үк «Астория» кунакханәсенең комендантына минем исемнән күрсәтмә биреләчәк. Сезнең комиссариатка әлегә, эшне башлап җибәрү өчен, биш бүлмә җитеп торыр бит?

— Артыгы белән,— диде Мулланур.— Канцелярия, юлаучыларны кабул итү бүлмәсе... Минемчә, әле анда клубка да урын калачак!

## Икенче бүлек

### 1

Пайтәхеттә Мөселман комиссариаты төзелү турындагы хәбәрне Казанга Әлим Хәкимов алып кайтты.

Шул көнне үк Мөселманнар комитеты башлыклары ашыгыч киңәшмә җыйдылар. Яңалык турында фикер алышмак, бу вакыйгага мөнәсәбәтне билгеләмәк, хәзерге шартларда ничек эш итәргә икәнен хәл итмәк кирәк иде.

Вахитовны Петроградка озаткач, Мөселманнар комитетының эше бик җанланып китте. Җитәкчесез калган Мөселман социалистлар комитетының беркадәр сүлпәнләнүен күреп, милләтчеләр кыюрак һәм көчлерәк хәрәкәт итә башладылар. Хәрби шура ашык-пошык үзенең отрядларын тупларга кереште, мөселманнар хезмәт итүче барча гаскәри частьларга мөрәҗәгать-хитабнамәләр юллады. Уң газеталар көн саен шашынып большевикларны сүктеләр, Халык Комиссарлары Советы властен бәреп төшерергә һәм Украин радасы үрнәгендә милли татар дәүләте төзергә чакырдылар.

Вакыйгаларның шушындый төс алуы милләтчеләрнең күңелен үстереп җибәрде, уй-ниятләренең һичшиксез барып чыгасына ышанычны ныгытты. Үзәк власть, большевистик Комиссарлар Советы хакимияте, ни әйтсәң дә, руслар власте дигән сүз. Әгәр дә бу хәлне әһле исламның төп өлешенә төшендереп җиткерсәңме,— алар шунда ук Совет властеннан йөз чөереп, хас мөселман оешмаларының кочагына ташланачаклар! Мөселман комитеты белән хәрби шура тулы хакимиятне үз кулына алачак!

Менә шундый өметләр белән җылынып йөргәндә, Мәркәз мөселман комиссариаты төзелү хәбәре бөтен дөньяны чуалтып ташлады. Совет властe моның белән Россиядәге барлык халыкларның мәнфәгатьләрен үз канаты астына алырга омтылуын раслады.

Әлеге шартларда Үзәк комиссариат төзелү һәм өстәвенә аның башында Мулланур Вахитов торуы баш өчында бомба шартлавына тиң иде. Татар буржуаз партияләре юлбашчыларының, бу яңалыкны ишетү белән, тәһарәтләре бозылды.

Әлим Хәкимовның сөйләвен караңгы чырай белән тыңладылар. Яман хәбәр алып кайтуына үзен дә гаепле сыман хис иткән Әлим, мөселман

кардәшләренең рухы төшүдән курка иде ахрысы: сүзне бик хәтәр әтәчләнеп, бәддога укучы мулла кебек дәһшәтле тавыш белән башлады.

— Әлеге нәҗес төзегән оешма,— дип кычкырды Хәкимов,— безнең милли инкыйлапның йөрәгенә төбәлгән большевиклар коралы ул, башка һични дә түгел! Үз дәрәҗәсен белгән бер генә революционер да, бер генә демократ та шул шакшы арбага утырмас. Тиккә генәме алар, һәр сөяккә ташланучы ач этләр кебек, безнең ишекләрне шакып йөрделәр! Әмма ләкин без,— Әлимнең артык көчәнүдән тавышы өзелеп алды,— вәсвәсәгә бирелмәдек! Без аларны ишектән куып чыгардык, йөзләренә бәреп әйттек: «Сезнең белән уртак юлыбыз юк, һәм булмас та»,— дидек!

— Ә бу Комиссариатка безнең Бөтенрусия милли шурасы ничек карый?— дип сорап куйды кемдер.

— Мондый сөаль булырга мөмкинме?! Әлбәттә, ул да бу эшкә каршы!— Әлим түшен тагын да киерә төште.

Төрле яктан:

— Афәрин! Бәрәкалла... Анда шул чын мөселманнар утыра!— дигән тавышлар ишетелде.

— Әфәнделәр, минем сүзем төкәнде,— диде Хәкимов.— Инде сезне тыңлап карыйк. Ул дәһриләрнең көлен күккә очыру өчен нишләргә икәнлеген бергәләп уйлашыйк.

Ябык, тар йөзле, иртә пеләшләнә башлаган бер кеше — «Алтай» газетасының мөхәррире Баттал урыныннан кузгалды.

— Мөселман кардәшләр...— Мөхәррирнең тавышы йомшак, юмакай иде.— Без сезнең белән олы тарихи дәвердә яшибез. Нәкъ менә хәзер — бәлки, берничә гасыр алданрактыр да әле — безнең милли хәятебезнең асыл мәсьәләсе хәл кылына...

Батталның теле язылa, бугазы майдана барды. Елаграк тавышы торабара шапырынулы-дәртле төскә керде, аннары янә күңелләргә үтеп керерлек булып йомшарды, сабырланды.

— Яшәү яки үлем!— дип ярып салды ул.— Мәсьәлә мотлака шулай тора, әфәнделәр! Әгәр дә без хәзер урысларның басымына каршы тора алмасак, бүтән һичкайчан да, тәкрарлап әйтәм, һичкайчан да татар, башкорт, мишәр вә гайре мөселман халыклары милли бәйсезлекләрен яклап баш күтәрә алмаячаклар. Безнең изге бурычыбыз — көч җыю вә сабыр итү. Аннары, ходайдан әмер булгач, бер куәтле селтәнү белән, гасырлар буена килгән изүне әйләндереп каплау вә азат демократик мөселман дәүләте төзү!

Батталдан соң «Корылтай» гәзите мөхәррире сүз алды. Ул сүзгә бик бай түгел иде, ахрысы:

— Сатлык җаннар... Тәмуг кисәүләре... Милли мәнфәгатьләр... Әһле ислам юл куймас...— дию белән чикләнде.

Аннары бу мәҗлескә кайдандыр килеп эләккән кызыл чырайлы бер сәүдәгәр сикереп торды һәм:

— Мәлгунь Вахитов аркабызга пычак кадады!— дип, күзләре әйләнеп чыгардай хәлгә җитеп кычкырды.

Шуннан соң боз кузгалып китте... Тыелгысыз шау-шу эчендә аерым сүзләрне генә аралап ишетергә мөмкин иде:

— Хыянәт! Нәләт! Кяферләр! Казанда эзләре булмасын!..

Туйганчы бер шаулап алгач, агай-эне бердәм нәтиҗәгә килеп таралышты: Мәркәз мөселман комиссариатын танымаска, аның карарларын һәм декретларын аяк астына салырга!

## 2

Төн уртасында Әлим Хәкимовның тәрәзәсенә чирттеләр. Кемдер бөтен шартын китереп, алдан килешенгәнчә шакый иде. Шуңа күрә Әлим төнге кунакка ишекне һич икеләнүсез ачты...

Өстенә җылы кыска тун, шәп бүрек кигән нык бәдәнле, киң җилкәле ир-ат, бусагадан үтү белән, үзенең исемен әйтте:

— Әдһәм Дөлделевич.

Әлим аны үз кабинетына чакырды. Кара-каршы утырышкач:

— Сезне бик мактап тасвирладылар миңа, Әдһәм әфәнде,— диде.

Дөлделевич сүзсез генә башын иеп куйды.

— Бик ышанычлы, безнең изге яшел байракка бөтен ихласы белән бирелгән кеше дип тәкъдим иттеләр...

— Әһле исламның яшел әләменә баш иямен,— диде кунак.— Олы хөрмәтемне эш белән расларга әзермен. Үзем генә түгел, дусларым да шул фикердә.

— Ә сез кемне дусларыгыз дип атыйсыз? Әгәр сер булмаса, әлбәттә...

— Юк, сездән яшерен серем юк. Минем дусларым — анархист-индивидуалистлар федерациясеннән.

— Казанда күптән яшисезме, Әдһәм әфәнде?

— Күптән түгел дисәң дә була. Икенче яктан карасаң — бик күптән, борын-борыннан.

— Кичерегез, төшенеп җитмәдем ахрысы...

— Мин сезнең шәһәргә әле күптән түгел генә килеп чыктым. Ләкин Казан — минем пайтәхетем. Борынгы бабамнар шул изге туфрактан. Аларның токымы борында Төркиягә качкан, Кырым ханына бил бөккән, соңга табарак Литвага күчеп килгән...

— Алай икән... Кыскасы, сезнең ата-анагыз Литва татарлары булып чыга?

— Анысы шулай. Ләкин безгә эш турында да сөйләшергә вакыт түгел микән? Сезгә ни өчен кирәгем чыгуын беләсе иде бит.

Хәкимов урыныннан калкып, ишекле-түрле йөреп килде. Ниһаять, тәвәккәлләп, сүз башлады:

— Син ишеттең микән әле... Петроградта Мәркәз мөселман комиссариаты дигән нәрсә тернәкләнеп килә...— Хәкимовның капылт «син»гә күчүе ике мәгънәле иде. Беренчедән, үзенең Әдһәмнән өстенлеген сиздерәсе килде. Икенчедән, иптәшен үз итү, аңа ышану төсмерләре салган иде ул болай эндәшүгә.

— Беләм,— диде Дөлделевич.

— Кемнең баш комиссар итеп билгеләнүен дә беләсеңме?

— Мулланур Вахитов, диделәр.

— Син аның белән танышмы?

— Юк. Бер генә мәртәбә күреп калган идем.

— Кайчан?

— Гыйнвар башында. Вокзалда. Аны Петроградка озатканнарын күрдем.

— Ә-ә... Нотык сөйләгәнен дә тыңлагансыңдыр әле алайса?

— Ишеттем.

— Я, нindirәк тәэсир калдырган иде ул?

— Икеле-микеле.

Дөлделевич һаман, ярым-йорты гына җавап биреп утыра иде. Сүзен дәвам итмәсме дип бераз көткәч, Хәкимов, сабырсызлана төшеп, тагын сорау бирергә мәҗбүр булды:

— Ничек инде ул — «икеле-микеле»?

— Ну, аның сөйләгәне миңа кара халыкны үзенә каратырга тырышу, кызыл сүзләр, буш вәгъдәләр сибү булып күренде...

— Менә-ә! Шул-шул!— дип, Хәкимов бик канәгать төс белән авызын чәпелдәтеп куйды.

— Ә ул үзе мәсләгенә бик тугрылыклы зат булса кирәк. Һәм һичшиксез намуслы кешедер дип уйлыймын.

Бу сүзләрне Әлим колак яныннан гына уздырып җибәрергә тырышты. Бүлмә буйлап тагын бер ишекле-түрле үткәч, Дөлделевичның каршына ук килеп басты.

— Карале, Әдһәм... Синең Петроградта булгалаганың бармы?
— Юк шул, туры килмәде.
— Әгәр без сиңа шунда барырга тәкъдим итсәк... Ничек уйлыйсың?
— Белмим шул. Мин бит Казанга дип, махсус килгән идем...
— Шулай. Синең яшел байракка хезмәт итәсең килгән. Бабаңнар туфрагы тарткан. Ләкин, беләсеңме, хәзер безгә кирәкле ботка нәкъ менә анда, Петроградта пешә... Кыскасы, без, Мөселман комитеты җитәкчеләре, сине Петроградка җибәрергә карар кылдык.

— Нинди максат белән?
— Анысы, мөгаен, соңрак ачыкланыр. Эш барышында. Ә хәзергә, әгәр риза булсаң, юлга җыен. Анда баргач, яхшылап урнаш. Үзеңә дусиш тап... Башкалада рәхәтләнеп бер яшәп күрсәт әле!
— Андый рәхәт тормышта яшәрлек янчыгым юк минем.
— Акча турында уйлама. Дөньяда әле без барында...
Дөлделевич Әлимне баштанаяк күздән кичерде.
— Димәк, миңа барыбер нindидер бурыч йөкләнәчәк?
Әлимгә кунакның кабат-кабат бер сорауны бирүе ошамый иде. Бу юлы ул тагын:
— Ашыкма. Һәрнәрсәнең үз вакыты бар...— дип кенә җавап кайтарды.
— Ярар, анысын бүтән төпченмим. Тик минем бер генә шартым бар: сез кушасы эш минем шәхси карашларыма каршы килергә тиеш түгел. Минем шуңа алдан ук ышанасым килә.
— Дустым!..— дип төче елмайды Хәкимов,— синең максатларың изге! Бу юлда син үзеңә бездән дә якынрак торучы бүтән кешене таба алмаячаксың. Билләһи дип әйтәм, ышан миңа!
— Рас шулай икән, мин ризамын,— диде Дөлделевич.— Казан татарлары әйтмешли, биш куллап ризамын.
Икенче көнне үк ул юлга чыгып китте.
...«Татар бәлшәвигы — урыс башлы солдат ул. Аның башын фронтта чабып өзгәннәр дә, госпитальдә яңасын куйганда, урыс башы белән бутаганнар...»

...«Татарлар үзләренең мәнфәгатьләрен бәлшәвиклар хөкүмәте төзегән комиссариат хәл итүенә беркайчан да юл куймаячаклар!»— Әдһәмнең саквояж төбенә сыенган зур бер төргәк «Корылтай» газетасы әнә шулай дип, авызыннан ут чәчә-чәчә, Петроградка бара иде.

## Өченче бүлек

### 1

Мулланурның бүген караңгы чырай белән килүенә иң әүвәл Галия Ланина игътибар итте. Җайлап кына:
— Ни булды сиңа, Мулланур?— диде.— Сине күптән инде болай, балтаң суга төшкән кебек итеп, күргәнем юк иде...

Галияне комиссариатка сәркәтип итеп алганнар иде. Әмма ул гаҗәп булдыклы һәм эшчән кыз булып чыкты, үз вазифаларын үтәүгә җанытәне белән ябышып ятты. Шуңа күрә дә Ланина тиздән Мулланурның иң якын ярдәмчеләреннән берсенә әверелде.
Кызның тамырларында ике кан бергә кушылып кайный: әтисе — касыйм татары, әнисе исә марҗа иде. Ул үзе Петербургта дөньяга килгән, русчасын да, татарчасын да су урынына эчә, икесен дә туган теле итеп саный. Галия эшкә дә җиңел өйрәнде: бармаклары машинка төймәләре өстендә биеп кенә тора, караңгы төбәкләрдән килгән юлаучыларның әллә нинди буталчык һәм четерекле гозерен дә бик тиз һәм мәгънәле итеп, рәс-

ми кәгазьләргә төшерә белә. Җыеп кына әйткәндә, инде Галиядән башка Мулланур үзен ике кулсыз итеп тоя башлаган иде.

Алар арасында үзеннән-үзе гади һәм эчкерсез җепләр сузылды. Бу мөнәсәбәтләрнең нинди дә бүтән төс алу ихтималы Мулланурның башына да килми иде. Менә хәзер дә, кызның аны кулыннан алуы, «Ни булды, Мулланур?»— дип борчылып күзләренә каравы табигый бер якынлык билгесе, дусларча хәлгә керү булып кына тоелды.

— ...Эч серең булса, төпченүем түгел,— дип өстәде Галия.

— Юк, бернинди дә сер түгел,— диде Мулланур.— Бүген Смольныйда булган сөйләшү һаман күз алдыннан китми.

— Нинди сөйләшү соң ул?

— Ленин белән. Теге ике декрет уңаеннан.

Галия ул декретларның проектын машинкада үзе басты. Аларда сүзнең ни турында барганын да яхшы хәтерли. Казандагы мәшһүр Сөембикә манарасына һәм Оренбургтагы атаклы Кәрван-сарайга кагылышлы иде әлеге декретлар. Мөселман комиссариаты шушы ике тарихи ядкарьне үз хуҗаларына — татар-башкортларга тапшыру турында эш кузгатты.

— Ә Владимир Ильич нәрсә ди? Ул каршымыни?

— Юк ла. Нишләп алай булсын! Безнең карарны ул да бик хуп күрде. Тик... Шуның ише һәр мәсьәлә буенча Смольныйга йөгермәгез инде, дип әйтте. Сез үзегез Мәркәз комиссариаты, шулай булгач, мөселманнарга кагылышлы бөтен эшләрне үзегез хәл итәргә тиешсез, диде. Кулыгыздан тотып йөрткәнне көтмәгез, мөстәкыйльлеккә күнегергә вакыт, диде.

— Ә бит монда үпкәләрлек берни дә юк, Мулланур!— Галия, туктап, яулыгын кысыбрак бәйләде: хәзер алар Нева ярына килеп чыкканнар, елга ягыннан дымлы, салкын җил исә башлаган иде.— Соң үзең уйлап кара: ул хаклы түгелмени?

Мулланур башын артка чөеп, читкә карады:

— Син әллә миңа шелтә биргәннәр дә, шуңа авызын салган дип уйлыйсың инде...

— Шелтәме, түгелме, шулай да... Үзеңне бераз кыздырып алганнар, күрәсең. Серкәң су күтәрмәгән.

— Юк, барыбер аңламыйсың... Владимир Ильич мине, кыюсыз булганга, җаваплылык алудан курыкканга күрә, көн саен үзенә йөгереп килә дип уйлавы бар... Ә бит хикмәт куркуда түгел. Юк!

— Нәрсәдә соң хикмәт?

— Ничек инде шуңа да төшенмисең, ә! Менә, әйтик, декретка Ленин үзе кул куйсын да, син аңа буйсынмый кара! Ә безнең күрсәтмәләргә җирле властьларның колагы да селкенмәскә мөмкин. Безнең комиссариатның абруе әле ул дәрәҗәдә үк түгел.

— Син Ленинга шулай дип әйттеңме соң?

— Әйттем, билгеле.

— Ә ул?..

— Владимир Ильич: болай булса, дустым, сезнең беркайчан да үз абруегыз булмаячак,— әгәр сез гел-гел безнең аркага ышыкланып барсагыз, диде. Абруй юк икән, аны яулап алырга кирәк, диде. Сезнең сүзгә колак салуларына, сезгә буйсынуларына ирешегез, бу хәзер беренче нәүбәттәге бурычыгыз, диде.

— Бигрәк әйбәт сөйләшү булган ич!— Галия кулларын чәбәкләп куйды.— Үпкәләрлек тә, борчылырлык та сәбәп юк икән. Әйдә әле, Мулланур, син миңа шул Сөембикә манарасы турында сөйлә әле! Чынлап та бик матурмы соң ул? Нишләп аны Сөембикә манарасы дигәннәр? Мин бит ул турыда берни дә белмим диярлек.

— Китче, бер дә ишеткәнең юкмы?

— Әй, эти генә ничектер бераз сөйләгән иде... Имештер, Сөембикә атлы бер ханбикә булган. Үзенең яуда шәһит киткән егетенме, иренме яд итеп кызыл таштан манара төзеткән... Әкият кенәме соң ул, әллә чынлап та шулай булганмы — белмим.

— Иренең һәлак булуына Сөембикә ышанмаган, дип сөйлиләр. Ул үзе дөньяда бер гүзәл булган, ире үлгәч күпләр аны яучылап караганнар... Ләкин ул гомере буе үзенең беренче мәхәббәтенә тугрылыклы булып калган. Хатын-кыз горурлыгы, тән һәм җан сафлыгы, какшамас тугрылык төсе итеп, шушы манараны төзергә фәрман биргән.

— Матур риваять...— дип көрсенеп куйды Галия.

Беркавым тын гына атладылар. Һәркайсын үз уе биләде. Мулланурның күз алдында ерактагы якын күренешләр рәшә кебек яктырып китте: Казан манзарасы, Кремльнең ак пулатлары, Сөембикә манарасы... Ә Галия үзенең янәшәсендә атлаган ир-егеткә карата күңелендә җылылык арта баруын сөенеп һәм бераз шөбһәләнеп тә тоя, йөрәгенең күкрәк читлегендә сәер тыпырчынуына колак салып бара иде.

Кинәт кенә ул Мулланурга үпкәләп тә куйды: кара син аны, ниндидер уйларга чумып, янындагы кыз кешене бөтенләй оныткан түгелме соң ул? Иңе белән ялгыш кына кагылгандай итеп, Галия Мулланурның күзләренә карарга тырышты:

— Карале... Син... Сөембикә турында уйлыйсыңмы?..

## 2

Мулланур эшкә иртә килергә гадәтләнгән иде. Һәр көнне җиде тулар-тулмас ул инде кабинетында була. Иртәдән үк әле йомыш белән йөрүчеләр күренми, тынычлап бераз эшләп алырга мөмкин.

Ләкин бүген, үзенең иске язу өстәле артына утырып, кәгазьләрен җәеп салырга да өлгермәде, Галия килеп керде һәм:

— Сиңа кунак бар, Мулланур,— диде.

— Кайдан? Кем?

— Казаннан.

— Казаннан?!— Мулланур шунда ук, урыныннан сикереп торып, ишеккә ташланды.

Килүче кеше, чыннан да, Казаннан, Мулланурның күптәнге дусты Һади Маликов булып чыкты.

Һади белән алар үсмер чакта ук танышканнар иде. Исхак абзасы белән Мулланур Болгар хәрабәләрен карарга баргач. Шунда, ниндидер борынгы сарай җимерекләре каршында туктап торганда, көтмәгәндә ташлар арасыннан озын буйлы бер кара малай килеп чыкты.

— Әй! Син нишлисең анда?— дип сәерсенеп кычкырганын сизми дә калды Мулланур.

— Бабамнар эзеннән йөрим,— дип авызын ерды теге малай. Кулындагы чынаяк тышы кебек ялтыр-йолтыр килеп торган, бик нәфис бизәкләр төшерелгән кирпеч кисәген күрсәтте.

— Нинди бабаңнар?— дип тагын да гаҗәпләнә төште Мулланур.

— Ә бу сарай минем ерак бабам Хуҗа Маликныкы дип сөйлиләр. Б-ә-әк атаклы кеше булган. Гыйлем иясе. Ханның да первай дусты булган, имеш...

Бу йолкыш малай борчак сибә идеме, әллә чын күңелдән ышанып сөйлидерме... Әмма Мулланурның күңеленә хуш килде. Дуслашып киттеләр. Һади Болгарга якын гына бер авылдан икән. Шулхәтле серләре килеште малайларның,— мөгаен, бер-берсенә якынлыклары да очраклы гына булмагандыр. Сугыш башлангач кына аралар бераз өзелеп торды: Һадины солдатка алганнар иде. Революциядән соң яңабаштан табыштылар. Хатлар алыштылар. Һади Тәтешкә кайтып урнашкан булып чыкты. Октябрьдән соң, Мулланурның киңәше белән, Маликов Казанга күчеп килде, һәм алар бергәләп Мөселман социалистлар комитетында эшли башладылар.

Беренче очрашудан соң күпме сулар аккан! Килбәтсез, чандыр үсмер

егет урынына озын буй-сынлы, таза ир-ат басып тора. Йөзе җилдә киселгән, маңгаен тирән сыр аркылы бүлеп төшә. Терекөмеш кебек йөгерек, җете күзләрендә ниндидер яшерен сагыш посып тора кебек. Ләкин дусларның арасында үзгәрешсез, хәтта көчәя генә баручы бер сыйфат сакланып килә — алар элеккечә үк бер-берсен ярты сүздән аңлыйлар. Шуңа күрә күрешү, кыскача хәл-әхвәл сорашу белән үк, үзләре дә сизмәстән, икесе берьюлы төп мәсьәләгә күчтеләр.

— Гаеп итмә, Мулланур, мин сиңа яхшы хәбәрләр алып килә алмадым,— диде Һади.— Син киткәч, калын кесә, зур корсакларның йогынтысы күзгә күренеп көчәйде. Алкин, Туктаров, Баттал ишеләр, авызларыннан күбек аркылып чыкканчы, сине сүгәләр, һәр чатта сине русларга сатылган, халкыңа хыянәт иткән, дип сөрән салалар.

— Ул бәндәләрдән тагын ни көтәргә була?— дип, Мулланур җилкәсен җыерып куйды.— Шунысы гына үкенечле, гади халык арасында да аларга ышанучылар әле табыла торгандыр.

— Кайсыберләре ышана, билгеле. Шулай да күпчелек, минемчә, аларга иярми.

— Син миңа әйт әле, Казанда безнең комиссариатның бүлеге оештырыла микән? Ул хактагы карар сезгә барып ирештеме?

— Нинди карар?— дип аптырап калды Һади.— Минем ул турыда бөтенләй ишеткәнем юк.

Мулланур аңа бер кәгазь бите сузды. Маликов тиз-тиз генә күз йөртеп чыкты.

Мөселман эшчеләре, крестьяннары һәм солдатларын берләштерү мәнфәгатеннән чыгып, Советлар каршында эчке Россия мөселманнары Мәркәз комиссариатының бүлекчәләрен ачарга, аларда хезмәт, крестьяннар, хәрби һәм культура-агарту бүлекләре оештырырга тәкъдим ителә. Комиссариат бүлекчәләрен оештыру эшен сул революцион мөселман оешмаларына тапшырырга.

Советларның башкарма органнарына Мөселман комиссариаты бүлекчәләрен һич кичекмәстән оештыруда һәрьяклы ярдәм күрсәтергә тәкъдим ителә.

Милләтләр эше буенча халык комиссары
*И. Сталин*

Мөселман эшләре буенча комиссар
*Мулланур Вахитов.*

— Казанда бу документны чынлап та белмиләр микәнни?— диде Мулланур.

— Бер генә мөселман газетасында да күренмәде.

— Мин аны шулай булыр дип уйлаган да идем. Ах, ничек шыр җибәрәләр бу Батталлар да Алкиннар. Безнең көч туплаудан куркалар. Алар өчен көрәшнең оттырылган булуын сизенәләр.

— Алкин бөтен дөньяны сасытып кычкыра: комиссарларны — рус булса ни дә, үзебезнеке булса ни — мөселман халкы яшәгән урамнарга аяк бастырмыйм, ди.

— Ничек инде ул — «аяк бастырмый»?

— Көч белән, янәсе. Хәрби шурага буйсынган гаскәри частьлардан файдаланырга җыена,— диде Һади.

— Анысы без дә кул кушырып утырмабыз. Комиссариат Эшче-Крестьян Кызыл Армиясендә мөселман частьларын төзү эшенә керешеп килә инде. Бу турыда киңәшербез әле. Син миңа Казан яңалыкларын күбрәк сөйлә, Һади. Безнекеләр нишли анда? Казан большевикларының ни хәлләре бар? Шейнкманның кәефләре ничек?

— Шейнкманнан сиңа хат бар.

Һади гимнастерка кесәсеннән сургучлы конверт суырып алды.

Совдеп рәисе, Мәркәз мөселман комиссариаты төзелүен Казан большевиклары хуплап каршыладылар, кулдан килгәнчә булышлык итәргә әзер торалар, дип язган. Бу хаттан хәзерге вакытта каладагы һәм бөтен губернадагы хәлләр дә шактый ачык булып күз алдына килде. Ситуация

бик катлаулы, дошманнар аякка басарга азаплана — Шейнкман менә шул хакта хәбәр итәргә теләгән иде.

— Бөтен эшне ташларга да юлга чыгарга туры килә, ахрысы,— диде Мулланур, хатны укып чыккач.— Казанга кайтырга кирәк!

Казаннан соң Уфа, Оренбург, Пермьгә барып чыксаң да әйбәт булыр иде, дип уйлады ул. Аннары Кавказда, тау арасында яшәүче мөселман халыкларының хәлен үз күзләрең белән күреп, аларга үз кулларың белән ярдәм итсәң, әй!.. Гомумән, мөселманнар тереклек итә торган төбәкләр белән, халык белән комиссариат арасында даими элемтә булырга тиеш. Көндәлек эш тәҗрибәсеннән, хәзерге уйлануларыннан Вахитов әнә шундый сөземтәгә якынайганнан-якыная бара иде.

3

Дөлделевичның әрсезлеге җитәрлек булып чыкты: башкала туфрагына ул иплән кенә тамыр җибәрә алды. Кесәсе бик калын булмаса да, әлегә анда җилләр дә уйнамый,Петроградка килеп төшүгә, Мәскәү вокзалы тирәсендәге бер кечкенә генә мосафирханәдә очсызлы номер алды. Фәкыйрьрәк рестораннарда тамак туйдырып йөри башлады. Шәһәр белән танышты, кеше ни кыланса, шуны эшләргә тырышты.

Ул үзен эзләп табуларын һәм эш кушуларын көтеп яши иде.

Көннәр уза торды. Дөлделевичны эзләп килүче һаман күренмәде. Әдһәмнең болай түшәмгә төкереп ятудан эче поша башлады. Эш кирәк, эш! Аның бөтен табигате, терекөмеш кебек тыелгысыз хәрәкәттәге күзләре, төрле караңгы эшләрдә шактый шомарган куллары тәкатьсезләнеп эш сорый иде.

Кулына китап-газета алырга яратмаганлыктан, Әдһәм бөтен хәбәрне халыктан тыңлап йөрергә күнекте. Шулай да көннәрнең берендә, инде шактый йөри торгач үзләшеп беткән «Чулпан» ресторанында аңа «Правда» газетасын укыштырырга туры килде. Кемдер онытып калдырган газета битләрен иренеп кенә ачып караганда бер белдерү күзгә чалынды. Белдерү үзе түгел, аның астындагы имза кызыклы иде Дөлделевич өчен. «Комиссар Вахитов, Хәрби бүлек мөдире Ибраһимов», дип кул куйганнар бит.

«Вахитов... Шул үзе — Казанда күпме кызыксыну уяткан комиссар лабаса бу! Яле-яле, большевикләр гәзитендә комиссар Вахитов ниләр яза икән...»— дип уйланды Әдһәм.

Ашаган арада белдерүгә дә күз йөртеп чыккач, ул канәгать бер төс белән кикереп куйды. «Кара син, әй!— дип уйлады Дөлделевич. — Бик кызык килеп чыга бит әле! Мин аны Казанда күргәндә үк чамалап өлгергән идем. Еракка китәр бу, дигән идем... Әнә бит, хәзер Армия турында сүз йөртә башлаган. Армия — көч!.. Кемнең кулында армия — шуның кулында власть».

Тыелгысыз бер теләк биләп алды Әдһәмне. Аның хәзер үк газетада күрсәтелгән адрес буенча — Жуковский урамындагы 4 нче йортка барасы һәм, ике дә уйламыйча, мөселман Кызыл гаскәренә ирекле булып язылуасы килде. Бу акылы, бу елдамлыгы белән ул анда бик тиз үсеп китәр иде. Җайлы мәлне кулдан ычкындырмаска кирәк! Моннан да шәбрәк мөмкинлек килеп чыкмаячак. Нәкъ менә шундый вакытларда яшь, талантлы прапорщиклар генерал булып житешәләр. Ә аннары... Аннары — күз күрер! Бәхетең басса, беренче консул булып китүең дә бар...

Юк шул... Әлим аны бик ныклап кисәтте бит: бер эшкә дә тыгылмаска кушты. Караштырырга, чамаларга, өйрәнә торырга. Иң мөһиме — сабыр итәргә. Хуҗалардан элемтәче килгәнен сабырлык белән көтәргә.

Ул шайтан алгыры элемтәчене янә күпме көтәргә мөмкиндер!

Өстәвенә шәһәрдә төрле хәбәрләр тарала башлады. Имештер, немецлар һөҗүм итеп киләләр. Хәл кискен, куркыныч. Кызыл Армиянең ашыкпошык оештырылган часьтлары тар-мар ителгән, һәм бүген булмаса, иртәгә башкала дошман кулына калачак икән, дип сөйлиләр.

Петроградта яшәү көннән-көн авырлашты. Мосафирханәләрдә тентүләр ешайды. Дөлделевичка да элеккечә яшәү мөмкин булмый башлады. Аңа хәвефсезрәк урын эзләргә кирәк булып чыкты.

Уйлана торгач, Әдһәм әлеге дә баягы «Чулпан»га юл тотты. Иң беренче нәүбәттә Мөхәммәт өммәте берләштергән кешеләр арасында утыру алай ук куркыныч түгел иде. Дөрес, ул берсе белән дә юньләп аралашмады. Шайтаннан да арык, аксак һәм пеләш, өстәвенә аңгы-миңге бер карттан кала аның танышлары да юк иде бугай. Каршына килеп, бөтен ашынның тәмен җибәрүләре, бушка сыйланырга өметләнеп баш июләре — фу... Дөлделевичка, чынлап та, аны бернича мәртәбә өстәлдәге калдык-постык белән кунак иткәләргә туры килде.

Картның исеме Вәлиулла иде. Бүген дә ул, һәрвакыттагыча, үз постында булып чыкты. Ерактан ук Дөлделевичны күреп, бөтен шартын китереп билен бөкте. Аннары дәшкәнне дә көтеп тормыйча, җитез генә аның янына килеп утырды. Күзләренә керердәй булып бераз текәлеп торгач:

— Нишләп син бүген болай боек күренәсең, Әдһәм энем? Сырхаулап киттеңме әллә?— дип хәл-әхвәл сорашты.

— Юк, картлач, сау-сәламәтмен, — дип коры гына җавап бирде Дөлделевич. Бу мәгънәсез карт белән аның сөйләшәсе дә килми иде.

Аның каруы, тегесе, бәйләнчек эт кебек, әрсезләнә барды:

— Күреп торам, Әдһәм энем, йөрәгеңне ниндидер корт кимерә синең.

«Бу шайтанның тыгылмаган тишеге юктыр. Бәлки, әле миңа ярдәм итә алыр...»— дип уйлады Әдһәм. Шулай да үзе ваемсыз булып күренергә тырышып:

— Юк, вак-төяк мәшәкатьләр генә. Мосафирханәләрдә аунау туйдырды,— диде.— Ниндидер торыр җир табасы иде. Хәлдән килерлек хакка, билгеле... Сиңа сер итеп кенә әйтәмен инде, картлач, мин бит әлегә миллионер түгелмен.

Вәлиулла ялагай тавыш белән хихылдап куйды.

— И-и, күптән әйтәсең калган, энекәем,— диде карт, тагын да ачыла төшеп. — Теләсәң хәзер үк алып барам үзеңне...

Әдһәм бу хакта сүзне артык сузмыйча, табынга ашамлык һәм эчемлек китертте. «Зәмзәм суларын» күргәч карт шайтанның күзләре ялтырый башлады. Өченче чәркәдән соң гына яңадан әлеге мәсьәләләргә әйләнеп кайттылар.

— Минем бер әшнә кеше бар,— дип ерактан башлап китте Вәлиулла. — Ул Питерда, аллага шөкер, бик күптәннән яши.

— Аңлашыла,— диде Дөлделевич. — Фатирлы солдаткалар белән кавыштырадыр әле синең дустың. Өстенә бастыммы?

— Юксана,— дип йөзен чытты карт. — Ул монда гомер буе байларда дворник булып эшләде. Ә хәзер сугышта йөри.

— Алдылармыни?

— Алганнардырмы, үзе теләп киткәндерме,— анысы безнең эш түгел. Иң мөһиме — аның бүлмәсе буш.

Ә хуҗалары? Алар мине кертерләрме соң?

— Нинди хуҗа ди ул! Алар күптән качып киттеләр. Өйләре хәзер халык милкенә әверелде. — Вәлиулланың күзләрендә бер генә мизгелгә хәйләкәр очкын кабынып сүнде.

— Халык милке, дисеңме? Синдәге хәйлә, картлач, җитмеш кешегә җитәрлек бугай.

— Таныш түгел адәмне мин анда алып та бармас идем. Тик синең өчен, энекәем...

— Ярый,— дип баш какты Әдһәм.— Сине дә буш итмәм.

Вәлиулла табып биргән почмак алай зарланырлык булып чыкмады. Чиста, җыйнак бер бүлмә иде бу. Иң мөһиме бередә аны беркем дә эзләп тапмаячак, борчымаячак...

Шул күрешүдән соң Вәлиулла кинәт юкка чыкты. Бер атна узды, ике

атна... Җир йоттымыни — югалды картлач. Хәтта «Чулпан» ресторанының хуҗасыннан белешеп карарга да талпынган иде Әдһәм, ярый әле тыелып калды. «Энә түгел, югалмас, кемгә кирәк ул дивана»,— дип уйлады.

Чыннан да, сабыр иткән — түш ите җыйган булып чыкты. Янә берничә көннән Вәлиулла үзеннән-үзе табылды һәм берни дә булмагандай Әдһәмнең өстәле янына килеп утырды.

— Күптән күрешкән юк, энекәем! Яңа урында тереклек итүләре ничегрәк соң?— диде.

Аллага шөкер, картлач. Беркем дә комачау итми. Башым җылыда, астым корыда.

— Язылламы соң китабың?

— Языла.

Күптән инде, Вәлиулла белән беренче сөйләшкәндә үк бугай, Дөлделевич аңа үзен язучы дип таныткан иде.

— И-и, энекәем, синең башыңда әллә нинди уйлар бардыр әле. Мәскәүгә күчәргә уйлыйсыңдыр...

— Мәскәүгә? Нишлимен мин анда Мәскәүдә?— дип аптырады Әдһәм.

— Соң, әдип кешегә пайтәхетнең үзендә яшәргә кирәк ләбаса,— диде Вәлиулла һәм хәтта үз итеп күз кыскандай булды.

— Мин менә шуңа күрә башкалада яшим дә инде,— диде Дөлделевич, картның тел төбен аңыша алмыйча. Ә тегесе Әдһәмнең югалып калуыннан да бераз тәм таба иде шикелле.

— Юк, энем,— дип башын чайкады ул.— Петроград пайтәхет иде. Өченче көн. Ә кичәдән бирле безнең пайтәхет Мәскәү.

— Мәскәү? Ничек? Кем әйтте сиңа?— диде Дөлделевич.

— Кичә большевиклар хөкүмәте Мәскәүгә күчеп китте,— диде Вәлиулла. Йөзенә ахмак бер елмаю җәелде.— Гәҗит укырга кирәк, Әдһәм энекәем. Әдипләргә дә фарыз ул эш... Менә мин, пример, барысын да белеп торам. Хәтта сиңа Мәскәүгә китәргә кирәк икәнен дә...

Дөлделевич, кинәт сискәнеп, сагая төшеп, картның майлы күзләренә карады:

— Нишләп алай дисең син?

— Юк, анысын мин уйнап кына әйттем,— дип боргаланды Вәлиулла. — Сиңа монда ошый икән, яшә, рәхәтен күр, энекәем. Мин үзем, пример, китап язучы булсам, берсүзсез Мәскәүгә күчеп китәр идем. Ә син үзең белгәнчә эшлә. Син бит үзеңә үзең хуҗа... Хак әйтәмме?..

Бу сөйләшү Әдһәмнең колакларын торгызды. Кайтып, сәкегә сузылып яткач, Вәлиулланың сүзен берәмтекләп хәтереннән кичерде. Хикмәтле дивана булып чыкты әле бу. «Әллә соң кайчаннан бирле көткән элемтәче шул картлач үземе?»— дигән уй баш миен көйдереп үтте. «Ә бәлки шымчыдыр?» Кыскасы, алга таба Вәлиулла янында үзеңне уяурак тотарга кирәк иде.

Әдһәмнең уйлануларын бүлеп, ишек артында кемдер йөри башлады. Ул урыныннан сикереп торды. Бикләми калган ишектән өстенә шинель кигән озын буйлы агай килеп керде. Аның бер кулында солдат капчыгы, ә икенче кулын бинтка урап муенына аскан иде.

— Сезгә кем кирәк?— диде Дөлделевич кырыс кына.

— Миңамы?..— Көтелмәгән очрашудан аптырашка калып, ишек төбендә бераз таптанып алды карт солдат. Аннары:

— Мин инде менә... ни... өйгә кайткан идем,— дип уңайсызланып кына елмайды. Бу өйдә үзенең хуҗа икәнлеген әйтергә оялган кебек иде ул.

— Ә-ә...— дип, ниһаять, эшне аңлап алды Дөлделевич.— Син кайтның дамыни, агай? Мине монда синең дустың Вәлиулла кертте. Хуҗа югында күз-колак та булып торырсың, дигән иде. Мин вакытлыча гынамын...

— Ярый, баш ярылып, күз чыкмаган...— диде солдат, капчыгын идәнгә ташлап.— Монда икебезгә дә урын җитәрлек.

— Димәк, синең фронттан кайтып килеш? Яралаганнар да икән үзеңне. Ялга җибәрделәрме, әллә... бөтенләйгәме?

— Бөтенләйгә лә,— дип исән кулын селтәп куйды солдат.— Минем өчен сугыш бетте...

Дөлделевич фатир хуҗасы белән уртак телне бик тиз тапты. Чакырылмаган кунакның мөселман бәндәсе булуы Габдулла картның күңеленә бик хуш килде. Алар икәү сөйләшеп туя алмадылар. Фронт хәлләре дә, каладагы яңалыклар да — берсе дә калмады.

— Ә синең шөгыль нинди? Казна хезмәтендә түгелсеңдер бит?— дип сорады Габдулла.

— Юк, мөхәррирмен мин. Китап язамын.— Әдһәмгә хәзер бер үк әкияткә ябышудан бүтән хәл юк иде.— Ә син алга таба нишләргә уйлыйсың инде, агай? Калган гомереңне дә урам себереп үткәрмәссең ич.

— Менә иртәгә үк комиссарга барып карыйм әле. Киңәш-уңаш итәргә. Алга таба нишләргә икәнен, бәлки, ул әйтер?..

— Нинди комиссар ул?

— Монда бар шундый бер комиссар. Безнең мөселман егете. Ул мине белә.

— Мөселман комиссары, дисеңме? Мулланур Вахитовмы... әллә? — дип ычкындырганын сизми дә калды Әдһәм.

— Тач шул үзе! Син дә аның белән таныш ахрысы?

— Юк! Таныш түгел... Шулай да күп ишетергә туры килде аның турында. Вахитовны белмәгән җан иясе юктыр. Зур кеше бит!

— Дөрес әйтәсең: зур кеше!— дип җөпләде Габдулла. — Башлы кеше, гадел кеше, мин сиңайтим.

— Син соң кайдан беләсең аны?

Вахитов белән беренче очрашуы, аның ярдәме тиюе хакында бөтен бер тарих сөйләп бирде карт.

Ул гомере буе Петроградның бер татар баена бил бөккән. Ләкин көннәрнең берендә байгура, юк гаепне бар итеп, Габдулланы урамга куып чыгарган. «Картаеп килгән көнемдә оясыз, эшсез, бер кабым ризыксыз калдым, инде кая барырмын?!» — дип, боз каткан тротуарда хәер теләнеп утырырга гына калганда, ходайның хикмәте, аңа әнә шул мөселман комиссары килеп юлыккан. Байның өенә үк барып, аны Совет власте исеменнән бик каты кисәткән. Шул хәлдән соң бай әфәнде, үзе каядыр олагасы көненә кадәр, Габдуллага авыз ачып сүз әйтергә шүрләгән...

— Синең ул комиссарың, агай, чынлап та, Хозер Ильяска охшаган,— диде Әдһәм. — Әүлия җан, хак мөселман бәндәсе икән. Миңа да ничектер аның белән күрешәсе, киңәшәсе иде. Насыйп булыр микән?

— Алайса, әйдәме, икәү бергә барабыз! — дип канатланып китте карт. — Иншалла, сиңа да булышмый калмас ул. Эш бирер. Мөхәррир дә булгач, укымышлы бала икәнсең бит. Укымышлы кешеләр хәзер кайда да кирәкле!

Икенче көнне алар икәү, җитәкләшеп дигәндәй, Жуковский урамына — Мәркәз мөселман комиссариатына юл тоттылар.

— Комиссар мине орышыр инде,— дип хафаланып барды Габдулла. — «Әй, бабай, бабай! Ничек инде пуля астына кердең? — дияр. — Дошманнарны куандырып, яу кырын ташлап кайткансың»,— дияр.

Дөлделевич аны тынычландырырга тырышты:

— Юкка борчылма әле син, агай,— диде.— Орышмас ул сине. Һәммәсе дә ходай кулында бит, кемгә шәһит китәргә дә, кемгә яраланырга... Ә кемдер хәтта тырналмыйча да кайта сугыштан...

Бик иртә булгангамы, комиссариат урнашкан йорт әле тирән тынлыкка чумган иде. Ерактан ук күреп килделәр: шакылдавык кочаклап баскыч

төбендә утырган карт каравылчының йокы килүдән башы сыгылып-сыгылып төшә. Шулай да уяулыгын югалтмаган икән. Ишек бавына үрелүгә, йокылы күзләрен әйләндереп, Габдуллага кычкырып җибәрде:

— Һәй, син кая?! Кая барасың дим, агайне!

— Мулланур Вахитов янына,— диде Габдулла һәм, бераз гына һавалана төшеп, өстәде:— Комиссар мине яхшы белә. Бар тиз генә әйт әле, сине анда Габдулла Әхмәтов сорый, диген.

— Юк бит... Юк монда синең комиссарың,— диде каравылчы, урыныннан кымшанмыйча да.

— Кайда соң ул?

Мәскәүгә китте.

— Озаккамы?

— Әй, агайне...— диде каравылчы. — Син бу заманнан артта калгансың бит. Бөтенләйгә китте ул Мәскәүгә. Комиссариаты да яңа башкалага күчте.

— Хөкүмәт белән бергәме? — дип сорады Дөлделевич.

— Шулай булмыйни... Комиссариат бит ул... хөкүмәткә карый! — диде карт һәм, бик белдекле кыяфәткә кереп, шакылдавыгын сыйпап куйды.



### 4

Һади Маликов тиз арада Мулланурның алыштыргысыз ярдәмчесенә, аның уң кулына әверелде. Вахитов аны, уенын-чынын бергә кушып, үзенең штаб начальнигы дип йөртә иде.

Мәркәз мөселман комиссариаты Мәскәүгә күчеп киткәндә, Һадига әле Петроградта калып торырга туры килде. Комиссариат файдаланып торган җиһазларны тапшырасы бар иде аның. Моннан тыш егеткә тагын да мөһимрәк бер бурыч йөкләнде: ул бөтен эш кәгазьләрен, архивны аралау һәм Мәскәүгә җибәрту хәстәрен күрергә тиеш иде. Комиссариат әле ныклап торып эшкә керешергә дә өлгермәде кебек, ә шактый биек кәгазь тавы өелгән икән. Бу тауны актарып чыкканчы атна-ун көн вакыт үтеп китте. Ярый әле, акылы җитеп, Мулланурдан Галияне ярдәмгә сорап калган, юкса өч атна эчендә дә очына чыгасы түгел иде. Хәзер менә җиңел сулыш алырга була: яндырасы кәгазьләр яндырылган, папкаларга тегеләсе тегелеп, әрҗәләргә тутырылган. Бүген Һади белән Галиянең, әрҗәләрне пичәтләп вокзалга җибәрү өчен, элеккеге комиссариат бинасына соңгы тапкыр килүләре иде.

Таныш йортка якынлашып килгәндә, каравылчы карт белән гәпләшеп торучы ике кешене алар еррактан ук күреп алдылар. Икәүнең берсе — солдат шинелендәгесе — озын, чандыр, бер кулын бәйләп муенына аскан, ә икенчесе гәүдәгә таза, яхшы киенгән, үзе шактый яшь күренә иде.

Һади: «Кемнәр булыр бу? Нишләп йөриләр?»— дип уйлап өлгермәде, солдат шинеле кигәне Галияне танып алды ахрысы, якын туганын күргәндәй яктырып, аңа каршы атлады:

— Чибәрем, уңмадык бит без... Комиссарны эзләп килгән идек, ә ул китеп өлгергән икән!— дип, тезеп китте.

Галия дә картны чамалап алды.

— Әбәү, Габдулла бабай, син түгелме соң бу? Урамда очраткан булсам — танымый үтәр идем. Бөтенләй яшәреп киткәнсең... Ни булды сиңа? Яраландың мәллә?

Картны һәм аның юлдашын (ягъни Әдһәмне) үзенең башлыгы белән таныштырды Галия. Дүртесе дә эчкә — Маликов кабинетына уздылар.

— Вахитовны күрәсем килгән иде. Син фатиха биргән мөселман солдатлары арыслан кебек сугышалар, димәкче идем... — Мулланурның китүенә әле дә булса ышанмагандай, әнә шулай, үз алдына сөйләнеп торды Габдулла карт.

— Озакламый мин дә Мәскәүгә китәм, бабай, Вахитовка синнән сәлам тапшырырмын,— диде Һади. — Минә бу «байлык»тан гына тизрәк котыласы бар,— дип итек очы белән әрҗәгә төртте.

— Нинди байлык соң монда? — дип сак кына сорап куйды Әдһәм.

— Безнең архив ла бу. Мәскәүгә җибәрәсе күчтәнәч.

Дөлделевич бер әрҗәне күтәреп карамакчы итте.

— Һо-һо! Саллы күчтәнәч икән бу. Ялгызың гына кузгатырлык та түгел.

— Кая ул! Ялгыз кеше бернишли алмый. Юлчыга янчык та авыр диләр. Комендатурадан бер гвардеец сорарга уйлап торам. Сак та кирәк бит әле. Ни әйтсәң дә, архив кадәр архив!

— Һәй! — диде Габдулла. — Комендатура дисеңме? Нәрсәгә кирәге бар аның? Ә мин кемнән ким сиңа? Мин дә бит гвардеец. Уң кулым, аллага шөкер, дага бөгәрлек егәре бар.

— Сине нужалыйммы соң, бабай! — дип башын чайкады Маликов.— Сугыштан кайткансың гына әле, әйдә, ял ит инде син. Аннары бу эш — уен-муен түгел, кәҗә майларын чыгара торган...

— Гафил сүз сөйләп торма! — диде карт, үпкәләгән төсле итеп. — Миңа монда барыбер ялгызым каңгырып йөрисе. Теләсәң генә ни әйт, хәзер синнән калды юк. Мәскәүгә барам, комиссар янына.

— Карагыз әле, чынлап та,— дип сүзгә кушылды Дөлделевич. — Нишләп сезгә әллә кайдан сакчы эзләп йөрергә? Габдулла агай — ышанмастай кеше түгел. Әле мин дә Мәскәүгә барырга җыенам. Бергәбергә юл җиңелрәк булыр.

Тагын бераз сатулашып торса да, Һадига бу тәкъдим ошады.

## 5

Алар икенче көнне иртәнге поезд белән юлга чыктылар.

Габдулла картның күңеленә бик хуш килгән иде Маликов. Ул аңа юл буе үзенең сугышта күргәннәрен сөйләп барды. Дөлделевич исә, шуннан файдаланып, кызның күңеленә ачкыч табарга, аны үзенә каратырга тырышты.

Монда инде тозсыз әкият белән генә ерып чыгармын дип уйлама: хатын-кыз күңеле очы-очка ялганмаган нәрсәләрне тиз сизүчән була. Шуңа күрә Дөлделевич үзе турында чынбарлыкка бик тартым хикәят уйлап чыгарды: аның чиреге саф дөреслектән гыйбарәт булса, калган өлеше, әлбәттә, чеп-чи ялган иде.

Дөлделевичның сүзгә осталыгы ярап куйды. Кыз аны авыз ачып тыңлый иде.

— Тумышым белән мин Литва татарларыннан,— дип сөйләнде Әдһәм. — Бабаларымның сөяге Кырым туфрагында күмелеп калган... Туфрак тарта, кан тарта, Галия туташ! Ниһаять, минем халкым шундый түбәнсетүләрдән соң мәңгелек йокысыннан уянды! — Дөлделевич үз сөйләгәненә үзе ышана барып, тагын да ялкынлы, канатлана төшкән иде. — Азат мөселман җөмһүрияте... Пайтәхете — Казан... Иманым камил: ул көн килде! Менә шунлыктан мин большевиклар ягына чыктым. Изелгән халыкларга хөррият вәгъдә итүче бердәнбер фирка — большевиклар!

— Ә сез, Казанны башкала булыр дип, кайдан чыгып әйтәсез? — диде Галия, матур күзләрен куе керфекләре белән яшереп.

— Казан — бик борынгы бөек кала, бөтен мөселманнарның икенче мәккәсе. Бу изге хәрәкәтнең башында Казан кешесенең торуы да юкка гына түгел.

Әдһәмнең соңгы сүзләрен кыз аңышып өлгермәде:

— Сез кем турында сөйлисез? — дип бүлдерде.

— Мулланур Вахитов хакында, әлбәттә! Бөтен Казан хәзер комиссар Вахитов рухы белән яши. Ул гаҗәеп кеше булырга тиеш, Галия туташ!

Синең күптәнге хыялың ни дисәгез,— аның белән танышу, мөмкин булса — аның кул астында эшләү, дияр идем.

Дөлделевичның бөтен кыяфәтенә ашкыну, рухлану төсе чыккан: халкына кайнар мәхәббәт утыннан менә-менә дөрләп китәр иде ул. Ә аның Вахитов турында шулкадәр хозурланып сөйләве — әле дә булса Галиянең күңелен биләп торган яктылыкны ишәйтүе!..

Кыз шул мәлдән башлап бөтен күңеле белән Әдһәмгә таба борылган, аңа тартыла башлаган иде. Әлбәттә, бу ихлас күңелле, кайнар йөрәкле кешене Мулланур да аңласын һәм яратсын өчен ул барысын да эшләячәк!



## Дүртенче бүлек

### 1

Мәскәү Мулланурны кояшлы зәңгәр күге белән ачылып каршылады. Анда-санда җыелган сулар ялтырап ята, бөтен тирә-юньнән яз исе бөркелә!.. Әлегә монда барысы да ят, үзгә, Петроградтагыга охшамаган. Шалтыр-шолтыр килеп йөргән трамвайлар гына да бөтенләй башка төс биреп тора.

Мәскәүдә Мәркәз мөселман комиссариаты, биш бүлмәгә генә сыймыйча, Кремльдән әллә ни ерак булмаган аерым бер бинага урнашты. Ике катлы йортның өстендә өченче кат дип санарлык шәп кенә чардагы да бар иде.

Елга аръягындагы әлеге особняк үз дәверендә шактый күпне күргән булса кирәк. Революциягә кадәр ул Солодовников дигән купецның йорты булган, ә тагын да элегрәк анда мәшһүр композитор Алябьев яшәгән, диләр. Һәм менә, дөньялар үзгәреп киткәч, язмыш бу йортны бөтен Рәсәй мөселманнарының революцион кыйбласына әверелдерде.

Йортның иркен подвалы типографиягә бик җайлы урын булып чыкты. Беренче кат төрле кабинетларга бүленде. Икенче катта да берничә кабинет урын алды. Ә калган бүлмәләрне торак иттеләр, Вахитовның үз кабинеты икенче катта иде; аннан Кремльгә турыдан-туры телефон элемтәсе сузылды.

Мәскәүдә Мулланурга эш арта төште. Комиссариат ярдәменә өмет баглаучылар һәм аның җитәкчелегендә башланган чаралар күбәйде. Шундый бик мөһим эшләрнең бер юнәлеше, мәсәлән, мөселман мәктәпләре төзүдән гыйбарәт иде. Революциягә кадәр мөселман халыкларында белем алу белән дин сабагы үзләштерү икесе бер нәрсә дип карау гадәти хәл булып килде. Совет властеның мәктәпне мәчеттән аеру турындагы декретына да карамастан, күнегелгән тәртипләр әллә ни үзгәрмәде.

Мулланур менә шул хакта уйланып, яңа мөселман мәктәпләре турында декрет караламасын язып утыра иде — ишек шакыдылар.

— Әйдә, керегез,— диде ул, кәгазьдән башын күтәреп.

Ишек шәрран ачылып китте дә, кабинетка өермә кебек бөтерелеп Һади Маликов килеп керде. Аның артыннан тагын нindидер таныш йөз күренде. Менә сиңа мә!.. Петроградтан сугышка киткән бабай! Нинди җилләр ташлаган аны монда?!

— Габдулла бабай! Һади!

Мулланур, урыныннан сикереп торып, аларның икесен бергә кочаклап алды.

### 2

Казаннан Ольленицкий килеп төште. Башкалада эшләре муеннан булса да, иң әүвәл Мөселман комиссариатына, Вахитов янына китте.

Тәрәзәдән карап торганда, кинәт аның таныш гәүдәсен күргәч, Мулланурның йөрәге кысылып куйды. Шатлык та, шөбһәләнү дә билән алды аны. Үзен-үзе тыя алмыйча, икенче каттан Ольlevницкийга каршы йөгереп төште... Бер-берсенең иңнәренә шапылдаткалап күрешкән, хәл-әхвәл сорашканнан соң, инде ашыкмыйча гына комиссарның эш кабинетына күтәрелделәр.

— Я, сөйлә инде, зарыктырма! — диде Мулланур, бүлмәдә икәүдән-икәү генә калгач.

— Губерна комитеты һаман да булса хәрби шура башлыклары белән килешергә тырыша... Ольkeницкий сүзне үзен иң борчыган мәсьәләдән башлап китте.

— Синнән сер түгел,— диде Мулланур,— бездә ул контрреволюция оясын тар-мар итәргә вакыт, дигән фикер ныгый бара.

Дөресен әйткәндә, без әле сабыр итү ягында.

— Син үзең дә шулай уйлыйсыңмы?

— Мин... — Ольkeницкий, иплерәк сүз әзләгәндәй, иреннәрен кыймылдатып алды. — Сезнең урында булсам, мин кискен чаралар күрергә ашыкмас идем. Хәрби шураның хәзер коралLы ун мең кешелек гаскәре бар. Без солдатлар арасында аңлату эшләре алып баруны көчәйтәбез, милли мәсьәләдә Совет властеның сәясәтен төшендерәбез. Кыскасы, хәл шактый катлаулы һәм аны мылтык белән хәл итү дөрес булмас иде.

— Алай... — диде Мулланур. — Без дә шулай уйлыйбыз. Хәлбуки...

Ул ярты сүздә туктап калды. Ольkeницкий да дәшмәде. Һәр икесе берберсенең ни уйлаганын сүзсез дә аңлыйлар иде.

— Хәзер без конференция әзерләү белән мәшгуль,— диде Мулланур.— Мөселман эшчеләренең беренче Бөтенроссия конференциясен. Аны әзерләүдә Мәскәү, Петроград, Казан, Уфа, Пермь мөселман социалистлар комитетлары да катнаша. Безгә Самара, Архангельск, Коканд калаларыннан мөселман эшчеләре җибәргән вәкилләр килеп җитте. Конференциядә мөселман приказчиклары җәмгыяте, мөселман хатынкызларының демократик союзы кебек оешмаларның да катнашасы килә...

Мулланур, мавыгып китеп, конференция турында бик тәфсилләп сөйләргә керешкән иде, кинәт:

— Сүзне нәрсәдән башладым соң әле? — дип, үзен-үзе бүлдерде.— Ә-ә... Менә шул конференциянең татар-башкортлар арасында милли мәсьәләне хәл итүгә тәэсире бик зур булыр дип уйлыйбыз. Милләтчеләрнең, һәртөрле хәрби шураларның аяк астыннан туфрак китәчәк,— диде.

Ольkeницкий аның сүзләрен хуплап баш какты.

— Ләкин конференция башланганчы ук, Татар-Башкорт республикасы турында Положениене игълан итү бик әһәмиятле булыр иде,— диде.

Мулланур өстәл тартмасын ачып, юка гына папка, ә аның эченнән «ундервуд»та басылган кәгазь бите алды.

Ольkeницкий, күзләренә якын ук китереп, әкрен генә укый башлады:

1. Көньяк Урал һәм Урта Идел буе территориясе Россия Совет Федерациясенең Татар-Башкорт Совет республикасы дип игълан ителә.

2. Чикләрне билгеләгәндә төп нигез итеп татар һәм башкорт революцион оешмалары төзегән проект алына: бөтен Уфа губернасы, Оренбург губернасының башкорт өлеше, Казан губернасы һәм Пермь, Вятка, Сембер һәм Самара губерналарының мөселманнар яшәүче күрше өлешләре. Республика чикләрен тәмам билгеләүне бу республика Советларының Учредительный съездына тапшырырга.

3. Республиканың көнбатыш өлешенең Башкортстан белән үзара политик һәм экономик мөнәсәбәтләре Татар-Башкорт республикасы Советларының Учредительный съезды тарафыннан билгеләнә...

— Болай булгач, сез барысын да әзерләп куйгансыз икән бит? Нишләп матбугатта игълан итмисез?

Мулланур уңайсызланып китте:

— Бу текст Милләтләр халык комиссариаты өстәлендә байтактан

бирле ята инде,— диде.— Кайсыдыр төшен ошатып бетермиләр кебек анда...

— Ярый, Иосиф Виссарионович белән мин дә сөйләшеп карармын әле,— диде Олькеницкий.

Саубуллашканда ул үзенең дә бер гозерен әйтми китә алмады:

— Мулланур Муллаҗанович! Беләм, синең комиссариатыңда һәр кеше исәптә, үзеңә дә җитмидер. Шулай да безнең төбәкләрдә хәл бигрәк шомлы бит. Уфага, Казанга, Оренбургка үзегезнең иптәшләрне җибәрә алмассызмы? Халык арасында исеме, абруе булганракларны... Син үзең дә беләсең инде...

Шул ук көнне кыска гына киңәшмәдән соң Оренбургка — Манатов, Уфага — Ибраһимов, Казанга Һади Маликов чыгып китте.

Мулланурны Сталин үзенә чакыртып алды.

— Утырыгыз, иптәш Вахитов,— диде ул, кул биреп күрешкәч.— Вакытны бушка уздырмыйк. Ялгышмасам, сез бит эшне тиз тотарга ярату-чылардан әле безнең.

— Анысы нинди эш булуына карап, Иосиф Виссарионович...— дип каршы төште Мулланур.— Бу очракта без, чынлап та, Татар-Башкорт республикасы турындагы Положениене мөмкин кадәр тизрәк игълан итү бик мөһим дип саныйбыз.

Сталин кашын җыерды. Ачык-якты күзләрен кысып, беркавым дәшми торды. Ул хәтта бу сөйләшүне дәвам итәргәме-юкмы дип уйлап, икеләнеп торган кебек иде. Күрәсең, башланган сүзне өзеп калдырасы килмәде:

— Беләсезме... Ул Положениене игълан итү-итмәү әлегә безнең эш,— диде коры гына.

«Ахрысы, Ольkеницкий белән сөйләшүемне яратмагандыр»,— дип уйлап алды Мулланур.

— Әгәр комиссариат әлеге мәсьәләне хәл итәргә ашыкмый икән,— дип дәвам итте Сталин,— димәк, халык комиссарының бу уңайдан үз фикере бар... Ул фикер сезгә никадәр мәгънәсез булып тоелмасын, сез барыбер безнең белән исәпләшергә бурычлы.

— Ә ул фикерегезне минем дә бик ишетәсем килә, Иосиф Виссарионович,— диде Вахитов.

— Мин баштан ук уйлаган идем, һәм хәзер дә шул уемда калам...— Сталин, балаларга диктант яздыручы мөгаллим кебек, һәр сүзне аермачык әйтергә тырышып, салмак кына сөйләп китте.— Сез әйткән Положениене кайчан игълан итүнең һичнинди практик әһәмияте юк. Сез, күрәсең, шул рәвешле Хәрби шураның аяк астыннан туфракны тартып алмакчы буласыз. Ләкин саф политик мәсьәләләрнең дә хәрби көч белән хәл ителгән чаклары була. Бу юлы, минем карашымча, сүз нәкъ менә шундый очрак турында бара.

Хәзер, әлбәттә, каршы дәшмәүдән дә яхшысы юк иде. Мулланур моны шунда ук сизеп алды, әмма тыелып кала алмады.

— Ә мин теләсә нинди очракта да сәяси мәсьәләләр сәяси чишелеш белән тәмамланырга тиеш дип саныйм,— диде ул кыза төшеп.

— Мин сезгә әле генә әйткән нәрсәләр турында уйланырга киңәш итәм,— дип куйды Сталин һәм, Мулланурны аптырашка калдырып, кинәт урыныннан торды да, кабинетыннан чыгып ук китте.

«Нәрсә булды соң бу? — дип, башына суккан кебек, бермәлгә исәңгерәп калды Мулланур.— Сүзен бирәсе генә килмәдеме? Әллә, чынлап та, үзен хаклы дип саныймы? Хәлнең асылын аңлап бетермәвеме икән?..»

Ул арада Сталин кире әйләнеп керде һәм, берни дә булмагандай, үз урынына барып утырды. Күзләрен кыса төшеп, авыр һәм озак итеп Вахитовка карап торды.

— Я, ничек? Уйладыгызмы?

— Уйладым, иптәш Сталин.

— Хуш... Инде ни диярсез?

Бу юлы Мулланур үзенең сүзен ипләбрәк, аз гына «салам кыстырыбрак» әйтергә булды.

— Чыннан да, бу мәсьәләдә сез хаклырактыр кебек, Иосиф Виссарионович,— диде. — Бер дә кан коюсыз гына барып чыкмас, күрәсең. Тик, хәтта андый бәрелештән котылып булмаса да, Хәрби шура әкиятләренә алданган мөселман хезмәт ияләре бар бит әле... Аларның хәзер кайсы якка борылулары безнең өчен барыбер була алмый!

Сталин авызыннан трубкасын алды һәм сизелер-сизелмәс ишарә белән генә Вахитовның сүзен бүлде.

— Кыскасы, сез һаман үз сүзегездән кайтмыйсыз, Положениене хәзер үк игълан итәргә кирәк, дисезме?

Инде артык боргаланырга урын юк, бары туры һәм ачык җавап таләп итела иде.

— Әйе,— диде Мулланур. — Әгәр сез мине барыбер хаклы түгел дип саныйсыз икән, мөселман эшләре буенча комиссар вазифаларыннан азат итегез һәм минем урыныма үз фикерегезне яклый торган бүтән кешене билгеләгез.

— Карале син аны, нинди үҗәт,— дип мыек астыннан гына көлемсерәгән итте Сталин. — Я, ярар, кайда әле ул сезнең проект... Укыгыз...

Татар-Башкорт республикасы турындагы Положение 1918 елның 22 мартында басылып чыкты. Совет властеның дошманнары өчен ул кырмыска түмгәгенә ут салу белән бер булды. Бигрәк тә «бүленмәс Россия» идеалларына табынучылар котырынды. Алар, янәсе, борын-борыннан русныкы булган җирләрне большевиклар әрәм-шәрәм итеп, таратып бетерә, бөек Рәсәй киләчәге өметсез вак хаерче дәүләтләргә бүлгәләнеп бетә, дип шыр ярып кычкыра башладылар. Максатлары, әлбәттә, катлаулы чорның кайбер аңлашылмаучылыкларын тагын да тирәнәйтү, Совет властена каршы көчләрне бәйдән ычкындыру иде.

Бу кискен проблемага карата большевиклар партиясенең фикере һәрвакыт принципиаль булды. Аны Хәрби флотның беренче Бөтенроссия съездында бик ачык итеп Ленин формалаштырды:

— Безгә әйтәләр, Россия чәлпәрәмә килер, аерым республикаларга таркалып бетәр, диләр. Ләкин безгә моннан куркасы юк... Безнең өчен дәүләт чигенең кайдан үтүе мөһим түгел, ә теләсә нинди милләт буржуазиясе белән көрәштә барлык милләт хезмәт ияләренең бергә берләшүе мөһим,— диде Владимир Ильич.

### 3

Дөлделевичка Мәскәү бик килеште. Теләге фәрештәләрнең амин дигән чагына туры килгәндер инде: аны монда берсүзсез эшкә алдылар. Әле кая диген,— нәкъ менә үзе омтылган төшкә — Мәркәз мөселман комиссариатына! Дөрес, комиссариатның да юньле кешеләргә мохтаҗ чагы туры килде. Ләкин барыбер урамнан килеп кергән кемсәне болай тиз генә кабул итмәсләр иде. Дөлделевич турында Габдулла картның да, Галиянең дә яхшы сүзе үтте бугай. Хәтта Һадига да ошады аның җегәрле булуы, эш җаен белүе. Юк, урамнан килеп керүче түгел иде Әдһәм!

Комиссариатта аңа оештыру-тәэминат эшләрен тапшырдылар. Ышаныч яулау, үзенең ролена керү өчен шактый тир түгәргә туры килде Дөлделевичка. Кушылган бер эшне бик тиз һәм төгәл үтәргә тырышты. Хәер, бу аңа әллә ни кыен да булмады. Гомердә күрмәгән кешеләр белән аралашып китү, уртак тел табу аның өчен ипи белән берәңге ашау кебек күнегелгән нәрсә иде.

Кыскасы, Дөлделевич бөтен кешегә ярап, яхшатланып өлгерде. Комиссар булып комиссар аның булдыклылыгын махсус приказ белән билгеләп үтмичә булдыра алмады. Бу бик мөһим иде! Әмма әһәмияте шуннан ким булмаган икенче бер нәрсә дә күңелен җылытып торды Әдһәмнең: комиссариат казанында кайнаганда, ул төрле кешеләр белән якынаерга, бигрәк тә аларның аз гына ризасызлык күрсәтүләрен дә тотып алырга тырышты. Ә канәгатьсезлеген сиздерүчеләр һәркайда табылып тора. Берәүләргә яңа власть ошап бетми, кайсыберләрен комиссарның таләпчәнлеге чыгырдан чыгара: Вахитов үзе эшкә бөтен җанын салгач, эленкесалынкы йөрүчеләргә көн күрсәтми... Әнә шул кешеләрнең башын әйләндерергә, вак-төяк үпкәләүләрен көчәйтергә, димәк, кирәк чагында аларны үзең теләгән якка авыштырырга мөмкин иде.

Дөлделевичны комиссариаттан ерак түгел бер йортка большевиклардан качкан присяжный поверенныйның квартирасына урнаштырдылар. Зур квартираны бөтенләе белән үзенә тапшырсалар да, ул элеккеге хуҗа кабинетын гына биләп алды. Мондый квартираның мичен ягу гына да урамны җылытырга азаплану белән бер иде. Ә адвокатның кабинетында «буржуйка» ажгырып утыра, яңа хуҗа аңа ваклап-ваклап кына борынгы затлы мебельне «ашата», кайвакыт хәтта присяжный поверенный китапханәсендәге алтын хәрефле, күн тышлы китаплар белән дә сыйлаштыра.

Инде Дөлделевич Мәскәүдә үзенең япа-ялгыз булуына да күнегеп килә. Һәрхәлдә, аның кайда яшәгәнлеген хезмәттәшләреннән кала беркем белми, ә комиссариат кешеләре, ничектер, бер-берсенә кунакка йөрешергә гадәтләнмәгәннәр. Шуңа күрә, көннәрнең берендә иртә таңнан ук ишек шакыган тавышка уянгач, Әдһәмнең йөрәге табан астына төшеп китте.

Казаннан кунак килгән иде. Кунакның да нindие әле — Дөлделевичны Петроградта ук зарыктырып көттергәне, Әлим Хәкимовтан хәбәр-йомыш алып килүче кеше булып чыкты ул. Хафиз исемле, чыпчык кебек әрсез, елгыр бәндә иде бу.

«Эзләп тапканнар, кабахәтләр,— дип уйлады Әдһәм. — Муеннан нужа буып алганда, исләренә дә кертеп карамаганнар иде. Әзрәк аякка баса башлавым булды, шунда ук килеп җиткәннәр...»

— Аллага шөкер, исән-имин икәнсез, Әдһәм әфәнде,— дип сөйләнде Хафиз, йомшак кәнәфигә чума биреп. — Мин сезгә дус-ишләрдән сәлам алып килдем.

— Сәламәт бул,— диде Дөлделевич. — Ниләр бар соң анда, безнең дусларның хәле ничек?

— Хәлләр изге. Үзегез дә ишеткәнсездер. Казан мөселманнары игълан иткән җөмһүрият турында...

— «Болак арты җөмһүрияте»н әйтәсеңме? Ничек инде ишетмәскә!

— Әстәгъфирулла! «Болак арты» дип. Сездән чыгамы шундый сүзләр?! Дошманнарыбыз таккан кушаматны сезнең авыздан ишетү бик авыр...

— Ярар, җитте сиңа! — дип бүлдерде Дөлделевич. — Син, дустым, халык җыенында түгел. Монда миннән башка җан иясе юк. Ә мине агитларга кирәкми. Мин сиңа дипломат та түгел, гаскәри кеше, шулай булгач, турыдан ярып әйт: чынлыкта хәлнең торышы ничек? Без нәрсәгә исәп тота алабыз? Аннары шуны да онытма: миңа күп нәрсә белгеле. Һәм бик ышанычлы чыганаклар аша.

Хафизның шунда ук кикриге шиңде. Тирән, шәп кәнәфидә ул хәзер бигрәк тә мескен, зәгыйфь булып күренә иде. Йокы күрмәүдән кызарган күзләрен бармак очлары белән каплап, ул бөтенләй тонык тавыш белән сөйли башлады:

— Турысын әйткәндә, әлегә эшләр шәптән тормый. Җөмһүриятне игълан итүен иттек, ләкин...

— Һәрвакыт шул «ләкин»... Ашыккансызмыни?

— Әллә ашыктык, әллә соңга калдык инде. Әйтүе кыен.

— Я, барысын да ничек булганча сөйлә әле. Башыннан алып.

— Гыйнварда мөселман сугышчыларының икенче Бөтенрусия корылтае ачылды. Без бу съездда мөстәкыйль мөселман дәүләте — Идел-Урал штатын игълан итәргә исәп тоттык. Моңа җирлек тә бар иде шикелле. Советка каршы барча көчләрнең берләшүенә ирештек. Кадетлар да, меньшевиклар да, дин әһелләре дә, шура вәкилләре дә безнеякларга әзер иделәр... Бу көчләрне берләштереп, Советка каршы көрәшү өчен зур милли гаскәр төзү күздә тотылды. Казандагы Совет башлыкларын һәм большевикларны кулга алу бурычы куелды.

— Соң, шайтан алгыры, нәрсә комачаулады инде сезгә! Ниятегезне нишләп тормышка ашырмадыгыз?

— Янә шул каһәр суккан большевиклар! Съезд делегатларының күбесе аларның сүзенә ышанды. Без көттек... Көттек...

— Нәрсә көттегез соң сез? Нәрсәгә өметләндегез?

— Өметләр зурдан иде. А-а... Финлянд полкы үзе генә дә ни тора иде! Безгә шушы мөселман полкының Петроград яныннан Казанга кайтырга теләве билгеле булды. Ул бит бөтен бер полк! Баштанаяк коралланган, сугышларда чыныккан!..

— Ә Казан Советының Петроградка, Подвойский исеменә биргән телеграммасы, полкны юлда туктарлауны үтенүе... Сезгә бит бу билгеле булырга тиеш иде!

— Аны без алдан ук белдек һәм үзебезнең максатларда әйбәт кенә файдаландык та. Ул телеграмманы юлда ук эләктереп алган идек. Съездда шуны кычкырып уку, беләсезме, ничек тәэсир итте! Чын-чынлап, гарасат купты! Безнең басым астында корылтай бик таләпчән, усал резолюция кабул итте: әлеге телеграмманы юк дип санарга, Казан Совдепын яңадан сайларга, мөселман финлянд полкын Казанга тоткарлыксыз үткәрергә... Тик боларны хәзер нигә сөйләп торырга, Әдһәм әфәнде! Үткән эштән төш яхшы, ди татар...

— Дөрес! Бүгенге көн белән яшик,— диде Дөлделевич. — «Болак арты җөмһүрияте«нең каршы торырлык дәрманы бармы?

— Иң мөһиме — дәрт бар! — дип, туры җаваптан качарга тырышты Хафиз. — Без анысы куркып кала торганнардан түгел. Тик көчләр тигезсез. Корал җитми, корал! Безнең бит броневиклар да, артиллерия дә юк.

— Ә кешеләр? Кешеләрегез бармы?

— Кеше җитәрлек, аллага шөкер. Менә минем килүем дә...

— Яле, яле! Ниндирәк капчык тотып килдең икән? Нәрсә теләнергә?

— Минем бурыч, Әдһәм әфәнде, Казанга яшерен рәвештә корал озатуны оештыру. Шуның өстенә, безнең яклы кешеләрне табасы, алар белән элемтә урнаштырасы бар. Синең дә күздә тоткан кешеләрең бардыр бит?

— Табарбыз. — Дөлделевич кабаланып кесәсенә кереп китте, аннан сәгатен тартып чыгарды.

— Хафиз туган, син монда үз өеңдәге кебек бул. Юлдан соң ял итеп ал.

— Ә син?

— Миңа эшкә китәргә вакыт. Комиссар Вахитов юксына башлар. Үзең беләсең, мин бик төгәл кеше. Комиссарны авыр хәлдә калдырасым килми.

Әдһәмнең бу сүзләре Хафизга төрттерү, алай-болай була калса, Казандагы «дуслар»дан башка да югалмыйбыз без, дип сиздереп кую иде. Ләкин Хафизның моңа бер дә исе китмәде.

— Дөрес эшлисең,— диде ул тыныч кына. — Вахитовның ышанычын яулап алуыңны беләбез. Безгә бит синең турыда барысы да мәгълүм...

— Ах, сезгә мәгълүммени? — дип, йөзенә мыскыллы төс чыгарды Дөлделевич. — Ә элегрәк кайда идегез соң сез? Шул гомер буе кая посып

яттыгыз? Әгәр мин тегендә, Петроградта, катып үлгән булсам?

— Һи, эш аңа ук барып җитмәс иде,— дип авызын ерды Хафиз.— Без сине анда да онытмадык.

— Эзәрлекләп йөрдегез мәллә?

— Нишләп эзәрлеклик ди? Үз кешебездән сиңа ярдәм итүен генә сорадык.

— Кемнән?! — диде Дөлделевич. Шунда ук:— Ә-ә...— дип исенә төшерде. — Әллә теге тинтәк картны әйтәсеңме? Вәлиулланы? Мин аны сизенгән идем шул... Чынлап та, дәрт кенә түгел, бераз дәрман да бар икән сездә... Карап карыйк соң! Бәлки, безнең җеннәр дә килешеп куяр әле...

4

Мулланурны Яков Михайлович Свердлов үзенә чакырды. Казандагы хәлләр турында тәфсиллерәк итеп, бөтен нечкәлекләре белән беләсе килә иде аның.

Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты Президиумының эш бүлмәләре әле шушы көннәрдә генә Икенче Советлар йортына күчкән иде. Болай күченүнең сәбәбе бик гади: Кремльгә махсус пропускысыз беркемне дә үткәрмиләр, ә Яков Михайлович исә үзенә йомышы төшкән һәркем бернинди тоткарлыксыз килеп керә алырга тиеш, дип саный. Шуңа күрә дә ул үзенең кабул итү бүлмәсе белән Кремль эченнән чыгып, Мәскәүнең үзәгенә үк барып утыра. Хәзер Свердловның кабинеты элеккеге «Метрополь» кунакханәсенең икенче катында, тәрәзәләре мәйдан ягына караган бер бүлмәдә, диләр.

Яков Михайловичның яңа «өендә» Мулланурның әле булганы юк иде. «Метрополь» диварларындагы пуля эзләре дә, тышкы ишек янындагы ашык-пошык кына язып куелган фанер такта да аның игътибарын җәлеп итте. Тактага кызыл кара белән зур итеп: «ВЦИК ПРЕДСЕДАТЕЛЕ. 237 БҮЛМӘ» дип язып куелган иде.

Мулланур башта ялгыш «237 А» дигән бүлмәгә килеп керде. Ләкин бу ВЦИК секретаре Варлаам Александрович Аванесовның кабул итү бүлмәсе булып чыкты.

Свердловның үз кабинеты да секретарьныкыннан әллә ни аерылмый икән. Тегендәге шакмаклы калын одеал белән капланган тимер койка урынына гына биредә тагын бер өстәл куйганнар. Аннары монда урындыклар саны күбрәк. Йомшак кәнәфиләр дә, затлы пәрдәләр дә юк. Беренче күргән кешедә, Председательнең кабинетын әле җиһазлап өлгермәгәннәр икән, дигән фикер калырга мөмкин. Мулланур да башта шулай дип уйлады. Соңыннан Варлаам Александрович кына аңлатып бирде: киресенчә, элегрәк монда кәнәфие дә, башкасы да булган. Тик Яков Михайлович бу бүлмәгә урнашырга карар кылгач:

— Пәрдә-чаршауларны алыгыз. Кәнәфи ише нәрсәләрне моннан чыгарыгыз! — дип боерган. — Менә монда өстәл куегыз. Тик алай түгел, әнә теге кыры белән! Соң сез үзегез уйлап карагыз: миңа килгән иптәш бу өстәл янына утыргач, күзенә туп-туры яктылык бәрсә, аңа ничек җайсыз булачак,— дигән.

Аванесов бүлмәсендә койка торуның үз хикмәте бар икән: ВЦИК секретареның тәүлекләр буе кунып-төнеп эшләгән чаклары күп. Ә Яков Михайлович йокларга өенә кайтып йөри. Тик аның да арыган чырае, кызара төшкән күзләре таңнан таңга кадәр эш өстәле янында утыруы турында сөйли.

ВЦИК Председателе, Мулланурны күрү белән, кызу гына урыныннан кузгалды:

— Саумысыз, иптәш Вахитов! — дип кулын кысты, якындагы урындыкны аңа таба этебрәк куйды.

Кабинетта Подвойский да бар иде.

— Безне Казандагы вакыйгалар белән җентеклэбрәк таныштырыгыз әле, иптәш Вахитов,— диде Свердлов.

Муллануp барысын да бәйнә-бәйнә сөйли башлады. Ләкин, беренче сорауларыннан ук, Яков Михайловичның Казан хәлләреннән яхшы хәбәрдар булуын сизеп алды.

— Әһә,— дип бүлдергәләп торды ул Вахитовны,— ә Мозаффаров, Токумбетов һәм Алкиннарны нишләп чыгарып җибәргәннәр? Ах, сүз биргәннәрмени... Ышандырганнар, димәк?..

Мулланур «Болак арты җөмһүрияте»н юкка чыгару, милләтчеләр оештырган «тимер дружиналар»ның кан коешсыз бирелүе вакыйгаларына тукталды. Мөселман комиссариатының бу юнәлештәге эшләре турында сөйләгәндә ул, мавыгып китеп, баштагы уңайсызлануларын да онытты. Свердлов та инде хәзер бүлдермичә тыңлый иде. Шунда гына Мулланур аның юри, сорау арты сорау биргән булып, әңгәмәне куертып җибәрүен абайлады.

Сүз түгәрәкләнеп килгәндә, Яков Михайлович пенснесын салды һәм арыган күзләрен угалады.

— Ярый... — диде ул канәгать тавыш белән. — Хәзер инде иң мөһиме — тынычланып калмау, уңышларны ныгыту. Сез һәрвакыт истә тотарга тиеш: Совет властеның дошманнары үз позицияләрен болай гына калдырып китмәячәкләр.

— Аңлыйбыз, иптәш Свердлов,— диде Мулланур.

— Шулай булгач, татар-башкорт гаскәри частьларын оештыруны дәвам итәргә кирәк. Кызыл армиячеләр гаиләсенә мөселман егетләре күбрәк кушылсын иде.

— Беренче татар-башкорт батальоны төзелүен беләсездер инде, Яков Михайлович. Беренче апрельдә приказга кул куелды...

Свердлов, урыныннан торып, Мулланурның янына ук килеп басты, иңенә кулын салды.

— Татар-башкорт Совет республикасы турындагы Положение бик вакытлы игълан ителде,— диде ул. — Татар хезмәт ияләрен безнең дошманнарыбыз: «Советлар сезгә үз армиягезне, үз мәктәпләрегезне, милли дәүләтегезне оештырырга юл куймаячак»,— дип куркытып килделәр. Ә инде Совет властеның мондый хокукларны бирүен күргәч, фетнә оештырып йөрүчеләрнең аяк астындагы соңгы туфрак тартып алынды. Буржуаз милләтчеләр, күз ачып йомганчы, армиясез генералларга әйләнеп калдылар...

Тагын берничә көннән Яков Михайлович Свердлов бу фикерне ВЦИКның конституция комиссиясе әгъзаларына да аңлатып бирде. Комиссия Татар-Башкорт Совет республикасы турындагы Положениене бертавыштан хуплады һәм, әлеге мәсьәләне тулысынча хәл итүне ашыктырырга кирәк, дигән теләк белдерде.

## Бишенче бүлек

### I

Комиссариатта эш муеннан, ә иң кыены — кул җитмәү иде.

Кызганычка каршы, Мулланурның иң якын ярдәмчеләре кебек, Һади Маликовлар кебек үз-үзен аямый эшләүчеләр күп түгел. Кайсыберләре авыр хезмәттән тайчынырга маташа, күрәләтә юкны бушка аударып йөри, икенчеләре гомумән эш рәтен белеп бетерми — аларны алыштырырга кеше дә юк. Шуңа күрә, үз вазифаларыңны үтәүдән тыш, кайчак кул астындагы хезмәткәрләр өчен дә эшләргә, аларның хаталарын төзәтеп йөрергә туры килә.

Аз гына эш күрсәтә башлау белән килеп чыга торган тагын бер бәла өстәлде: әледән-әле һәртөрле шикаятьләргә җавап биреп утырасы булды. Әллә нинди буржуй калдыкларыннан турыдан-туры яла ягучы хатлар да килеп тора иде.

Менә әле дә Мулланур, авызына әрем капкандай, йөзен чытып, шундый кәгазьләрнең берсен укып утыра. Казаннан ниндидер «исемсез» бәндә милләтләр халык комиссары Сталинга «мөһим хәбәр» җиткерергә тели: янәсе, Вахитовны панисламистлар сатып алган. «Алыш-биреш»нең төгәл күләменә кадәр күрсәтелгән: мең дә ике йөз тәнкәгә!..

Ишек шакыдылар.

Җинелчә аксап, озын буйлы, якты чырайлы бер ир кеше килеп керде. Мулланур аны акыллы коңгырт күзләреннән танып алды: Богородскийдагы мәктәп мөгаллиме иде бу. Әлегәчә милли шураның Мәскәү оешмасы карамагында булган бу уку йорты, башка мөселман мәктәпләре кебек үк, Комиссариат канаты астына күчкән иде.

— Сезгә гозер белән килдем,— диде мөгаллим, бик матур кул белән язылган кәгазь битен сузып. — Без бик авыр хәлдә калдык...

Мулланур кәгазьгә күз салып алды: ул инде башта ук эшнең нәрсәдә икәнен чамалаган иде.

— Ике ай инде хезмәт хакы алганыбыз юк,— дип дәвам итте ачык чырайлы агай. — Укытучыларның күбесе мәктәпне ташлап китәбез дип куркыталар... Мин үзем анысы, ач-ялангач калсам да, балалардан аерыласы түгелмен,— дип елмайды ул.

— Кыен хәл,— дип башын чайкады Мулланур. — Аңлыйм... Мөселман мәктәпләре өчен без кулдан килмәгәнне дә эшләргә тырышабыз. Безнең карамакта булган бөтен акчаны мөгаллимнәргә хезмәт хакы түләү өчен бүлдек.

— Анысы бит февраль аенда булды. Аннан соң инде март үтте, ә хәзер — апрель...

Әйе, хәзер инде апрель шул... Мулланур уйга калды.

Бер тын дәшми торгач, кунак яңадан үзен искә төшерергә батырчылык итте:

— Шулай да, кайткач, хезмәттәшләремә нәрсә дип әйтермен соң?

— Өч көн элек Милләтләр халык комиссариатына без менә шундый хат җибәргән идек... — Мулланур папкадан бер язу суырып алды. — Бу — икенче нөсхәсе... Менә, күз йөртеп чыксагыз...

— Мин аны кычкырып укыр идем,— диде мөгаллим, кәгазьне күзләренә якын ук китереп. — Балалар белән шулай күнегелгән. Кычкырып укырга дим.

— Анысы сезнең ихтыярда,— диде Мулланур.

Мөгаллим, балаларга сабак биргән кебек, һәр сүзне аерып, басым ясап, әкрен генә укый башлады:

Мәркәз мөселман комиссариатының карары белән бетерелгән Мәскәү «Милли шура» оешмасы карамагында биш мөселман башлангыч мәктәбе бар иде: аларның икесе — малайлар, икесе кызлар өчен, ә берсе катнаш. Бу мәктәпләрдә укучыларның иң зур күпчелеге мөлкәт хәле ягыннан ярлы гаиләләрдән (Богородскийдагы мәктәп тулысынча пролетар балаларыннан тора), шуның өстенә болар — асылы белән һич тә конфессиональ түгел, ә демократик типтагы, шул яктан рус шәһәр школаларына туры килә торган мәктәпләр...

Мөгаллим, укуыннан туктап, башын күтәрде һәм Мулланурга карап:

— Бик дөрес,— диде.

Хатта әлеге мәктәпләрнең авыр матди хәле, нинди ярдәмгә мохтаҗ булуы аңлатыла һәм, бу мәсьәләне дәүләт күләмендә хәл иткәнче, кирәк булган төгәл сумма күрсәтелә иде: 29 665 тәнкә.

— Милләтләр халык комиссариаты безнең сүзгә колак салыр, дип уйлыйбыз,— диде Мулланур.

— Әлегә, димәк, шул кәгазьдән кала җавап юк? — дип куйды мөгаллим.

— Туктагыз әле,— диде Мулланур. — Хәзер без аны ачыкларга тырышып карыйк әле. — Ул, ишекне ачып, Дөлделевичны чакырырга кушты.

Дөлделевич озак көттермәде.

— Әдһәм,— диде Мулланур,— безнең теге мәктәпләр уңаеннан язылган хатның хәлләре ничек?

— Мин аны җибәрдем.
— Җибәрдегез? Ничек җибәрдегез? — диде аптырап, комиссар.
— Почта белән, әлбәттә,— дип иңнәрен җыерып куйды Дөлделевич.
— Мин бит, үзегез илтегез һәм нарком урынбасарының кулына тапшырырга тырышыгыз дип, кат-кат әйткән идем.
— Алай ук ашыгыч дип уйламадым мин.
— Инде ниһәнче тапкыр шулай аңламавыгыз бик сәер бит әле, иптәш Дөлделевич. Югыйсә, сез бит шактый тәҗрибәле кеше...
— Ә, минемчә, почта аша эш итү әйбәтрәк. Ул рәсми кәгазьләрдә теркәлеп кала, аңа рәсми җавап бирәчәкләр.
— Анысы да почта ашамы?— диде Мулланур, кызып китмәскә тырышып.
— Шулай, билгеле,— дип баш какты Дөлделевич. — Кара-каршы утырып сөйләшүне — хәтта ул нарком урынбасары белән булса да — делога теге куя алмыйсың. Кәгазь — кәгазь инде ул!
— Соң бит сез,— комиссар аны ачу белән бүлдерде,— сүзнең укытучыларга хезмәт хакы түләү турында барганын белә идегез бит! Инде икенче ай бер тиенсез утыралар алар. Һәркайсының гаиләсе бар! Балалары! Аларны туендырырга кирәк!
— Болай кайгыртучанлык күрсәтүегез сезне бизи, әлбәттә,— диде Дөлделевич. — Әмма эш кәгазьләрендә хискә урын юк. Анда тәртип булырга тиеш. Рәсми хатка рәсми җавап биргәннәрен көтәргә кирәк.
— Ичмаса, дәшмәгез!— дип кулын селтәде Мулланур. — Сез хатны илтеп бирергә иренгәнсез, бөтен эш шунда гына.
Дөлделевич хәтере калган кыяфәт белән башын чөйде, кашын җыерды.
Мулланурның тавышы коры, рәсми иде.
— Хәзер хатның икенче нөсхәсен алып, Милләтләр халык комиссариатына барасыз һәм бүген үк — аңладыгызмы?— бүген үк бу мәсьәләнең хәл ителүенә ирешәсез, иптәш Дөлделевич.
Әдһәм, хатны укытучы кулыннан алып, сүзсез генә башын иеп, чыгып китте.
— Мин барысын да аңлыйм. Авыр чор кичерәбез. Көч җитеп бетми. Нишлисең бит... Шулхәтле күп эш-мәшәкать, башлар әйләнеп китүе дә бар... Шулай да тапшырылган эшне намус белән үтәмәскә мөмкин түгел. Бу хезмәткәрегез, чын әгәр, мине гаҗәпкә калдырды.
— Монда мин гаепле,— диде Мулланур. — Минем күзәтү җитмәгән. Шулай да сез борчылмагыз. Сүз бер булыр. Бүген кичкә сез ачык җавап алырсыз.
— Рәхмәт яусын, иптәш комиссар,— диде мөгаллим, Мулланурның кулын учларына алып. — Минем шуны да әйтәсем килә... Нинди генә хәлдә дә безгә, укытучыларга, исәп тота аласыз. Сынатмабыз. Чөнки без барыбыз да сезгә ышанабыз. Комиссариатка ышанабыз...

Мәркәз мөселман комиссариаты ихтыяҗларына Совнарком 90180 тәңкә акча бүлеп бирде. Бу — бүтән милли комиссариатларга бүленгән суммадан шактый артык иде. Әлеге хәзинәгә Мулланур, күк капусы ачылганын көткән шикелле, зур өметләр баглады.
Вакыт су кебек ага торды, әмма Совнарком «күчтәнәче» һаман кулга кермәде. Бу эшне юллау да Дөлделевичка тапшырылган иде.

— Тоткарлык нәрсәдә соң? Ачыкладыгызмы? — дип сорады аңардан Мулланур.
— Милләтләр эше буенча комиссариат тоткарлый.
— Кем белән сөйләштегез?
— Нарком урынбасары белән.

Мәсьәлә бик җитди, шуңа күрә Мулланур бу эшкә үзе алынырга булды. Шалтыратып караган иде, телефонга әлеге дә баягы урынбасар — Пестковский үзе эләкте.

— Хәерле көн,— диде Мулланур. — Мин иптәш Сталин белән сөйләшеп алыр идем.

— Ә нинди мәсьәлә буенча, иптәш Вахитов?

— Совнарком биргән акчаны һаман ала алмыйбыз бит, тоткарлыкның сәбәбен беләсем килә.

— Алайса нәкъ кешесенә туры килдегез инде,— диде Пестковский.— Ул акчаны бирмәскә мин куштым.

— Сез?! Моңа сезнең ни хакыгыз бар?

— Без монда иптәшләр белән киңәштек тә, сезнең комиссариат өчен туксан мең тәңкә, могаен, артык мул булыр, дигән фикергә килдек. Сез генә түгел бит әле дөньяда.

— Гафу итәсез! — Вахитовның ачуы кабарды. — Акчаны Совнарком бүлде!

— Менә шуңа күрә дә без Совнаркомга протест җибәрдек.

— Халык Комиссарлары Советының карары сезнең өчен мәҗбүри түгел булып чыга алайса?

— Совнарком ул карарны безнең белән килешеп кабул итмәгән.

— Ярый... — диде Мулланур, тыныч булырга тырышып. — Болай булгач, Совнаркомга мөрәҗәгать итәргә туры килә инде.

— Ихтыярыгыз. Ләкин без үз фикеребезне үзгәртмәячәкбез. Кисәтеп куям.

Бераз икеләнеп торгач, Мулланур үзен Ленин белән тоташтыруларын сорады.

— Сезгә дөресен әйткәннәр,— диде Владимир Ильич. — Совнаркомга чынлап та шундый протест килде. Наркомнац коллегиясе исеменнән.

— Ничек инде ул алай? — дип ярсыды Мулланур. — Алар бит Совнарком карарына буйсынырга тиешләр! Югыйсә, бөтенләй анархия килеп чыга!

— Сезнең белән тулысынча килешәм, иптәш Вахитов,— дип тынычландырды аны Ленин. — Нәкъ менә анархия. Наркомнацтагы иптәшләр үзләренең хокукларын һәм бурычларын бигүк дөрес аңламыйлар. Я, ярый. Без бу хәлне төзәтербез. Мөселман комиссариатына бирелгән акчаны сез тулысынча алырсыз. Мин моны сезгә вәгъдә итәм.

Үзенең вәгъдәсен Ленин шул көнне үк үтәде. Милләтләр эше буенча Комиссариатка ул: «Вахитов сметасы белән нәрсә килеп чыкты? Нигә аны тоткарлыйсыз?» — дигән язу җибәрде.

Мулланурны, бәхәснең уңай чишелүеннән бигрәк, Ленинның аны ярты сүздән аңлап алуы — әлеге акчаның революция өчен бик тә мөһим, зарури эшләргә тотыласын белүе куандырды.

Совнаркомның Владимир Ильич председательлек иткән утырышында Милләтләр эше буенча комиссариат коллегиясенең протесты кире кагылды. Халык Комиссарлары Советы үзенең өч көн элек кабул иткән карарын тагын бер кат раслады: «Мөселман комиссариатына 90 180 тәңкә ассигнование бүлеп бирергә».

Шул ук көнне Мулланурның кабинетында Кремль телефоны шалтырады.

— Иптәш Вахитовмы? — Трубкада Ильичның бик таныш, күңелгә якын тавышы яңгырады. — Сезнең эш җайга салынды. Комиссариатка бирелгән сумманы бүген үк тулысынча ала аласыз.

— Рәхмәт, Владимир Ильич,— диде Мулланур, бугазына килеп бөялгән шатлыгын эчкә йотып.

— Ул акчалар тиешле урынга тотылыр дип ышанам.

— Әлбәттә, Владимир Ильич! Башкача булуы мөмкинме соң!

Әлим Хәкимов болай ук хурлыкка калуны көтмәгән иде. «Болак арты җөмһүрияте»нең тулысынча уңышсызлыкка дучар булуын ул бик авыр кичерде. Чынлап та бит, яхшы өйрәтелгән, коралланган, «җөмһүрият» идеясенә тугрылыклы ун мең сугышчыны берләштерүче оешма, комнан ишелгән бау кебек, таралыр да китәр дип кем уйлаган! Күз ачып йомганчы барысы да бетте! Ярый әле бәхете бар икән — Әлим качып өлгерә алды!

Ул хәзер, артына да борылып карамыйча, Самара ягына сыпырта иде. «Сикорский әфәндегә ничек күренермен...»— дип уйлаганда, Әлимнең йөрәге үкчәсенә төшеп китә. — «Ничек каршылар инде мине ул таш бәгырь...»— дип Идел ярына ук төшеп китүче тын урамнан атлый. Әле генә ун мең штыкка ия булган Хәкимов белән элмәктән качып баручы, сыену сорап килүче саламторхан арасында җир белән күк аермасы шул!

Ләкин бөтен шик-шөбһәләр юкка гына булган, ахрысы.— Сикорский Әлимгә ачык йөз белән ишек ачты. «Болак арты җөмһүрияте»нең тар-мар ителүенә аның исе дә китмәгән кебек иде.

— Сез исән, сез иректә — иң мөһиме шул,— диде ул, Хәкимовның кулын кысып.

— Ах,— дип башын чайкады Хәкимов, ялган пафос белән.— Уртак эшебез җиңеп чыкса, мин шәһит китсәм дә үкенмәс идем!

Сикорский башын югары чөеп, кукраеп:

— Безнең эш үлмәде, дустым. Сезнең белән без исән булганда, безнең идея дә яшәячәк,— диде.

Бүтән чак булса, башына череп беткән идеяләр тутырган бу солдафон белән янәшә басып торырга да хурланыр иде Хәкимов. Тик бернишләр дә хәл юк. Юрганыңа карап аягыңны сузарга туры килә. Башыңа төшкәч, дуңгызга да кияү дип эндәшәсең, диләр бит. Эчтән шулай дип уйлады Әлим, ә теле:

— Дөрес әйтәсез, Сикорский әфәнде, безнең идея, аллага шөкер, исән,— дип тибрәнде.

— Минем белән бер сүздә булуыгызга шатмын,— дип тагын да яктыра төште Сикорский. — Сезгә минем өметем зур, безнең хезмәттәшлек әле дәвам итәр бит?

«Бер вакыты җиткәнче! — дип уйлады Әлим. — Яәҗүҗ-мәәҗүҗ большевик вәсвәсәсеннән котылганчы... Аннары безнең юллар аерылачак...» Сикорскийга исә:

— Әлбәттә, алга таба да кулга-кул тотынышып эшләрбез, иншалла,— диде.

Бөтен шартын китереп ишек шакыдылар. Сикорский шунда ук яңа кунакны каршыларга йөгерде. Тиздән аның ишек катында күгәрчен кебек гөрләве ишетелә башлады.

— Ниһаять, килеп чыгарга булгансыз, Август Петрович! Без инде сезне көтә-көтә көтек булып беттек.

Август Петрович дигәне олы гәүдәле, мәһабәт кыяфәтле кеше булып чыкты. Өстендәге ярым хәрби кием — френч һәм галифе чалбар гына аның шактый күркәм корсагы һәм сакалы белән ятышып бетми икән.

— Сезне таныштырырга рөхсәт итегез,— диде Сикорский,— бу — Казаннан килгән кадерле кунагыбыз, татар республикасының хөкүмәт әгъзасы Хәкимов әфәнде.

— Күрешүебезгә бик шатмын,— дип кулын сузды яңа кунак. — Август Амбрустер булабыз, юрист.

— Утырышыгыз, әфәнделәр,— диде Сикорский. — Сезнең танышуыгыз шәп булды бит әле. Менә шулай өчәүләп элегрәк күрешкән булсак та зыян итмисе икән. Ярый, соң булса да уң булсын инде. Безне алда олы эшләр көтә, дусларым. Безнең алга большевикларга каршы бөтен көчләрне берләштерү бурычы куелган. Шуңа күрә уртага салып уйлашырга, киңәшеп эш итәргә кирәк...

Сүзне Амбрустер башлады; ул шактый асыл кош булса кирәк. Сикорскийдан да берничә башка югарырактыр әле. Һәрхәлдә, Казан хәлләрен Хәкимовтан шундый итеп сораштырырга кереште, әйтерсең лә Амбрустер — генерал, ә Әлим ниндидер штабс-капитан кисәге иде.

— Ничек уйлыйсыз, Хәкимов әфәнде,— дип башлады ул,— шушы дәрәҗәдә үк тар-мар ителү сезнең тарафдарларга бик көчле тәэсир ясады микән?

— Кисеп әйтүе кыен,— дип, сүз таба алмый торды Әлим. — Көчебез җитәрлек иде, берәү дә болай килеп чыгар дип уйламый иде. Яшерен-батырын түгел, күпләрне хафага салды бу хәл. Ләкин Совет властена нәфрәт, минемчә, чын мөселманнарда тагын да арта гына төште.

Амбрустер каш астыннан гына сөзеп карады:

— Чын мөселман дип атаган кешеләрегез белән элемтә сакланып калгандыр бит?

— Яшерен очрашу урыннары барысы да элеккечә,— диде Әлим, башлык алдында җавап тотучы төсенә керә барып.

— Ә шуннан кала?

— Безнең кешеләр хәзер бөтен дөнья буйлап сибелгән, күбесе белән бәйләнеш та өзелде.

— Ул элемтәләрне җайга салырга кирәк,— дип, үзенең «генерал» икәнлеген тагын бер искә төшереп куйды Амбрустер. — Инде башка төрләрәк сорау. Комиссар Вахитов идеясенә мөселманнар ничек карый, сезнеңчә? Мин Татар-Башкорт республикасын төзү турында әйтәм.

Әлимнең гаҗәпкә калуын күреп «генерал» бераз ачыклык кертергә булды:

— Бу мәсьәлә белән мин бик кызыксынам, Хәкимов әфәнде,— диде.— Сезнең хаталарны бүтән кабатламыйсы иде.

— Мулланур Вахитов — ни җитте кеше түгел,— дип әкрен генә җавап бирә башлады Әлим.— Татар-Башкорт җөмһүриятен төзү ниятен дә ул әйткәндер, иманым камил. Гадәттән тыш көчле зат... Болай дигәч тә, сез мине Вахитовка теләктәшлек итә дип уйламассыз, шәт. Кулымнан килсә, мин аны беренче баганага астырыр идем.

— Вакыты җиткәч, без андый мөмкинлек бирербез сезгә,— дип елмайды Август Петрович.— Гафу итегез, сүзегезне бүлдердем...

— Әйе, Татар-Башкорт җөмһүрияте — нәкъ менә Вахитов уйлап чыгарган әкәмәт. Чынында, әлеге идеяне ул бездән урлаган! Безнең Идел-Урал штаты...

«Ну, сезнең Идел-Урал штаты белән Татар-Башкорт республикасы икесе бер нәрсә түгел...— дип эчтән генә көлеп куйды Амбрустер.— Җир белән күк аермасы монда...»

— Мөселманнарның Вахитов ятьмәсенә эләгүе бер дә гаҗәп түгел...— дип дәвам итте Әлим.

— Чү, мин сезне аңламый калдым,— дип тагын бүлдерде аны Амбрустер.

— Нәрсәсен аңламаска мөмкин? Без халык күңеленә бәйсез мөселман дәүләтен төзү уен салдык. Тырышып-тырмашып туфрак йомшарттык, азатлык орлыклары чәчтек, ә бу иблис килде дә бөтен уңышны үзенә урып алды!

— Шулай да мин төшенеп бетә алмадым, Хәкимов әфәнде. Әгәр большевиклар идеясе сезнекеннән берничек тә диярлек аерылмый икән, ул чакта нишләп соң мөселманнар сезгә түгел, ә аларга ияреп киттеләр?

— Вахитов бездән чыккан фикерне матур сүзләргә төрде. Аларның лозунгларын сез миннән яхшырак беләсез. Алар һәр чатта: «Без ярлылар хакимияте!»— дип кычкыралар. Ә кемнәр алар ярлылар? Эшлексез хәерчеләр! Менә шул бөтен хәерчеләр Вахитов әләме астына барып егылды, аның кызыл гаскәрен ишәйтте.

— Сезне тыңлап торсаң, Хәкимов әфәнде, бөтен татар белән башкорт түшәмгә төкереп ятучы гына булып чыга. Кардәшләрегез турында бер дә матур фикердә түгел икәнсез.

— Эшлексезләр һәм бушбугазлар һәммә халыкта бар, Август Петрович,— дип көрсенеп куйды Әлим. — Кызганычка каршы, алар һәркайда күпчелекне тәшкил итәләр. Большевикларның көче менә шуңа бәйле дә инде.

— Ала-а-ай,— дип сузды Амбрустер. — Карагыз әле, ә комиссар Вахитов тирәсендә дә сезнең үз кешеләрегез бармы?

Көтелмәгән сораудан Әлим каушап калды:

— Мин... миңа...— дип авыз эчендә боламык пешерә башлады.

— Безне уртак максатлар берләштерә, Хәкимов әфәнде. Бер-беребездән яшерен серләребез дә булырга тиеш түгел.

— Әйе,— диде Әлим, Август Петровичның кырыс тавышына буйсынып.— Мәркәз мөселман комиссариатында минем кешеләр бар. Әмма...

— Җитте,— дип бүлдерде аны Амбрустер. — Миңа артыгын белү кирәкми. Ул сезнең бәләкәй генә серегез икән, рәхим итеп, үзегездә саклагыз. Җитәр бер вакыт, ул кешеләрнең безгә бик зур ярдәме тияр. Мин шуңа өметләнәм. Ә хәзергә алар белән элемтәләрне яңартыгыз, ни дәрәҗәдә ышанычлы булуларын тикшерегез...

Амбрустер аягүрә басты.

— Август Петрович! — диде Әлим, тирән кәнәфидән тора алмыйча каударланып. — Миндә бер өмет чаткысы булса да калдырыгыз инде! Әйтегез, зинһар, большевикларны әйләндереп капларлык көч бармы соң сездә?

— Сездә шик калмасын, Хәкимов әфәнде,— диде Амбрустер. — Андый көч бар.

— Соң, шайтан алгыры... Гафу итегез, минем алай диясем килмәгән иде... Нәрсә көтәсез икән сез һаман?

— Хафаланмагыз, әфәндем. Һәр эшнең үз вакыты бар. Без нәкъ шул вакытка туры китереп сугачакбыз: иртә дә, соң да түгел. Бу юлы безгә ялгышырга ярамый.

## 3

1918 елның 10 май иртәсе гаҗәп аяз, якты, җылы иде. Кояш чынчынлап җәйге бер юмартлык белән нурын сибә.

Бу көнгә әзерләнгәндә Мулланурга мең төрле эш башкарырга туры килде. Мең төрле уй тынгылык бирмәде. Бигрәк тә аны Уфадагы хәлләр борчуга салды.

Уфага махсус йомыш белән Галимҗан Ибраһимовны җибәрделәр. Ул анда үзара дошманлык итүче күпсанлы төркемнәрне килештерү өчен җирлек әзерләргә тиеш. Әлеге төркемнәрнең һәркайсы бары тик үзен генә башкорт халкының төп мәнфәгатьләрен чагылдыручы дип күрсәтергә тырыша. Бер группаның башлыклары: «Башкорт ул үзенә бер төрле халык, аның татар белән һичнинди уртаклыгы юк, теле, гореф-гадәтләре, культурасы белән кискен аерыла»,— дип раслыйлар һәм аерым башкорт дәүләте төзергә чакыралар. Икенче төркем Татар-Башкорт җөмһүрияте булуына каршы түгел, тик әүвәл Башкорт штаты төзеп, аннары гына аңа Казанны кушарга кирәк, дип бара. Өченчеләре исә, татар белән башкорт икесе бер халык, аларны аерып сөйләүнең дә мәгънәсе юк дип, мәсьәләне тагын да җиңелрәк хәл итмәкче.

Мулланур болай бәргәләнүчеләрнең ахыр чиктә иң гадел һәм дөрес чишелешкә киләсенә шикләнмәде. Ләкин хәзерге шартларда алдынгы карашлы барлык башкортларның большевиклар алга сөргән Татар-Башкорт республикасы турындагы Положение нигезендә берләшүе бик мөһим иде. Менә шуңа күрә дә Галимҗанның Уфадан әйләнеп килүен дүрт күз белән көтте Мулланур.

Ибраһимов тугызы көнне төштән соң кайтты.

— Я, сөйлә! — дип, сабырсызланып каршылады аны Мулланур. Галимҗан авызын гына ерды.

— Нәрсәсен сөйләргә? Бөтенесе дә тәртиптә... Татарлар һәм башкортлар белән ике зур җыелыш үткәрдек. Безгә барысы да тулысынча ышаналар. Уфада әлегә кадәр ике комиссариат яшәп килде: мөселман һәм башкорт комиссариатлары. Аларны Татар-Башкорт комиссариатына берләштердек.

— Монысы ярый,— диде Мулланур. — Ә андагы газеталар моңа ничек карый?

Галимҗан тагын елмайды. Кесәсеннән берничә кат бөкләнгән кәгазь алып, тантаналы төстә Мулланурга тапшырды.

Мулланур газета битен җәеп җибәрде. Күз алдында юллар биеште. «...Аңлашылмаучылыкларга бернинди сәбәп калмады. Бүгеннән башлап татар-башкорт демократиясе һәркайда кулга-кул тотынышып эш итәчәк...»— дип яза иде газета.

— Күрәсеңме? Борчылыр өчен бер дә нигез юк,— диде Галимҗан йомшак кына итеп.

— Шәт шулайдыр,— дип килеште Мулланур. — Акыл: «Барысы да әйбәт бара»,— ди. Ә менә йөрәк... Йөрәкне тыеп булмый бит... Күңелем тыныч түгел, Галимҗан... Күрәсең, холкым шундый инде.

— Ярый, иртәнгә кадәр түз. Кичке исәп иртәнгә ярамый.

Менә ул күптән көтелгән иртә.

Киңәшмәне Милләтләр эше буенча халык комиссары Сталин ачты. Ул милли мәсьәләләрдә Совет хөкүмәтенең тоткан юлы турында сөйләде, бу киңәшмәнең бурычларын һәм максатын аңлатты.

Президиумда утырган Вахитов, танышларын эзләгәндәй, залга, һәр делегатның йөзенә текәлеп карый, әйтерсең лә аларның күңелендә, бик тирәндә яткан уйларын чамаларга тырыша иде... Күз карашы белән бөтен залны бер иңләп чыкты да, сул яктагы икенче рәттә утырган ниндидер кешегә әйләнеп кайтты. Аның киң яңагы, килешле генә мыегы, гаҗәп мөлаем чырае Мулланурга бик таныш булып тоелды. Бу коңгырт-кара күзләрне, сул күзеннән түбәнрәк зур миңне һичшиксез кайдадыр күргәне бар иде аның...

Төрле чыгышларны тыңлаганда да, Мулланур әлеге кешедән күзен алмады. Кайда күрдем соң аны дип искә төшерергә тырышудан да бигрәк, бу ачык, беркатлы чырай залның көзгесе, «атмосфера басымы»ндагы аз гына үзгәрешне дә күрсәтә торган барометры буларак җәлеп итә иде.

Киңәшмәнең максаты һәм бурычлары турында сүз барганда, әлеге «барометр»да чын-чынлап кызыксыну, игътибар, фикер хәрәкәте чагылды. Казан Советы вәкиле Грасис чыгыш ясый башлагач, ул газаплы кичерешләр, каршылыклы хисләр төене булып укмашты...

Менә Казан мөселман комиссариатыннан килгән большевик Камил Якубов сүз алды.

— Мине киңәшмәгә җибәргәндә,— диде Камил,— эшчеләр комитетлары һәм клублары вәкилләре миңа: «Татар-Башкорт җөмһүриятен яклагыз, әгәр дә шуны эшли алмасагыз, Казанга кире кайтмагыз»,— диделәр. Татар-Башкорт шуралар җөмһүрияте хакындагы Положение — ул мөселман пролетариатының теләкләрен тормышка ашыру дигән сүз...

Вахитов күзәтеп утырган «барометр» — делегат Камил Якуб сөйли башлауга ук яктырып-балкып киткән иде. Кинәт ул урыныннан сикереп торды да:

— Чуваш пролетариатының теләкләрен дә дип әйт! — дип кычкырды.

Шул чак Мулланур аны танып алды. Бу чуваш белән ул ярты ел элек поездда — Питерга, Учредительное собраниегә барганда танышкан иде. Серләре килешеп, юл буе сөйләшеп бардылар. Исеме татарчага бик тартым иде аның. Ничек соң әле... Биктимер... Пиктимер... Әйе, шул үзе!

Мондый сәер исемне кайдан алуын сорарга теле бик кычытса да, кыймаган иде Мулланур,— бәләкәй генә табышмак булып калган иде бу кеше.

...Ул чакта сүз, ничектер, икесен дә борчыган мәсьәләләрдән башланып, уртак танышлар, ә тора-бара милли бәйләнешләр тирәсенә үк күчте.

— Чуваш белән татарның уртак әкиятләре, риваятьләре булуы тикмәгә генә түгелдер. Сезнең уйлап караганыгыз юкмы шул хакта? — диде Пиктимер.

Чыннан да, чувашларның да үзләренчә Алып батырлары, Камыр батырлары бар бугай шул. Әле бала чакта ук Мулланур Болгар хәрабәләрендә намазлык җәеп утырган татар карты белән янәшәдә үз догасын укып утыручы чуваш карчыкларын күргән иде...

— Ә Көнгыш хакындагы риваять?! — диде Пиктимер, гәптәшенең уйларын дәвам иткән кебек. — Аны татарныкымы, әллә чувашныкымы икәнен аерган кеше юктыр, шәт...

Мулланурның да ишеткәне бар иде ул риваятьне.

*Борын-борын заманда ерак-иркен далада яшәгәннәр икән безнең бабайлар, дип башлана иде ул. Дала кебек җиде җилгә ачык, хөр күңелле булганнар, азатлыкны тереклек итүдән артык күргәннәр.*

*Шул ук әүвәл заманда, шул ук сахра-далада көн кошы, кояш кошы Көнгыш бар иде, ди. Каурыеннан көн яктысы тама, аны күргән һәр кешегә дәва булыр иде, ди. Усалларның усаллыгы тими, куркакларның куркаклыгы кими икән, күз кырың белән генә булса да аны күрсәң. Кайгы-хәсрәттән котыласың, йортыңа кот иңә икән шул чакта.*

*Ләкин көннәрнең берендә бу тылсымлы кош турында сыңар күзле явыз Кара-хан ишетеп алган. Ишетеп алган да, үзенең иң мәкерле хезмәтчеләрен чакырган.*

*— Җилдерегез далага, тотыгыз ул кошны, ябыгыз тимер читлеккә, алып кайтыгыз сараема! — дип әмер биргән.*

*Ялмавызлар җитез атларга атланып, канлы кылычларын айкап, далага чапканнар. Көнгышны тапканнар, тотканнар, читлеккә бикләп алып та киткәннәр. Дала кешеләре: «Җибәрегез Көнгышны! Ул ябылудан һәлак булачак бит!»— дип юкка гына ялварып калганнар.*

*Кара-хан сихри кошка бер ялгызы хуҗа булмакчы икән. Аның матурлыгын кешеләрдән яшерәсе, рәхәтен үзе генә күрәсе килгән.*

*Кояш төшми торган төшкә куеп, читлек өстендәге кара ябманы ачып җибәргән хан: яктылыктан камашмасын дип, күзләрен йомган.*

*Тик... читлек эчендә бөрешеп, канатларын салындырып, шыксыз бер соры кош утыра, ди. Яктысы түгел, өстенә карарлыгы да юк икән. Бу — шулай, иректән аерылгач, Көнгышның канаты каерылган, сихри матурлыгы җуелган.*

*«Һай, нинди ахмак бәндәләр бар! — дип кычкырган хан. — Ничек ялганларга яраталар, тозсыз әкиятләр тараталар! Аларның атаклы Көнгышы шул карачкы булып чыгамы? Бу йолкыштан йөз кат матуррак кошлар азмыни соң дөньяда!»*

*Шуннан соң хезмәтчеләрен дәшеп алган да Кара-хан: «Күз алдымнан алып китегез бу карачкыны!» — дип боерган. Тегеләре үрелеп ала гына башлаганнар икән, читлеккә кояш нуры төшеп, кош-Көнгыш өздереп сайрап җибәргән. Хезмәтчеләр баскан урыннарында таратакка әйләнгәннәр. Читлектәге кош кинәт тимер рәшәткәгә бәрелеп талпынган, җилпенгән һәм аның канатлары... авызын ачып торган ханның күз алдында ялкын телләренә әверелгән. Ялкын торган саен биеккәрәк үрләгән һәм тиздән эреп, күккә ашкан.*

*«Әрәм булды кош! — дип уйлаган хан. — Ярар... Аннан барыбер файда юк иде».— дигән.*

*Ләкин Көнгыш юкка чыкмаган. Икенче көнне таңнан ук ул яңадан далада пәйда булган. Кояш чыгу белән, аның каурыйлары салават күпере төсләренә кереп янган. Бу якты балкыштан кешеләрнең күңелендә тагын да көчлерәк булып хөрлек уты уянган.*

*Шул көннән соң Кара-ханның ялмавызлары Көнгышны кабат-кабат тотып, тимер читлеккә япканнар, сарайга алып кайтканнар. Читлекне көннән-көн калынрак тимер таяклардан үргәннәр, зур-зур йозаклар белән бикләгәннәр. Ләкин һәр юлы бу сихри кош, ут-ялкынга әверелеп, күккә ашкан, ә иртә таңда дала киңлегенә, кешеләр күңеленә әйләнеп кайткан...*

— Искиткеч матур риваять! — дигән иде Мулланур. — Үзенең яктылыкка, гаделлеккә омтылышын халык нинди гаҗәеп әкияткә әйләндергән. Бу бит — халыкның берниндидә йозак салып, киртәләп булмый торган үлемсез рухы турында хикәят! Әгәр минем ихтыярымда булса, Көнгыш сурәтен мин безнең көрәш байрагына төшерер идем, аны революция төсе итәр идем.

— Сез бик дөрес әйттегез,— диде ул чакта Пиктимер дә. — Көнгыш, чынлап та, революция символы... Халыкны якты көн өчен көрәшкә әйдәүче азатлык гәүдәләнеше...



Поездда өзелеп калган танышлыкны дәвам итәсе, бу кызыклы кеше белән тагын бер рәхәтләнеп сөйләшәсе, фикер алышасы килеп китте Мулланурның. Шуны сизгән кебек, Пиктимер Марда янә урыныннан торды һәм үзенә сүз бирүләрен сорады.

— Чувашлар Татар-Башкорт республикасы төзелүгә каршы килмиләр,— дип, тыныч кына сөйләп китте ул.

Ни өчен чуваш халкы Татар-Башкорт республикасы оештырылуын хуплый, ни өчен аның чикләрен киңәйтү турында борчыла,— Пиктимер шул хакта, дәрес аңлатучы мөгаллим сыман, сабыр гына аңлата башлады.

Аны бүлдереп залдан берәү каты итеп кычкырып куйды:

— Ә нишләп сез үзегезгә автономия таләп итмисез?!

Пиктимер, кычкыручыны танырга теләгәндәй, тавыш килгән якка таба озак кына карап торды. Кашларын җыерды. Теге кешегә хәзер усал гына җавап кайтарыр кебек иде. Ләкин көтмәгәндә рәхәтләнеп бер елмаеп куйды һәм:

— Дөресен әйткәндә, без ул хакта уйланган идек,— диде.— Ләкин әлегә бездә чуваш автономиясе турында ачык кына бер идея юк. Һәрхәлдә, без барыбер чувашлар яшәгән җирләр Татар-Башкорт республикасына керергә тиеш дигән фикерне яклыйбыз. Мәсьәләне шулай хәл итү хәзерге чорда безнең халык өчен файдалы булыр иде.

Баягы кеше тагын да төрттеребрәк:

— Монда, киңәшмәдә утырганда, шундый фикергә килдегезме? — дип кычкырды.

Пиктимер яңадан кашын җыерды. Әмма тамчы да сабырлыгын җуймыйча җавап бирде:

— Юк, иптәш,— диде. — Бу — хәзер генә минем башка килгән фикер түгел. Инде январь аенда ук Бөтенроссия чуваш хәрби съезды парламентар Идел-Кама штатын яклау турында карар кабул иткән иде.

Бу чыгыш Мулланурның бөтен борчылуларын юып алып китте. Күңелдә җиңү шатлыгы талпынды. Хәзер инде киңәшмәнең уңышлы тәмамланасына шик юк иде.

Шулай булып чыкты да. Күпчелек Республика идеясен яклады. Бары Грасис чыгышы гына авыр тойгы калдырды.

— Мондый милли автономияләр соңгы исәптә, пролетариатка түгел, ә буржуазиягә файдалы,— диде ул. — Мөселман пролетариаты Татар-Башкорт республикасын төзүгә каршы! Татар большевиклары

аңа житәкчелек итә алмаячаклар! Ә Мөселман комиссариаты — үзенә ялган исем тагып йөрүче бер оешма гына ул...

Грасисның милли буржуазиягә нәфрәте бик ихлас, әлбәттә. Мулланур аның, автономия идеясеннән буржуазия файдаланырга азапланачак, дигән фикере белән дә килешә. Ләкин бөтенләй икенче чиккә ташланып, яла ягуга кадәр барып җитүе, большевиклар партиясенең милли программасына — милләтләрнең үзбилгеләнүе идеясенә каршы чыгуы... Бусы зур акылсызлык һәм оятсызлык, аңа кискен җавап бирергә кирәк иде.

— Бу тарихи утырышта,— дип сүзен башлады Вахитов,— җирле советларның кайбер вәкилләре, мөселман пролетариаты Татар-Башкорт Совет республикасын төзүгә каршы, дип әйтергә батырчылык иткән вакытта, минем аларга, бигүк теләп булмаса да, Чацкий Репетиловка әйткәнчә: «Карале! Алдала, ләкин чамасын бел!» дип кычкырасым килде.

Көлү һәм кул чабулар тәмамланганын көтеп алгач:

— Мин үземнең чыгышымда бары тик фактларга гына таяначакмын,— диде. — Мөселман пролетариатының Татар-Башкорт Совет республикасына чын мөнәсәбәте белән таныштыру өчен, минем сезгә берничә телеграмма гына укып китәсем килә. Ә мондый телеграммалар бездә дистәләгән.

«25 мартта,— дип укый башлады Мулланур,— Казан дары заводы эшче мөселманнарының гомуми җыелышы булды. Большевик Әхтәмовның **Татар-Башкорт** җөмһүрияте турындагы доклады кул чабып каршы алынды...» Пермь губерна Советы һәм мөселман комиссариаты вәкиле хәбәр итте: «1 апрельдә Пермьдә завод эшчеләренең мөселманнар съезды булып узды, анда республиканы якларга карар кылынды». Ә менә Чистайдан, мөселман крестьяннары һәм мөгаллимнәре съездыннан хәбәр... Уфадан, Оренбург, Ташкент һәм башка төбәкләрдән телеграммалар...

Зал буйлап шау-гөр килеп хуплау, көчле кул **чабулар** дулкыны йөгереп үтте. Вахитов кулындагы кәгазьләрне бер читкә этеп:

— Менә, иптәшләр, мөселман пролетариатының республикага мөнәсәбәте чынлыкта шулай,— диде.

Грасиска җавап сүз көрәштерүгә генә әйләнмәсен өчен, Мулланурга дулкынлануын сиздермәскә, тыныч булырга кирәк иде. Ләкин иң соңгы мизгелдә ул сабырлыгын җуйды:

— Буржуаз матбугатта безгә мондый гаепләрне сәяси хулиган Гатаулла ахун Баһаветдинов ташлаган иде. Нинди җан әрнеткеч бердәмлек... — Мулланурның тавышы тыелгысыз ачу белән тулды. — Грасис иптәшнең үзе үк дошман күргән буржуазия ягындагы иң кара көчләр белән нинди дулкынландыргыч бердәмлеге! Мин иптәш Грасиска һәм аның фикердәшләренә, һич югы төрле төбәкләрдә үзеннән-үзе барлыкка килгән мөселман комиссариатларын гына санап чыгарга киңәш итәм. Ул чакта, минемчә, аларга күп нәрсә аңлашылыр.

Зал тын да алмыйча комиссарны тыңлый иде. Берәүләр — хуплап, елмаеп, икенчеләре — нәфрәттән кара көеп, телләрен аркылы тешләп. **Никадәр** генә сәер булмасын, нәкъ менә дошманнарының караңгы чыраен күреп, Мулланур кабат үз-үзен кулга алды.

— Монда, милләт дигән төшенчә хәзер искерде инде, диләр. Монда кайбер вәкилләр без тарихи перспективаны югалттык, дип сөйләделәр... Минемчә, нәкъ менә бу сукырлар үз перспективаларын һәм, иң элек, халыкара перспективаларын югалтканнар,— диде ул.

Тынып калган залда Мулланурның тавышы чаң каккан кебек кискен һәм көчле булып яңгырады:

— Дуслар! Иптәшләр! Кардәшләр! Мәгърур Кавказ тауларыннан, Себер киңлекләреннән, калалардан һәм авыллардан туып килүче Татар-Башкорт җөмһүриятен якларга ашыгыгыз!.. Яшәсен яңа тормыш өчен уянучы, рус пролетариаты белән берләшкән мөселман пролетариаты!

# Алтынчы бүлек

## I

Унсигезенче елның җәе яшь Советлар республикасы өчен авыр булды. Фронтлардан берсеннән-берсе шомлырак хәбәрләр килеп торды.

Көнчыгыш фронттагы хәлләр аеруча катлаулы иде. 15 июньдә «Правда» газетасының беренче битендә В. И. Ленин һәм Мулланур Вахитов имзалары белән «Барлык мөселман хезмәт ияләренә» мөрәҗәгать басылып чыкты.

«Иптәшләр, туганнар, мөселман хезмәт ияләре! Милләтләрнең Россия Социалистик Федерациясе дәһшәтле сынау сәгатьләре кичерә...— диелә иде анда. — Контрреволюцион бандалар, Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасы территориясенә басып кереп, үзләре белән ачлык, хәерчелек, көчләү һәм канлы патша заманындагыча богаулар алып киләләр...

Кадерле иптәшләр, әгәр дә сезнең авыр газаплар белән туып килүче Татар-Башкорт Совет республикасы гражданнары буласыгыз килә икән, әгәр дә күңелләрегезнең өмете җәберләнгән һәм изелгән миллионнарның изге өметләре белән бергә икән, Мөселман Социалистик Армиясенең кызыл байраклары янына ашыгыгыз! Җиңүче революцион мөселман сугышчылары, эшче һәм ярлы крестьян властен саклау өчен, Россиянең барлык почмакларыннан утлы өермә булып килсеннәр!»

Казан — Урал — Самара... Бу — борын-борын заманнардан ук төрки халыкларның ватаны булып килгән җирләр. Хәзерге шартларда революция язмышы әнә шушы туфракта тамырланган халыкларның күңеленә ачкыч табуга, аларның ышанычын яулауга, ниһаять, алардан гаскәри берләшмәләр туплауга бик нык бәйле. Мондагы җир-суны белү, халыкның үз телендә сөйләшү гаять мөһим хәрби-стратегик факторга әверелде.

Мулланур һәм комиссариатның башка хезмәткәрләре Көнчыгыш фронттагы кызыл гаскәрләргә мөмкин кадәр күбрәк мөселман сугышчылары кушылсын өчен бөтенесен дә эшләделәр. Алар оештырган Беренче татар-башкорт батальоны инде Казанны якларга килде.

Рус контрреволюцион көчләренең еракка төбәлгән канлы күзләренә Казан бик майлы бер калҗа булып күренә иде. Аклар хәрәкәтенең аеруча танылган бер эшлеклесе соңыннан болай дип язды:

«Казанны бернигә дә карамастан алырга карар кылынды. Чөнки Казанда Россия дәүләтенең бөтен алтыны тупланган иде. Анда гаять зур күләмдә сугыш кирәк-яраклары калган иде. Болардан тыш, Казан Россиянең мөһим сәяси үзәге һәм Идел буеның башкаласы да иде бит әле!

Шул ук сәбәпләр аркасында, Казанны дошманга калдырмау өчен, коммунистлар бөтен мөмкинлекләрдән файдаланырга тырыштылар. Ләкин көчләр тигез түгел иде.

Казан Советына һәм партия губкомына алынган хәбәрләргә караганда, шәһәр оста яшеренгән акгвардиячеләр һәм милләтчеләр белән мыжлап тора. Контрреволюцион яшерен оешмалар белән көрәшү гаять кыен. Эшнең хәтта урам сугышларына кадәр барып житүе ихтимал. Казан һәм Мәскәү чекистлары, Татар-башкорт батальоны сугышчылары ярдәмендә уңышлы гына операцияләр үткәрсәләр дә, дошман барыбер төп көчләрен саклап калды шикелле. Аларны рухландырып, шәһәргә баш күтәргән чех полклары һәм аклар армиясе ыргыла иде.

Аяусыз, канкойгыч көрәш көннәре якынлашты.

...Инде төн урталары авышты. Ә Мәркәз мөселман комиссариаты хезмәткәрләре әле һаман таралышмадылар. Барысы да Вахитовны көтә. Аны ашыгыч рәвештә Ленинга чакырып алганнар иде. Бу сөйләшүнең

Казанга кайту белән бәйле булуын барысы да аңлый, әмма әлегә һәркем үзенчә юраудан уза алмый. Йөзләрдә киеренкелек, борчулы көтү. Төрлесе төрлечә утырышкан. Бары Һади Маликов кына әлегә бирешми. Өстәвенә гадәтенчә, башкаларның да күңелен күтәрергә, уен-көлке белән уздырырга тырыша. Менә әле дә:

— Карагыз әле, борынгы китапларны укыганыгыз бармы сезнең...— дип серле генә итеп башлады ул.

Берәү дә дәшмәде.

— Аларның кайсысындадыр: «Килер бер көн, барча халыкларның вәкилләре бер урынга җыелырлар һәм гаскәрләрне тарату, чик баганаларын алып ташлау, бөтен дөнья бер булып, туганнарча яшәү турында килешерләр»,— дип язылган...

Һадиның бу сүзләрен дә ишетмәмешкә салышып утырдылар. Ул барыбер исе китмәгән кыяфәт белән:

— Ә мин аларның кайда җыеласыларын да беләм...— диде.

Ниһаять, арадан берсе түзмәде:

— Кайда?— дип куйды.

— Казанда.

Кемдер йөзен чытты, кайсыдыр көлеп җибәрде.

— Ә нишләп,— диде Маликов, юрамалый-җитди төс саклап.— Хәзер дә безнең Казанда бөтен милләт вәкилләре яши ләбаса! Татар кебек киң күңелле халык, булса да, дөньяда тагын бер-ике генәдер...

Теле тегермән тартты Һадиның, ә үз күңелендә борчылу арта барды. Ул түземсезләнеп, ишекле-түрле йөри башлады. «Мулланур бик озак тоткарланды. Нинди дә булса үзгәреш килеп чыкмады микән?»— дип сагайды.

Тик нәрсә үзгәрергә мөмкин? Өченче көн генә Совнарком утырышында Мулланур Вахитов Идел буеның азык-төлек буенча гадәттән тыш комиссары итеп билгеләнде. Юлга чыгу көннәре төгәл ачыкланды. Болай искәрмәстән чакырып алуның нинди хикмәте булырга мөмкин?

— Ни генә булса да, без теләсә кайсы вакытта чыгып китәргә әзер торырга тиеш,— дип сөйләнде Һади.— Ә бәлки хәзер үк...

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады. Коридорда кызу, нык аяк тавышлары ишетелде. Ул арада ишек ачылып, бүлмәгә бик җилле генә итеп Мулланур килеп керде.

— Владимир Ильич белән бөтен планнарны кабат карап чыктык,— диде ул, иптәшләренең борчылуын йөзләреннән күреп.— Көнчыгыш фронтын ныгыту өчен күреләсе чаралар ачыклана төште. Соңгы мәгълүматлар буенча, анда хәлләр ифрат җитди, иптәшләр... Мин һәркайсыгызның тагын бер кат тирәнтен уйлануын, дөрес нәтиҗәләр ясавын телим. Казанның әһәмияте гадәттән тыш була бара. Ленин, Казан — төп звено, аны саклап калудан безнең революция язмышы тора, диде һәм иң соңгы мөмкинлекләрне дә эшкә җигүебезне үтенде.

— Димәк, юлга? — диде Һади.

— Әйе, юлга! Владимир Ильич миңа тулы вәкаләт бирүче мандатка кул куйды. Беренче августта кузгалабыз.

## 2

Казанда иртәдән үк коеп яңгыр ява башлады. Күк белән җирне тоташтырган иксез-чиксез су чаршавы ишелеп-ишелеп төшә, шәһәрне агызып китәргә теләгәндәй, авыр чабуы белән йортларга китереп бәрә. Вокзал тирәсендәге урамнар төбенә таш җәйгән ярсу инешләргә охшап калды. Бүген Мәскәү поездын каршыларга килүчеләр дә вокзал бинасыннан перронга чыгарга куркып утыралар иде. Яңгырның шундый шаулы һәм калын дивары аша алар, әлбәттә, поезд килгәнен дә ишетми калдылар.

Кинәт кешеләр сәерсенеп бер-берсенә караштылар. Бер мизгел эчендә бөтен тирә-юнь тирән тынлыкка чумды. Яңгыр шып итеп туктап калды.

Казанга килеп ябырылган туфан, әйтерсең лә, бер төш кенә булган иде! Әле генә килеп туктаган поездны күреп, каршы алырга төшүчеләр, аяк астындагы суны ера-ера, перрон буйлап йөгерделәр. Алар нибарысы алты кеше иде.

Иң алдагы вагоннан Мулланур төште, аның артыннан Һади белән Пиктимер сикерде. Ишектә Әдһәм Дөлделевичның зур гәүдәсе күренде.

Башка вагоннардан перронга сибелгән кызылармиячеләр шунда ук корал бушатырга керештеләр.

Мулланурны кочагына алган Шейнкман да хәл-әхвәл сорашуны корал бушатып ятучы әнә шул егетләргә ымлап башлады.

— Кайтуыгыз бик әйбәт булды бит әле! Үзегезне дә, «күчтәнәч»ләрегезне дә дүрт күз белән көттек... Күпмеләп булыр анда?

— «Күчтәнәч»не әйтәсеңме? Берәр чәйлек булыр...— дип елмайды Мулланур.— Калада ни хәлләр соң? Эшчеләр кайсы якта?

— Хәлләр төрлечә... Ләкин эшчеләр безнең белән. Шәһәрне сакларга исәбебез бөтен. Корал гына җитсен!

Күк йөзе ачыла төште, болытлар арасыннан аксыл йөзле кояш карап тора башлады. Вахитов белән Шейнкман, сүзгә мавыгып, бу үзгәрешне сизмәделәр дә шикелле. Мулланур юл уңаенда сорау арты сорау яудыра, шәһәрдәге көчләр нисбәтен төгәлрәк чамаларга тырыша иде.

— Яков Семенович, хәл чынлап та шомлымы?

— Кызганычка каршы, сез уйлаганнан да шомлырак шул. Шәһәрдә ак офицерлар. Авылда кулаклар бик көчле. Эсерлар шашына... Синең кайтуыңны күк капусы ачылуын көткән кебек көттек.

Мулланурның сораулы күз карашын тоеп, Шейнкман сүзен дәвам итте:

— Мөселманнар арасында синең абруең бик зур. Кешеләр сиңа иярерләр, дип уйлыйм.

— Ә эсерларга?

— Ул хакта сорама да инде... Менә иртәгә волость крестьян комитетлары съездын җыябыз.

— Шулай укмыни?

— Нишләмәк кирәк. Башка чара юк... Авыл ярлыларын үз ягыбызга ныклап каратыр чак җитте. Большевикларның авыр хәлдә калганлыгын аңлатырбыз. Ни әйтсәң дә, җирне бит эсерлар түгел, без бирдек аларга.

— Әгәр эсерлар провокация оештырсалар?

— Куллары кыска.

— Кыска микән соң? Әгәр сине дөрес аңлаган булсам, авылларда, бигрәк тә баерак төбәкләрдә, эсерларның йогынтысы әле шактый көчле, күрәсең. Мондый съездга алдан ук, сиздермичәрәк әзерләнәсе калган. Һәм бик-бик җентекләп!

— Анысы, без дә кул кушырып утырмадык инде.

— Ярый. Күз күрер... Крестьян комитетларының һәммәсенә дә большевиклар кердеме?

— Юк шул, кызганычка каршы, һәммәсенә дә булмады...

«...Алай— дип уйлап куйды Мулланур.— Съезд өчен җайсыз вакыт сайланган. Әй, ашыкмаган булсаларчы... Бөтен көчне эшчеләр отрядлары төзүгә биргән булсаларчы...»

Ләкин хәзер инде бу хакта сүз кузгатуның соң икәнлеге көн кебек ачык иде.

Көн азагына таба, ниһаять, алар бергә җыелып, иң төп мәсьәләләр турында киңәшергә утырдылар.

Өченчесе — күптән түгел генә Көнчыгыш фронтның командующие итеп билгеләнгән Иоаким Иоакимович Вацетис иде. Гәүдәгә ул төп кебек таза, килеш-килбәте — гомерлек хәрбиләрчә, җыйнак, ыспай. Акыллы-

житди чыраена, бигрәк тә чәче коелган башына карап, Мулланур белән Шейнкманга ул шактый карт булып күренде. Югыйсә командующийга әле нибары кырык биш яшьләр тирәсе генә иде.

Вацетис сүзне хәрбиләрчә кырт кисеп башлады:

— Разведка мәгълүматлары буенча,— диде ул, һәр сүзне аерым-ачык әйтеп,— дошман бүген иртән һөҗүмгә күчәргә маташып карады. Төш авышкач, акларның флотилиясе, искәрмәстән шәһәр пристаньнары тирәсенә үтеп кереп, Идел ярына десант төшерде.

— Атака кире кайтарылдымы? — дип бүлдерде Мулланур.

— Фронт штабы шунда ук ул районга Бишенче латыш укчы полкын һәм беренче татар-башкорт батальонын җибәрде,— диде Вацетис.

— Аларга ярдәмгә Алафузов һәм Крестовников заводларыннан эшчеләрнең коммунистик отрядлары китте,— дип өстәде Шейнкман.

— Әйе, анысы да бар,— дип раслады командующий.— Безнең гаскәрләр бик тиз һөҗүм итеп, десантны ярдан алып ташладылар. Дошманның ике корабы суга батырылды.

— Ә менә монда нәрсә булды? — дип, Мулланур картадан Югары Ослан тирәсен күрсәтте.

— Безнең эшләрне белеп торасыз икән,— дип гаҗәпләнде Вацетис.— Анда бик авыр хәл килеп чыкты... Чехлар безнең разведка отрядын уратып алганнар. Тигезсез бәрелештә барлык иптәшләр дә һәлак булган.

Мулланурның чырае караңгыланып китте.

— Бернишләр хәл юк. Сугыш...— Вацетис гаеплесыман җилкәләрен җыерып куйды.— Сугыш корбансыз булмый.

Шушы гади, кырыс хакыйкатьне расларга теләгәндәй, ачык тәрәзәдән җыр ургылып керде:

Смело-о мы в бой пойдем
За власть Совето-ов.
И, как один, умрем
В борьбе за это...

Җыр, ничек искәрмәстән башланган булса, кисәк кенә өзелеп тә калды. Ләкин авыр солдат итекләренең тигезсез дөпелдәве, ераклаша барып әле шактый озак ишетелеп торды.

— Эшчеләр отряды,— дип куйды Шейнкман, үзалдына гына әйткән кебек.— Кабан аръягында позиция биләргә киттеләр.

Өчесе дә торып тәрәзә янына килделәр. Урам буйлап шундый ук икенче отряд узып бара иде. Эшчеләр төрлесе төрлечә киенгәннәр. Күбесенең башында кепка. Хәрбиләрчә бер аяктан атламасалар да, адымнары нык, сафлары шактый тигез. Йөзләре дәртле күренә. Иң мөһиме — һәркайсының иңендә винтовка.

Мулланурның эченә җылы йөгерде: винтовкаларны бик вакытлы алып кайтканнар икән!

— Сынатмаслар микән? — дип уйчан гына әйтеп куйды Вацетис.— Өйрәтелмәгән кешеләр бит.

— Болар сугыш һөнәренә баррикадаларда өйрәнгән эшчеләр,— дип җавап бирде Шейнкман.— Аларда — революциянең төп көче...

### 3

Шул ук кичне, күз бәйләнү белән, штаб урнашкан Стахеев йортыннан озын буйлы, киң җилкәле бер ир-ат килеп чыкты. Як-ягына каранып алгач, башын якасына яшерердәй булып иелде һәм урам буйлап тиз-тиз генә каядыр китәргә ашыкты.

Кичке тынлыкта, тәрәзә күзе төшеп чәлпәрәмә килгән кебек сискәндереп, кыз бала тавышы яңгырады:

— Әдһәм!

Озын буйлы кеше баскан төшендә катып, куырылып килде:

— Галия... Син монда нишләп йөрисең? Бер ялгызың... Караңгы төшкәндә...

— Синең яныңа килүем иде, Әдһәм! Ничек җайлы килеп чыкты әле! Әз генә кичеккән булсам да, очрашмый идек бит.

— Минем эш белән китеп барышым шул.

— Алайса, сине озата барыйм, яме? — дип, кыз Дөлделевичны култыклап алды.

— Юк, Галия, ярамый,— диде Әдһәм, пышылдауга күчеп.— Бик ашерен эш бу. Аерата мөһим бурыч йөкләнде миңа.

— Шулаймыни?..— Кызның тавышы калтырап чыкты.— Ә минем сине бик күрәсем килгән иде... Әйтәсем килгән иде...

— Шулай ук кирәкле сүзмени? Ашыгычмыни?

— Кирәкле шул... Минем өчен... Сиңа да кирәкле хәбәр булыр дип уйлаган идем.

— Соң, әйт инде! Әйт! — Дөлделевич, түземе бетеп, Галиянең кулын кысып тотты. «Нәрсәдер белә, ахрысы... Сизенде микәнни?...» — дип хафага төште ул.

— Әдһәм, җаным! Безнең... бәләкәебез булачак!

Әдһәм, каушап, Галиянең кулларын ычкындырды.

— Безнең? Ничек инде... безнең?

— Син шатланмыйсың! — дип ачынды Галия.— Шулай буласын белгән идем мин...

Әдһәм ялгышын төзәтергә ашыкты:

— Гафу ит, мин башта аңлап җиткермәгәнмен, төрле уйлар белән буталган чагым, башыма тиз генә барып җитмәде. Бу бит... бигрәк көтмәгәндә...

— Мин инде сиңа аны Мәскәүдә үк әйтәсем килгән иде. Тик ул чакта әле үзем дә ачык белеп бетерми идем. Хәзер инде беләм... Син нишләп сүзсез калдың, Әдһәм?

— Мин шатмын... Бәхетлемен... Тик... вакыты нинди бит... Тынычлан, Галия. Иртәгә бу турыда иркенләп сөйләшербез, яме... Хәзергә мин китим инде.

— Шулай да сине озата барыйм әле? Әз генә булса да?

— Юк, юк! Һич тә ярамый. Син хәзер үзеңне сакларга тиеш. Безнең булачак бәләкәчебез турында уйларга тиеш... Бәләкәй Әдһәм турында...

Якын кешесе белән янәшә басып торуы һәм булачак бәбиләрен «бәләкәй Әдһәм» дип атавы Галиянең башын әйләндерде, бу мәлдә ул искиткеч бәхетле иде. Әдһәмне яратып, янып үбеп алды да, кая басканын да белмичә йөгереп китеп барды Галия.

Дөлделевич, кесәсеннән кулъяулык алып, маңгаена бәреп чыккан салкын тирне сөртте.

— Шул гына җитмәгән иде,— дип теш арасыннан сыгып чыгарды.— Менә ичмасам, каптым! Уеннан уймак чыкты. Хәзер инде җиңел генә котылу юк. Ничектер җаен табарга туры киләчәк...

Тагын бер кат тирә-юньгә күз йөртеп алгач, ул юлын дәвам итеп, якындагы тар тыкрыкка борылды һәм тәбәнәк кенә бер өйнең ишегалдына кереп китте. Ярым караңгыда таш баскычны кармалап менде дә зур, авыр ишекне җилкәсе белән этте:

— А-а, дустым килгән! Синме соң бу? — дип кочак җәеп каршы алды аны Хафиз.

Юхалануымы, әллә мыскыл итеп кылануы идеме бу Хафизның — һичкайчан аңламассың. Шулай да бу юлы аның йөзеннән елмаю әсәре бик тиз качты. Күрешү белән үк:

— Я, яңалыклар бармы? Нәрсәләр майтара алдың? — дип кырыс-дорфа гына сорау бирде.

— Исеңдә калдыра бар. Дүрт йөз бомба. Дүрт йөз дә өч винтовка. Унбиш мең патрон...

— Ә пулеметлар?

— Дүртәү.

— Эшчеләрне коралландырырга уйлыйлармы? Кайчан корал таратачаклар?

— Иртәгә.

— Тоткарлап буламы?

— Бик кыен. Бу эш белән Вахитов үзе шөгыльләнәчәк.

— Шулай да тоткарларга кирәк. Ничек кенә булса да! Һич югы кечкә кадәр сузасы иде. Безнекеләр бит инде Казанга бик якын.

— Мин кулдан килгәннең барысын да эшләрмен.

— Әгәр шуны эшли алсаң!.. Бу бит тулы бер полкны сафтан чыгару белән бер булачак. Аңлыйсыңмы шуны? Я, хәзер барысын да бәйнә-бәйнә сөйлә.

— Нәрсә турында?

— Сезнең батальонның ничек урнашуы, кораллануы, нинди бурыч үтәргә билгеләнүен... Бер генә вак-төяген дә онытып калдырма. Ну!

Әле кайчан гына үзен малай-шалай урынына куеп, мескенләнеп йөргән Хафизны, әйтерсең лә, алыштырып куйганнар иде. Хәзер аның йөзенә тәкәбберлек төсе йөгергән, тавышы бөердән чыга, кыскасы, дилбегәнең үз кулында икәнлеген бөтен кыланышы белән сиздереп тора. Шушы үзгәрешне күрү — ниһаять, үзенең бу уендагы урынын аңлый башлау Дөлделевичка, әлбәттә, бик күңелсез иде... Ләкин инде бернишләр дә хәл юк: үлгәч тәүбә кабулмыни...

## Җиденче бүлек

### 1

Алтынчы август кояшы, төшлек турысына күтәрелеп, Казанны баштанаяк нурга коендыра, тәрәзәләрдә, чиркәү гөмбәзләрендә ялтырап күзне чагылдыра иде. Чалт аяз. Эссе. Яфрак та селкенми.

Пиктимер белән Габдулла бушап, тынып калган урамнар буйлап Вахитов тукталган «Никольский номерлары»на таба юл тоттылар. Кәефләре әйбәт. Һәркайсы үз уйларына чумып атлый иде. Кинәт Габдулла куркып-шомланып кычкырып җибәрде:

— Ә-әй! Карале, нәрсә ул?!

— Кайда? — дип як-ягына каранды Пиктимер.

Габдулла якындагы таш коймага сыенып, сак кына үрелеп карады; сугышта күп йөрергә туры килмәсә дә, солдатта алган сабак ярап куйды тагын.

Ерак та түгел, урам чатыннан кулына винтовка тоткан бер кеше сикереп чыкты. Шунда ук иелә-сыгыла вокзал ягына таба йөгерде. Аның артыннан берәм-берәм башкалар йөгерешеп үтә башлады.

— Һәй, карт куян! — диде Пиктимер.— Безнекеләр ич бу.

Ләкин шул мизгелдә үк иң алдан йөгерүче офицерның кояшта ялтырап киткән погонын күреп алды.

— Чехлар!..

Хәзер инде Габдулла аңа ышанып җитмәде:

— Нишләп чехлар булсын? — дип пышылдады.

— Күрмисеңмени? — диде Пиктимер һәм койма артыннан тагын башын сузып карады. Алтын укалы погоннарын ялтыратып янә бер офицер һәм берничә солдат инде бу юлы туп-туры алар яшеренгән якка таба йөгерәләр иде.

Пиктимер тиз генә төзәп атып җибәрде. Алдан йөгергән офицер, кул-

ларын һавада бутап, урам ташына чәнчелеп төште. Аптырашып, туктап калган солдатлар төрлесе-төрле якка шарт та шорт ата башладылар.

— Габдулла! — диде Пиктимер.— Йөгер штабка. Бернигә дә карамыйча комиссарны эзләп тап. Шәһәргә чехлар саркылып кергәнен хәбәр ит.

— Юк инде,— диде Габдулла.— Мин сине ташлап китә алмыйм. Үләргә тек бергә үләргә.

Габдулланың шулай тәрәлеп, хәтта киреләнеп торуыннан Пиктимер гаҗиз калды. Аның уенча, хәзер иң мөһиме Мулланурны кисәтү иде. Мөгаен, шәһәргә дошманның артык зур булмаган бер төркеме генә үтеп кергәндер. Бәла-каза чыкканчы, аны юк итәргә кирәк!

Картны яхшылык белән күндерә алмагач, Пиктимер усал итеп кычкырып җибәрде:

— Габдулла! Соңгы чиктә мин синең командирың да бит әле. Хәзер үк боерыкны үтисе бул. Казанны син миннән яхшырак беләсең. Соңыннан җавап бирәсең булыр!

— Ярар,— диде Габдулла теләр-теләмәс кенә.— Мин хәзер әйләнеп килә алайса. Син үзеңне харап итә күрмә!

Пиктимернең яшеренгән урыны әйбәт: койма артыннан бөтен урам чаты күренеп тора! Дошманнар бүтән күренмәгәч, ул баягы фикеренең дөреслегенә ышана бара иде. Әйе, ак чехларның кечкенә бер төркеме генә очраклы рәвештә үтеп кергән булса кирәк. Ләкин, шулай дип уйлап өлгерә алмады, арттан тагын ату тавышлары ишетелде.

Әле генә Габдулла киткән тарафтан, штаб ягыннан, бөтен тирә-якны иңләп, чех солдатлары якынлаша иде. Хәзер бер шик тә калмады: димәк, фронт өзелгән, дошман шәһәргә кергән. Бу — инде ниндидер аерым төркемнәр генә түгел, ә чехословак корпусының зур гаскәри берләшмәсе ныклап торып Казанны штурмлауга керешкән, дигән сүз.

Урам чатына каяндыр карт үгез кебек шыксыз броневик килеп чыкты һәм авызыннан ут түкерекләре чәчеп, туп-туры бирегә таба килә башлады. Пиктимергә уйлап торырга ара юк иде, ул тимер үгезнең «күзләренә» — маңгаендагы тар ярыкка төбәп атып җибәрде. Броневиктагы пулемет шып итеп туктап калды.

Ләкин Пиктимернең үзен дә күреп калдылар, ахрысы. Шунда ук коймага таба төрле яктан солдатлар үрмәли башлады.

«Я, туган, нык тор! — дип эндәште Пиктимер үзенә-үзе.— Хәзер сиңа мунча булачак!» Ул биленә кыстырган бердәнбер бомбасын тартып алды, аны кулында нык итеп кысты һәм бөтен буена торып басты. Чехлар аны бирелә дип уйлап, өерләре белән өстенә ябырылдылар.

Күзне ачытып ялкын сирпелде. Каты шартлау тавышы таш коймага бәрелеп яңгырады. Тирә-юньгә куе төтен җәелде. Шундый ук кара пәрдә Пиктимер Марданы да уратып алды.

Шәһәр үзәгендә дә каты атышлар бара иде. Кырмыска оясы кебек кайнап торган «Никольский номерлары»нда бер җан әсәре сизелми. Коридор буш, ишекләрнең күбесе шар ачык... «Качып өлгергәннәрме, әллә барысын да атып киткәннәрме?» — дип аптырашта калды Габдулла. Шулчак Вахитов яшәгән номерда нәрсәнеңдер шапылдап төшкәне ишетелде. Бәләкәй мич алдына иелеп, комиссар ниндидер кәгазьләрне ерткалый һәм утка сала бара иде.

— Мулланур! — дип ярсып һәм гаҗиз булып кычкырды Габдулла.— Шәһәрдә чехлар!

— Беләм, бабай, барысын да беләм,— диде Мулланур артына да борылып карамыйча. Ул артык тыныч кебек иде.

— Нишләп торабыз соң? Тизрәк штабка хәбәр итәргә кирәк!

— Соң инде,— диде Мулланур, кайбер кәгазьләрне янындагы кечкенә күн сумкага салып.— Штаб җавап бирми, хәзер анда, күрәсең, берәү дә юк.

— Мин сиңа ничек булышыйм, комиссар?

— Хәзер Һади килеп җитәргә тиеш. Аңа каршы чыга тор. Минем тагын аз гына эшем калды...

Мулланур яңадан мич янына иелде.

Габдулла ишегалдына чыгып, як-ягына каранып торды. Бер кеше дә күренми. Төрле яктан винтовка, пулемет тавышлары ишетелә. Вокзал тирәсендә, ахрысы, туптан аталар. Нишләп озаклады соң бу Һади? Тиккә басып торудан эче пошып, кемне дә булса очратмаммы дип, Габдулла штаб ягына таба юнәлде. Ләкин беренче чатта ук аның каршысына чехлар килеп чыкты...

Һади Маликов йөгереп килеп кергәндә, Мулланур иң соңгы кәгазьләрне утка ташлап тора иде.

— Безнекеләр әлегә бирешмиләр,— диде Һади, еш-еш сулыш алып.— Бигрәк тә беренче батальон кызу сугышлар алып бара. Алар янына үтеп чыгарга тырышырбыз.

— Менә моны каядыр яшерергә кирәк,— дип Мулланур, күн сумкасын Һадига сузды.

— Яндырып өлгерә алмадыңмыни?

— Юк, бу — партия документлары һәм мандатлар. Аларны җуярга ярамый. Без әле әйләнеп кайтырбыз.

— Кая яшереп калдырыйк соң?

— Беләсеңме! Әтинең бакчасына күмәргә кирәк моны. Аннан беркем дә эзләп йөрмәс. Әйдә, киттек тизрәк!

Ишегалдына чыгу белән, Мулланур нәрсәседер онытылып калгандай, шып туктады:

— Син Габдулла бабайны күрмәдеңме?

— Юк.

— Шунда гына булырга тиеш иде бит. Кая киткән соң ул, ә? Мулланур картны исеме белән дәшеп караса да, бернинди тавыш-тын ишетелмәде. Хәзер аны эзләп йөрергә дә вакыты түгел иде.

— Ярар,— диде Мулланур, кулын селтәп.— Бабай югала торганнардан түгел. Аңа әле бездән башка тынычрак та булачак.

Портфельне күмгәч, Мулланур өйдән әтисенең иске чапанын алып чыкты.

— Мә, Һади, рәхәтен күр, моны кисәң, сиңа илтифат итүче дә булмаячак. Исән-имин чыксаң, безнекеләргә барысын да сөйләрсең...

— Ә син?.. Аерым-аерым китик дисеңме әллә?

— Юк, мин шәһәрдә калам.

— Саташма, Мулланур! Шәһәр дошман кулында. Сине монда эте-бете дә таный бит.

— Борчылма, Казан зур ул, яшеренермен. Эшчеләрнең коралы баш күтәрүен әзерләргә кирәк. Бу бит озакка түгел. Чехларны без моннан бик тиз өреп чыгарачакбыз.

Тагын да сүз көрәштерүнең мәгънәсе юк иде.

— Сиңа бер генә үтенечем бар,— диде Һади, дустын кочаклап.— Сак бул, зинһар.

— Сиңа да шул теләк, Һади. Безнең яшәвебез революция өчен кирәк. Ярый, туган, көрешкәнчегә кадәр...

Һади китте. Артына борылып карамады. Күңеле сыкрый иде аның. Күңеле сизә иде: Мулланур белән бу аерылу, ахрысы, бик озакка булыр. Ә бәлки, бөтенләйгәдер...

## 2

Әлим Хәкимовка ялланган этләр бөтен Казанны айкап чыктылар, борыннарын сузып әрле-бирле йөгерештеләр. Вахитов исән-имин иректә йөргәндә үзенә һәм дус-ишләренә көн булмасын Әлим яхшы аңлый. Бу эшне ул турыдан-туры Хафиз белән Әдһәмгә йөкләде. Алар, әлбәттә, иртәме-соң-

мы уңышка ирешәселәренә ышаналар. Ләкин әлегә бернинди дә нәтиҗә күренми: Вахитов суга төшкән кебек юкка чыкты. Шунлыктан Дөлделевичның аеруча кәефе юк иде. Кинәт ишек шакуларына да:

— Керегез...— дип мөгрәп кенә җавап бирде.

Базык гәүдәле җиз мыеклы поручик килеп керде:

— Комиссар Вахитовның элемтәчесе кулга алынды! — диде.

— Элемтәчесе?! — дип кычкырып җибәрде Дөлделевич.— Кайда соң ул? Хәзер үк миңа китерегез! Үзем сорау алам!

Поручик, ишекне ача төшеп, кемгәдер әмер бирде:

— Кулга алынган хатынны кертегез!

Теге яктан: «Җәһәтрәк атла, сөйрәлчек! Яле!..» — дип җикеренгән тавыш ишетелде. Дөлделевич түземсезләнеп ишеккә карады һәм телсез калды: эткәли-төрткәли Галияне алып керәләр иде. Бичаракайга күп газап күрергә туры килгәндер, күрәсең: өстендәге күлмәге ерткаланган, йөзе танымаслык булып күгәргән. Ләкин, әлбәттә, бу — ул иде.

— Галия... — диде Дөлделевич, телен көч-хәл белән әйләндереп.— Синме соң бу?

— Әдһәм! — дип йөрәк яргыч итеп кычкырды Галия.

Аптырап калган поручик һәм солдатлар күз алдында ул Дөлделевич каршына атылып килде, аның кулларыннан тотып алды.

— Юк! Юк! — дип күз яшьләренә тыгылып пышылдады Галия.— Ышанмыйм!.. Миңа сөйләсәләр дә, ышанмаган идем. Хәзер дә ышанмыйм... Бер генә сүз әйт! Мин сиңа шунда ук ышанырмын... Нигә син дәшмисең, Әдһәм?

Әдһәмнең теле тартышты. Тешләре кара-каршы ябышкан шикелле иде.

Куркыныч төштән уяна алмаган кебек, Галия авыр ыңгырашып куйды:

— Алай булгач, барысы да хак икән...

Бу сүзләрдән Дөлделевич исенә килеп, күз ачып йомганчы үз-үзенә бик ышанган кыяфәткә керде, Галиянең иңенә кулын салды һәм күзләренә озак итеп карап торды:

— Юк, мин хыянәтче түгелмен,— диде.

— Ничек инде? — диде Галия аптырап.— Ә бу солдатлар?!. Бу нинди күз бәйләш уены соң?

— Сезгә китәргә мөмкин,— диде Дөлделевич, поручикка һәм солдатларга ымлап. Тегеләрнең әле бу күренештән һаман ис-акыл җыя алмый торуын күреп, кулын селтәде: — Барыгыз дим бит!

Дөлделевич Галияне кәнәфигә утыртты, графиннан стаканга су салды.

— Тынычлан әле башта. Мә, эчеп куй...

Галия аның кулын кисәк этеп җибәрде, су келәм өстенә түгелде.

— Кирәкми. Минем түземлегем җитәрлек. Һушы китеп егылыр дип курыкма... Я, мин көтәм! Син бит бу күз бәйләшнең нәрсә икәнлеген аңлатырга теләгән идең.

— Хәзер түгел ул күз бәйләш...— диде Дөлделевич әкрен генә.— Элек иде ул... Мин үзебезнең мөселман эшенә намуслы хезмәт иттем, ә Вахитов безнең милли мәнфәгатьләрне большевикларга сатты. Менә кем ул сатлык җан!

— Ничек синең телең күтәрелә, Әдһәм!

— Аңлыймын, сиңа бу хәлләрне башыңа сыйдыру кыендыр. Без бик катлаулы заманда яшибез. Революция — хатын-кыз эше түгел. Син бу хакта уйламаска тырыш. Туасы балабыз турында уйла.

Соңгы сүзләре шулай көчле тәэсир итәр дип Әдһәм һич көтмәгән иде. Галия кинәт, хәлсезләнеп, кулларын салындырды һәм сабый бала кебек үкси-үкси елап җибәрде. Карынындагы җан парәсен искә алу гына да аны фикерләү куәсеннән, каршы тору мөмкинлегеннән, үз карашларын яклау сәләтеннән дәррәү мәхрүм итте.

— Әдһәм, мин куркам! Куркам! Куркам! — дип такмаклый башлады ул үкси-үкси.— Үзем өчен түгел, аның өчен! Безнең бәләкәебез өчен... Мине җибәрерләр микән? Син ничек уйлыйсың?

— Бу ни диган сүз? Җибәрерләр, әлбәттә. Мин дә алардан синең белән бергә китәм, Галия. «Бүлгәләнмәс бердәм империя» өчен минем дә кан коясым килми. Китәбез! Тик моның өчен...

— Нишлик, җаным? Нишлик?

— Иң җиңел юлны сайларга кирәк. Менә шул өстәл янына утыр да, берничә сүз яз.

— Нәрсә дип языйм соң?

— Вахитов белән иң соңгы очрашуыгызны исеңә төшер. Ул сиңа нәрсәләр әйтеп калдыруын яз... Берничә сүз генә. Я, нигә уйга калдың инде? Кил, утыр...

— Юк, булмый, кулымнан килми! Теләсәң нишләт мине, сатлык җан була алмыйм.

Дөлделевичның маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Ул инде максатыма ирештем дип уйлаган иде. Тагын бер талпынып алса, Галия түзмәс, аның хәйләкәр, көчле басымына тулысынча буйсыныр кебек иде. Тик шушы нечкә билле, йомшак күңелле кызыйга кинәт каяндыр яңа, җиңелмәс көч иңеп өлгергән иде.

— Мин берни дә әйтмәячәкмен. Теләсәгез нишләтегез.

— Акылыңа кил, Галия! Аңла: синең хәзер бүтән котылу юлың юк. Кирелек белән барсаң, моның ахыры бик начар бетәчәк.

Куркытырга азаплану — хата иде. Бу сүзләр Галиягә тагын да көч өстәгән кебек кенә булды. Ул башын югары чөйде, күзләреннән очкыннар чәчелде:

— Синең янауларыңнан курыкмыйм мин!

— Ни сөйләгәнеңне колагың ишетми. Әнә, күрше бүлмәдә бөтенләй бүтән кешеләр утыра. Алар синең белән болай лыгырдашып тормаячак... Аларга әле таза-таза ирләр дә чыдый алмады.

— Син үз balaңның анасын шул газраилләр кулына бирерсеңме?

— Алар миннән сорап тормаячак! Җүләр сатып торма монда. Синең Вахитов элемтәчесе булуың аларга күптән билгеле.

— Я, алайса, нәрсә дип вакытны сузып торасың. Чакыр дусларыңны сөяк кимерешергә... — Галия үзалдына гына сөйләгәндәй ярым пышылдый, күзләре нәфрәт белән яна иде.— Уйласаң, акылдын язарлык: нинди җирәнгеч хәшәрәтне яратканмын бит... Тфү!

Дөлделевичның бу кадәресенә түземе җитмәде:

— Дәшмә...— дип, Галиянең чәченнән умырып алды.— Дәшмә, әнчек, яп авызыңны!

Әлим Хәкимов, йомшак кәнәфигә җәелеп, кулындагы кылдан үргән камчысы белән уйнап утыра һәм мыек астыннан гына елмаеп, Әдһәмнең бәргәләнүләрен күзәтә иде.

— Ничек, кардәш? Бу тутый кош ухайладымы үзеңне? Күз төшмәслек түгел шул! Поручик та, кыр кәҗәсе кебек... диде аны.

Дөлделевич каш астыннан усал итеп карап куйды.

— Тагын бер кат очрашып карамыйсыңмы? Серләрегез килешә кебек бит...

— Юк инде, миннән бүтән булмый,— диде Дөлделевич кулын селтәп.

— Алайса үзем сөйләшәм, Әдһәм әфәнде...Гаеп итештән булмасын.

Дөлделевич, авыр сулап, Әлимнән бушап калган кәнәфигә чумды.

Берникадәр вакыт күрше бүлмәдән Хәкимовның күгәрчендәй гөрләве ишетелеп торды. Сүзләре аңлашылмый, ләкин аның ярсыганнан-ярсый баруы сизелә. Һәм кинәт — үзәк өзгеч тавыш. Галия тавышы... Түзә алмаслык авыртудан шашынып кычкыру иде бу...

Дөлделевич бераздан бу тавышның кабатланасын һәм тагын да көчәясен белә, аны тыңлап торырга көче җитмәсен аңлый. Шуңа күрә ул ашыгып урыныннан торды һәм урамга чыгып китте.

Икенче көнне поручик Дөлделевичка кереп хәбәр итте: теге яшь хатын — Вахитовның элемтәчесе — газаплауга түзә алмыйча җан биргән.

Комиссарның кайда яшеренгәнен барыбер әйтмәгән. Чибәр иде, чукынган, кыр кәҗәсе кебек шәп иде...

3

Ике катлы йорттан өстенә зәңгәр костюм, башына йомшак фетр эшләпә кигән чандыррак бер кеше чыкты. Төтен сыман пыялалы күзлеге аша тирә-юньгә күз салып алгач, тиз генә урам аша чыкты. Хәзер әнә шул чаттан борылып, тар урам буйлап бераз барасы. Анда күптән көтеп торалардыр аны. Шәһәрдә калган большевиклар инде эшне җайга салып килмәләр иде.

Мулланурга үз гомерендә шымчылар һәм «койрыклар» белән шактый эш итәргә туры килде. Шуңа күрә тәҗрибәсе юк түгел, күңеле шунда ук сизеп алды: бу юлы аның артыннан күзәтәләр. Ул адымын ешайта төште. Тагын, тагын бер талпынып аласы да, таныш ишегалды аша гына йөгереп үтәсе... Печән кибәнендәге энә кебек юкка чыгачак. Ләкин арттан адымнар якыная. Көтмәгәндә генә ишегалдында да кемнәрдер пәйда булды. Юк, алда юл ябык! Китеп булмаячак! Бу — чын-чынлап камап алу, бу — алдан исәпләнгән ау иде...

Әлим Хәкимов тантана итте.

Изелгән, йолкынган бичара комиссарның тиздән үз каршында басып торачагын күз алдына китереп, ул үзенчә чәнечкеле сүзләр, сораулар әзерләгән иде. Ләкин әсирнең үзе белән күрешү Әлимнең муенына бозлы су салган кебек тәэсир итте. Вахитов, кайчандыр комиссариат оештырып йөргәндә Әлим белән очрашкан кебек үк, үз-үзенә ышанган, көчле кыяфәттә басып тора һәм әле гүяки яңадан: «Миңа калса, хәзер килеп туган хәлне син бигүк дөрес бәяләмисең шикелле...» — дип әйтергә җыена иде.

Әлим, чыннан да, аның сорау бирүеннән куркып, сүзне үзе башларга ашыкты:

— Синең милләткә хыянәтеңне халык хөкем итәр,— диде ул, тез буыннарының калтыравын басарга тырышып.— Безнең исә бер генә сорау бар. Акчаны кая куйдың?

Вахитов дәшмәде. Әлим моны үзенчә аңлады:

— Комиссариат кассасын кая яшердең, дим мин сиңа! — дип җикерде.

— Ә сиңа ник кирәк ул? — дип елмайды Мулланур.— Ул акчаларга Совет власте хуҗа бит. Алар — халык милке.

— Халык — без ул! — дип кычкырды Әлим.

— Сезме? Сез — тере мәетләр...— диде комиссар. Аның йөзенә шундый ачык булып җирәнү һәм нәфрәт төсе чыкты — Әлим, артык түзә алмыйча, кулындагы камчы белән бөтен көченә Мулланурның йөзенә китереп сукты.

Бу — калганнар өчен сүзсез әмер иде. Алар эт өере кебек ябырылып, куллары бәйләнгән комиссарны аяктан ектылар. Адәм кыяфәтле бу зобанилар Совет властена карата җыелган чиксез ачудан хәзер канлы бер йодрыкка әверелеп калганнар иде.

— Туктагыз! — дип кычкырды Әлим.— Үтерергә өлгерербез әле! Башта сорау алырга кирәк!

Ләкин аны беркем дә тыңламады.

Комиссар Вахитовның, ниһаять, кулга алынуын белеп, полковник Сикорский аны хәзер үк үзенә китертергә кушты.

Вахитов белән очрашу буласын ишеткәч, Сикорский кабинетына берничә офицер җыелды. Август Петрович Амбрустер ашыгып килеп керде: мәшһүр татар комиссарын аның да күрәсе килә!

Ләкин канга баткан әсирнең Мулланур Вахитов икәнлеген тануы да читен иде.

— Бу ни бу? — дип бозлы-салкын тавыш белән сорап куйды Сикорский.— Поручик! Мин сездән сорыйм!

Комиссарны алып кергән поручик кыл кебек тартылды.

— Кулга алганда әсир коточкыч каршылык күрсәтте,— диде ул, күзен дә йоммыйча.— Көч белән җиңәргә туры килде.

— Оят сезгә, поручик! — дип тавышын күтәрә төште полковник.— Сезнең аркада Вахитов әфәнденең әллә ниләр уйлавы бар... Вахитов әфәнде — зыялы кеше һәм безнең тарафтан иң әдәпле мөнәсәбәткә лаек. Чишегез аның кулларын!

Комиссарның кулларын шундук чиштеләр.

— Рәхим итеп, утырыгыз,— Сикорский аңа таба бер урындыкны этебрәк куйды.— Ә сез,— диде ул поручик белән солдатларга карап,— ычкыныгыз моннан! Эзегез дә булмасын! Ишәкләр...— дип дәвам итте полковник, тегеләр шым гына чыгып киткәч.— Менә шундый кешеләр белән эш итәргә туры килә инде безгә, кызганычка каршы. Вакыты шундый. Гаеп итмәгез, Вахитов әфәнде. Алар, һичшиксез, моның җәзасын алырлар...—Сикорский кызыл чырайлы капитанга борылды: — Врачны чакырыгыз. Хәзер үк.

Ниһаять, үз-үзеннән бик канәгать полковник комиссарга таба иелә төште:

— Күрәм, Вахитов әфәнде, сезнең хәлләр хәзер сөйләшерлек түгел. Ярый, вакыт бар әле. Ял итегез, хәл алыгыз, аннары иркенләп сөйләшербез,— диде.

Мулланур арыган күзләрен бер генә мизгелгә йомып алды. Бу хәрәкәтне үзенең сүзләре белән килешү дип аңлап, Сикорский канәгать төстә баш кагып куйды:

— Менә шулай...

Тиздән врач кереп, комиссарны үзе белән алып чыккач, полковник үзе утырган кәнәфидә киерелә төшеп:

— Өйрәнегез, әфәнделәр, менә шулай политик булырга,— диде.— Комиссар Вахитов — мөселманнар арасында бик популяр шәхес. Кызганычка каршы, моның белән исәпләшми булмый. Менә минем исәп — аны үзебезнең якка аудару. Сез ничек уйлыйсыз? Ә?

— Кадерле дустым, бу эшегез барып чыкмас дип куркам, — диде Амбрустер, башын чайкап.

— Мин алай дип кырт кисмәс идем,— дип каршы төште Сикорский.— Үлемнән һәр җан иясе курка. Бу дөньяда оҗмах рәхәтен татумы, әллә кара гүргә керүме... Мондый юл чатына кую теләсә кемне уйланырга мәҗбүр итә. Комиссар да бит, ни генә әйтсәң дә, тимердән ясалмаган. Сезнең белән безнең кебек үк алла бәндәсе ләбаса!

## Сигезенче бүлек

### 1

Пелатән — элек-электән яманаты чыккан төрмә: патша Россиясенең иң әшәке таш капчыкларыннан саналып килде. Аклар кулында ул җан суыручы убырга әверелде.

Бу көннәрдә төрмә шыгрым тулы. Күбесе — шәһәрдән китеп өлгерә алмаган совет һәм партия хезмәткәрләре, әсир сугышчылар, арада яралылары да байтак.

Мулланур Вахитовны да бирегә алып килеп яптылар.

Аны хәзер көн саен сорау алуга йөртәләр. Сорау алуның барышы көн саен полковник Сикорскийга җиткерелә бара. Ләкин әлегә бер нәтиҗә дә күренми. Комиссар, телдән калган кебек, бөтенләй дәшми.

Ниһаять, Сикорский аңардан үзе сорау алырга булды. Юк, ул бу очракта да «сорау алу» кебек тупас сүзне кулланмады:

— Ярый, миңа чакырыгыз әле аны. Үзем сөйләшеп карыйм,— диде.

Ишарә белән генә сакчыларны кире чыгарып, комиссарны аягүрә басып каршылады.

— Мин сезне бик җитди әңгәмә кору өчен чакырдым, Вахитов әфәнде,— диде ул йомшак кына.— Нindидер мәгълүматлар, гаскәр, корал саны — бу чүп-чар белән, әйдә, контрразведка малайлары шөгыльләнсен... Сезнең алар белән сөйләшергә теләмәвегез миңа аңлашыла. Әсирлеккә төшсәм, мин дә үземне нәкъ шулай тотар идем.

«Йомшак җәя»,— дип уйлады Мулланур.

— Әйе, Вахитов әфәнде, мин солдат кеше, хәрби антка тугрылык минем өчен буш сүз түгел... Ләкин мин солдат кынамы соң? Мин бит әле адәм баласы да. Шуңа күрә мин акылга күбрәк таянам. Сез дә, шәт, ул сыйфатыгызны югалтмагансыздыр дип уйлыйм...

«Нindидер яңа сүз әйтергә җыенамы соң бу? — дип уйланды Мулланур.— Тыңлап карыйк».

Сикорский, аның йөзендә кызыксыну билгеләрен абайлап, сүзен тагын да дәртләнебрәк дәвам итте.

— Без сезнең белән сугышлы уйнаучы малайлар түгел, шулай бит, Вахитов әфәнде? — дип комиссарның күзләренә карады полковник.— Тормыш ул искиткеч аяусыз җанвар... Мин сезне шушы аяусыз дөреслеккә туры карый аласыздыр дип өметләнәм...

— Сез мине фәлсәфә куертырга чакырдыгызмыни? — дип сорады Мулланур.

— Юк,— дип елмайды Сикорский.— Бу әле сүзнең башы гына. Мин сезгә үземнең әлегә чиксез властька ия булмавымны әйтергә теләгән идем. Шулай да бүгенге көнгә кадәр мин сезнең баш өстендәге әҗәл элмәген читкәрәк тибәреп тора алдым. Ышаныгыз, мин ихлас күңелдән сезне саклап калырга тырышам. Ләкин мине төрле яклап кысалар. Артык зыялы булуда, ялгыш өметләр баглауда гаеплиләр. Сезне үлем тырнагыннан алып калырлык көчем бар минем, әлбәттә. Тик бу эш әгәр үзегез булышсагыз гына барып чыгачак.

— Мин нишләргә тиеш соң? — диде Мулланур, полковникның тел төбе кая барганын күптән сизсә дә.

Сикорский, әһә, алма пешеп җитте, менә-менә авызга өзелеп төшә, дип уйлады һәм ачыктан-ачык:

— Безнең белән эшләвегез кирәк,— диде.

— Ник алай әйләндереп-тулгандырып йөртәсез? Турысын әйтегез: сез минем хыянәтче булуымны телисезме?

— Ах,— дип йөзен чытты Сикорский,— сез яңгыравык сүзләрдән әле һаман туймагансыз икән, Вахитов әфәнде! Дөреслекнең күзенә туры карыйк. Үзегезгә мәгълүм, Совет властена кабер казылган. Рус халкы аны кабул итмәде. Безнең гади халык, үзара гына әйткәндә, демократия өчен җитлекмәгән әле. Бүген-иртәгә безнекеләр Мәскәүне алачак. Борчылмагыз, мин сезгә Советлар вакытында биләгән урыныгызга тиң, хәтта аннан зуррак дәрәҗә ышандыра алам. Яхшылап уйлагач, сез минем тәкъдимне дөрес аңларсыз һәм кабул итәрсез дип уйлыйм.

— Юк, полковник,— Мулланур башын чайкады.— Сез ялгышасыз. Тәкъдимегезне мин кабул итмәячәкмен.

Сикорский бу сүзләрне колак яныннан гына уздырды.

— Хәзер үк җавап бирегез димим. Ашыкмагыз. Барысын да исәпләп карагыз. Сез — акыллы кеше...

— Вакытны сузу кирәк түгел, полковник. Сез инде яңгыравык сүзләр яратмыйсыз икән, мин бүгенге сөйләшү турында күңелемдәген әйтим. Сез бит, дөресен генә әйткәндә, үзегезнең боргалануларыгызга мине ышандырырга исәп тотмадыгыз. Бары тик миндә үлемнән курку тойгысы уяныр дип кенә өметләндегез. Һәм шул галиҗәнап Курку сезнең кулга әзер корбан китереп тоттырыр дип көттегез. Ләкин сез исәпкә алмагансыз: дөньяда куркудан да көчлерәк бер хаким бар.

— Шулаймы? Кем соң ул? — диде Сикорский, авызын чалшайтып.

— Ул — бөек инану көче,— диде Мулланур уйчан гына.— Сезнең өчен иман, идея — барысы да яңгыравык сүзләр генә булып тоела. Ә без үзебезнең инануыбызга шундый ачы һәм шундый газаплы тәҗрибә аша килдек, хәзер хәтта үлем куркынычы астында да аннан баш тартмаячакбыз.

Вахитовны инде күптән алып киттеләр, ә Сикорский әле һаман, башын куллары белән кочаклап, урыныннан кымшанмыйча утыра.

Ул үзен шушы үҗәт комиссар урынына куеп карады. Юк, юк, ул түзә алмас иде...

## 2

Ишегенә әллә дегет, әллә кара буяу белән зур итеп «15» саны сугылган камерада, комиссар Вахитов пәйда булганга карап кына берни дә үзгәрмәде кебек. Шул ук авыр тынчу һава, яман ис килеп торган шул ук шулпа... Шулай да ниндидер яңалык та бар һәм ул көннән-көн көчлерәк сизелә иде кебек. Күзгә күренмичә генә кешеләрнең кәефе үзгәрә башлады. Яшәүгә омтылыш көчәйде аларда. Һәм бу хәл, һичшиксез, янәшәдә генә Мулланурның булуы белән бәйле иде.

Башта ул ничектер, ялгыш кына ычкындырган кебек, үзенең Ленин белән бер сөйләшүен әйтә куйды.

— Туктале комиссар,— диде матрос тельняшкасы кигән киң җилкәле егет.— Син бутамыйсыңмы? Ул сүзләрне Ленин үзе әйттеме сиңа? Алайса, син Ленин белән якыннан таныш булып чыгасың бит... Шулаймы? — Матрос кырыс итеп, сынап карый иде.

— Якыннан таныш,— дип елмайды Мулланур.

Идәнгә тар гына булып кояш яктысы төште. Әллә шушы бер тотам кояш нурыннан, әллә комиссарның рухландыргыч сүзләреннән камера эче дә яктыра төшкәндәй булды. Өмет һәм ышаныч белән дәррәү яктырып киткән йөзләр Мулланурга таба борылды.

Камерадагылар бөтенесе аның тирәсенә өелделәр һәм тагын, тагын сөйләвен көттеләр. Ул Ильич белән беренче очрашуын искә төшерде. Комиссариат төзелгәч, Ленин белән сөйләшү-киңәшүләре турында телгә алды.

Шул урында, артык әсәрләнүдән булса кирәк, Казан янындагы сугышларда яраланган яшь татар егете түзмәде:

— Сөбханалла-машалла! Ленин безнең мөселман халкын шулай ук бик ярата микәнни? — дип куйды.

— Мөселманның ни катнашы бар монда? — диде баягы матрос аңа акыл биреп.— Ленин ул бөтен эшчеләрне ярата, безнең өчен гомерен бирергә әзер тора.

— Ә мин шулай дип аңладым... Ул безне, мөселманнарны, барыбер әз генә артыграк ярата кебек... Дөрес бит, комиссар?

Мулланур, егетнең күңелен төшермәс өчен, аның иңенә кулын салып, көлемсерәде генә.

Комиссарны допроска алып киткән чакларда камерадагыларның кәефе шунда ук үзгәрә. Барысы да чираттагы сорау алудан аның әйләнеп кайтмавы ихтимал икәнне аңлый. Комиссар өчен борчылу йөрәкләрне кыса.

Шундый чакларда камерада авыр, киеренке тынлык урнаша. Бары яралы татар егете генә, таш идәнгә утырып, һаман бер җырны суза:

Төрмәләрдә мин черсәм дә палачларның кулында,
Җаным-тәнем фида булсын хөрриятнең юлында...

Бүтән милләт кешеләренә дә тылмачсыз аңлашыла бу җыр. Аны һәрвакыт барысы да басынкыланып, уйга чумып тыңлыйлар. Ләкин бу юлы матрос түзмәде:

— Болай да эч поша әле монда, өстәвенә син шыңшыйсың. Җитәр! — диде.

Сәндерәдә яткан карт солдат егетне яклап сүз кушты:
— Ерласын...— диде.— Бәлкем, аңа шулай җиңгелрәктер...
— Анысы да дөрес! Җырласын, әйдә,— дип кушылдылар аңа бүтәннәр дә.— Йөрәк януын баса бу җыр,— диештеләр.

Авыр тимер ишек шыгырдап ачылды. Камерага Вахитовны төртеп керттеләр. Ул агарынган, бераз аптыраган кыяфәттә иде. Сорау алудан әле беренче тапкыр менә шундый сәер кыяфәттә кайтуы аның.

Башкалар, бу хәлгә сәерсенеп, ничек дип сүз башларга кыймый торганда, матрос беренче булып килеп җитте:
— Иптәш комиссар! Нишләттеләр алар сине? — дип Мулланурның күзләренә карады.— Газапладылармы әллә?
— Газапласалар, җиңелрәк булыр иде,— диде Мулланур теш арасыннан гына. Һәм кинәт, күңеле күтәрелеп, бөтен камераны яңгыратты: — Сезнең ишеткәнегез бардыр бит, туганнар,— ут, су һәм җиз торбалар аша узган кеше турындагы әйтемне?.. Утны, суны кичү—анысы һәркемгә аңлашыла. Ә менә җиз торбалар нәрсә дигән сүз? Аларның монда ни катнашы бар? Ничек уйлыйсыз?

Барысы да аптырап сүзсез калды.
— Җиз торбалар,— дип елмайды Мулланур.— Ул фанфаралар, ягъни мәсәлән, мактау, дан, дөньяны шаулату дигән сүз. Кайчакта ул бары юха сүз, салпы якка салам кыстыру гына. Менә шул сынауны үтү, туганнар, утлар-сулар кичүдән дә кыенрак икән. Борынгы кешеләр тиккә генә шундый нәтиҗәгә килмәгәннәр.
— Бу ни дияргә теләвең соң, комиссар? — диде матрос.
— Мин бүген, туганнар, әнә шул соңгы сынауны үтеп кайттым. Юк, газапламадылар алар бу юлы. Киресенчә! Полковник Сикорскийның йөзе кояш, теле бал иде. Мине үзләренә эшкә чакырды...
— Менә хәшәрәт! — дип сүгенеп куйды матрос һәм полковник хөрмәтенә тагын бер-ике йомры сүз өстәп куйды.

## 3

Корпус штабы каршындагы тикшерү комиссиясе комиссар Вахитовның язмышын хәрби-кыр судына тапшырды. Моны ишеткәч, Әлим Хәкимов шартларга җитеште:
— Күрегез әле, ничек тәкәллефләнеп торалар! Иясез эт кебек, хөкемсез-нисез тотып асарга иде дә аны — вәссәлам.

Мөбарәк ак гаскәр файдасына иганә җыю хакында сөйләшү өчен, аның янына шәһәрнең атаклы сәүдәгәрләре җыелган иде.
— Ә ул хәрби-кыр хөкеме дигәннәре, кем Әлим әфәнде, ышанычлы микән соң? — дип сорады аларның кайсыдыр.
— Һа,— диде акларның штаб күсесенә эверелеп килүче Дөлделевич.— Әлим әфәнде юкка борчыла. Хәрби-кыр суды — ул атып үтерү дигән сүз. Комиссарны хәзердән үк мәет дип саный аласыз, әфәнделәр.
— Шулай дагын аларга ни... Ничектер әйтеп кую зыян итмәс иде,— диде икенче сәүдәгәр.— Өстәмә сөйләшеп куюның зарары юк, фаразан.
— Син нәрсә димәкче буласың соң?
— Хат языйк дим. Ягъни мәсәлән, без, фәлән-фәләннәр, шул тиклем иганә җыеп, әйтергә кирәк, соңгы тиеннәребезне ватан файдасына исраф итеп, шуны сорыйбыз ки, татарның сатлыгы вә бәдбәхете, мәккә кяфере, тәмуг кисәве гадел җәзасын алсын иде...
— Менә дигән фикер!
— Баш үзеңдә, агайне, баш түгелдер — курчага!
— Бик мәслихәт эш бу. Төшемле эш. Моның сумасы кайтыр! — дип кычкырыштылар төрле яктан.

— Чынлап та, кызыклы тәкъдим күренә бу, әфәнделәр,— дип, Әлимнең дә күзләре яна башлады.— Хәзер үк язарга кирәк. Яле, Әдһәм туган, сырлап бир безгә. Син шактый шомардың хәзер ул эшкә...— Дөлделевичның комиссар турындагы яла ягулы хатларын искә төшерде бугай Әлим.

Әдһәм, җилкәләрен җыерып, күзләрен челт-мелт йомып алган булды да, кәгазь-каләм алып, өстәл янына утырды. Ә дигәнче әлеге изге хатны әвәләп тә бирде.

—... Без, татар революционерлары, төрле демократик фирка һәм гөруһ вәкилләре, татар халкының иң явыз дошманы, бөтен мөселман, бөтен төрки дөньясына хыянәт кылган Мулланур Вахитовны һич кичекмәстән җәзалап үтерүне таләп итәбез! — дип үзе үк укып бирде Әдһәм.

— Шәп!

— Искиткеч!

— Нәкъ без әйткәнчә язылган! — дип хуплап, шау-гөр килде кызыл танаулы, зур корсаклы «революционер» агайлар.

Хәрби-кыр суды комиссар Вахитовны атып үтерергә хөкем итте. Хәер, башкача булуы да мөмкин түгел иде. Суд әгъзалары үзләренең карарларын азмы-күпме җитдирәк дәлилләр белән ныгытып та маташмадылар. Хөкем кыска һәм коры иде. Шулай да комиссар каны өчен бөтен җаваплылыкны үз өсләренә алырга шүрләп, карарны Самарага, аклар «хөкүмәте» раславына җибәрделәр. Аннан бик тиз телеграмма килеп төште: «Хөкем карарын җиренә җиткерергә».

## 4

Пелатән төрмәсендә комиссарны үлем җәзасына хөкем итүләрен беләләр иде инде. Шулай да, бу коточкыч карар гамәлгә ашырылыр дип беркемнең дә ышанасы килми.

Адәм баласы соңгы чиккә хәтле нәрсәгәдер өметләнә, күңеле белән фаҗигаләрнең дә азагы әйбәт бетүен тели. Ләкин Мулланур буш хыялларга бирелмәскә тырышты, вәсвәсәле уйларны читкә куды. Ул бөтен тормышына йомгак ясый иде.

Тагын өч-дүрт көннән аңа утыз өч яшь тула. Җиңелү һәм җиңү, табу һәм югалту еллары. Көрәш еллары... Бәлки, ул һәрвакыт тиешенчә генә эшли алмагандыр? Бәлки, ниндидер саксыз адым атламаса, дөнья белән болай иртә хушлашырга туры килмәс иде? Юк, ул барыбер бернигә дә үкенми. Үзенә насыйп булган гомер юлын намус белән кичте. Тагын бер гомер өстәп бирсәләр дә, ул аны бары тик шулай гына исраф итәр иде. Йөрәгенең һәр тибеше белән кешеләргә, туган халкына, бөек, изге максатларга хезмәт итәр иде...

Таң алдыннан авыр тимер ишек шыгырдап ачылды. Камерага коралы ике солдат килеп керде. Ишектә тагын берәү — офицер пәйда булды. Җирәнүен яшерә алмыйча, тоткыннарга бер күз йөртеп чыкты:

— Вахитов биредәме?

Мулланур урыныннан калыкты.

— Җыеныгыз. Әйберләрегезне алыгыз,— диде офицер, каш астыннан гына карап.

— Кая алып китәсез аны? — дип, үзенең сәндерәсеннән матрос кузгалды.

— Синең ни эшең бар, сабакы! — дип җикерде аңа офицер. Шулай да Вахитовка таба борылып: — Сезне... губерна төрмәсенә күчерәләр,— диде.

Мулланур көлемсерәп баш какты. Ул инде ишек ачылу белән аңлап алды: бу — барысы да бетте дигән сүз. Сабыр гына, иплап кенә өстенә киенә башлады. Киенеп беткәч:

— Бәхил бул! — дип матросны кочаклап алды.— Ә син, энекәш, тизрәк савык,— дип, яралы егет өстенә иелде. Аннары тураеп, нык, көчле тавыш белән:

— Бәхил булыгыз, иптәшләр! — диде.— Рухыгыз сүнмәсен! Көрәшне дәвам итегез!

— Авызын томалагыз шуның! — дип җикерде офицер.

Солдатлар ике яктан Мулланурның кулына ябышып, ишеккә таба сөйрәделәр.

— Кагылмагыз аңа,— дип офицерга таба ташланды карт солдат.

Офицер кизәнеп торып аңа китереп сукты.

Авыр ишек шапылдап ябылды.

Матрос, рәшәткәгә ябышып, тәрәзәгә үрелде:

— Иптәшләр! Комиссар Вахитовны атарга алып киттеләр! — дип кычкырды.

Идәнгә сикереп төшеп, ул ишеккә килде һәм итеге белән типкәләп, яңадан:

— Иптәшләр! Вахитовны атарга алып киттеләр! — дип кычкырды.

Аның тавышын ишетеп, күрше камерадагылар кузгалды. Бер минуттан бөтен төрмә дөбер-шатыр килә башлады. Төрле яктан:

— Бәхил бул, иптәш комиссар!.. Акларның муенын борырбыз!..— дип кычкырган тавышлар ишетелде.

19 нчы август таңы иде бу.

Тагын өч көннән — Мулланурның туган көне.

Тагын өч атнадан — Казанны Кызыл Армия азат итәчәк...

1918 елның 19 нчы август таңы атып килә иде.

Авыр солдат итекләренең тавышыннан сискәнеп, җирдән ак күгәрчен күтәрелеп китте һәм чыгып килүче кояшка таба җилпенеп очты. Аның канатлары иртәнге шәфәкъ балкышына манчылып, алтынсу-ал төсләр белән янды.

«Көнгыш — үлемсезлек кошы...— дип исенә төшерде Мулланур.— Канатлары ялкын телләренә әверелгән кош... Торган саен биеккәрәк үрли һәм күккә аша...» Ул, күкрәгендәге мәңгелек ялкынның талпынуын тоеп, үзенә нурсыз күзләрен төбәгән винтовкаларга каршы атлады.

*Җир! Син ул таңда да, чиксез Галәм киңлегендә серле йомгактай бөтерелеп, ал Кояшка таба очтың.*

*Ләкин син шул көннән башлап кызурак әйләнә башлаган кебек идең:*
*ал байраклар тарафына йөз баглап,*
*халыкларның сихри Көнгыш сыман үлемсез хыялларын якынайтып...*

*Җир! Үзең тудырган һәм үз куеныңа алган балаларың — изге көрәштә шәһит киткән фидаилар җаны һәр таңда яңа буыннар күңеленә әйләнеп кайта.*

*Яңа буыннар күкрәгендә, ерак йолдыз нуры булып, ул шанлы көннәрнең кайтавазы яши:*

Үтереп була кояш нурын,*
Үтереп була һәр халыкның
Мулланурын,
Үтереп булмый
Үлемнәрдән туган җырын.
. . . . . . . . . .

Хәрәкәттә безнең аң һәм безнең кан —
Мәңге исән синең җан,
Мулланур,
Мәңге исән!..

---

* Р. Харисның «Мулланур» поэмасыннан (1975).

# МӘҢГЕ ИСӘН МУЛЛАНУР

«КӨНГЫШ — ҮЛЕМСЕЗЛЕК КОШЫ» ӘСӘРЕННӘН БЕРЕНЧЕ ТӘЭСИРЛӘР

Повестьның соңгы юлларын укыгач, анда сурәтләнгән хәлләрне янә бер кат күз алдыннан кичереп, революцион көрәш ялкынында чыныккан яшьлегебезне искә төшердем. Миңа, бөек юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинны ике тапкыр күрү һәм аның ялкынлы сүзен тыңлау бәхете насыйп булган карт большевикка, ул көннәрдән искән кайнар җилгә йөземне куеп тору кебек тоелды бу әсәр белән танышу. Шуңа күрә беренче тәэсирләремне дә «Казан утлары» укучылары белән бүлешмичә кала алмыйм.

Бу әсәрнең языласын мин моннан ун еллар элек белә идем. Ул чакта чуваш язучысы Михаил Юхма телефоннан шалтыратып: «Якуб ага, мин Мулланур Вахитов турында китап язарга керештем. Данлы комиссарның көрәштәше, шул чорның шаһиты буларак, Сезгә дә сорауларым бар иде...» — диде. Очрашырга сүз куештык.

Михаил Юхманы мин әдәбият мәйданында шактый ат уйнаткан язучы дип беләм. Ул миңа «Мәскәү юлы», «Кук ук» дигән тарихи романнары буенча да, чуваш халкының үткәне һәм бүгенгесе турындагы башка әсәрләре аша да таныш. Бер сүз белән әйткәндә, талантлы әдип, җитди автор дияр идем.

Тик Мулланур Вахитов хакында китап язу — ул бит үтә дә каршылыклы елларны, четерекле мәсьәләләрне колачлап алу, бик күп детальләргә яңабаштан ачыклык кертү, ниһаять, кайбер нюанслары әле дә томанлы булган документаль нигезне табу дигән сүз. Булачак китапка нәшрият (ә ул — КПСС Үзәк Комитетының «Политик әдәбият» нәшрияты!) куйган таләпләрне дә искә алсаң... Шул дәрәҗәдә әзерлеге, әдәби куәте җитәрме, максатына ирешә алырмы язучы?..

Яшермим: Михаил Юхманың үзе белән күрешкәнче, шундый икеләнүләрем-шикләрем бар иде. Бәхеткә каршы, ул шикләр беренче очрашуда ук ышаныч һәм өмет белән алышынды: юк, тугандаш халык язучысы бу авыр, зур эшкә очраклы гына алынмаган икән, ул үзенең иҗаты һәм тормышы белән шушы темага әзер икән.

Халкыбыз мәхәббәтен яулаган драматург Туфан Миңнуллинның яшьләргә гыйбрәт итеп әйткән бер фикерен һич онытмыйм: «Олы шәхеснең Ил, халык алдындагы намус чисталыгы турында язганда үзеңнең дә күңелең, хәтта өс-башың да чиста булырга тиеш»,— дигән шикеллерәк иде ул. Михаил Юхманың үлемсез революционерыбыз, ялкынлы йөрәкле каһарман хакында әсәр язуы мисалында да шул сүзләрнең хаклыгын раслап булыр иде, дип уйлыйм. Мин язучының үз героена эчкерсез мәхәббәтен, бик түземле һәм намуслы рәвештә вакыйгаларны, кеше язмышларын тергезүен, Вахитов тормышының һәм характерының тирән катламнарына үтеп керүен күрдем. Кемгә генә мөрәҗәгать итсә дә, изге максатын аңлап, үтенечен кире какмауларын, бигрәк тә Рәфыйк Нәфиков, Вәзих Исхаков кебек танылган галим һәм язучыларның хуплавын, ярдәм итүен ишетеп сөендем, ул чорны, комиссарны яхшы белгән кешеләр белән элемтәгә керергә хәлдән килгәнчә үзем дә булышырга тырыштым. Шул рәвешле, Юхма Мулланурның кәләше Мәхфүзә, һади Маликовның хатыны Рәбигә һ. б.лар белән очрашты. Шундый очрашулардан соң язучы миңа яңа гына язылган аерым күренешләрне, эпизодларны укып күрсәткәли иде. Хәтта беренче карашка очраклы булып тоелган фактлар, штрихлар язучы каләме астында бер җепкә теркәлә, аларга күзгә күренеп «ит куна», җан керә бара иде...

Ниһаять, китап язылып бетте, 300 мең данә булып басылып чыкты, һәм иң гаҗәбе — шул бик зур тираж комга сипкән су кебек тиз таралды. Халкыбызның абруйлы матбугат органы — «Казан утлары»ның да бу әсәрне күреп алуы, бастырып чыгаруы мине ихластан сөендерә. (Биредә укучылар аның журнал варианты — күләм ягыннан өчтән бер өлеше белән таныша алалар).

Мулланур Вахитовның каһарман язмышы, кабатланмас тормышы турындагы әсәр (тулы күләмендә ул — роман) минем өметләремне аклады, дип әйтәсем килә.

Мин бу әсәрне партия Үзәк Комитетының апрель Пленумы барган тарихи көннәрдә укыдым һәм ленинчы җитәкче образы аша революцион үткәнебездән социализм тәзелешенең бүгенге этабына салынган күперне күрдем. Партиябез эшчәнлегендәге ленинчыл эш стиле, совет халкын яңа казанышларга рухландыручы көчле җитәкче шәхесе турында уйландым.

Михаил Юхма татар халкының үлемсез улы хакында тирән соклану, зур ышандыру көче белән яза. Тарихи дөреслеккә тугрылыклы язучы чорның киеренке сулышын тоярга мөмкинлек бирә, баррикадаларның ике ягында калган кешеләрне җанлы итеп күз алдына

бастыра. Мулланурның Владимир Ильич белән сөйләшү-киңәшүен тасвирлаган сәхифәләрне, янсә аның дошманнар белән күзгә-күз калган минутларын гына искә төшерегез. Әсәрдә кырыс документаль нигезнең әдәби хыял җимеше булган күренешләр, геройлар белән чиратлашуы, нисбәте әйбәт саклана һәм бик табигый үрелеп бара. Мәңге исән Мулланурның онытылмас образы күз алдына килә.

Мулланур Вахитов — халыкның үз арасыннан калкып чыккан, бөек Лениннан нур алып балкыган күренекле шәхес. Ул туган халкының бәхете өчен ут эченә керде, ленинчы революционер буларак, барча милләт хезмәт ияләренең азатлыгы өчен, халыклар дуслыгы тантанасын яклап көрәште. Ул чын интернационалист табигатьле иде. Рус, татар, башкорт һәм чуваш халыкларының эчкерсез дуслыгы, Совет власте өчен уртак көрәше әсәрнең буеннан-буена кызыл җеп булып сузыла. Большевикларның ленинчыл милли политикасы, пролетар интернационализм рухы белән сугарылган бу китап илебездәге халыклар дуслыгына бер һәйкәл булып та кабул ителә.

«Көнгыш — үлемсезлек кошы»н укыганда, мин сугышчан дусларым — Яков Шейнкман, Гирш Олькеницкий, Һади Маликов һәм башкаларны яңадан күргәндәй булдым. Алар әсәрдә Мулланур образын тагын да тулыландырып яшиләр.

Михаил Юхма революция һәм халык дошманнарын да төгәл штрихлар белән тасвирлый. Алар арасыннан без һәртөрле милләтчеләр, ак гвардиячеләрне һәм җөмләдән берсе булган Әдһәм Дөлделевичны да танып калабыз. Әдһәм — мәкерле дошман. Аңа «җан иңдергәндә» язучы Октябрь революциясе Үзәк дәүләт архивы материалларына да нигезләнгән. Бу образ артында кайбер иптәшләрнең ышанычын яулап, Комиссариатка үтеп кергән, Мулланур Вахитовка, татар революционерларына коточкыч яла яккан һәм үзенең доносы астына «Былбыловичь» дип имза салган бер бәндә тора.

Игътибар иткәнсездер: ышанучан күңеле белән Дөлделевич ятьмәсенә эләксә дә, бөтен газапларны батырларча кичереп, революция эшенә хыянәт итмәгән Галия, гомере буе байларга бил бөгеп, соңыннан аңлы көрәш юлына баскан Габдулла солдат әсәрдә нинди җылылык белән сурәтләнәләр! Габдулла образында мин революция таңында билен турайткан, беләкләрендә яңа көч тойган һәм хөррият намына көрәшкә ташланган хезмәтчел халык гәүдәләнешен күрдем.

Гомумән, әсәрдә изүчеләргә каршы изге яуга күтәрелгән халык идеясе бик эзлекле рәвештә чагылдырылган. Хәтеремдә, хәтта аның бер варианты халкыбызның «Ком бураны» дигән мәгълүм җыры белән ачылып китә иде: «Без давылдан курыкмыйбыз, үзебез давылдай булгач...» Габдулла, Галия һәм Пиктимерләр революция эшенең, комиссар Вахитов рухының җиңелмәслегенә, мәңге исән каласына инаналар, бөек Россия өстендә азатлык кояшы балкыйсын беләләр, шул якты киләчәк хакына үзләрен фида кылалар. Үлемсез Көнгыш турындагы риваять әсәрдәге халык рухының үлемсезлеге идеясен табигый рәвештә бер үзәккә туплый һәм тагын да калкурак итә.

«Көнгыш — үлемсезлек кошы» — халкыбызның революцион көрәш сәхифәләрен сәнгатьчә буяулар белән, тарихи дөреслеккә омтылып тасвирлаган китап. Күренекле революционер, беренче совет дәүләт эшлеклеләреннән берсе, халык массаларының җитәкчесе һәм ялкынлы трибун Мулланур Вахитовның 100 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә бу әсәрнең «Казан утлары» журналы аша меңнәрчә укучыларга барып ирешүе — зур вакыйга. Тугандаш халык әдибенең җитди уңышы булган бу әсәр мисалында илебез халыкларының һәм әдәбиятларының интернациональ табигате, эчкерсез тирән бәйләнешләре чагыла. Һәм бу һич тә гаҗәп түгел: безнең күкрәкләрдә әкияти-серле һәм искиткеч дәрәҗәдә реаль булып талпынган бер кош — Көн кошы — үлемсез идея-рух гәүдәләнеше дә, халыклар дуслыгының мәңгелеген раслаучы тирән мәгънәле символ да ул.

**Якуб ЧАНЫШЕВ,**
1917 елның мартыннан КПСС члены,
отставкадагы генерал-лейтенант.

*Мәскәү*

# Гамил Афзал

## Муса Акъегет

*Каенсар төбендә кар булмас,*
*Кайгылы йөрәктә май булмас.*

Халык сүзе.

Таңнарга карап куандың,
Таң чишмәләре пакь диеп,
Чишмә башыннан су алдың,
Муса әфәнде Акъегет.
Идел буйлап саллар ага,
Тирбәлешеп таллар кала.
Өмет белән йөрәк яна,
Муса әфәнде Акъегет...

Җиде диңгез артларыннан
Кошлар да кайта ватан, дип,
Оя корырга кайтам, дип,
Муса әфәнде Акъегет.
Җылы җилләр, суык җилләр,
Көмеш тәңкә кебек күлләр.
Илдә чыпчык үлми диләр,
Муса әфәнде Акъегет...

Ерак диңгез артларыннан
Карап күзләрең күгәрер,
Эчләрең поша нигәдер,
Муса әфәнде Акъегет.
Илла да матур чак, диеп,
Ил күңелләре шат, диеп,
Ятсаң төшеңә керәдер,
Муса әфәнде Акъегет...

Кайда да була киртәләр,
Үги анаң да үпкәләр,
Бер какса да бер иркәләр,
Муса әфәнде Акъегет.

Күңел дәрьялар буйлыйдыр,
Ватан бүреккә сыймыйдыр.
Туган җырләрең ямьле бит,
Муса әфәнде Акъегет.

Шимал яктан җил киләдер,
Таң таралып кояш чыккан.
Яшь даһилар җилкенәдер:
Тукай, Гафури, Әмирхан,
Барыбызга уртак ватан,
Торыр, кузгалыр чак диеп.
Сызылып кына ай калыккан,
Муса әфәнде Акъегет.

Язлар килә, көннәр көләч,
Гөлләр үсә, җирләр кибеп.
Туган җиргә басып көрәш,
Муса әфәнде Акъегет...
Күзләр җитә, ява яңгыр,
Кара-кучкыл болыт килеп.
Шушы җиргә ятып җан бир,
Муса әфәнде Акъегет.

Таң беленер-беленмәстә,
Без уяндык җиңелмәскә.
Кыюлык юк кызыл фәстә,
Муса әфәнде Акъегет:
Ирекне сөйгән балалар
Әҗәлне таптап баралар,
Бәхетне яулап алалар,
Муса әфәнде Акъегет!

●

Бетмәс кайгы-хәсрәт булмагандыр,
Гел елап һәм сыктап тормагандыр,
Җырлаган да халык, көлгән дә...

Бөгелә-сыгыла урман шаулагандыр,
Җилле-салмак кылыч сайлагандыр,
Ил чигенә дошман килгәндә.

Дугалардан биек арыш уңган,
Басу читләрендә яшел урман,
Халык йөрәгенә моң тулган...

Тараканнар төшкәләгән ашка,
Трактор да сәер иде башта.
Һай, заманнар башка, чор башка...

Әйдә әле, кордаш, җыр башла!

●

Без бер вакыт ерак күкрәүләрнең
Нәҗәгаен күреп уяндык.
Яз җилләре кебек аваз килде:
«Ireклек,
Тигезлек,
Туганлык!»
Гайрәт белән, кулга корал алып,
Тыгыз сафка басып сөендек.
Бер тавыштан әйтте бөтен халык:
— Туганлык,
Ireклек,
Тигезлек!
Кызу көрәш барган ут-төтендә,
Бәхетле көннәргә ирештек.
Байрак булып барды баш өстендә
Тигезлек,
Туганлык,
Ireклек!

●

Оеп кына утырып, әй, ява кар,
Кар сафлыгын сулап сөенмәле.
Ак бәхетләр алга киләсе бар,
Ап-ак карга басып йөрим әле.

●

Баш әйләнеп беткәч шигырь уйлап,
Дөнья тынган айлы кичләремдә,
Атка менеп, ялтыр кылыч болгап,
Наполеонны куам төшләремдә.

Таулар арасында ташлы юллар,
Бормаланып китә тар сукмак.
Кайда, кемнең нинди моңнары бар —
Кычкырасы килә бер туктап.
Таулар арасында тар сукмак.

Гомер язлары үттеләр,
Җитте гомер кышы.
Оеп яуган кар өстендә
Оча күңел кошы,
Җанга җылы тапмый язган
Моңлы җырым — шушы.

Череп барган дөнья вәхшиләнә,
Таплар күрә айда, кояшта...
Агу чәчеп фашизм килә дә,
Шагыйрьләрне үтерә иң башта.

Зарланмадым, түгелмәде яшем,
Аллы-гөлле юллар юрамадым.
Мин көрәшеп, бәхәсләшеп яшим,
Бүтән төрле язмыш сорамадым.
Шома гына язмыш кирәкми дә
Намуслы һәм усал көрәшчегә.

Гомер-бакый дигән бу елганың
Дулкынына ишкәк сугам мин,
Алтмышта да йөрәк ярылмады,
Җитмешкә дә йөгереп чыгам мин.
Тал чыбыгы кебек сыгылмалы,
Камыт бавы кебек чыдам мин.

Гомер язлары гел яхшы
Үтмәгәннәрен беләм.
Хыяллар тормышка ашты
Кетмәгәннәре белән.

Заманча тигез барам дип
Минутлар чаба икән.
Иң туры юллар ярам дип
Эзләгән таба икән.

Кышын-җәен: буран, томан, тузан,
Суык, эссе тормыш юлларында,
Күпме кеше җанга кагылып узган,
Күз елтыраулары күз алдымда.

Ертылып еллар үткәннәр,
Елмаеп еллар үтә.
Елаган еллар бүтәннәр...
Еракта үрләр текә.

Ефәктәй еллар көтәбез,
Еландай юллар бара.
Елгалар кичеп үтәбез,
Елтырап утлар яна.

«Сагы барның сагы ятар,
Сагы юкның башы ятар»,—
Дигән борынгы бер татар.
Баш кадерсез чордан калган
Мәкальнең мәгънәсе хәтәр.

Таш табылыр, баш табылмас,—
Дигән дә ул, эчтән тынган.
Ярый әле, башны ташка
Ора торган чорлар узган.

Сары яфраклар коелган,
Алтын көзләр уйчан-уйчан,
Уйчан сахраларга чыгып,
Көзнең матурлыгын җыйсаң...

Сахраларда сары сафлык,
Алтын әрҗәгә салырлык,
Моңсу гына көлемсери
Бәхетләр көткән сабырлык.

Сүнгән вулкан йөз ел йоклап ятты,
Тавыш-тыны чыкмый бер тамчы.
Кошлар сайрап, тыныч таңнар атты,
Кот очарлык сәгать сукканчы...

Кайнап, үкереп, утлы лава ага,
Һаваларга оча таш кыя.
Тамчылар да шулай тын арада
Ташкын булыр өчен көч җыя.

●

Җилли дә тирбәлә усак,
Их, малай, иртәрәк тусак!
Нигәдер ямансу бу чак,—
Дөрлә, учак!

Күңелсез уйларны кусак,
Нык итеп билләрне бусак,
Тарихлар сокланыр бу чак,—
Дөрлә, учак!

●

Син барасың, көн дә нидер яулап,
Хыялыңда гөлләр үскән төшкә.
Бер булганга биш булырдай ялгап,
Дөнья сокланырлык бизәк эшлә!

●

Кирәк, кирәк диеп алдан йөргән,
Тормыш юлын үткән бизәкләп,
Үзенә алмыйча, илгә биргән
Абыйларга рәхмәт!

●

Көлә-көлә матур чәчәк өләш,
Әҗер-фәлән көтмә бер тамчы.
Көлә-көлә ялган белән көрәш
Янып-көеп җаның чыкканчы!

●

Юл буенда утыра ялгыз каен,
Юлчыларга яшел яулык болгап,
Бер утырып ял ит, абзыкаем,
Үткән гомерләрне уйлап!

●

*С. Сөләймановага*

«Җырлап яшик, дуслар!»,— дидең дә син
Дәртле, моңлы хисләр диңгезендә.
Язгы җилләр, көзге җилләр исә —
Синсез генә...

## Рафаил Төхфәтуллин

# КОЯШЛЫ ЯКЛАР ГӨЛЕ

ХИКӘЯ



Соңгы вакытларда аның гадәтенә кереп китте: берәр таныш-белеше очрап, хәл-әхвәл сораша башласа, Нурислам, авыр гына көрсенгәндәй итеп:

— Картаябыз, малай, мич башына таба үрмәләп барыш хәзер,— ди.

— Нәрсә, әллә пенсиягә дә чыгарга вакыт җитәме?

— Нихәл итәсең, безнең бурильщик халкын бүтәннәргә караганда биш елга алданрак списать итәләр бит,— ди Нурислам һәм санаулы гына бөдрәләрен, баш селкеп, бер биетеп ала, хәйләкәр-шук көлемсерәү яшерелгән ыспай гына мыегын имән бармагының аркасы белән ян-якка сыпыргалап куя. Шулай егетләрчә маңгай бөдрәләрен биетүеннән, мыегы яшереп бетерә алмаган шук көлемсерәвеннән мондыйрак мәгънәне аңлавы кыен түгел: «Шундый ул безнең бурильщик халкы, особый токымнан! Әйтәләр безгә, авыр хезмәттә бик таушалгансыздыр, инде лаеклы ялга озатабыз сезне, диләр. Ә без, күреп торасың, теләсә нинди бәйгеләргә чыгарга әзер!»

Чыгарга әзер әзерен... Шулай да ялга китәр көннәрен бик көтә иде Нурислам; айларын, атналарын саный-саный көтә иде. Пенсиягә чыкса, иң беренче эш итеп, ничәмә дистә елларның ачы җил-бураннары өшеткән сөяк-санагын җылытырга Кырымга, Кара диңгез буйларына китәчәк ул. Гаҗәеп матур глициния гөлләре чәчәк атып утырган Кырымга! Ниһаять, ул гүзәл гөлне барып күрер көннәре дә якынлаша Нурисламның. Күңел түрендә бик тирәнгә яшерелгән, берәүгә дә, шул исәптән, Нәсимәгә дә берни сиздермәгән хыял бу, әлбәттә. Әйе, Нәсимәгә дә... Аның җанкисәгенең, бу тарафтан үз хыялы.

Әнә, бүген дә шул турыда сүз ачты Нәсимәсе:

— Пенсиягә чыксаң, Зөлкәрәм кебек син дә бакчаны тәмам рәткә кертер идең, име? Шул эт оясы кук будкаңны да чын дача өе итеп салып куяр идең.

— Әйе шул,— диде Нурислам, бик җитди итеп, карчыгы белән бик тә килешкәндәй итеп әйтте.— Пенсиягә чыксам, икенең бере инде: я бакча корты булам, яисә кайберәүләр кебек рәхәтләнеп өч борынга кереп йөрим.

— Бик салып йөри алмассың, малайка. Машина алырга чиратың килеп җитә, салдым башларны бик тиз рульдән куалар хәзер.

— Рульдән куылганга кадәр муенны сындырып өлгермәсәм.

— Син, малайка, җүләр сатып утырма монда, яме. Бер-бер артлы

өч туй борын төбендә, туйның яме машина белән хәзерге заманда. Гараж турында да хәстәрләнә башларга бик вакыт.

— Бик вакыт, карчык, бик вакыт,— диде Нурислам тагы да күндәмрәк күренергә тырышып.— Булмаса, мин бер әйләним әле. Зөлкәрәм, кемнәндер таш белешәм, дигән иде анда.

Нәсимә, «малайка»га да җитди сүзнең үтә башлавына бик канәгать калып, аны озатып калды.

Көн кичкә таба авышып, урамнарның иң ыгы-зыгылы чагы иде. Кояш җәйге чилләдәгечә кыздыра, ә юл буе өрәңгеләре узучылар өстенә кырлы-сырлы алтынсу яфраклар ыргытып кала. Нурислам баш түбәсендә бөтерелгән яфракны ялт кына эләктереп алмакчы иде, тоттырмады наянкай, күбәләктәй талпына-талпына читкә очып китте.

«Шулай инде ул дөньялар,— дип уйланып бара Нурислам.— Картлар чүгә, яшьләр канат кага... Чыннан да, Нәсимә, кайчан гына килеп җитте соң әле ул бер-бер артлы өч туй күтәр заманнар? Әле үз туебыз шаулап үткәнгә дә кичә генә сыман. Бер-бер артлы ук булмас булуын туйлар. Бик алайга ошамый. Айсылуы әле өченче курста гына, институтын бетерсен. Илдусның да диплом алганына ничә генә ай, әле һаман малайлыктан чыгып җитми шикелле. Ә менә Рашатка башлы-күзле булырга да бик вакыт инде, канатлары нык хәзер аның. Эшкә генә ераккарак китеп барды. Нефть белгеченә, әйтерсең монда эш беткән, тоткан да Төмән ягына китеп барган».

Сәеррәк бит әле бу. Әнә, ишегалдында Нурисламнан да яшьрәк күршеләре, вәкарь белән генә атлап, оныкларын җитәкләп йөри, ә Нурислам, тиздән пенсиягә чыгып, чыннан да «бабай» исемен күтәрергә хаклы була торып, чәчбай үсмерләр белән стадион юлын таптасын, шак-шок домино сугып утырсынмы? Бер дә күңелле күренеш түгел бит әле бу, Рашат улым... Һәр язның, җәйнең үз яме, көз белән кышның да үз хозуры. Һәр агач, вакыты җитүгә, бөре яра, шаулап чәчәк ата, яфрак коя. Кошлар да оя кора, нәниләрен канат кактырыр чакны һич соңлатмый. Кеше тормышы, әлбәттә, катлаулырак. Ләкин еш кына үз тормышыбызны үзебез үк катлауландырабыз түгелме без?

Тагын ни кötә дә нәрсә җитми ул малайга? Барын бардыр аның да, әйтик, үз глициниясе. Булмый калмас.

Глициния... Нигә тагын хәтергә төшеп тора соң әле ул кояшлы яклар гөле?

...Ул чакларда әле бу яшел аллеялы урамнар урынына олыдан-олы чокыр-чакыр да муеннарын күккә чөйгән краннар хакимлек итә, Нурислам да хәзерге кебек бөтен идарәдә танылган бораулаучылардан түгел, вышка башындагы оясына бормалы баскычлардан мәче җитезлеге белән менеп-төшеп йөри торган җиңел сөякле верховой егет иде. Егет дигәч тә, буйдак дигән сүз түгел — Нәсимәсе бар, иске Әлмәт ягындагы штукатур тышлы такта баракта үз куышлары бар, вахтадан кайтып тамак ялгап алгач та аяклар тизрәк клуб ягына каермый башлаган чаклар иде инде. Яшь кәләш куенын калдырып, чокырлы урамнар буйлап атлауның хаҗәте дә юк, ә менә җәйге яллар якынлашуга, күңел дигәнең бу озынча бараклардан ераккарак — туган якларга ашкына башлый иде.

Яллары бергә туры килмәде дә, Нурислам ул елны авылга ялгызы гына кайтты. Яллары туры килмәүнең ни сәбәбе чыккандыр, анысы истә калмаган, ә менә Нәсимәгә карата: «Килен булып бирата нигезенә кунакка да кайтасы килми монын»,— дигән үпкәсе яхшы хәтердә. Шул яшерен үпкә аркасында бугай инде, самолетта очканда аның урыны бөдрә коңгырт чәчле бер кыз белән янәшә туры килде. Кемнедер хәтерләтә иде

бу эре бөдрәләр, ләкин кызый, түгәрәк тәрәзәгә иелә төшеп, Нурисламның туксан тугыз соравын колагына да элмичә, юлдашыннан йөзен дә, телен дә яшереп бара бирде. Тик стюардесса, поднос тулы конфет күтәреп, юлчыларны сыйлап йөри башлагач кына, бөдрә чәч бире таба борылды, көлемсерәвен яшереп кенә күршесенә сынаулы-наян бер караш ташлады.

Әйтерсең лә шунда Нурисламның башына кинәт кенә үзе йомшак, үзе авыр тукмак белән китереп суктылар...

— Сез... Таһирә түгелме соң?— диде ул, телен көчкә әйләндереп.

— Юк, әти-әнием миңа башка исем кушканнар,— диде бөдрә чәч, инде көлемсерәвен яшереп тә тормастан.

— Алайса, кем соң Сез? Исемегез ничек?

— Очраган берәүгә анкета мәгълүматлары бирә торган гадәтем юк,— дип, бераз ачулырак итеп әйтте кыз.

Әлбәттә, Таһирә түгел иде ул, Нурислам үзе дә ышанмыйчарак аңа шулай дәште. Таһирә гәүдәгә дә калкурак, яшькә дә өлкәнрәк иде. Әмма күзләре, аннан да бигрәк, елмаю-көлемсерәүләре... Охшаса да охшар икән!

— Әллә сезнең Таһирә исемле апагыз бармы?

— Апаларым юк. Үзем апа кеше мин.

— Апа кеше, кайсы яктан үзегез?

— Көнчыгыш яктан.

— Ерак Көнчыгыштанмы, әллә Якын Көнчыгыштанмы?

— Ерак та түгел, якын да түгел, иң кояшлы якта безнең авыл.

— Тулысынча ышанырга була, апа кеше. Йөзегезгә кояш нурлары бигрәк мул сеңгән.

Кыз бөдрәләрен кискен генә тибрәтеп куйды да яңадан түгәрәк тәрәзәгә иелде.

— Әйтегез әле, Сез Таһирәгезгә дә шулай тәмле телләнәсезме?— диде ул бераздан. Тавышы тагын җитди-кырыс, шул ук вакытта күршесенең теленнән һич тә тикмәгә генә ычкынмаган бу сүзләр, алардан Таһирә дигәннең кемлеген белергә теләү аермачык сизелеп тора иде.

— Юк шул, апа кеше... Мин аңа тәмле телләнү түгел, бер кәлимә сүз әйтергә дә өлгерә алмый калдым. Кунак кыз иде ул, ай күрде, кояш алды.

— Бичаракай... — Кыз рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Бичара шу-ул...— Нурислам, мескен кыяфәткә кергән булып, авыр көрсенгәндәй итте.

Ах, бу язмыш дигәннәрен.

Теге вакытта: «Менә, Нурислам, синең мәхәббәтең шушы кыяфәттә булыр»,— дип, аны Таһирә белән юри генә очраштыргандыр язмыш. Ә инде янәшәдәге бу кыз мәхәббәтнең чыны, күктән җиргә иңгәне түгел микән? Чыны... Нигә алайса алдан Нәсимә белән кавыштырып өлгердең син, язмыш?

Кызый үзенең исемен, шөгылен аэропортта саубуллашканда гына әйтте: Гөлсинә атлы икән, медицина училищесы студенткасы.

— Бигрәк баеп киткән ахры бу картлач, сәлам дә бирми.— Зөлкәрәмнең карлыккан тавышы аны сискәндереп җибәрде.

—Сәлам! Байлык-хәзинә җитәрлек монда, малай!—Нурислам күкрәк турысына суккалап куйды.

Зөлкәрәм моны үзенчәрәк аңлады бугай.

— Алайса, картлач, бигрәк урынлы очрашканбыз икән,— ул гадәтенчә, сул күзен чет-чет кыскалап, «Нефтяник» ресторанынынң ягына ияк какты.— Сәбәбе дә бар: сөенче!

— Әҗерең уң колагың үзеңә, дияр идем, башта әйт, нинди?

— Буркомнан кайтыш минем. Син көткән путевка кайтып җиткән

анда. Кырымга, Ялтага. Булатов сер итеп кенә әйтте: үзен лаеклы ялга озатканда кулына тапшырабыз, ди.

— Хәбәрең хак булса, юарга да була моны,— дип, Нурислам ресторанга таба китә дә башлады. Ләкин бераз баруга кырт борылды да парк тыкрыгына юл алды.

— Син, картлач, алай шылдыртмале,— дип, Зөлкәрәм аның җиңеннән эләктереп алмакчы иде, тукталып калды. Дистә еллар бергә эшләп, һич кенә дә аңлап бетерешле булмады шушы Нурисламны. Аннан юмарт, аннан җилҗак кеше бөтен идарәдә юктыр, дип кенә йөргәндә, кинәт әллә нишли дә куя...

Паркка житүгә, Нурисламның аяклары кинәт атламас булды. Куллары белән таяныр нәрсә эзләгәндәй, һавада капшана-капшана, көчкә генә якындагы эскәмиягә килеп утыра алды.

Нишләвең инде бу, йөрәк? Үтәр үтүен... үтә иде бит. Тирәнрәк, тирәнрәк сулыш аласы иде. Шуны булдырып булса, үтте-китте дигән сүз... Менә бит, була. Тагы да тирәнрәк... Тагы да... Ю-ук, йөрәккәй, шаярма син алай. Нурислам абзаң булыр бу! Менә үтә дә ич.

Шулай да, врачлардан алай һаман-һаман качып йөрү ярамас. Бер күренеп кайтасы булыр.

Ялтага диген, ә! Күптәннән хыялланган, һаман җае чыкмаган, һаман кичектереп киленгән сәфәргә. Гүзәл глицинияләр таҗларын коймагандыр әле, кара күзгә кадәр шау чәчәктә утыра, диләр бит ул гөлне.

Глициния... Гөлсинә. Исемнәрегез үк шифалы ахры сезнең, менә бөтенләй җиңел булып китте.

Теге вакытта да шулай кәефсез көннәре иде аның. Юк, бер җире дә авыртмый да, сызламый да, нindidер күңел кәефсезлеге иде. Хәер, «нindidер» диясе юк, сәбәбе ачык. Авылдан кайтуына Нәсимәсе бигрәк сәер каршылады аны. Күрешү минутларында сагынуының иге-чиге юк кебек иде хатынның, иртәгесен алыштырып куйдылармыни үзен. Иренең шук-шаян сүзләренә генә түгел, һәр дәшүенә авыз ерырга торган Нәсимә, гомер булмаганны, караңгы чырайланды да куйды. Ике көн шулай тырпыр йөрде дә өченче көнне юлга җыена башлады. «Син гулять итеп кайттың, инде миңа чират»,— ди.

Һәм китеп тә барды.

Әнә бит ничек кылана. «Бергә кайтыйк» дигәндә кырык сәбәп тапты, инде менә ир сүзе дә колагына керми... Ничек аңларга бу хатынны?

Шулай уйланып, ашханәгә барышы иде Нурисламның, кинәт колак төбендә гаҗәеп ягымлы, юк, дөньяви гына түгелдер, иләһи бер дәшү яңгырады: «Нурислам абы-ый!..»

Күтәрелеп караса...

Аның каршында нәкъ беренче очрашкандагыча, дөресрәге, аерылышкандагыча бугай, оялчан-наян елмаеп, Гөлсинә басып тора иде. Кулында кечерәк кына кызыл сумка.

— Өнемме бу, әллә төшемме, Гөлсинә... Чыннан да синме бу?

— Мин идем дә... Алай бик ягымлы каршыламады әле Әлмәтегез.

— Кем икән ул безнең Әлмәттә андый рәхимсезе? Әйт кенә, Гөлсинә, хәзер арт сабагын укытабыз аның.

Гөлсинә, нигәдер ашыга-ашыга, бүредәге медсанчасть практикага җибәрелүе, горздрав хәзерләп куйган квартирлар барысына да житмәгәч, гостиницага килүен, анда да урын булмавын, инде менә адресын да төгәл белмәгән чыбык очы туганнарын эзләп йөрүен сөйләп бирде.

Нурислам, шушы кадәр дә сөйкемле бөрелеп-бөрелеп килгән чия төсле иреннәрдән күзләрен ала алмыйча, аны тыңлап тора, ә сүзләренең мәгънәсен аңлый да, аңламый да иде.

— Әй, җае чыгар әле! Ахыр чиктә бүгенгә генә автовокзал да бар,— диде Гөлсинә, шул якка таба атлый ук башлады.

Нурислам шунда гына кыз сөйләгәннәргә төшенеп житте бугай.
— Нәрсә син!— диде ул, һәм майлы курткалар, бушлатлар, тәмәке төтене, мазут, көнбагыш, сарымсак исләре белән тулы кысан залны күз алдына китерде дә (шундый иде ул елларда автовокзал дигәннәре), коты чыгып әйтте:— Тапкансың кунар урын. Әйдә безгә, монда гына безнең өй.— Нурислам кызны житәкләп үк алды.
— Син, Гөлсинә, бер дә тарсынма. Хатын өйдә юк минем, үзем эшкә китәм, төнге сменага. Өйдә берүзең хужа булып калырсың.
Ай, ул көннәр! Ничәмә потлы торбалар бер каеруда күперчектән тәгәрәп менеп кенә китә. Вышка башындагы оясына күтәрелергә аңа минутлар түгел, секундлар да житә. Ә биек оядан кире төшәр өчен аңа бормалы баскычларның кирәге дә калмады — карт мастерның котын алып, инструмент торбасы буйлап шуып кына төшәр иде. Менә бит ничек үзгәрде Нурислам.
Күпме дәвам итте икән бу сихри әкият? Бәхетлеләрнең вакыт белән бернинди исәп-хисаплары булмый.
Ләкин иң матур әкиятнең дә ахыры була.
— Тагын кайчан очрашырбыз икән, Гөлсинә?
— Сорама, Нурислам абый. Безгә бүтән очрашырга ярамас. Хакыбыз юк.
— Шулай да?
— Вөжданыммы, язмышыммы, дим шунда, рөхсәт итсә, мин үзем хәбәр салырмын, яме, Нурислам абый.
Ахыры була әкиятнең, әмма аның тылсымлы моңы мәңге дәвам итә. Бик зарыгып, сагынуларына чыдар әмәлләре менә-менә төкәнер дәрәҗәләргә житеп, Гөлсинәдән хәбәр көтте ул.
Хәбәр булмады.
Ял көннәре жыйналып, ике-өч көн буе жанына урын таба алмыйча йөргәндә, Гөлсинә укыган шәһәргә юл тотарга жыенып беткән чаклары булды.
Ләкин ярамый иде.
Нәсимә тиздән ана булачак, андый кешене аз гына да борчырга, күңелен аз гына да ямьсезләргә ярамый, диләр мондый чакта. Сабырлыгыңны жыя күр, Нурислам!..
Еллар үткәч, бер шәфкать туташы белән очраклы сөйләшүдә Гөлсинәнең эшкә кайсы районга китүен белеп алды ул. Сабырлыклар чиктән ашты, йөрәк түзмәде. Үз якларына кайтышлый, юлы шул районга килеп чыкты.
Ләкин очрашу насыйп булмады. Гөлсинә биредә күп эшләмәгән, бергә укыган иптәш кызының чакыруы буенча еракка, жылы көньяк тарафларына китеп барган. Төгәл адресын белүче юк.
...Кайвакыт язмышның бу кадәр шуклыгына үпкәләп куя Нурислам. Көзгә авышкан көннәр иде. Кырымда ял итеп кайткан Зөлкәрәм, вахта алмашка килгәч, Нурисламга пөхтә генә бер төргәк тапшырды.
— Кырым күчтәнәче бу сиңа, картлач,— диде, гадәттәгечә сул күзен кыскалап.— Үземнән түгел, үземнекен авыз итәргә өйгә килерсең, монысын... теге жибәрде.
— Теге-теге тегермән. Син, абзыкаем, ачыклап сөйләш.
— Соң... Үзең беләсеңдер.

Нурислам, ачулы гына мыгырданып, төргәкне ача башлады. Шома нейлон чүпрәкне сүтте, чытырдык саргылт кәгазьне, аннары ал кәгазьне ачты. Төргәк кәгазьләр алдына тау булып өелгәч, аннан... китап тышына охшаш бер катыргы килеп чыкты. «Тагын нинди этлек-шаянлыклары инде бу егетләрнең?» Нурислам, дөр шаркылдау көтеп, кисәк башын күтәрде. Будкада ул япа-ялгызы иде.
Катыргыны ачып карауга, шап кире япты, тагын ачты. Инде таcланып кипкән булуына карамастан, матурлыгын һич жуймаган алтынсу-

кызгылт чәчәк иде анда. Язуы да бар. «Нурислам, глициния гөле бу. Шуңа карап, бәлки, мине дә искә төшерерсең. Гөлсинә».

Йөрәк, авыртулы да, рәхәт тә итеп, дөп-дөп тибә башлады.

Менә кайларда йөрисең икән син, Гөлсинә! Глициния-Гөлсинә. Сайлый да белгән гөлне.

Буркомнан путевканы Зөлкәрәм урынына ул алган булсачы!.. Ничек хәтерең калмасын бу язмыш дигәннәренә.

Тукта, тукта... Әйткән иде бит Гөлсинә, вөҗданыммы, язмышыммы рөхсәт итсә, үзем хәбәр салырмын, дигән иде. Инде менә шушы рәвешчә хәбәр салуы, чакыруы түгелме соң аның?

Ул курорт картасы дигәнен алулары шактый мәшәкатьле эш булып чыкты. Калын кара ырмаулы зур күзлеге белән япь-яшь йөзенә кырыс житдилек өстәп алган врач сеңел, нечкә көпшәле кара төймәсен Нурисламның аркасына, күкрәгенә кат-кат куеп, озаклап тыңлагач, салкынчарак нәфис бармаклары белән суккалап-каккалап та алгач, бик озаклап нидер язды.

— Соңгы мәртәбә врачка кайчан күренгән идегез?— диде аннары, күзлек пыялаларын хәтәр генә ялтыратып.

— Әллә инде... Бервакыт буровойда үз саксызлыгым белән менә шушы бармакны кыстырдым да, бик авырткач, килгән идем. Больничный да биреп йөрттеләр әле үземә. Ун еллап үтте бугай инде аңа.

— Сез шаяртасыз, әйе?

— Аллам сакласын, шаярып утыра торган җирме бу! Тизрәк бирсәгез шул картаны, ычкыныр идем.

— Йөрәгегез еш борчыймы?

— Менә-менә, ярый хәтергә төшердегез, ул хакта да әйтмәкче идем. Хатын да колакка тукып җибәрде. Ни... Шаяргалый башлады шул соңгы вакытта йөрәк дигәне.

— Менә нәрсә, Шәяхмәтов... Чәршәмбе көн сәгать унга килегез, Виктор Михайлович та монда була, мәсьәләне шунда хәл итәрбез.

— Нинди мәсьәләне?

— Дәваланырга кирәк сезгә, Шәяхмәтов. Хәзергә менә шушы даруларны эчә торыгыз.— Сеңел өч-дүрт рецепт кәгазе сузды.

Бүлмәдән чыгуга Нурислам, артыннан кугандай, тышкы ишеккә йөгерде, ишегалдында яшь каеннар астындагы эскәмиягә килеп утырды.

Уф!.. Ул врачларга йомышың төшә күрмәсен диләр иде аны. Чәршәмбе тагын килергә, ди бит әле.

Белсәң иде, Гөлсинә дә шулай кемнәрнеңдер теңкәсенә тиеп утыра микән? Зөлкәрәм врач диде бит аны.

Әй, дөньялар!.. Чакырды, хәбәрен салды Гөлсинә теге чакта, ә һәр килмеш ел Нурисламның гүзәл глицинияләр иленә таба сузылган юлына үз киртәсен куя торды.

Бервакыт төшенә керде аның глициния гөле. Шундый да матур алсу-алтынсу гөл аны сәламләгәндәй тын гына чайкала, таҗкайлары дерелдәп-тибрәнеп куя, үзе бик нәфис зеңелдәп, нидер җырлый-көйли...

Көндезен дә төштәге гөл бик озак күз алдыннан китми йөдәтте. Шунда кинәт Нурисламның уена килде: ә нигә Гөлсинәнең үзе түгел, ядкәр итеп җибәргән гөле генә төшенә керә соң әле? Их! Беренче очрашканда Гөлсинә үзе дә иң гүзәл гөлдән гүзәлрәк иде, инде менә ничәмә еллар үтте, гомер һәм вакыт аның йөзенә дә, җанына да сырлар-җыерчыклар сырлап үтмәгән дисеңме? Нурислам үзе ниндирәк кыяфәттә хәзер? Жентекләбрәк көзгегә бак.

Димәк, очрашмаулары хәерлерәк. Гөлсинә Нурислам күңелендә һаман да гүзәл гөл, ә Нурислам Гөлсинә хәтерендә ничек калгандыр — һәрхәлдә, яман булып түгелдер — шулай булып кала бирсен!

Әнә шулай өлкәннәргә хас булганча сабырланды, утырды күңел. Инде менә аны Ялтага сәяхәт көтә.

Ничегрәк булыр икән очрашу? Беләсе иде, килеп төшкәч, кайдадыр искәрмәстән очрашсалар, бер-берсен танырлар иде микән? Гөлсинә, белмим, нишләр, ә менә Нурислам аны күрүгә үк таныр иде шикелле.

Ярар, юрамый тор, күңел, күпкә түзгәнне азга гына түз!

Үтте ул санаулы көннәр.

Иртән бөтен дөньясын кәжә мамыгыдай куе томан баскан, күперчеккә чыгып карасаң, биш-алты адымдагы будка да күренми, югарыдагы вышка утлары болыт артындагы нурсыз кояшка охшап калганнар иде.

Нурислам, дым тарткан авыр курткасын кыштырдата-кыштырдата будка ягына атлады, борынына майда кыздырылган суган исе килеп бәрелде дә, кире борылды. Поварбикә нидер чаж-чож китерә дә башлаган анда. «Нәрсә тәкатьсезләнеп иснәнеп йөри бу картлач»,— дип уйлавы бар.

Салкын-юеш торбалар өстенә килеп утырды.

Соргылт томан гүя аның ми күзәнәкләренә хәтле дыңкычланып кереп тулган, кул-аяклар сыкраулы кымырҗый.

Егетләр юньләп эшләргә дә ирек бирмәделәр аңа бүген. Килеп өсбашын алыштыргач та идарә итүне Зөлкәрәм үз кулына алды. «Сиңа караганда нәкъ унбер ай да унҗиде көнгә яшьрәк бит әле мин, картлач»,— ди. Торбалар өеме янына килсә: «Кая, Нурислам абый, биреп кенә тор әле»,— дигән булып, кулыннан ломын булсын, ыргагын булсын, тартып диярлек алып китә тордылар.

Инде менә утыр мәлҗерәп-изрәп.

Күпме утыргандыр, урман юлындагы шома усак кәүсәләрен тоныкяктылык нуры капшап узды, өзек-өзек сигнал тавышы ишетелде. Автобус, гадәттәгечә бирегә җитәр-җитмәстән, кара май сеңгән мүкле юан төпне әйләнеп узып, будка янына ук килеп туктады.

Вышкалы алан ни арада сабан туе иртәсенә охшап калды диген. Алмаш вахта егетләре генә түгел, төнге сменанык ылар да килгән, әле берсе, әле икенчесе Нурисламның кулбашына, касыгына төрткәләп, кулын кысып китәләр. Кияү егете сыман иңе аша кызыл пута бәйләп алган бурком Булатов бөтен аланны бер итеп тәгәрәп кенә йөри, өшеткеч томан да, итәк-чабуларын җыйгалап, инде усак һәм каен очларына табарак үрмәләгән иде.

Ул да булмады, алан уртасына ындыр табагы чаклы брезент өсте алма, помидор, кыяр өемнәре, алюмин тәлинкәләр, сырлы стаканнар белән тулган, көмеш муенлы шампанский шешәләре дә кукраеп утыра иде. Будка ишегеннән бурлаттай кызарган, кулына озын саплы чүмечен тоткан поварбикә һәм куәс чиләгедәй зур кастрюль күтәргән ике егет килеп чыктылар. Монысы күзгә чалынуга, Нурислам абзагыз кинәт... Һавага очты-китте: ике егет искәрмәстән генә күтәреп алдылар да, ул «Кылангагыз, матри!»— дигәләгәнче, брезент табынның түренә китереп тә утырттылар. Шул арада кайсыдыр аска мендәр салырга да өлгерде.

Озын-шома нотыклар сөйләнмәде, алай озаклап-җәелеп утырырга вакыты ул түгел, янәшәдә генә: «Карап торыйк, нишләвегез икән бу»,— дигәндәй, сынаулы ут-күзләрен аларга төбәп, мәһабәт-горур буровойлары басып тора, автобуслары да йөзен юлга таба борган, тигез генә гөрелдәп утыра.

Шулай да, «сугыш ветераны», «нефть ветераны» дигән, «яшь бораулаучыларның остазы» дигән сүзләр кабат-кабат яңгырарга өлгерде.

Ветеран... Остаз... Кара инде, аны әле «яшь солдат», «яшь нефтьче» дип йөрткәннәренә дә кичә генә кебек ләбаса.

Әйе, сугышта бөтен взводның иң яшь солдаты иде ул. Бик хәтердә, кырыс Карелия җирендә оборонада торган чаклары иде. Нурислам, килеп төртелмәсәң шайтанның да шәйләмәслек итеп яшерелгән пулемет

оясында ята иде, шинель итәгеннән килеп тарттылар. «Сине чакыралар анда, тиз бул!»— диде мыеклы солдат. Штабка чакырулары шуңа булып чыкты: каядыр арттарак фронтның яшь солдатлары слеты булачак, Нурисламны шунда җибәрәләр икән.

Бөгелмә театрының борынгы кандилләр белән җемелдәгән биек залы да онытырлык кына түгел. Татарстан яшь нефтьчеләренең беренче слеты үтте анда. Буровой гөрелтесенә колаклары яңа гынаияләшкән чаклары иде. Монда алар нефть «генераллары» белән очраштылар.

Инде менә, ишетмәсәң ишет: син — ветеран, син — остаз. Сиңа — лаеклы ял...

Ял... Аның да ниндие әле! Больницага ук кереп ятарга, дәваланырга әйтәләр, шуңа кыстыйлар.

Чәршәмбедә нәкъ әйтелгән сәгатькә поликлиникага килеп җитте Нурислам. Врач сеңелнең күзлек пыялалары бу юлы тагы да хәтәррәк ялтырап алды.

— Мин беркөнне дә әйткән идем, Шәяхмәтов, менә Виктор Михайлович та шул фикердә. Сезгә, санаторийга кадәр, иң элек бик житди дәваланырга кирәк. Ятып дәваланырга. Хәзергә курортный карта тутыра алмыйбыз сезгә. Хакыбыз юк.

— Без алай ашыкмыйк әле тегендә таба,— диде Виктор Михайлович та. Нурислам чамасындагы ир.— Яшисебез бар әле безнең.

Шулай итеп, глициния гөлен Гөлсинә җибәргән ядкарьдә һәм төшендә генә күрергә язган микәнни соң?!

Гөлсинә белән беренче очрашканда Нурисламга ничә яшь иде икән? Әнә шул Бөгелмәдәге беренче слетка барган ел бит ул, Нәсимә белән яңа тормыш итә башлаган чаклары. Рашат инде ул яшьне дә узды, ә башлы-күзле булырга исендә дә юк.

Кем белә, бәлки, ахырдан язмышка үкенерлек булмасын дип, үз глициниясен, бары тик үзенең генә гөлен эзләве, шуны көтүедер?

Тизрәк кайтсын гына, барысын да уртага салып, икәүдән-икәү генә ирләрчә бер сөйләшәсе булыр үзе белән.

Ә нигә кайтканын көтеп торырга? Врачлар аңа климат алыштырырга ярамый, диделәр. Абзаң исә Карелия сукмакларын да, Балтик буе җилләрен дә тәненә яшьтән сеңдергән егет. Түмән ягы аңа нигә климат алыштыру булсын?

Озын-озакка сузмастан, тотарга да, юлга кузгалырга! Бәлки әле, кем белә, эше буенча да карт останың киңәш-ярдәменә мохтаждыр яшь белгеч?

...«Ветеран», «лаеклы ял» дигән сүзләр яңгырый торды, шул сүзләр белән Нурислам алдына дәүрәк-кечерәк төргәкләр дә китереп куйдылар. Вахта егетләре исә үз бүләкләрен алай кәгазьгә төреп маташмаганнар, икесе ике башыннан күтәреп, осталары алдына бик зур сәгать бастырып куйдылар. Нурисламның үз биеклегендә булыр.

Нурислам рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

Күбәйде инде аның сәгатьләре. Бөек Жиңү еллыгы дип тә, нефтьчеләр көне дип тә, планың арттырып үтәлде дип тә сәгать бүләк иттеләр. Кулга тага торганы, кесәдә йөртә торганы, будильнигы дисеңме...

Ә егетләр, молодцы, сәгатьнең почмакка бастырып куя торганын алганнар. Әнә, даң-доң сугып та җибәрде. Матур доңгылдый, колакка ягымлы. Тик егетләр сәгатьнең телләрен дөресләп куярга онытканнар, нәкъ егерме өч минутка алдан чаң суга башлады бу.

Нурислам күптәннән сизмәгән житезлек белән урыныннан сикереп торды да сәгать телләрен үз белгәндәгечә дөресләп куйды. Юк, вакыткай, ашыкмый тор әле син, Виктор Михайлович әйтмешли, яшисе бар әле безнең, кул житмәгән эшләребез күп!

# «КАЛЕВАЛА»ГА — 150 ЕЛ

Һәр халыкның үлмәс батырлары, аларның батырлыкларын сурәтләгән эпос-дастаннары бар. Без борынгы грек шагыйре Гомерның «Одиссея» һәм «Илиада»сын, рус халкының «Игорь полкы турында жыр»ын, французларның «Роланд турында жыр»ын, Америка шагыйре Г. Лонгфеллоның «Гайавата турында жыр»ын, грузин Ш. Руставелиның «Юлбарыс тиресе ябынган батыр»ын, әрмәннәрнең «Давид Сасунские»н, кыргызларның «Манас»ын, якутларның «Нюргун Боотур»ын, калмыкларның «Җангар»ын һәм башкаларны беләбез. Үзебезнең Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы да шулар рәтендә.

Карел һәм фин халыкларының уртак эпосы «Калевала» да әнә шундый гүзәл әсәрләрнең берсе. Быел «Калевала»ның беренче мәртәбә китап булып басылып чыгуына 150 ел тулды. Бу күренекле вакыйга безнең илебездә Бөтенсоюз күләмендә зур әдәби-мәдәни бәйрәм итеп билгеләп үтелә.

«Калевала»— аерым жыр-руналардан торган шактый катлаулы һәм зур күләмле әсәр. Ул үз эченә борынгы туй-йола җырларын, аучылар-балыкчылар-игенчеләрнең әфсенырым такмакларын; дөнья яралу, җир-күк-су аерылу, беренче кеше — Вяйнямейнен туу, аннары шул геройның һәм башкаларның төрле маҗараларын бәян итүче руналарны туплаган.

Эпосны халыктан тукми-чәчми җыеп алып, эзлекле сюжетлы бербөтен әсәр итеп фин фольклорчысы Элиас Ленрот (1802—1884) эшкәрткән. Аның 32 рунадан торган беренче басмасы 1835 елда, ә инде 50 руналы тулы басмасы 1849 елда дөнья күрә.

«Калевала»ның эчтәлеге бик борынгы заманнарга — ыруглык җәмгыятенә, сыннарга-потларга табынган мәҗүсилек дәверенә карый. Төп герой Вяйнямейнен — хикмәт иясе, хаким, руналар җырлаучы. Шул ук вакытта ул — ыруг башы, җирдә табигать-ана Илматардан туган беренче кеше. Илматар исә күк-Тәңренең гүзәл кызы. «Дөнья яралу» исемле башлангыч җыр-рунада «җил кабарткан кыз карынын, диңгез авырга калдырган» диелә. Димәк, Вяйнямейнен — җилдән-диңгездән табылган бала. Эпосның сюжеты әкиятифантастик мотивларга корылган. Әмма ул мотивлар хезмәт җырлары, халыкның тормышкөнкүрешен чагылдырган реаль чынбарлык, гореф-гадәтләр, йолалар белән аралаша. Вяйнямейнен исә хикмәт иясе, җырчы гына түгел, ул урманнар үстерүче, иген игүче, көймәләр ясап балык тотучы, халык музыка коралы — кантелене иҗат итүче — кыскасы, гади җир кешесе. Шул ук вакытта ул — әкияти маҗаралар герое, кешеләргә ут табып бирүче (Прометейны хәтерләгез!), кара көчләргә каршы көрәшүче. Икенче герой — тимерче Илмаринен. Ул — тимерне буйсындыручы, сихерле тегермән — сампоны ясаучы. Эпосның башка геройлары да көтүче Куллерво, сыра пешерүче кыз Капо, пәһлеван Лемминкяйнен һ. б.— бер яктан, җир кешеләре, икенче яктан, әкияти көчләргә ия затлар. Һәм шунда ук, әлбәттә, убырлы карчык Похьола. Җыр-руналарда бар табигать, бар тереклек җанландырып-сынландырып бирелә. Анда шүрәле, су анасы, йорт иясе кебек һәрбер халыкка хас образлар яши.

«Калевала»ның теле гаҗәеп гади, халыкчан. Шул ук вакытта искиткеч шигъри, образлы. Руналар рифмасыз, сигез иҗекле ритмик шигъри юлларга бүленеп, җырлап-көйләп сөйләнгәннәр.

Гадәттә эпос-дастан геройларының язмышы хөрмәтле һәм озын гомерле була. Алар озын-озак йокыга талырга, тау-ташка әйләнергә, күккә ашарга, тагын әллә нинди язмышларга очрарга мөмкиннәр. Әмма халыкка кирәк булганда алар еш кына яңадан пәйда булалар, яңадан җирдә хаклык өчен, гаделлек өчен көрәш алып баралар. Яхшылык һәрвакытта да явызлыкны җиңә.

Вяйнямейнен да ахырда көймәсенә утырып каядыр бик еракка китеп югала. «Кирәк булсам, чакырырсыз, кайтырмын»,— дип әйтеп китә. Димәк, герой — үлемсез. Батырлары үлемсез халык — үзе үлемсез.

Мин байтак еллар Американың бөек демократ шагыйре Уолт Уитменның «Үлән яфраклары» исемле мәшһүр китабын татарчага тәрҗемә итү белән мәшгуль булдым. Моның өчен

Американың Уитменга кадәр булган әдәбиятын, бигрәк тә индеецлар фольклорына таянып атаклы «Гайавата турында җыр» (1855) әсәрен язган Лонгфелло иҗатын өйрәнергә туры килгән иде. Баксаң, Лонгфеллога «Калевала»ның йогынтысы гаять көчле булган икән! Ул үз әсәренә хәтта бу эпосның ритмик үлчәмен дә алган. Шулай итеп мин «Калевала»га килеп юлыктым. Юлыктым һәм... аерыла алмадым. Лонгфеллоны да, Уитменны да куеп торып, эпосның күп кенә руналарын татарчага тәрҗемә иттем.

Бүген шул тәрҗемәнең бер үрнәген — бер җыр-рунаны журнал укучыларына тәкъдим итәм.

**Марс ШАБАЕВ**

# КАЛЕВАЛА

## Дөнья яралу

Төн артыннан төннәр үткән,
таң артыннан таңнар аткан,
шулай көннәрдән бер көнне
мәңге яшәр җырчы-шагыйрь
Вяйнямейнен туган икән
сылу, зифа Илматардан.

Зәңгәр күкнең гүзәл кызы,
назлы табигать анасы
озак саклаган намусын,
гыйффәтле килеш яшәгән
олы һава юлларында,
күз җитмәс иркенлекләрдә.

Вакыт җиткән, моңсуланган,
тормышыннан авырыксынган,
туйган инде ялгызлыктан —
яшь кызларның язмышыннан
олы һава юлларында,
иксез-чиксез киңлекләрдә.

Җиде кат күктән иңгән ул,
төшкән зәңгәр дулкыннарга,
ярсыз диңгез өсләренә,
җил уйнаган иркенлеккә.
Кинәт көчле җил чыккан да
диңгезне кайнаткан шунда,
ярсыткан чал дулкыннарны.

Гүзәл кызны җил тирбәткән,
кызны дулкын айкап йөрткән
чиксез диңгез киңлегендә,
ак күбекле иркенлектә.
Җил кабарткан кыз карынын,
диңгез авырга калдырган.

Үзенең каты корсагын,
авырларның да авырын
җиде гасыр күтәргән кыз,
тугыз батыр гомере үткән,
ләкин тудыра алмаган...

Матур гына кыр үрдәге
су өстендә бөтерелә,
кайда оя корырга дип,
аулаграк урын эзли.

Оча төньяк, көньягына,
көнчыгышка, көнбатышка —
аптырашта кыр үрдәге,
балалары өчен оя
корырлык җир таба алмый,
бер кайда да коры җир юк.

Шулай бик озак оча ул,
уйлана да фикер йөртә:
«Оямны үрсәм җилләрдә,
дулкыннарда бәпкәләргә —
җилләр тузгытырлар аны,
дулкыннар юар оямны».

Шунда кошка колак салып,
үрдәк төшеп утырсын дип,
үзенә оя корсын дип,
су анасы һәм күк кызы
тезен күтәрә дулкыннан.

Матур гына кыр үрдәге
су өстендә бөтерелә,
зәңгәр диңгез киңлегендә
күтәрелгән тезне күрә,
аны түмгәк диеп белә,
яшел кәсле түмгәк диеп.

Очып-очып йөри дә ул,
кызның тезенә утыра,
җылы-йомшак оя корып,
алтын йомыркалар сала.

Менә инде кыр үрдәге
утыра йомыркаларда,
кызның тезен җылыта ул.
Бер көн, ике көн утыра,
өченче көн су анасы
тоя: тезе яна-пешә,
эсседән эри тамырлар.
Түзми, тезен тартып ала —
коелып төшә йомыркалар,
коелалар дулкыннарга,
чәлпәрәмә ватылалар,
тирә-якка чәчеләләр.

Чәчелгән китекләр шунда
күз алдында үзгәрәләр:
аскылары — тупыйклары
җир-энкәгә әвереләләр,
өскеләре — очлылары
күк гөмбәзе булып куя.
Йомырканың сары өсте
якты кояш булып балкый,
йомырка агының өсте
ай булып кабына күктә;
китекләрнең чуарлары
әверелә йолдызларга,
китекләрнең каралары,
куерып, була кара болыт.

Вакыт ага, ару белми —
ел арты ел чиратлаша.
Яңа кояш балкый күктә,
яңа ай алтындай яна.

Су анасы алга йөзә,
су анасы, күкнең кызы,
тынып калган суда йөзә,
томан сарган дулкыннарда;
алда — чал диңгез сулары,
артта — аяз күк гөмбәзе.

Унынчы ел киткәндә кыз
йөзен күтәрә диңгездән,
биек дулкыннардан өскә.
Тотына ул табигатьне
белгәненчә бар кылырга
якты диңгез киңлегендә,
күз җитмәс иркенлекләрдә.

Кулы белән бер сыпырса —
калка диңгез борыннары,
аягы белән бер басса —
балыкларга чокыр була,
суны чәчрәтеп коенса —
тирән чоңгыллар уела.

Җиргә кырын ятып алса —
тип-тигез яр күтәрелә,
ярга карап колач салса —
семгаларга уңай урын,
ярга чалкан йөзеп килсә —
тын култыклар хасил була.

Яр буеннан эчкә йөзә,
ачыклыкка, киңлекләргә;
кораблар бәрелеп батсынга,
моряклар батып үлсенгә
диңгезгә кыялар тезә,
су астына кыяташлар.

Инде атаулар калкалар,
калка диңгез кыялары,
күк гөмбәзе терәкләре,
төрле илләр-җирләр туа
Вяйнямейнен генә тумый,
мәңге яшәр җырчы-шагыйрь.

Су анасы һаман йөзә
көнбатышка, көнчыгышка,
көньягына, төньягына,
офыкларны йөзеп үтә,
утта яна, өзгәләнә,
тулгаклардан газаплана.
Үкси-үкси тилмерә ул:
«Хәсрәтле көннәрем килде
каңгыраган мин мескенгә!
Кайларга юлыктым соң мин —
баш очымда — күк гөмбәзе,
җилләр шәфкатьсез исәләр,
дулкыннар айкый да чайкый.

Хәзерге шикелле менә
дулкыннарда интеккәнче,
һава-күкләр кызы булып
калган булсам, мең яхшырак:
мин мескенгә салкын монда,
туңам мин боздай бу суда.

И син, Укко, күк тәңресе,
җилнең, күкнең иҗатчысы!
Кирәк чакта җиргә иң син,
ишет ялваруын кызның!
Бәладән коткар бахырны,
коточкыч авыртулардан!
Бирегә син ашык тизрәк,
миңа бик тиз ярдәм кирәк!»

Акыллы карт Вяйнямейнен
энисенең карынында
утыз ел йөргән адашып,
шул кадәр үк озын кышлар
тын суларда тирбәлгән ул,
томанлы чал дулкыннарда.

Уйлана да фикер йөртә:
«Ни кылырга, нишлим икән
бу караңгы бишегемдә,
ай бөтенләй күренмәгән,
кояш нурлары кермәгән
бу тар-кысан торагымда?»

Шундый сүзләр сөйләнә ул,
өметләнеп әйтә шунда:
«Ай, Кояш, бирегез ирек,
Җидегән йолдыз, син юл күрсәт,
ничек моннан чыгарга соң,
бу оядан җәһәт кенә,
бу тар-кысан торагымнан?
Озат син мин ирне җиргә,
чыгар баланы һавага,
күктәге айны күрергә,
якты йолдызлар багарга».

Юк, чыгармый ireккә Ай,
чыгармый аны Кояш та.
Тагын бераз түзә дә ул,
башка түзәргә калмагач,
кальгасенең капкасына
бармагы белән кагыла,
сөяк йозакны ача ул
сул аяк чәнчәсе белән;
тырнагында шуып төшә
бусагадан, тезләрендә
шуып чыга өйалдыннан.

Диңгезгә тәгәрәп төшә,
дулкынга тотына кулы;
шаулы диңгезнең иркендә,
дулкыннарда кала батыр.

Дулкыннарда биш ел ята,
алтынчы ел шунда һаман,
җиде-сигез ел диңгездә.
Ниһаять, корыга чыга,
күз күрмәгән бер урынга,
урмансыз ярыматауга.

Тезләре белән этенеп,
кулларында әйләнә ул:
Ай күрергә күтәрелә,
ал Кояшка сокланырга,
Җидегән йолдыздан өйрәнеп,
ерак йолдызлар багарга.
Сылу, зифа әнкәсеннән,
Илматардан, гүзәл кыздан
шулай туа Вяйнямейнен,
үз ыруын башлый җырчы.

# АБАЙ КОНАНБАЕВ

(1845—1904)

Абай — казах язма әдәбиятының нигез ташларын салучы олуг шагыйрь һәм мәгърифәтче. Тугандаш әдәбиятта бик күп нәрсә Абайдан башланды дисәк, мөгаен, ялгышмабыз.

Абай туры сүзе, барыннан да бигрәк гаделлекне, кешелеклелекне алга сөрүе белән яшьли үк феодаль җәмгыять кануннарына, аның мәрхәмәтсез әхлагына каршы чыга, хаким сыйныф вәкилләренең дошманына әверелә.

Беренче шигырьләрен ул гаять соң — утыз биш яшьтә генә яза башлый. Шулай да тиз арада аның даны далага таралып өлгерә, шигырьләре һәм җырлары телдән-телгә йөри. Шигырьләр иҗат итү белән бергәттән, яраткан шагыйрьләреннән Пушкинны, Лермонтовны, Крыловны казах теленә дә тәрҗемә итә.

Шагыйрь яшьтән үк көнчыгыш телләрен, шәрык дөньясының бөек культура әһелләрен өйрәнә. Семипалатинск мәдрәсәсендә укыганда рус революционерлары белән аралаша, алар аша Толстой, Салтыков-Щедрин, Белинский әсәрләре белән таныша. Болар исә Абайның уй-фикерләрен, дөньяга карашын тирәнәйтә, үзе яшәгән мохитка ул тәнкыйть күзе белән карый. Шагыйрь даладагы тормышны, яшәп килгән тәртипләрне үзгәртү турында хыяллана, иске гадәтләрдән арынырга чакыра, ислам дине кануннарына сукырларча табынуны тәнкыйтьли, хатын-кызның хәлен җиңеләйтү өчен көрәшә.

Казах әдәбияты тарихына Абай, барыннан да бигрәк, зур шагыйрь һәм фикер иясе буларак кереп калды. Туган әдәбиятын эчтәлек ягыннан да, форма ягыннан да нык баетты, аны тормышка якынайтты.

Шушы елның июль аенда казах әдәбияты классигы Абайның тууына 140 ел тула. Түбәндә без аның берничә әсәрен урнаштырабыз.

* * *

Ак көмештәй коеп куйган киң маңгае,
Кара күзләрнең йолдыздай, нурланганы,
Кара кашлар кыйгач кына сызып куйган,
Хәтерләтә яңа туып килгән айны.
Маңгаеннан туры төшкән нәфис борын,
Аксыл чырай, ал-кызыл битләр алмалы,
Иренен ачса — тезеп куйган ак тешләре,
Күрү белән җанда дәртнең кайнаулары!
Сөйләр сүзе әдәпле дә, мәгънәле дә,
Көлүендә — сандугачның сайраулары.
Түп-түгәрәк ак ефәктәй ап-ак муен,
Йомшак ияк асты,— ала күз яуларын.
Калак сөякләре — канат, иңнәре төз,
Күкрәгендә пар алманың уйнаулары.
Буе-сыны озын түгел, кыска түгел,
Нечкә биле тал-чыбыктай сыгылмалы.
Беләкләре яшь баланың тәнедәй саф,
Бармаклары нәзек, төрле эшкә җайлы.
Таралып, дулкынланып иңгә төшкән
Кара чәче хәтерләтә ефәк талны.

Казахчадан **Нури АРСЛАНОВ** тәрҗемәсе.

* * *

Бирәүләр ходайдан ялварып бала телиләр. Янәсе, үләр көнендә караучысы, дога кылып калучысы булыр. Картайган көнендә асраучысы яки тупланган малын тапшырыр кешесе булыр.

Урынлы борчылумы соң бу? Юк!

Малны кем генә тупламасын, әле аның дөньяда иясез калганы юк! Шулай ук дөнья малын үзе белән алып китәрдәй комсыз карун да

тумаган. Үлем якынлашканда малым чит-ятларга кала дип кызганып яту урынсыз. Баланың да бит әле төрлесе була. «Яхшысы сөенеч булса да, яманы — көенеч»,— дип, халык белми әйтмәгән. Ходайдан көткән баланың кем буласын алдан белмисең. Шулай ук ул баланың үзебезнең баштан үткән авырлык-хурлыкларны ничек күтәреп аласын да алдан белә алмыйбыз.

Инде, балам мине соңгы юлга җайлап-хәстәрләп, ясин чыгып озатсын дисәң, исән чагыңда башкаларга күп яхшылыклар эшләсәң, шул башкалар бу вазифаны үти алмас идеме? Әгәр дә гомереңне яман эшләр белән үткәргәнсең икән, балаңның соңгы тырышлыклары да, өстеңдә коръән укып утырулар да берни бирмәячәк. Исән чакта үзең эшләмәгән яхшылыкларны синең өчен балаң үти алмый инде. Әле аның шунысы да бар, гомере буе башкаларга бер яхшылык та кылмаган адәмнән яхшы, тәрбияле бала үсәрме икән әле? Андый ир-егет тәрбияләр өчен үзеңә башкачарак булу кирәк шул.

Картаймыш көнемдә балам тәрбия итәр дип ышану да буш сүз. Иң беренче — әле картая алырсыңмы, кем белә бит. Аннары ул балаң миһербанлы булып туамы-юкмы бит әле. Ә инде терлек-туарың күп икән, сине болай да караучы, тәрбия итүче табылачак. Үзе ачлы-туклы яшәсә миһербанлы улыңнан да рәт чыкмас. Мал табу һәр ир-егет кулыннан килә торган эш түгел әле ул.

Инде балаң да булсын ди. Аңа яхшы тәрбия бирә алырсыңмы соң? Булмаса бит үз гөнаһларың өстенә балаң гөнаһы да өстәлер, аны ничек күтәрмәк буласың? Гадәттә без балаларыбызны иң әүвәл алдашырга өйрәтәбез. «Әнә аны бирермен, әнә тегене бирермен»,— дибез дә, баланың алдануыннан кызык тапкан булабыз. Аннары, үсә төшкәч, бала алдашса, аңа башкаларны гаеплибез, күршедән күрәбез. Күрше-күлән белән әрләшкәнне дә күреп үсә бала. Берәр тиңе белән тарткалашканда: «Әйдә, сук!»— дип тә җибәрсәң, бөтенләй тинтәкләнәчәк инде ул.

Баланы сабакка биргәндә дә мулла-мөгаллимнең иң арзанын эзләп, хат танытырлык булса ярамаганмы дип, эш итеlә. Укыганда да: «Фәләннең баласы синнән яман, төгәннең баласы синнән көнләшә»,— дип, баланың җанына тиеп, ялгыш, ят кыланышларга юл куйсаң, аннан ни көтмәк? Шуннан кешеләргә хәерхаһ адәм үсәр дип уйлыйсызмы?

Инде мал, байлык туплау мәсьәләсенә килик. Кайвакыт анысын да ходайдан телибез, «ходай бирсә», дибез. Ә ул инде сиңа барын да биргән, югыйсә. Хезмәт итеп мал табарлык исәнлек-саулык, көчегәрлек биргән. Тик без ул көч-куәтне хәләл кәсеп белән үз кирәгеңне булдыруга тотабызмы соң? Укып белем алырга, һөнәр үзләштерергә тырышабызмы? Һөнәре булган иренми хезмәт итсә, армыйталмый эзләнсә, үз урынын табып эшләсә, мал-туарлы булмас, баемас идеме әллә. Барын да булдырыр иде. Ә бездә ул юк. Кемне дә булса куркытып малын талап алырга тырышу, һич югы түбәнсенеп, ялынып үз кирәгеңә ирешергә теләү, алдау-йолдау — менә шуңа күбрәк омтылабыз шикелле.

Бу инде ходай биргән көчеңә таянып түгел, намусың, абруең сатып, алдашып яки ялагайланып, теләнчелек итеп тапкан ризыгың. Хуш, шулай итеп син мал таптың, баедың да ди. Һич югы инде хәзер шул малыңны сарыф итеп укырга, гыйлемгә табына белергә кирәк. Үзең булдыра алмасаң, балаңны шул юлга юнәлтә бел. Кисәт: «Гыйлемсез-һөнәрсез сиңа бу дөньяда да, ахирәттә дә көн булмас»,— диген. «Белми укысаң, намазның да савабы юк»,— диләр түгелме соң?

Әмма әлегә бер генә казахның да яманлык белән баеп та, малын, байлыгын яхшы эшкә тотканына шаһит булганым юк. Алай була алмыйдыр да шул. Этлек белән табылган мал этлеккә үк китеп тә барадыр. Соңында үкенү-көенү газаплары гына кала. Байлар да әнә, малы барында: «Мин бай!»— дип мактана. Маясы кими төшсә: «Мин бай идем»,— ди. Хәерчелеккә калучылары да аз түгел.

Казахчадан **Лирон ХӘМИДУЛЛИН** тәрҗемәсе.

**Марат Мулюков,**
тарих фәннәре кандидаты

# МӨСЕЛМАН СОЦИАЛИСТЛАР КОМИТЕТЫН ТӨЗҮЧЕ

Февраль буржуаз-демократик революциясе патша самодержавиесе тарафыннан изелеп килгән барлык милләтләрне хәрәкәткә китерде. Шул исәптән татар халкы да үзенең милли азатлыгы өчен көрәшне нык активлаштырды. Бу көрәшнең башында кем торуы зур роль уйный иде. Татар буржуазиясе, моны яхшы аңлап, милли-азатлык хәрәкәтендә җитәкчелекне үз кулына алырга омтылды, бөтен милләт, хәтта Россиядәге барлык мөселманнар исеменнән сөйләргә маташты.

Казанда ул чорда эш иткән иң көчле һәм йогынтылы буржуаз оешмаларның берсе Мөселман комитеты булуын әйтергә кирәк. Февраль революциясенең беренче көннәрендә үк (1917 елның 7 мартында) барлыкка килгән бу оешмага буржуазия, дин әһелләреннән, кадетлардан (Апанаев, Сәетгәрәй Алкин, И. Үтәмешев, Садри Максуди һ. б.) тыш, Вәлидхак Танычев кебек татар меньшевиклары вәкилләре, Фуад Туктаров, Latыйп Мостафин кебек уң эсерлар да керә иде.

Бу комитет һәм буржуазиянең төп максатлары гомумдемократик таләпләр артына яшеренгәнлектән, аңа каршы көрәш алып бару гаять кыен иде. Мөселман комитеты, татар буржуазиясенең финанс ярдәменә таянып, тиз арада эшне киң җәелдерә алды.

Билгеле, патша бәреп төшерелгәннән соң хезмәт иясенә буржуаз оешмаларның карашларын аңлап бетерү кыен иде. Шунлыктан политик яктан өлгермәгән эшчеләр һәм крестьяннар массасы милләтче буржуазия йогынтысына эләкте. Ләкин бу хәл озак дәвам итмәде. Революциянең тирәнәюе, хезмәт ияләре киң массасының революцион аңы үсү нәтиҗәсендә җәмгыятьнең сыйнфый бүленеше ачыклана барды. Татар җәмәгатьчелеге акрынлап ике лагерьга аерылды: бер якта үзенең хезмәттәшләре (меньшевик-оборончылар, уң эсерлар һәм реакцион кадетлар ягына авышкан милләтче оешмалар) белән милләтче буржуазия торса, икенче якта демократик милли оешмалар революцион пролетариат һәм ярлы крестьяннар белән бер союзда тора иде.

Моңа ирешү өчен Казан большевикларына, демократик татар интеллигенциясенә һәм татар эшчеләр сыйныфына зур һәм әзлекле эш алып барырга туры килде. Алар алдында бик катлаулы бурыч — милләтче татар буржуазиясенең һәм аның союзникларының ялган демократизмын фаш итү, татар халкының демократик позицияләрдә торган һәм идарә итүнең Совет формасын таныган барлык көчләрен бергә туплау бурычы тора иде. Тарихи шартлар моны хәл итү өчен татар халкының үз милли-демократик оешмасын — буржуаз-милләтче Казан Мөселман комитетына каршы тора алырлык оешма булдыру зарурлыгын көн тәртибенә куйды.

Бу бурычны 1917 елның 7 апрелендә оешкан Мөселман социалистлар комитеты (МСК) уңышлы башкарып чыкты. Аның оештыручысы һәм җитәкчесе ялкынлы революционер-ленинчы Мулланур Вахитов булды.

Тарих фәннәре докторы М. К. Мөхәррәмов үзенең «Октябрь һәм Татарстанда милли мәсьәлә» дигән китабында (Казан, 1958, 40—44 бб.) күрсәтеп үткәнчә, Мөселман социалистлар комитеты милли-демократик, социалистик оешма иде. Ул үзенә эшчеләр сыйныфы, крестьяннар вәкилләрен һәм татар интеллигенциясенең алдынгы өлешен берләштерде. Тагын да төгәлрәк әйткәндә, МСК партия түгел иде, ул тарихка татар хезмәт ияләренең массовый милли революцион-демократик оешмасы буларак керде.

РСДРП(б)ның Казан комитеты органы булган «Рабочий» газетасы болай дип язды: «Күптән түгел Казанда Мөселман социалистлар комитеты барлыкка килде: яшәп килгән

төрле социалистик группалар социалистик көчләрен экономияләү йөзеннән аның тирәсенә тупландылар. Комитет үз алдына хезмәт иясе массаларын оештыру, татар пролетариаты һәм крестьяннары арасында социализм идеяләрен тарату бурычларын куя. Комитет ана телендә социализм мәсьәләләре буенча брошюралар һәм газета чыгару эшенә кереште» («Рабочий», 1917, 7 апрель).

Биредә әйтелгән максат һәм бурычлар МСКның беренче җыелышында ук бәян ителә. Шунда ук Комитетның Мулланур Вахитов тарафыннан төзелгән Уставы раслана. Уставта, Мөселман социалистлар комитетына социализмны үзенең идеалы иткән барлык гражданнар кабул ителә, дип бик ачык күрсәтелә. Мөселман социалистлар комитетының программ таләпләре МСК чыгарган «Кызыл байрак» газетасындагы «Алга, алга!» дигән мәкаләдә бәян ителә. Анда мондый таләпләр куела: «1) власть эшчеләр, крестьяннар һәм солдатлар советына күчсен; 2) бөтен җир һич тә кичектерелмичә крестьяннарга бирелсен; 3) Дәүләт думасы, Дәүләт шурасы таратылсын; 4) иске хөкүмәтнең союзниклары белән ясаган барлык могаһәдәләре (договорлары — М. М.) халыкка фаш ителсен; аларны үтәүгә Россия халкы мәҗбүри булмасын; 5) сугыш бетсен; 6) заводлар, фабрикалар һәммәсе эшчеләрнеке, эшләүче халыкныкы итеп игълан кылынсын!» («Кызыл байрак», 1 сан, 15 июнь, 1917).

Менә шушы политик таләпләр яктылыгында МСК һәм аның органы «Кызыл байрак» газетасы татар хезмәт ияләре арасында оештыру һәм агитация-пропаганда эше җәелдерә.

МСКның гомуми җыелышында көндәлек практик эшләр алып бару өчен Комитетның Президиумы һәм Комиссияләре (бүлекләре) сайлана: эшчеләр мәсьәләсе комиссиясе, аграр комиссия, милләт мәсьәләләрен тикшерә торган комиссия, хатын-кыз мәсьәләсен карый торган комиссия, гыйлем вә мәгариф комиссиясе, малия (финанс) комиссиясе, хокук комиссиясе, тикшерү комиссиясе, тәхрир (редакция) комиссиясе, информация комиссиясе.

МСКның структур составыннан күренгәнчә, бу оешма бик күп төрле мәсьәләләр белән шөгыльләнүне үз өстенә алган.

Мөселман социалистлар комитетының (шулай ук президиумының да) рәисе итеп бертавыштан Мулланур Вахитов сайлана. Аның урынбасары — Әминә Мөхетдинова, секретаре — Ибраһим Кулиев, секретарь урынбасары — Шәһид Хәмидуллин, казначее — Хатип Мөхетдинов, аның урынбасары — Каюм Саттаров була.

Һәр комиссиягә шулай ук рәис (председатель) һәм членнар сайлана. Моннан тыш эре предприятиеләрдә, профсоюз оешмаларында, уку йортларында МСК үзенең махсус вәкилләрен булдыра. Бертуган Крестовниковлар заводында, мәсәлән, Абдулхай Козлов һәм Фәтхулла Төхфәтуллин, Пороховойда — И. Зиннәтуллин, Алафузов заводларында — Бохараев, һөнәрчеләр союзында — большевик К. Саттаров, приказчиклар союзында — большевиклар В. Шәфигуллин һәм Х. Гайнуллин, уку йортларында — Х. Мөхетдинов. Арчада Ш. Гайнетдинов, Тәтештә Г. Гатауллин, Спаста Абдулла Денисов, К. Сафа, Бондюгта Сәхабетдинов һ. б.лар МСКның активистлары буларак эш итәләр (Нәфиков Р. И. «Мулланур Вахитов». Казан, 1975, 109 б.). Моннан тыш Россиянең күп кенә шәһәрләрендә, шул исәптән Мәскәү һәм Петроградта, Уфа һәм Оренбургта,Түбән һәм Томскида, Әстерхан һәм Троицкида МСКга буйсынган шундый ук комитетлар сайлана.

Хәзер МСКның политик һәм культура-агарту эшчәнлегенә тукталыйк. 14 майда ул Эшчеләр клубы ача. Аның стеналарына революцион лозунглар, Маркс, Энгельс, Бебель, Чернышевский һәм башкаларның портретлары элена. Клубның үз уставы булдырыла. Шуның нигезендә аңа көн саен яңа членнар кабул ителә. Клубка килүчеләр биредә газета-журналларның яңа саннарын укый алалар.

Әлеге Эшчеләр клубының берничә секциясе һәм комиссиясе була: хатын-кызлар, яшьләр арасында оештыру секцияләре — әнә шундыйлар. Музыка һәм драма түгәрәге эшли. Эшчеләр, хезмәткәрләр, шәкертләр һәм хатын-кызлар өчен көн саен диярлек лекцияләр укыла, докладлар ясала, әңгәмәләр үткәрелә.

РСДРП(б)ның Казан комитеты МСКның Эшчеләр клубы эшчәнлеген зур кызыксыну белән күзәтә һәм аның хезмәт ияләре арасында бик тиз танылуын билгеләп үтә. «Рабочий» газетасы әлеге клуб ачылу уңаеннан: «...приказчиклар һәм эшчеләр арасында эшчеләр клубына ихтыяҗ бик зур, ул приказчиклар, эшчеләр, крестьяннар, солдатлар... өчен ял сәгатьләрендә очрашу үзәге булачак. Эшчеләр клубы, һичшиксез, пролетариат көчләрен оештыру эшенә гаять зур хезмәт күрсәтәчәк»— дип яза («Рабочий», 1917, № 12, 18(5) май).

МСКның Казан большевиклар оешмасы белән тыгыз бәйләнеше профессор Р. Нәфиков хезмәтләрендә дә ачык күрсәтелә.

Мөселман социалистлар комитеты белән большевикларның Казан комитеты арасындагы бәйләнеш Вакытлы хөкүмәткә каршы бергәләп коралды восстание әзерләүләрендә дә ачык чагылды. МСК вәкилләреннән берсе — эшче большевик Абдулла Измайлов большевиклар партиясенең VI съезды эшендә киңәш бирү хокукы белән катнаша, ул съезд эше, анда кабул ителгән карарлар турында МСК утырышында чыгыш та ясый.

РСДРП(б) VI съездының кораллы восстаниегә әзерләнү турындагы карарына таянып, МСК халык массаларын кораллы восстаниегә әзерләү эшен көчәйтә. Мулланур Вахитов җитәкчелегендәге бу Комитет, Казан большевиклары белән берләшеп, татар эшчеләре, хезмәткәрләре һәм крестьяннары арасында аңлату эшләре җәелдерә, шул ук вакытта Казан Мөселман комитетының халыкка хезмәт итү турында h. б. шундый ялган демократик лозунгларын фаш итә, аңа каршы аяусыз көрәш оештыра. Мулланур Вахитов, мәсәлән, «Кызыл байрак»та басылган «Байлар һәм социалистлар» дигән мәкаләсендә, Мөселман комитеты әһелләрен байларның кузбуяучылары, халык колагын ялган белән дыңгычлаучылар дип атый.

Татар эшчеләре арасында социализм идеяләрен тагын да киңрәк тарату максатында Эшчеләр клубы каршында пропагандист һәм агитатор әзерләү өчен алты айлык социаль фәннәр курслары оештырыла. Мондый кадрларга ихтыяҗның утә кискен торуын исәпкә алып, бераздан әлеге курсларның сроклары ике-өч айга калдырыла. Аларда политик экономия, 1871 елгы француз революциясе тарихы, политик партияләрнең тарихлары һәм программалары, милләт һәм дин мәсьәләләре, дәүләтне идарә итү формалары һәм структурасы кебек фәннәр белән беррәттән, дөньяның барлыкка килүе, җирдә тереклек ярал, кешенең барлыкка килүе кебек табигать фәннәре дә өйрәнелә.

Бу фәннәрне укытуга Казанның күренекле галимнәре һәм политик эшлеклеләре чакырыла. РСДРП(б)ның Казан комитеты җитәкчесе Я. Шейнкман да большевиклар партиясе һәм аның программасы турында лекцияләр белән чыга.

Социаль фәннәрне өйрәнү, пропагандист һәм агитаторларны оешкан төстә әзерләү татар хезмәт ияләре арасында социализм идеяләрен киң таратырга ярдәм итте.

Мөселман социалистлар комитеты Казанның эшчеләр кварталларында зур политикоештыру эше алып барды. Пороховой, Алафузов, бертуган Крестовниковлар заводлары кебек эре предприятиеләр МСКның таяныч пунктлары иделәр. Әлеге заводларда эшләүче татар эшчеләре башта буржуаз Мөселман комитеты йогынтысында иделәр, чөнки Февраль революциясе булгач та, Бишбалтага Мөселман комитеты әһелләре килеп, бик күп эшчеләрне үзләре ягына авыштыра. МСКның Елга аръягы оешмасын төзегәндә (Алафузов заводлары шунда урнашкан) Зәйнетдинов, Бохараев кебек активистларга Казан Мөселман комитетының буржуаз-милләтчелек политикасын фаш итү буенча зур көч куярга туры килә. Алафузов заводларында Мулланур Вахитов үзе дә берничә тапкыр чыгыш ясый. Биредә шулай ук МСК һәм большевикларның Казан комитеты митинглар һәм җыелышларны бергәләп тә уздыралар.

Казан большевикларының Мөселман социалистлар комитеты белән хезмәттәшлеге бергәләп җыелышлар һәм митинглар уздыру белән генә чикләнми, әлбәттә.

25 майда Алафузов театры бакчасында татар эшчеләренең гомуми җыелышы үткәрелә. Анда Казан Мөселман комитетының эшчәнлеге кискен тәнкыйтьләнә, ул «эшчеләр интересларын яклауга бик салкын карый, эшчеләр секциясенә үз вазифалары белән шөгыльләнергә юл бирми, дип күрсәтеп үтелә («Аваз», 9 сан, 8 июль 1917). Җыелыш резолюция кабул итә, аңа җыелыш рәисе Әбләев, секретаре Зәйнетдинов (большевик, МСК члены) һәм башка членнар кул куя. Бу резолюциядә: «Мөселман комитеты составына сайланган вәкилләрне чакыртып алырга һәм аларның мандатларын юкка чыгарырга. Шунлыктан мөселман эшчеләренең Бишбалта районы бюросы шушы көннән Мөселман комитетыннан чыга, дип белдерә», диелгән. «Аваз» газетасының шул ук санында Мөселман эшчеләренең Казан Мөселман комитетына резолюция рухындагы гаризасы да игълан ителә, моңа «сарыкларның бүреләр белән бергә яши алмаулары күптән билгеле» дип тә өстәлә.

Татар эшчеләре Казан Мөселман комитетыннан чыкканнан соң Елга аръягында МСКның район оешмасы барлыкка килә. Аның составына И. Зәйнетдинов, С. Хөснетдинов, А. Әхмәдуллин, Г. Хисмәтуллин, Г. Гайнетдинов, Г. Маннапов, Г. Хәсәнов һәм башкалар керә.

Мөселман Социалистлар комитетының татар хезмәт ияләре арасында нинди зур эш алып баруын Казан мисалында бик ачык күрергә мөмкин. Биредә ул сентябрь аенда гына да 120 митинг, 300 ләп җыелыш үткәрә. Боларның бөтенесе хезмәт ияләрен алда торган социалистик революциягә әзерләүдә мөһим роль уйный.

МСК шәһәр эшчеләре һәм хезмәткәрләре арасында эшләү белән бер үк вакытта авылдагы күп меңле крестьян массалары арасында да политик агитация эшен киң җәелдерергә омтыла. Бу эшне ул беренче чиратта крестьян депутатларының губерна Советы, Земская Управа (М. Вахитов бу Управаның члены була) аркылы гамәлгә ашыра. Сугышның авырлыгы татып, политик вакыйгаларга шактый төшенеп туган якларына кайткан солдатлар агитаторлар итеп киң файдаланыла. Фронтовик-солдатлар авылларда һәм

волостьларда солдат, эшче һәм крестьян депутатлары Советлары комитетларын оештыруда ярдәм итәләр. МСК членнарыннан большевик Г. Сәйфетдинов крестьян съездларында катнаша. Крестьян депутатларның губерна Советы председателе урынбасары Фәйзрахман Хәкимов һәм Совет башкарма комитетының башка күп кенә членнары М. Вахитов белән эшлекле бәйләнештә торалар. Р. И. Нәфиковның «Мулланур Вахитов» дигән китабында (Казан, 1975, 102 б.) М. Вахитов белән Ф. Хәкимовның, МСК белән крестьян депутатлар губерна Советының үзара бәйләнешләре шактый калку күрсәтелә. Татарстан Үзәк Дәүләт архивыннан Ф. Хәкимовның тагын бер кызыклы хаты табылды. 1917 елның 4 июлендә Царево-Кокшайский земство больницасыннан (командировка вакытында шунда эләгә) крестьян депутатларның губерна Советына яза ул аны. «Кадерле иптәшләр,— ди ул,— алла хакы өчен Мөселман социалистлар комитетына 10 июльдә булачак съездларда (мөселман съездларын күздә тоткан булса кирәк— М. М.) ярдәм итүегезне үтенеп сорыйм, югыйсә буржуаз Мөселман комитеты бөтенесен басачак. Әхмәтшин бөтен тәртипне белә. Әгәр дә сезнең, башкарма комитетның, көче азрак булса, полк комитетларыннан сорагыз,— ярдәмгә саф мөселман-крестьяннарны җибәрсеннәр. Хәрби мөселман комитеты белән килешү ясарга мөмкин, хәер, анда да купчелек буржуа... Мөселман комитетында бары тик октябристлар һәм кадетлар. Шул рәвешчә алар җитәкчелекне үз кулларына алсалар, Учредительное собраниегә бары тик буржуа эләгәчәк. Безнең аграр мәсьәлә җимереләчәк. Тагын да нигезлерәк мәгълүматны Вахитов бирер».

Әлбәттә, крестьян депутатлары Советы белән бәйләнеш урнаштыру Мөселман социалистлар комитетына крестьяннар арасында үзенең йогынтысын шактый көчәйтергә мөмкинлек бирә. Бу мәсьәләдә ул РСДРП(б)ның Казан комитеты ярдәмен дә тоя. Өязләрдәге крестьян съездларына МСК үз вәкилләрен җибәрә. Алар арасында большевиклар да бар. Мәсәлән, Г. Сәйфетдинов берничә өяздә булырга өлгерә. Большевик В. Шәфигуллин Казан өязе крестьяннары арасында эш алып бара. Олы Мәңгәр һ. б. волостьларда бай һәм кулакларның провокацион чыгышларын фаш итә. М. Вахитов һәм Ш. Әхмәдиев Чистай өязендәге крестьяннар съездларында катнашалар.

Мөселман социалистлар комитеты членнарының урыннардагы большевиклар белән тыгыз бәйләнештә эшләүләре дә игътибарга лаек. Гельсингфорс матросы — большевик Г. М. Хәеровны мисалга китерергә мөмкин. Партия аны Мамадыш өязенә эшкә җибәрә. Биредә ул МСК белән элемтә урнаштыра. Бөек Октябрь коралды восстаниесе алдыннан да ул Мөселман социалистлар комитетына килә, М. Вахитов белән пролетариат диктатурасы өчен алда торган көрәш хакында озаклап сөйләшә. Тарихи мәгълүматларга караганда, МСКның Кронштадттагы Казан землячествосы мөселман секциясе белән дә элемтәсе була.

Губерна өязләрендә алып барылган зур эше МСКның крестьяннар алдында абруен күтәрә. Мөселман социалистлар комитетына авыллардан киңәш сорап ходоклар килә башлый. Алар, бер яктан, үзләренә киңәш һәм күрсәтмәләр алсалар, икенче яктан, МСКга крестьяннар арасындагы чуалышлар турында җиткереп торалар. Мөселман социалистлар комитетының аграр мәсьәләне үзенең утырышларында берничә тапкыр каравы, ә гомуми җыелышларында крестьяннар арасында эшләү мәсьәләсен тикшерүе әнә шуңа бәйләнгән. 6 майда үткәрелгән шундый җыелышларның берсендә газетага крестьяннар тормышы турында язучы хәбәрчеләр булдыру турында карар чыгарыла. 11 майда үткәрелгән икенче бер җыелышта исә крестьяннар арасында агитацияне яхшыртуга юнәлдерелгән карар кабул ителде, бу карарда агитаторлар сорап мөрәҗәгать иткән төбәкләргә кичектергесез рәвештә МСК вәкилләрен җибәрергә кушыла («Аваз», 6 сан, 13 май, 1917). Шушы ук җыелышта МСКның Тәтеш өязе буенча вәкиле тыңлана.

Большевиклар һәм алар йогынтысында МСКда солдатлар арасында политик агитация алып баруны үзәккә куялар. Бу вакытта мөселман солдатлары хәрәкәте гомумдемократик характерда булса да, аның үзенчәлекләре турында да әйтергә кирәк. Алар үзләренең хокукларын мөселман булмаган солдатларныкы белән тигезләүне, сугышны кичекмәстән туктатуны таләп итәләр. 16 мартта прапорщик И. Алкин җитәкчелегендә Хәрби мөселман комитеты оеша. Ләкин солдат массаларын (милли изүнең авырлыкларын үз җилкәләрендә татыган солдат киемендәге крестьяннарны) Хәрби мөселман комитетының буржуаз-милләтчелек юнәлеше канәгатьләндерми, шунлыктан алар демократик оешмаларга тартылалар. Мондый шартларда Хәрби мөселман комитеты, бер яктан, милли буржуазия һәм Вакытлы буржуаз хөкүмәт белән, икенче яктан, солдат массаларын үзенә җәлеп иткән МСК кебек демократик оешмалар арасында койрык болгауны мәгъкуль күрә.

Большевиклар дилбегәне кулларында нык тоталар. Мөселман солдатлары арасында Хәрби шура (Совет — М. М.) членнарыннан күренекле большевиклар Камил Якубов, Якуб Чанышев һәм башкалар актив эшли. Шунлыктан Мөселман хәрби комитеты тарафыннан крестьяннар арасында эшләргә әзерләп җибәрелгән агитаторларның бик күбесе Ва-

кытлы хөкүмәт политикасын үткәрү урынына большевистик лозунглар белән чыгалар. Хәлнең мондый борылыш алуы Мөселман хәрби комитеты җитәкчеләрен дә, Вакытлы хөкүмәт вәкилләрен дә пошаманга төшерә.

Мөселман социалистлар комитеты фронттагы солдатлар белән бәйләнеш булдыруга да зур әһәмият бирә. М. Вахитов 225 нче Ливанск полкы врачы Ф. Г. Мөхәммәдъяров, Көньяк-Көнбатыш фронтның Аерым Армиясе башкарма комитеты члены И. М. Казаков белән даими хәбәрләшеп тора. 1917 елның 13 маенда Ф. Г. Мөхәммәдъяровка М. Вахитов һәм В. Шәфигуллин имзасы белән МСК члены булуы турында таныклык җибәрелә, аңарда: «Иптәш Фатыйх Гарифович Мөхәммәдъяровка Мөселман социалистлар комитеты исеменнән социализм идеяләрен пропагандаларга», дип күрсәтелә. МСК члennары Казанга бераәр йомыш белән килгән фронтовик-солдатларны да элемтә урнаштыру өчен оста файдаланалар. Элекке солдат Габдулла (Гыйльметдин) Шаммасов миндә саклана торган истәлекләрендә большевик Камил Якубов һәм Мулланур Вахитов белән шундый очрашуларын шактый тулы тасвирлый.

1917 елның сентябрендә МСК утырышында кораллы восстаниегә әзерлек планы раслана. Мөселман социалистлар комитеты, бигрәк тә Мулланур Вахитов өчен сентябрь-октябрь айлары кораллы восстаниегә тырышып әзерләнү чоры була. МСК һәм М. Вахитов үзе, большевикларның Казан комитеты членнары белән бергәләп, эре предприятиеләрдә Кызыл Гвардия отрядлары төзиләр. Мөселман социалистлар комитетында хәрби секция булдырыла. Аның эшендә Я. Чанышев, Г. Әхтәмов һ. б.лар актив катнаша. Татар солдатлары арасында бу секция башкарган оештыру-аңлату эшләре нәтиҗәсендә МСК Октябрь кораллы восстаниесе алдыннан солдатлар арасында бик абруйлы оешмага әйләнә.

РСДРП(б) Үзәк Комитетының 1917 елгы 10 һәм 16 октябрь тарихи карарларыннан соң большевистик оешмалар урыннарда Вакытлы хөкүмәт вәкилләре белән кискен бәрелешкә әзерләнәләр. Алар В. И. Ленинның «Россиядәге һәм Европадагы сыйнфый көрәшкә политик анализ ясаудан иң кискен һәм иң актив политика кирәклеге килеп чыга, ул политика исә кораллы восстание генә булырга мөмкин»[1], дигән сүзләрендә ачык чагыла.

Бердәм революцион фронтны тәшкил иткән барлык көчләр, шул исәптән МСК членнары да, большевиклар белән бер сафта һәм алар җитәкчелегендә хәлиткеч көрәшкә әзерләнде. МСКның 22 октябрьда үткәрелгән киңәйтелгән утырышында карар кабул ителә. Ул МСК членнарын эшчеләр һәм хезмәткәрләр арасында булырга, кораллы восстание башлана калганда, аларны көрәшкә күтәрергә мәҗбүр итә. Хәсият Гайнуллинга, мәсәлән, Казанда татар хезмәткәрләре массасын оештыру һәм аларны якындагы предприятиеләрнең (Крестовников, Арсланов һ. б.) эшче отрядлары белән элемтәгә кертү бурычы йөкләнә. Шушы ук утырышта 94, 95 һәм 240 нчы полклардагы татар роталарында солдатлар арасында аңгәмәләр уздырырга кушыла.

Бөек Октябрь социалистик революциясе көннәрендә татар кызыл гвардиячеләре рус эшчеләре һәм солдатлары белән берлектә РСДРП(б)ның Казан комитеты һәм МСК җитәкчелегендә кораллы восстаниедә актив катнаштылар.

Большевикларның Мөселман социалистлар комитеты белән блогы татар хезмәт ияләрен социалистик революциягә тартуда бик мөһим роль уйнады.

Мөселман социалистлар комитеты тарихына күз ташлап шуны әйтергә мөмкин: кайбер тайпылуларны исәпкә алмаганда, ул вакыт сынавын уңышлы узды. Россиянең мөселман районнарында Совет властен ныгыту өчен зур эш башкарды. МСК җитәкчесе М. Вахитов Россиядә мөселман эшләре комиссары итеп билгеләнә, В. И. Ленинның олы хөрмәтенә лаек була. МСКның күп членнары революция барышында большевиклар партиясе сафларына бастылар.

Мулланур Вахитов, 1918 елның 19 августында Казанда акгвардиячеләр һәм акчехлар җәзалаганда, Коммунистлар партиясе сафларында була һәм «Җиңү безнең якта булачак. Коммунизмны үтерә алмассыз!» дип якты киләчәккә тулы ышаныч белән һәлак була.

---

[1] Ленин В. И. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 26 т., 180 б.

# УРАЛЬСКИДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ



Уральскидагы Хан урманы. 1905 елда биредә уздырылган эшчеләр маевкасында Габдулла Тукай да катнашкан.

*Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

*Татарстан — туган төбәгем*



**В. Д. Стекольщиков,**
КПССның Чистай шәһәр комитеты беренче секретаре

# КАМА СУЫ БУЕНДА

Чистайга килеп кергәндә кешеләрнең күз карашы ачык төстәге буяулар белән ясап куелган эмблемага төшә. Бу рәсемдә районның бүгенге экономик тормышын бик кыска һәм төгәл билгели торган әйберләр — зәңгәр дулкын, мөлдерәп тулган тук башак һәм сәгать шөребе сурәтләнгән. Хәер, бүгенге чынбарлык турында сөйли башлаганчы, районыбыз кешеләре узган зур тарихи юлга күз салыйк әле.

Районның үзәге булган Чистай шәһәре бик күптәннән бирле рус дәүләте тарихында мәгълүм урын били. Аның бай язмышы халыкның крепостнойлык хакимлегеннән котылу өчен, илдә Совет власте урнаштыру өчен, соңрак Бөек Ватан сугышында җиңеп чыгу өчен алып барылган данлы көрәш юлы ул. Кыскасы, бу — илебез тарихының бер төбәктәге чагылышы.

Чистай шәһәренең барлыкка килүе үк халыкның азатлыкка омтылышы белән тыгыз бәйләнгән. XVIII йөзнең беренче яртысында Кама суының сул ярында үзәк Россиянең крепостнойлары, ачы язмышларына буйсынырга теләмичә, хуҗаларыннан качып китеп, ирекле бер биләмә булдыралар. Андый качаклар Себер ягына да, Урал буйларына да киткәлиләр. Кама аръягына килеп урнашучылары, кыргый урманнарны кисеп, үзләренә җир ясыйлар, иген игеп, балык тотып, терлек асрап яши башлыйлар.

Тик бу исемсез-нисез биләмә рәхәт чигеп озак тора алмый. Патша галиҗәнапләренең кискен боерыгы буенча качкан крестьяннарны ауларга, җәзаларга, кабаттан үз хуҗаларына тапшырырга тотыналар. Власть ялчылары коточкыч ерткычлыклар күрсәтәләр: крестьяннарның тораклары яндырыла, иген кырларына су җибәрәләр, Кама буе моңаеп, шәрәләнеп кала.

Шуңа да карамастан, крестьяннарның азат тормышка омтылуы кимеми. Кама аръягына, әлеге буп-буш, чип-чиста калган җиргә азатлыкка сусаганнарның яңадан-яңа төркемнәре килеп урнаша. Бу юлы инде урынның исеме алдан йөри: Чиста басу, Чиста кыр, дип, телдән-телгә сөйлиләр. 1781 елны император Екатерина II нең указы нигезендә Чистай шәһәр итеп билгеләнә. Бу вакытта анда 3500 кеше яши. Соңыннан ул Казан губернасындагы күренекле өяз шәһәре буларак танылa. XX йөз башында Чистай икмәк белән сәүдә итү үзәгенә әйләнеп китә.

Күренекле совет шагыйре Н. Н. Асеевның безнең район үзәгенә карата: «Мин ышанам: Чистай каласының үткәне генә түгел, киләчәге дә гаҗәеп бай булачак»,— дигән сүзләре бар. Шагыйрь фикеренең тормышка ашуын әллә ни озак көтәргә туры килмәде. Бүгенге Чистай — Татарстанның иң эре промышленность һәм культура үзәкләренең берсе. Монда хәзер промышленность, төзелеш, транспорт, элемтә, сәүдә, көнкүреш хезмәте предприятиеләре житмешкә якын исәпләнә. Алар көн саен 650 мең сумлык продукция житештерәләр, 68 мең сумлык төзиләр, 281 мең сумлык сәүдә итәләр, 58 мең пассажирга хезмәт күрсәтәләр.

Чистайның 21 промышленность предприятиесе ел саен 175 миллион сумлык әйбер ясый. Бу коллективлар арасында ил күләмендә генә түгел, дөньяга ук яхшы мәгълүм сәгать заводы аерым урын алып тора. Завод «Восток» исемле кул сәгате, автомобильләргә куела торган сәгатьләр һәм халык хуҗалыгына кирәкле күп төрле башка приборлар чыгара. Монда эшләнгән әйберләрнең шактые дөньяның 50 иленә озатыла. Иң зур мактанычыбыз, әлбәттә — шәһәргә шул абруйны яулап алган уңганнарыбыз. Чистай

сәгатьчеләре кемнәр соң алар? Алар — бүгенге матур тормышыбыз өчен көрәшкән каһарманнар токымыннан. Ата-бабалары безнең якта Совет власте урнаштыру өчен тырышканнар, Колчак бандаларына каршы торганнар, Бөек Ватан сугышы елларында батырлык күрсәткәннәр. Фронтта гына түгел, монда, Чистай районында да бик кирәк булган ул батырлар, бергә-бергә җиңгәннәр дошманны. Хәзер шуларның оныклары заводыбызның төп таянычын тәшкил итә. Алар һәр яңалыкны бик тиз тормышка ашырырга алыналар һәм башкарып та чыгалар. Эштә иң отышлы ысуллардан файдалану Чистай сәгатьләренең сыйфатын яхшыртканнан-яхшырта барырга мөмкинлек бирә. Шулай булмаса, без сәгатьләребез турында ике тапкыр Советлар Союзы Герое очучы-космонавт Г. М. Гречкодан мактау сүзләре ишетә алыр идекмени?! «Сезнең завод кешеләре янына мин ашкынып килдем,— диде ул безнең сәгатьчеләр белән очрашу вакытында.— Сезгә тирән рәхмәтемне белдерәм. Без Алексей Александрович Губарев белән бергәләп «Салют-4» орбиталь станциясе бортында ясаган очышыбыз вакытында сезнең сәгатьләрнең төгәл йөрүенә сокландык. Күңел җылыгызны кушып башкарган фидакарь хезмәтегез өчен мең рәхмәт сезгә. Миңа илнең теләсә кайсы заводында ясалган сәгатьне тагарга мөмкин иде. Мин Чистайныкын сайладым һәм ялгышмадым...»

Кама елга пароходчылыгында Чистайның суднолар ремонтлау заводы арада зур предприятиеләрдән санала. Монда ремонт белән генә шөгыльләнмиләр, бозваткычлар, гидротөягечләр, грейферлар һәм үзйөрешле паромнар да ясыйлар. Идел белән Камада йөзә торган теплоходлар арасында безнең заводка теркәлгәннәре дә бар. Судноларның исә барысында да диярлек Чистайның 5 нче СПТУын тәмамлаган егетләр эшли. Гражданнар сугышы елларында безнең елгачылар, икмәк һәм кызылармиячеләр төялгән кәрванны саклап калган өчен, В. И. Ленинның үзеннән рәхмәт ишеткәннәр. Заводның биш эшчесе Ленин орденлы, ә «Сормовский-5» земснарядының элекке командиры М. А. Егоровка бу олы бүләкне ике тапкыр тапшырдылар.

«Автоспецоборудование» заводы турында да, җиңел промышленностебыз турында да рәхмәт сүзләрен еш ишетәбез. Чистай тегү фабрикасы аеруча югары культурага ия. Социалистик ярыш нәтиҗәләренә караганда, ул Татарстанда гына түгел, Россия Федерациясе күләмендә дә яхшы фабрикалар исәбендә тора. Трикотаж фабрикабыз да ел саен яхшыра бара, заман таләпләренә тулырак җавап бирердәй өлгеләр үзләштерә.

Районыбызның йөзек кашыдай үзәге саналган Чистай шәһәре һаман үсә, алга бара. Әле соңгы елларда гына пионерлар өчен йөзү бассейны да булган сарай салдык, күп кенә яңа кибетләр ачылды, ресторан, көнкүреш комбинаты эшли башлады. Балалар белән кереп ял итәргә «Әкият» кафесын оештырдык. Ржавец елгасы аша күпер суздык. Шәһәр янында гына авыл хуҗалыгы техникумының укыту һәм көнкүреш комбинаты барлыкка килде. Ул аерым бер шәһәрчек кебек. Үзе җыйнак, пөхтә, уңайлы. Без һәр эшкә, кешеләргә уңайлы булсын дигән теләк белән тотынабыз. Бу изге омтылыш асфальтланган якты урамнардагы чәчәкле гөлләрнең күплегеннән дә, яңа йортларның күңелгә ятышлы иттереп бизәлүендә дә сизелә. Үткән ел шәһәрнең чисталыгы, җайлылыгы РСФСР Министрлар Советының һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл Байрагы белән дә зурлап билгеләнде.

Шәһәр кешеләре ял сәгатьләрен файдалы үткәрсеннәр өчен дә мөмкинлекләр шактый: унҗиде китапханә, өч кинотеатр, дистәгә якын клублар һәм Культура йортлары, музыка һәм сәнгать мәктәпләре, халык театры, стадионнар, спорт заллары — барысы да хезмәт ияләре карамагына тапшырылган.

Районындагы колхоз-совхозлар игенчелек, терлекчелек, яшелчәчелек белән шөгыльләнәләр. Бөртеклеләр үсә торган басуларыбыз гына да 64 мең гектар чамасы. Хәзер шул җирдән мөмкин кадәр зуррак уңыш алу серләрен ачарга кирәк. Бу юнәлештә сугарулы басуларны арттыру, югары сортлы орлыклардан гына файдалану, җирне ашлау, аны дөрес эшкәртү кебек бурычлар алга куела. Аларны тормышка ашырырдай уңган механизаторларыбыз бар. Кутлушкино колхозындагы Микаил Сибгатуллин, Жданов исемендәге колхоздагы Равил Мирсияпов, техникум-совхоздан Иван Просвиркин кебек механизаторлар белән горурланабыз без.

Соңгы елларда терлек азыгы үстерүдә бай тәҗрибә туплана. Узган ел, мәсәлән, Галактионов исемендәге совхоз эшчеләре, җәйнең коры килүенә дә карамастан, тамыразыкларның һәр гектарыннан сигез йөз центнер уңыш җыеп алдылар. «Йолдыз» һәм «Каргалы» совхозларында да азык чөгендеренең уңышы шул чама булды.

Терлекчелек безнең районда заманча үсеш юлыннан, ягъни хуҗалыкларның специальләшүе, эшнең концентрацияләшүе юлыннан бара. Әйтик, мөгезле эре терлекләр симертү буенча бай тәҗрибә туплаган «Йолдыз» совхозы, Роман совхозындагы дуңгыз үрчетү һәм симертү комплексы чын мәгънәсендә ит фабрикаларына әйләнделәр. «Йолдыз»ның Петр Краснов бригадасындагы бозаулар тәүлегенә 700 әр грамм артым бирә. Шул ук совхозның Валентина Завьялова бригадасындагы дуңгыз караучылар коллектив подряды белән эшли башладылар. Яңалыкның әйбәт нәтиҗәсе күз алдында: үткән елның тугыз ае дәвамында алар планда каралган 1600 центнер урынына 2954 центнер артым алдылар. Бер центнер итнең үзкыйммәте егерме сум чамасына арзанайды. Киләчәктә башка терлекчеләр дә яңа алымга күчә барачаклар. Чөнки аның отышлы икәнлеген тормыш үзе раслый. Мәсәлән, Кутлушкино колхозының мөгезле эре терлек симертүчеләре, шул ысулга күчкәч, бер центнер сыер итенең үзкыйммәтен 15 сумга киметтеләр.

Савымчыларыбыз да осталыкларын арттыра баралар. Сыердан дүрт мең литр сөт савучылар шактый. «Урожай» колхозы савымчысы Лидия Храмова исә үткән ел, Чистай тарихында беренче буларак, һәр сыердан бишәр мең литр сөт савуга иреште.

Соңгы елларда авыллар зур-зур төзелешләр үзәгенә әйләнеп китте. Гаделша, Татар Баганасы, Кубас авылларының бүгенге күренешләре аеруча күркәм. Алар башка хуҗалыклар өчен үрнәк булып тора. Быел чистайлылар данлы юбилейларны лаеклы каршы алу дәртендә яндылар. Арада иң көтеп алганы — Бөек Җиңүнең 40 еллыгы. Сәбәбе аңлашыла: безнең яклардан бу изге сугышка меңнәрчә егетләр-кызлар киткән. Күбесе, ил азатлыгын яулап, фронтларда мәңгегә ятып калганнар. Сигез мең кешебез, яу кырында күрсәткән каһарманлыклары өчен, хөкүмәтебезнең орден-медальләре белән бүләкләнгән, ә унбиш батыр Советлар Союзы Герое дигән иң бөек исемгә лаек булган. Андыйларның якты истәлеген без бүген дә хәтердә саклыйбыз. Чистай урамнарына В. Маринин, К. Ситдиков, А. Кулясов, П. Миронов кебек Советлар Союзы Геройларының исемнәре бирелде. Батырларның данын мәңгеләштерү максатыннан чыгып Чистайда Батырлар аллеясы булдырдык. Һәйкәл янында мәңгелек ут дөрли.

Яуда сер бирмәгән солдатларыбызның сугыштан соңгы елларда күрсәткән хезмәт батырлыгын да искә алу кирәк. Дан орденының барлык өч дәрәҗәсенә лаек булган якташыбыз Николай Семенов, мәсәлән, утыз ел буена трикотаж фабрикасында эшләде. Җиңүнең 40 еллыгын билгеләү алдыннан фабрикада Семенов исемендәге бүләкне алу өчен социалистик ярыш җәелде.

Безнең якларның тарихында якты сәхифәләр бик күп. Чистай—дөнья күләмендә танылган химик галим А. М. Бутлеровның туган җире. Монда Я. М. Свердлов, Н. К. Крупская, Г. И. Успенский, А. П. Чехов, В. А. Жуковский булып киткән. Бөек Ватан сугышы елларында Чистайда СССР Язучылар союзының Константин Федин җитәкчелегендәге бүлекчәсе эшләгән. Шәһәр ул чакта Л. Леонов, К. Тренев, А. Твардовский, С. Щипачев, М. Исаковский, Н. Асеев, С. Маршак, Б. Пастернак, К. Паустовский кебек илнең күренекле әдипләрен үзенә сыендырган.

Безнең районда Татарстанның күпсанлы әдәбият-сәнгать әһелләре тәрбияләнеп үскән. Якты образы бөек Тукай иҗатына кергән революционер-интернационалист Хөсәен Ямашевның да эшчәнлеге Чистай белән тыгыз бәйләнгән. М. Вахитовның фикердәше, Г. Ибраһимовның якын дусты, 1917 елдан КПСС члены, Казан губернасының беренче мәгариф эшләре комиссары, беренче буын совет язучыларыннан якташыбыз Шәһит Әхмәдиев иҗаты татар совет әдәбиятында билгеле бер урын алып тора. Бүгенге көндә актив яза торган Барлас Камалов, Рәисә Ишморатова, Михаил Скороходов, Кояш Тимбикова, Валентин Ерашов (Мәскәү) — шулай ук Чистай ягыннан. Әле районнар бүленгәнче үк Чистай өязендә үсеп чыккан талантлы артист һәм режиссер Габдулла Кариев белән дә хаклы рәвештә горурланабыз без. РСФСРның атказанган артисткасы Вера Минкина, ТАССРның атказанган артисты Фәйзи Юсупов та — безнең мактанычыбыз.

Районда бу иҗат көчләренең эшчәнлеге белән һәрчак танышып торалар, әледән-әле очрашулар оештырыла. Яхшы аңлыйбыз: омтылышлар уртак безнең, максатлар якты. Киләчәкнең тагын да матуррак, мулрак булуы хакына бердәм тырышабыз.

## Альберт Хәсәнов

# КАЙСЫ ЫСУЛ КУЛАЙРАК?

Беренче карашка бик гади сорау бу. Иң кулай ысул,әлбәттә, күбрәк файда китерә торганы. Ләкин нефть мәсьәләләрен хәл итәргә теләүче галимнәр, чал чәчле академик агайлар бүгенге көндә кабат һәм кабат шул сорау алдында калалар. Һәркемгә мәгълүм, нефть запаслары елдан-ел кими бара. Сыек ягулыкка мохтаҗлык исә артканнан-арта тора. Нефть бит әле — сыек ягулык кына түгел, бик кадерле чимал да. Нишләргә? Күпьеллык эш тәҗрибәләренең, фәнни күзәтүләренең нәтиҗәсе итеп галим агайлар бу мәсьәләдә әлегә бердәнбер дөрес юл итеп, бүгенге көндә файдаланууда булган ятмалардан тагын да колачлырак файдалану, катламнарның продуктлылыгын арттыруны алга сөрәләр. Ә ничек? Нинди ысулга таянып?...

Без кояш чыкканчы ук кузгалдык. Күк йөзедәй зәңгәр, уенчыктай матур микроавтобуста «Азнакай нефть мәйданындагы катламнарга мицелляр сыекча кудыру буенча тәҗрибә участогы»на ашыгабыз. Тәрәзәдән күземне ала алмыйча хозурланып барам. Безнең якның табигате иртән таң атканда, кичен кояш баеган чакларда сөйләп биргесез моңсу матурлыкка күмелә. Әйлән-бәйлән уйнаучы буй җиткән кызларны хәтерләтеп, юлның һәр ике ягында зифа каеннар күренеп кала. Барысының да өсләрендә — матур бизәкләр чиккән ак сарафаннар, кулларында — яшел кыекча яулыклар. Шул яулыкларын иртәнге таң җилендә салмак кына изәп, алар безне күздән югалганчы озаталар сыман.

Автобуста без бишәү. Иң алда, шофер егет белән янәшә утырып баручыбыз инженер-электроник Саша Игнатьев. Ул моннан бернинчә генә ел элек башкалабыздагы иң дәрәҗәле югары уку йортларының берсен тәмамлаган. Хәзер скважиналарның нефть бирүчәнлеген геофизик ысуллар белән күтәрү юнәлешендә эшли. Саша хәтта автобуста барганда да вакытны бушка уздырырга теләми. Каршына ачып салган калын гына белешмәдән куен дәфтәренә ниндидер тигезләмәләр күчерә.

Аның янына калын соры портфелен тез өстенә салып, «Татнефтегеофизика» трестының Тәҗрибә-методика партиясенең баш геофизигы Мазгар Хәбибуллович Хөснуллин сыенган. Ул — кырык җиде яшьлек фәннәр кандидаты. Ә портфелендә инде докторлык диссертациясе. Бу хезмәт шулай ук әлеге мәсьәләгә багышланган: «Катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрүдә геофизик методлар һәм аларның практик кулланылышы» дип атала.

Уртада барыбызга да мөлаем елмаеп, юл буе каеннарына сокланып, ерак Һиндстаннан килгән кунагыбыз Джайн Пракаш утыра. Җаваплы миссия белән безгә кемне җибәрергә белгәннәр! Пракаш — шул хәтле чибәр егет, аны бер сүз белән генә һич әйтеп бирешле түгел. Аның куе, калын чәче шул хәтле кара, хәтта бераз шәмәхә дә төсле, мин аны ни белән дә чагыштыра алмадым. Елмаюы да шул хәтле эчкерсез, ягымлы, әгәр бу егет берәр үтенеч белән мөрәҗәгать итә калса, аны канәгатьләндермәү мөмкин булмас иде. Кунак бик әдәпле. Егетләрнең сөйләвенә караганда, алар кичә генә Баулы ягындагы буровойдан янгырга әләгеп, юлда байтак вакыт батып ятып бик соң гына кайтканнар. Ә иртән, без Пракашның бүлмә ишеген шакыганда, ул инде кырынган-юынган, өс-башын тәртипкә китереп, кырт итеп киенеп куйган иде.

Менә шушы ягымлы, чибәр егет белән авыз тутырып бер гәпләшеп барасы килә дә, инглизчә белүебез чамалы. Пракаш үзе исә әлегә русчаны: «Эт-то пок-ка я нэ знайю» кадәр генә аңлый. Тәрҗемәче барын бар. Ләкин ул, автобуска утырганнан бирле, башын күкрәгенә салып йоклавын белә. Горькийдагы чит телләр институтын тәмамлаган бу егет: «Татарга тылмач кирәкми», дип нәтиҗә ясаган бугай.

Һәм, чыннан да, баш геофизик Мазгар Хәбибулловичның сүзләре мине кызыксындырган күп кенә сорауларны ачыклады.

— Бүгенге көндә нефтьчеләр алдында торган проблемаларны, кем әйтмешли, тавык чүпләп бетерешле түгел,— дип башлады ул. — Яңа чыганаклар эзләү дисеңме, аларны иң отышлы, алдынгы ысуллар белән бораулау, чыгарылган, җир өстенә күтәрелгән чималны промышленность үзәкләренә озату дисеңме — барысы да глобаль проблемалар. Әмма шулар арасында иң мөһиме, иң җитдие — файдаланудагы ятмаларның продуктлылыгын күтәрү. Галим агайларыбыз һәм белгечләребез беренче чиратта менә шушы мәсьәлә өстендә баш ваталар.

— Ватарлык та икән шул!— дип Мазгар Хәбибулловичны бүлдерергә мәҗбүр булам.

— Әйе, әлегә иң алдынгы техника белән җиһазландырылган промыселларда да нефтьнең тик уннан өч, уннан дүрт өлеше генә өскә чыгарыла.

— Калганнары?

— Калганы җир куенында, Девон бабай амбарларында кала бирә. Һәрхәлдә, Америкаың шушы өлкәдә шөһрәт казанган галимнәре әнә шулай дип раслыйлар. Бу фикергә безнең ил белгечләре дә кушылалар.

Әйе, зур гаделсезлек бу. Күпме көчләр түгеп, миллиардларча сумнар чыгарып файдалануга бирелгән нефть ятмаларының файдалы эш коэффициенты әлегә нибары 35-40процент-тан артмый. Шунлыктан хәзерге эзләнүләр катламнарда калган нефтьне кузгатуга, аларны өскә күтәрүгә юнәлдерелә...

Моннан берничә генә ел элек республикабыз нефтьчеләре Татарстан промыселларыннан илебезнең халык хуҗалыгына ике миллиард тонна сыек ягулык озату тантанасын бәйрәм иткәннәр иде. Бу күләмдәге ягулыкны шушындый кыска срокларда моңарчы дөньядагы бер ятмадан да ала алганнары юк иде. Әмма аны кулга төшерү кыенлашканнан-кыенлаша бара. Катламнарның басымын күтәреп, контур артындагы мәйданнарга су куып та, һәр скважинага сиртмәләр куеп та карыйлар. Җир үз байлыгын кулында нык тота. Ә нефть кирәк, бик кирәк. Ансыз бүгенге халык хуҗалыгы ихтыяҗларын канәгатьләндерү мөмкин түгел. Нишләргә? Менә шунда инде: «Чәйне кай тарафларга сугарга?»— дигән сорау килеп баса.— Кайсы ысул кулайрак?»

Мәсьәлә шулай җитди, шундый глобаль масштаблы булгач, билгеле, аны хәл итү турындагы идеяләр дә күп төрле. Араларында шактый кыюлары бар. Шушы идеяләрне алга сөреп, аларның тормышларын җәмәгатьчелек алдында исбатлап, кыска гына вакытлар эчендә баш әйләнерлек тиз карьера ясаучылар, дөньякүләм дан-шөһрәт казанучылар, академик дәрәҗәсе алучылар да булды. Шушы өлкәдә сөнгеләрен сындырып, дан-дәрәҗәләрен югалтып, портфельләреннән колак кагучылар да байтак.

Сүз инде төп җелегә суырылган катламнарның стеналарына, андагы төрле ярыкларга, бушлыкларга сыланып, ягылып калган нефть запасларын хәрәкәткә китерү, төрле ысуллар кулланып, шуларны өскә чыгару турында бара. Аңлашылса кирәк: ике мең метрлар тирәнлектә яткан нефть калдыкларын хәрәкәткә китерү, катлам стеналарыннан юып алу — җиңел эш түгел. Моннан берничә еллар элек Башкортстанның нефть фәнни-тикшеренү һәм проектлау институты баш геологы Г. А. Бабалян катламнарның продуктлылыгын күтәрүдә үз ысулын алга сөрә. Ул катламнарга кер сабыны эретелгән кайнар су кууны тәкъдим итә. Баш геологның власте дә, мөмкинлекләре дә зур. Махсус җайланмалар тудырып скважиналарга сабынлы кайнар су куарга кѐрешәләр. Эш дүрт елларга сузыла.

Тәҗрибә өчен бирелгән нефть мәйданындагы скважиналарның продуктлылыгы бер кашыкка да артмый. Ел ахыры, халык хуҗалыгына сыек ягулык озату планының өзелү куркынычы алдында калган чагы була, күрәсең. «Башнефть» берләшмәсенең генераль директоры әлеге баш геологны үзе янына чакырта да аңа кичекмәстән эшен тапшырырга боера.

Икенче бер белгеч тагын да күңелсез язмышка дучар була. Катламнарның продуктлылыгын күтәрүгә багышланган үз фикеренә нигезләнеп, ул җиңел генә кандидатлык диссертациясе яклый, фәннәр докторы булырга әзерләнә. Тик тәҗрибә мәйданындагы скважиналарның нефть бирүе ник бер тамчыга артсын?! Белгечне, фәнгә ялган теорияләр алып керүдә гаепләп, диссертацияләреннән мәхрүм итәләр. Үзен җавапка тарталар. Идея белән генә түгел шул, скважинаң нефть бирүен арттырмаса берни дә эшли алмыйсың, синең идеяңнең дә хаҗәте шул хәтле генә.

Барлык галимнәр, шулай ук чит ил галимнәре дә, скважиналарны «яшәртүдә» активлыкны көчәйткеч матдәләргә зур өметләр баглыйлар. Сабын суымы ул, селтеме, кислотамы, башка берәр төрле катлаулы химик составмы—барыбер, мәсьәләне хәл итүдә төп ышаныч әлеге АКМнарда, ягъни активлыкны көчәйткеч матдәләрдә. Германия Федератив Республикасында, Японниядә, Канадада әлеге АКМнарның шактый эффектлылары бар. Без аларны байтак күләмнәрдә сатып алабыз. Безнең күп нефть регионнарында бу матдәләрдән уңышлы тоста файдалана да башладылар. Ләкин бу — мәсьәлә хәл ителде дигән сүз түгел. Бу матдәләрне чит илдән кертү гаять кыйбатка төшә. Икенчедән, капиталист агайлар белән сату-алу

итү халыкара хәлнең ниндирәк булуына да бәйле. Уренгой-Помары-Ужгород газ үткәргечен төзүдә катнашырга ризалык биреп тә соңыннан баш тартулар шуңа ачык мисал. Димәк, безгә мәсьәләне үзебездә хәл кылырга кирәк. Һәм бу өлкәдә һәр нефть регионында конкрет чаралар күрелә.

Безнең республикада «Татнефтьпромхим» берләшмәсе төзелде. Аның төп шөгыле — катламнарның продуктлылыгын күтәрү, шуңа уңай этәргеч ясардай махсус химик катнашмалар уйлап табу һәм куллану. Шушы берләшмәнең Лениногорскидагы Геннадий Власович Чебарев житәкчелек иткән цехы узган елны ун скважинага унбер мең тонна күкерт кислотасы кудырды. Галимнәребез фикеренчә, катламга кудырылган һәр тонна кислота анда үзенең шифалы вазифаларын башкарып ун ел эчендә утыз тонна өстәмә нефть бирергә тиеш. Монда әле аның шунысы да бар. Бирелә алга беренче чиратта үзкыйммәт дигән нәрсә килеп баса. Катлам бушлыкларына җибәрелә торган элексирларны, мөмкин кадәр азрак кулланып, ягулыкны күбрәк чыгарырга кирәк. Хәзер Лениногорск промыселларында кулланыла башлаган күкерт кислотасына, бу яктан, тел тидерерлек түгел. Беренчедән, аның тоннасы кырык алты тиен генә тора. Икенчедән, бу кислота-химия заводларының ташландыгы. Аны барыбер кая да булса куярга, һич югында, тирән коелар казып, җир астына күмәргә туры килер иде.

Болар өстенә әлеге «Татнефтьпромхим» берләшмәсе цехлары катламнарында гидрошартлатулар ясыйлар, забой тирәсе зонасын чистарту эшләре алып баралар. Бу чаралар шулай ук скважина тамагына нефть җыйналуга ярдәм итәләр, катламнарның продуктлылыгын күтәрәләр.

«Иркеннефть» газ-нефть чыгару идарәсе үз мәйданнарындагы скважиналарның продукт бирүчәнлеген күтәрү буенча башка күп ысуллар белән берләттән мондый чара да билгеләде. Тольятти җиңел автомобильләр заводы белән бәйләнешкә кереп, әлеге заводтан Лениногорск промыселларына өч йөз километрлы кислота-үткәргеч салырга керештеләр. Бу кислота — шулай ук автомобиль заводының ташландыгы. Нефть катламнарына ул сиземле тәэсир итә, нәтиҗәдә скважиналарның нефть бирүчәнлеге арта...

Микроавтобусыбыз, әле сөзәк үрләргә менеп, әле тау астына төшеп, өлгер генә чаба бирә. Шулай байтак вакытлар гәп корып килгәннән соң Мазгар Хәбибуллович тан:

— Бу мәсьәләдә сез үзегез ничек фикер йөртәсез?— дип сорадым.

— Һәр казык каккан җирдән нефть фонтаны бәргән чаклар артта калды,— дип сөйләп китте ул. — Хәзер безгә нефте нык кимегән мәйданнар белән эш итәргә туры килә. Минемчә, бу ятмаларның «уңдырышлылыгын күтәрүдә» төп җаваплылык геофизиклар өстенә төшә. Ике мең метрлар тирәнлектә нинди хәлләр булуын төгәл итеп алар гына әйтә алалар. Димәк, скважиналарны да геофизиклар кулына озаграк вакытларга биреп торырга туры киләчәк.

— Сез үзегез нинди ысул тәкъдим итәсез?

— Минем фикер ярыйсы гына бәхәсле ул. Яклаучылары булган кебек, аңа каршы чыгучылар да байтак,— дип Мазгар Хәбибуллович портфеленнән калын гына дәфтәр чыгарды.— Менә монда бик кызык күзәтүләр тупланган. Мин боларны егерме еллап җыйдым. Минемчә, ятмаларның продуктлылыгын күтәрү нефть мәйданындагы скважиналарны арттыруга да бәйле. Без баштагы елларда, скважина ундүрт мең тонна нефть бирсә, үзен артыгы белән аклый, дип саный идек. Бу Ромашкино нефть ятмасын ачкан елларда шулай булды. Хәзер бу күрсәткеч, бик табигый рәвештә, нык үзгәрде. Мин скважиналар челтәрен тагын да тыгызлый төшү ягында.

Татарстанда, беренче проектлар нигезендә, утыз сигез гектарга бер скважина бораулана иде. Соңгы елларда скважиналар артты. Ләкин бу да аз. Мин үзем һәр унбер гектарга бер скважина бораулауны уңай күрәм. Мин бу фикергә күпьеллык тәҗрибәләргә йомгак ясау аркылы килдем һәм аны, һич тә икеләнмичә, ил күләмендәге трибунага басып яклыйм.

Шунысы да кызык: Америка академигы Ван Эвердингем да шушы ук фикердә икән. Америкада кырык акрга, безнеңчә, уналты гектарга бер скважина бораулау гадәткә кергән. Академик исә нефть чишмәләрен егерме акрга, ягъни сигез гектарга, берне борауланы кирәк саный. Аның фикеренчә, нефть ятмаларындагы скважиналар челтәрен куерту хисабына катламнарның продуктлылыгы бермә-бер артачак.

Баш геофизик иптәш Хөснуллин соңгы мәкаләсендә басылган саннарны китерә. Сынау астындагы биш скважинада катламны су баса. Алар нефть бирми башлыйлар. Тәҗрибә өчен әлеге скважиналар белән янәшә яңа биш скважина бораулана. Алардан мул итеп нефть килә. Мазгар Хәбибуллович ның мәкаләләрендә бәхәсле урыннар да бар кебек. Ләкин бу кыю геофизикның күпчелек фикерләрен «Татнефть» берләшмәсенең баш геологы, фәннәр кандидаты Ренат Мөслимов та хуплый. Аңа еш кына нефть мәсьәләләрен күпьяклап яктыртып килүче «Нефтяное хозяйство» журналына җибәрелгән мәкаләләрне рецензияләргә бирәләр. Яшь галим Мазгар Хөснуллин туплаган мәгълүматларны ил күләмендә игълан итәргә дә беренче рөхсәтне Ренат Мөслимов биргән.

— Алайса, сез скважиналар челтәрен куерту, ягъни ун-унбер гектар саен бер скважина бораулау ягында?— дип сорыйм.

Ул арада безнең автобус матур гына аланлыкка килеп туктады.

— Тәҗрибә участогы менә шушы инде ул, килеп җиттек,— дип, Мазгар Хәбибуллович беренче булып җиргә сикерде.

Катламнарга АКМнар кудыру, гидрошартлату, геофизик тикшеренүләр өчен куелган машиналарның бирегә исәбе юк кебек. Әлеге машиналар, агрегатлар, лабораторияләрдәге эшнең мөһимлеге кешеләрнең йөзләренә чыккан. Фәнни-тикшеренү алып баручы инженерларга, геофизикларга, геологларга ярдәмгә килгән җир асты ремонты бригадасы мастеры Марс Хәбипов, оператор Таһир Харрасов, кран машинисты Фирдәвес Вафинның да үз вазифаларына бик җитди каравын, беренче күз ташлау белән үк, сизеп аласың. Алар үзләренең бик кирәкле кешеләр икәнлекләрен дә тоялар, бугай. Егетләрнең һәркайсы нефть промышленностенда егермешәр-утызар ел эшләп, дан - шөһрәт казанганнар. Һәркайсының орденнары, күпләгән медальләре бар.

Без Геофизик тәҗрибәләр отряды начальнигы Игорь Георгиевич Карпин хуҗалыгына таба атлыйбыз. Зур автобус эченә бик тә акыллы һәм зирәк «фикер йөртүче» электрон-хисаплау машинасы җиһазландырылган икән. Көчле насослар ярдәмендә алар катламга «тамгалы нейтроннар» кудыралар. Әгәр тикшерелгән катламда нефть запаслары күп булса, алар шунда йотылып калалар. Әгәр инде катлам кысыр булса, кире өскә чыгарга ашыгалар. Бу, әлбәттә, гади тел белән аңлатканда гына шулай. Ә идарә пультында Мәскәүнең — электроника, Ташкентның атом-төш-кибернетика институтларын тәмамлаган егетләр утыралар. Моңа хәтле күп сорауларга: «Эт-то пок-ка я нэ знайю»— дип килгән Пракаш та, автобус салонына керү белән, күлгә җибәргән чуртандай булды. Пультка үзе утырды. Күп санлы төймәләр өстендә бармакларын оста пианист кебек кенә йөртә. Машинага төрле «сораулар» бирә, аны үзе теләгән режимнарда эшләтә. Машинаның сорауларга җавап төсендә чыгарган перфокарталарын да Пракаш су эчкән кебек кенә укый. Бирегә аңа тылмачның да хаҗәте шул кадәр генә. Егетнең йөзе шат: приборларның, аппаратларның эшеннән ул канәгать.

Катламнардан нефтьне күбрәк алу мәсьәләсе Һиндстан промыселларын да борчый икән. Алар безнең илдән катламнарга әлеге «тамгалы нейтроннар» кудыра торган машиналар сатып алырга килешү төзегәннәр. Инженер-электроник Джайн Пракаш шул приборларны, лабораторияне эш вакытында күрергә, сынап карарга җибәрелгән. Егетнең роман калынлыгы дәфтәре дә үзе белән. Перфокарталарның мәгълүматларын ул, берсен дә калдырмыйча, шул дәфтәренә теркәп бара. Безнең егетләр аңа ярдәм күрсәтәләр.

Төш вакыты җитте. Бирегә якын тирәдә генә ашханә - фәлән юк. Азнакайга ук төшеп китсәк, вакытны күп югалтабыз, дип, без якындагы каеннар күләгәсенә күчеп, кемнең портфелендә нәрсә бар, шуны чыгарып, уртак табын оештырдык. Пракашны табын түренә дәштек. Егетләрнең кайсы ысланган дуңгыз ите, кайсы колбаса, тозлы кыяр, суган-сарымсак чыгарды.

— Әй булдырган, минем хатын бүген сынатмаган, егетләр,— дип, күз кысып, Мазгар Хәбибуллович табынга кыздырган тавык китереп салды.

Инде тәмләп кенә ашарга керештекме дисәк, кунагыбыз боларның берсен дә авызына якын да китерми, ул — вегетарианец, ягъни итле ризыкларны ашамый икән.

Мазгар Хәбибуллович:

— Пракаш дус, Һиндстан моннан бик еракта, кем күрә дә, кем ишетә: кунак сые итеп кенә кыздырган тавыктан авыз ит инде!— дип кыстап та карады.

— Минем күңел Һиндстанда түгел бит. Инануларым — йөрәгемдә, күңелем түрендә,— диде Пракаш.

— Сүз кузгалгач, шуны да белик инде, Пракаш туган, аракыга ничек карыйсың?— дип тагын берсе сорап куйды.

Пракаш тылмач егеткә аңлатып бирде:

— Моннан бернична еллар элек, Англиянең Оксфорд университетында стажировка үткәч, саубуллашу кичәсендә виски йотып караган идем,— диде.— Коточкыч әшәке нәрсә. Шуңа кадәр алкогольне авызыма алганым юк иде, моннан соң да аласым юк. Бөек Аристотель эчүчелекне, ирекле рәвештә акылдан шашу, дип атаган. Мин шуны һәрчак исемдә тотам.

Минем сүзләр боларга ничек тәэсир итә соң, болар миннән көлмиләрме?— дигән төсле, Пракаш безнең һәркайсыбызга төбәлеп-төбәлеп карап чыкты.

— Шулай нык ихтыярлы булуың белән безнең күңелләрне тагын бер мәртәбә яуладың,— дип, Мазгар Хәбибуллович кунакның аркасыннан какты.

Әмма егетне ач утыртып та булмый иде. Без машинаны якындагы авылга җибәрдек. Аннан каймак, сөзмә, йомырка алып мендeләр. Пракаш аларны бик кадерләп, чамасын белеп, әдәп белән генә ашарга кереште. Ә мин баядан бирле күңелемне борчыган соравымны бирергә ашыктым.

— Алайса сез, Мазгар Хәбибуллович, чынлап торып скважиналарның челтәрен тагын да куерту ягында? Сезнең бу фикерегез бер кадәр аңлашыла да. Байтак өлешен суырткач, катламда басым кимегәч, нефтьнең скважина тамагына таба хәрәкәте дә көчсезләнә. Читтәрәк яңа скважина бораулаcаң, аңа нефть килә. Анысы шулай. Ләкин без бу юлга бассак, бөтен җир өстен скважиналар капламасмы? Ул җирдә игәргә дә кирәк бит әле?! — дидем.

Мазгар Хәбибулловичны мин күп еллар беләм. Башта ул Лениногорск Геофизиклар конторасында эшләгән иде. Аннары аны Бөгелмәгә, трестка алдылар. Сүзгә дә тапкыр, үткенлеге дә бар. Аның җавабы миңа гына түгел, диссертациясен яклаган чакта аңа каршы төшәрдәй оппонентларына да әзер.

— Басуларда югары вольтлы электр линиясенә, телеграмм баганаларына беребез дә каршы түгел,— диде ул.— Алар иген игүгә комачауламыймы?

— Алар бит багана гына.

— Беренчедән, скважиналарны да телеграмм баганалары төсле үк җыйнак итеп төзергә мөмкин. Җир өстенә су кранындай мөгез чыгарып калдырдың, шул бик җиткән. Калганын акыллы приборлар, автоматлар эшләргә тиеш. Хәзер бит техника заманы! Икенчедән, без күбрәк скважиналарны иген игәргә ярамаган җирләргә: текә тау башларына, чокыр-чакыр, сазлык-баткаклык урыннарга кора башладык. Шушындый төштән торып та кыеклатып, берничә скважина ясарга мөмкин. Бер төбәктә берничә скважина бораулау безнең республикада хәзер киң кулланыла...

Төкъдимнәр, теләкләр күп. Шуларның кайсысы иң уңай, иң отышлы, иң тормышчан? Боларны исбат итү өчен вакыт кирәк. Алар барысы да вакыт белән сыналырга тиеш. Шунлыктан: «Кайсы ысул кулайрак?» дигән сорау көн тәртибендә кала бирә.

# ГЕРОЙЛАР — ТОРМЫШНЫҢ ҮЗЕНДӘ...

Тормыш һәм әдәбият. Болар — бер-берсен туендырып, тулыландырып торучы ике зур дөнья. Әдәбият үзенә кирәк материалны тормыштан чумырып ала, аны художество чаралары ярдәмендә сәнгать дәрәҗәсенә күтәрә. Үз чиратында тормыш та әдәбиятның даими йогынтысын тоеп яши, җәмгыятьтәге социаль һәм рухи үзгәрешләрнең катлаулылыгын аңларга өйрәнә.

Совет әдәбиятының көче шунда: ул халык тормышына, халык интересларына аерылгысыз бәйләнгән. СССР язучылар союзының илле еллыгына багышланган юбилей пленумында билгеләп үтелгәнчә: «Әдәбият һәм сәнгатьтәге тулаем уңышларның иң төгәл критерие — халыкның идея-әхлак йөзен формалаштыруга ясый торган йогынтының реаль дәрәҗәсе...» Әйе, социализм шартларында чыныккан әдәбиятыбыз үзенең шушы тарихи миссиясен намус белән үтәп килә.

Халык тормышының сфералары гаять күп. Безнең исә бүген игътибарны шуларның фәкать берсенә — авыл тормышы һәм аның проблемаларына юнәлтәсебез килә. Ни өчен дигәндә, авыл темасы татар әдәбиятында элек-электән төп юнәлешләрнең берсе булып килде. Бу хәзер дә шулай, чөнки республикабыз тормышының бүгенгесен баетуда, киләчәгенең нигез ташларын ныгытуда авыл һаман да хәлиткеч факторларның берсе булып кала бирә.

Әдәбиятның халык тормышына йогынтысы ничек һәм ни дәрәҗәдә соң? Тормыш белән әдәбият арасында тирән элементлар бар дибез икән, аның практик бәйләнешы конкрет мисалларда ничек чагыла? Мамадыш районы. «Чулпан» колхозының почетлы колхозчысы, Татарстан АССРның атказанган культура работнигы Галимҗан ҖИҺАНШИН белән әңгәмәбез, нигездә, әнә шул хакта булды.

— Безнең илебездә китап сүзенә кече яшьтән үк хөрмәт тәрбияләнә. Шуңа күрә авыл халкы тормышында китапның роле зур булу бер дә гаҗәп түгел. Бүгенге терлекче яки игенче Тукай һәм Пушкинны, Ибраһимов һәм Айтматовны бердәй яратып укый. Ләкин истән чыгармыйк: бүгенге авыл кешесенең интереслары да үзгә. Гайҗан бабай, әнә, алдынгы булганы өчен заманында самолетта очып әйләнгән. Бүгенге колхозчыны мораль һәм материаль яктан кызыксындыру чаралары, һичшиксез, үзгәрде.

Авылда, кызганычка каршы, күләгәле яклар да аз түгел. Аларның бер өлеше, «атадан калган хата» дигәндәй, кайберәүләрнең итәгенә ябышып килә: әйтик, колхоз малына кул сузу, шәхси мәнфәгатьләренә генә кайгыртып яшәү. Хәзер көчәеп киткәннәре дә бар: мәсәлән, акча артыннан куу, байлык туплауда ярышу, эчүчелек, шулар җирлегендә мораль «яңарту»... Бу күренешләр бездә дә, рус әдәбиятында да тәнкыйтьләнде. Әмма, билгеле булганча, тәнкыйтьләү — бердәнбер юл түгел. Бүгенге колхозның чын йөзен, аның рухи культурасын билгели торган менә дигән игенчеләр, терлекчеләр һәм авыл интеллигенциясе бар. Алар — җәмгыятебезнең иң зур байлыгы.

Галимҗан абый, тормыш һәм әдәбият бәйләнешләрындагы менә шушы катлаулы процесслар турында сез ничегрәк уйлыйсыз? Чыннан да, әдәбиятның халык тормышына йогынтысы ничек, ни рәвешле бара? Безнең хәзерге прозаның, аерым алганда, «авыл прозасы»ның тормышка тәэсире кими төшкән кебек тоелмыймы?

— Сүз дә юк, әдәбиятның халык тормышына йогынтысы ифрат зур. Ләкин, күпме генә теләсәк тә, без аның нәтиҗәсен төгәл үлчи алмас идек. Ул бит көшелдәге уңыш сыман күзгә бәрелеп тормый. Язучы сүзенең хикмәте — кеше күңеле аша узуда. Яхшы китап кешенең күңелен күтәрә, рухын баета. Ә бу кечкенә нәрсә түгел. Рухы күтәренке булганнар эшен дә әйбәт башкара, тормышын да матур алып бара. Әйтик, авыл китапханәсен бер елга ябып тордылар, ди. Минемчә, колхозчыларның кәефенә, хезмәт җитештерүчәнлегенә нык сугар иде бу.

Дәрес, бодай башагы төрлечә булган кебек, укучының да төрлесе бар. Берәүләр әсәрне кичереп, эчтән елый-елый укырга мөмкин. Андыйлар үзен борчыган сорауларга җавап таба, тормыш турында уйлана. Икенчеләр өстән-өстән генә укый, мәсьәләнең асылын электермичә кала. Өченчеләр детектив ярата. Яшерен-батырын түгел, китапны бөтенләй укымаучылар да бар. Эчүчеләр, колхоз милкенә кул сузучылар күбрәк нә шундыйлар арасыннан чыга да инде.

Хәзерге татар прозасының тормышка тәэсир итү көче кимегәндер дип уйламыйм. Язучылар әзерлекле, авылның үткәнен һәм бүгенгесен белеп язалар. Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән...», Мөсәгыйть Хәбибуллинның «Чоңгыллар», Мөхәммәт Мәһдиевнең «Мәңгелек яз» әсәрләрен укып мин үземә байтак гыйбрәт алдым, үткәннәремне әр-яңадан барлап чыктым. Әмма бер урында таптану әдәбиятка да килешми. Авылын, җирен-суын,туган колхозын яраткан хезмәт кешесе, гап-гади колхозчы турында күбрәк язылсын иде. Зур идеаллар белән яшәгән үрнәк геройның әдәбиятта ныклап күренмәве, әлбәттә, юксындыра. Киләчәк көн герое, авылның киләчәге ничек — бу сораулар язучы иптәшләрне ныграк борчысын иде.

— Соңгы елларда әдәби тәнкыйтькә «производство романы» дигән билгеләмә керен китте. Безнең уебызча, татар әдәбияты нефтьчеләр, төзүчеләр, шәһәр кешеләре турында язганда күпчелек очракта әлегә мөһим бер сыйфатка тиешенчә ирешә алмады: ул да булса — кешенең шәхси тормышы һәм хезмәте, күңел яшәеше һәм эш процессы арасындагы гармонияне табу мәсьәләсе. «Авыл» әсәрләрендә исә бу — күптән һәм табигый хәл ителгән проблема. Хәзер кайберәүләр «урбанизация» дип сөйләргә ярата. Чынлап та, шәһәр күпмедер дәрәҗәдә авылны «йота». Икенче яктан, ул үзе дә ныгый, шәһәрләшә бара. Шушы җәһәттән караганда, авыл кешесенең психологиясе нык үзгәрдеме? Гомумән, өзлексез бер процесс булган крестьян хезмәтен, аның поэтикасын, философиясен, традиция һәм перспективасын әдәбиятта сурәтләү, ачып бирү сезне канәгатьләндерәме?

— Авыл тормышын сурәтләгән әсәрләр безнең күңелгә бигрәк тә якын. «Авыл» әсәрләрендә язучылар кешене тулырак, табигыйрәк тасвирлый, дисез. Миңа калса, моның сере бик гади. Чөнки авыл кешесенең яшәү рәвеше туфракка, табигать әйләнешенә — ягъни турыдан-туры игенче хезмәтенә бәйләнгән. Аның өчен «буш вакыт» һәм «производство вакыты» юк. Яңгыр ява икән — муллыкка юрый, кар калын төшә икән — дым буласына сөенә ул. Колхозчының эчке дөньясы, уй-теләкләре, сулышы, мәхәббәте һәм нәфрәте җир белән, хезмәт белән аерылгысыз. Бу гомергә шулай булып калачак, мәгәр робот-машиналарның иген үстерә алуына ышанмыйм мин. Икмәк үстерә алу бәхете фәкать кайнар йөрәкле игенче кулларына гына бирелгән.

Ә инде авылның шәһәрләшә баруы — башка мәсьәлә. Әйе, телевизор, мотоцикл, машина тормышыбызга нык үтеп керде. Телевизорыңны кабыздың — Казаны, Мәскәве дигәндәй сөйләп тора. Колхоз автобусына яисә шәхси машинаңа утырып Казанга барырга, «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклен карап китәргә мөмкин. Хәзер авылда киенү дә шәһәрчәрәк. Социологлар шулай аңлата бит: шәхеснең эчке культурасы никадәр бай булса, андый кешенең тормышы да күпкырлы, эше дә нәтиҗәлерәк була, диләр. Бу нәрсә авыл кешесенә дә кагыла, без моны һәрчак истә тотабыз. Культура йортында дистәләгән түгәрәк эшли — теләгәнеңә рәхим итеп йөр генә. Китапханәгә газета-журналлар мул килә. 22 алдынгы колхозчыга 1985 ел өчен «Казан утлары» журналы яздырган идек. Ел буе килеп торачак бу гаҗәп үзенчәлекле бүләк тантаналы җыелышларның берсендә тапшырылды.

Авыл киләчәккә атлый, матур хыяллар белән яши. Комбайн штурвалы артында утырган игенченең йөзенә игътибар иткәнегез бар микән сезнең? Нинди горурлык, никадәр җаваплылык! Г. Ибраһимовларда, әйтик, авыл хезмәтенең поэзиясен күрсәтеп бирү — печән өсте, урак өсте — хезмәттә матур кешеләр... Игенченең менә шул халәтен соңгы еллар әдәбиятында да күрәсе килә. Илне туйдырам дип эшлиме ул, әллә акча яисә орден өченме? Авылның киләчәге нинди, рухи-әхлакый байлыкларын югалтмасмы ул? Бу сорауларга да төпле җавап тапканым юк әлегә.

— Билгеле булганча, партия һәм хөкүмәтебез әдәбият-сәнгать вәкилләрен тормышны ныграк өйрәнергә өнди, халык массалары арасында ешрак булырга чакыра. Сездә язучылар еш буламы?

— Әгәр шулай әйтергә яраса, язучылар арасыннан безнең даими кунагыбыз, якын дустыбыз, киңәшчебез бар. Ул безнең һәр көнебезне, башкарган эшләребезне барлыйдыр шикелле. Әйе, якташыбыз, авылдашыбыз шагыйрь Шәйхи Маннур турында әйтүем. Туган авылы Тулбайга еш кайта иде, үзе исән чагында ук бирелгән китапларыннан килгән акчага китапханә салдырды. Иҗаты белән якын ул безгә. Халыкның үз шагыйренә хөрмәте һәм рәхмәте зур.

Инде менә, әдипнең васыяте нигезендә, «Чулпан» колхозына караган Шәйхи Маннур исемендәге китапханәнең еллык премиясен булдырган идек. Ул якташыбыз иҗатына

багышланган тантаналы җыелышта тапшырыла. Алдынгы комбайнчы Шаһинур Хәсәенов, сыер саву алдынгысы Һаҗирә Мәүлина, әдәбиятны пропагандалау һәм агитмасса эшен нәтиҗәле алып баруга зур өлеш керткәне өчен китапханә мөдире Васига Зәйнетдинова премиягә беренчеләрдән булып тәкъдим ителделәр. Хезмәт алдынгыларын ел саен әнә шулай бүләкләү күркәм традициягә әверелде.

Гомәр Бәшировның «Намус» романын, әсәрнең төп герое — уңган, кешелекле, ил өчен дәртләнеп эшләүче татар кызы Нәфисәне кайсыбыз гына белми икән! Ә бит аның прототибы — безнең колхоз кешесе Хәдичә апа Шакирова. Бу — күп нәрсә турында сөйли торган куанычлы факт.

Язучылар бездә еш була дип әйтер идем. Киләләр, колхоз тормышы һәм кешеләр белән якыннан танышалар, үзләренең язылачак әсәрләренә азык алып китәләр. Әлеге очрашулар язучыларның китаплары, матбугатта чыккан яңа әсәрләре аша дәвам итә. Үзегез әйткәнчә, халык язучы сүзенә зур ихтирам белән карый, аңардан яңа сүз көтә. Яхшы сүз — җан азыгы, диләр бит. Тырышып эшләү өчен илһам безгә дә кирәк. «Тере» язучылар белән очрашу безне эшкә дәртләндерә, күңелләргә илһам өсти.

— Соңгы елларда әдәбият табигатьне саклау мәсьәләсендә чаңны ныграк суга башлады. Илебез әдәбиятларындагы мәгълүм мисалларны кабатлап тормастан, Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» романын гына хәтерлик. Әйе, фәнни-техник революция тудырган үзгәрешләр һәм тормыш ихтыяҗы табигатьне торган саен ныграк кысрыклый. Сезнеңчә, бу проблеманы беренчеләрдән булып әдәбият күтәрдеме, әллә әүвәл халык үзе чамалап өлгердеме? Бәлки, эш вакытында, әйтик, урман кискәндә янсә болынны сукалаганда колхозчы бу хакта уйлап карамыйдыр...

— Утын янсә агач материалы кирәк икән, без туп-туры урманга юнәләбез. Аяз Гыйләҗев әйтмешли, «урман үзебезнеке!» Бу элек-электән шулай килгән. Әлбәттә, исәпчел халык һәр заманда урманның киләчәге турында кайгырткан: коры-сарыны кискән, просекалар ачкан, үсентеләр утырткан. Агачларны каян әлекте шуннан дөбер-шатыр ега башласак — бу гафу ителә торган эш булмас иде. Партия һәм хөкүмәтебез карарларының берсендә дә «уңыш кына булсын — табигатьне нишләтсәң дә ярый» дигән сүзләрне укыганым юк әле минем. Табигатькә сакчыл мөнәсәбәт — һәркайсыбызның намус эше. Бер тракторчының сөйләгәне бар: тургай оясына тап булгач, суканы күтәреп ул урынны әйләнеп уздым, дип...

Хәтерлисездер, чәчүлек мәйданнарны арттыру һәм сугарулы көтүлекләр булдыру максаты белән берничә еллар элек сазлыкларны киптереп, болыннарны сөрә башладык. Бер яктан, файдалы хәрәкәт иде бу. Икенче яктан, без моның шактый гына зыянын да күрдек: табигать балансында үзгәрешләр килеп чыкты, кош-корт кимеде, чишмәләр кипте, күкрәп торган матурлык югалды. Безгә, бәлки, болыннарны өлешчә генә сөрү кирәк булгандыр. Сазлыкларны киметтек — елгалар саекты, тәкрарлек тавышлары сирәгәйде. Кызыклы бер факт: кыр куяннары ферма тирәсенә иялләшә башлады. Тагын да гаҗәбрәге — гомер буе фәкать кырда яшәп өйрәнгән әрләннәргә хәтле авылга күчә башлады. Моның бер сәбәбе: бөртекләрне югалтусыз җыеп алырга өйрәндек, салам эскертләрен кыштан ук фермага кайтарабыз. Икенчесе турыдан-туры заманга бәйләнгән: язын-көзен туфракны аммиак суы, химикатлар белән ашлыйбыз. Менә шулар йогынтысы бу.

Кызык бит менә: бездән эш һәм аның нәтиҗәләренә сорала, икенче яктан табигатьне саклау да кирәк. Менә шушы каршылыкны җиңү фәненә бик нык өйрәнәсебез бар әле безнең. Бу мәсьәләнең дәүләт күләмендә куелуы, тормышта практик чараларны киңрәк куллану, һичшиксез, уңай нәтиҗәләр бирәчәк. Бер генә мисалга тукталасым килә. Узган ел Олыяз урта мәктәбе укучылары Мамадыш урман хуҗалыгына 25 мең төп каен кәлшәсе үстереп бирделәр. Бу матур башлангыч традициягә кереп бара.

— Галимҗан абый, сезнең озак еллар колхоз председателе булып эшләвегезне истә тотып, сөйләшүне әдәбият һәм тормыш бәйләнешләрыннан тагын бер нәрсәгә юнәлтәсе килә. Авыл — ил, халык тормышында зур урын тоткан, үзенә даими игътибар сорый торган өлкә. Хөкүмәтебезнең кардиналь чараларын һәм, ниһаять, илебезнең Азык-төлек программасын хәтерлик... Партия авыл хуҗалыгындагы ялгыш юнәлешләрне, карашларны вакытында кисәтеп, дөрес юлга кертеп тора. Кукуруза, комплекслар һ. б. белән мавыгуларда, мәсәлән, берьяклылык үзе сиздерде. Әдәбиятта да шундый мавыгулар була һәм ул беркадәр табигыйдер дә. Әйтик, соңгы еллар прозасында колхоз председателе образларының бик ишәеп китеп, арада игезәкләр дә «туууына» сез ничек карыйсыз?

— Үзеңнең эшеңә, һөнәреңә, тормышыңа кагылышлы әсәрне уку һәрвакыт кызыклы. Чөнки син белгән нәрсәләр турында сүз бара, кайчандыр үзең үк уйлап йөргән фикерләргә юлыгасың. Татар прозасында председатель образларының күбәеп китүе яхшымы, начармы? Минемчә, әйбәткә бу. А. Гыйләҗев, Ф. Хәсни, Г. Ахунов, В. Нуруллин, М. Мәһдиев М. Хәбибуллин, Х. Хәйруллин һ.б. әсәрендәге колхоз җитәкчеләре истә кала, уйландыра торган тормышчан геройлар. Һәрхәлдә, сан үсеше тора-бара сыйфат әверелеше китереп чыгарыр дип өметләнәм мин.

Повесть яки романдагы председательләр бер-берсенә охшый башлый икән, минә монысы мактанырлык хәл түгел. Чыннан да, председатель образы схематиграк бирелә бездә: кыю, тәвәккәл ул, әлбәттә, колхоз һәм аның кешеләре өчен җанын биреп эшли, игең эшен яхшы белә, кимчелекләргә карата аяусыз. һәм иң нык борчыганы — аларның күбесе кичәге көн җитәкчесен хәтерләтә. Ә бит соңгы елларда колхоз тормышының социаль һәм рухи катламнарында гаҗәеп үзгәрешләр барлыкка килде. Җир шул ук, әмма проблемалар яңа: заманча техникага кемне утыртырга? Авылда яшьләрне беркетеп калдыру өчен нишләргә? Культура һәм көнкүреш шартларын текә күтәрү өчен нинди чаралар күрергә? Ун-унбиш ел элек мондый сораулар колхоз җитәкчесенең башына килеп тә карамый иде. Тормыш үзгәрде. Колхозчы үзе дә нык үзгәрде. Акчасы мул, тормышы таза, берәз иркәләнә төште бугай ул. Тормышның үзендә бер-беренә нык охшаган кешеләрне табу кыен ич. Әдәби геройларның да үз йөзе, кабатланмас характерлары булу хәерлерәк.

Иҗтимагый тормышыбызга, идеалларыбызга зур йогынты ясарлык уңай герой ягында мин. Ләкин пьедесталда басып тормасын ул. Әйдә, хаталары да, тормыш кешесенә хас кимчелекләре дә бар ди аның. Тик иманы нык, әхлакый позициясе чиста булсын. Соңгысында бигрәк тә саклык сорала. Мәсәлән, В. Нуруллинның Булаты — җилбәзәк хатын, М. Мәһдиевнең Ахияры япь-яшь кыз белән мавыгып ала. Минемчә, һәр ике очракта да чама хисе, геройларның бу адымын нигезләү кирәк иде.

— Галимҗан абый, безнең ишетүебезчә, сезне, сугыштан ике Кызыл йолдыз ордены һәм медальләр тагып кайткан сержантны, авылдашларыгыз председатель итеп сайлап куйган. 37 ел инде сез шушы җаваплы постта эшләдегез. Председательләр турында сүз чыккан икән, тормышта һәм әдәбиятта хәзерге заман җитәкчелек стиле, халык белән эшли белү мәсьәләләренә дә тукталыйк әле. Председательдә кайсы як иң көчлесе, иң мөһиме булырга тиеш: оештыручы, белгеч, тәрбияче, администратор... Халык шушы сыйфатларның кайсысын өстенрәк күрә? — аеруча бәяли?

— Юлбашчыбыз Ленинның: «Кешелек җәмгыяте эшләп чыгарган барлык байлыклар белән зиһенеңне баетканда гына чын коммунист булырга мөмкин»,— дигән сүзләрен без барыбыз да яхшы хәтерлибез. Бу фикер бүгенге көндә дә актуаль яңгырый. Бүгенге көн җитәкчесе универсаль булырга тиеш, моны заман үзе таләп итә. Әйтик, бик яхшы оештыручы булып та, экономика, агрономия һәм ветеринария мәсьәләләрендә сай йөзәсең икән, кай урындадыр эшнең аксавы көн кебек ачык. Председатель хезмәте — улчәүсез хезмәт. Ил-көн күләмендәге яңалыклар, фән һәм тормыш хәбәрләре белән даими танышып, авыл хуҗалыгы өлкәсендәге алдынгы эш алымнарын иҗади өйрәнеп барырга кирәк. Кырга чыксаң — агроном, сәхнәгә чыксаң оратор бул. Халыкны, бигрәк тә яшьләрне тәрбияләүнең мөмкинлекләре — синең кулда. Шушы җаваплылык таңнан алып кичкә кадәр эшләргә мәҗбүр итә. Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм: хезмәтеңне яратып башкарсаң гына уңышка ирешеп була. Язучы иптәшләр председательләрнең бу сыйфатына юкка гына игътибар итмидер, күрәсең.

Халык нәрсә тели җитәкчедән? Аның гадел булуын, колхоз өчен янып йөрүен. Барыннан да бигрәк эшләгән эше өчен җылы сүз, рәхмәт сүзе көтә. Кеше күңеле белән эш иткәндә боларны исәпкә алмасаң, хезмәтең җилгә очты дигән сүз. Кешенең кайсына яхшы сүз, кайсына кимчелекләрен күрсәтеп сөйләшү үтемлерәк. Фәкать әйткәннәрең ихлас һәм дөрес булсын. Кыскасы, председатель өчен мәсьәләнең һәр ягы мөһим.

— Сез алдарак татар прозасындагы председательләрнең һәм гомумән авыл тормышының 50-60 нчы еллар тирәсендә тулгануына игътибарны юнәлткән идегез. Мондый фикер әдәби тәнкыйтьтә дә бар. Күрәсең, бу — әлеге әсәрләрнең автобиографик характерда булуы, авторларының авылда яшәгән еллары белән дә бәйледер. Соңгы елларда әдәбиятка килгән яшь язучыларның әсәрләрен дә укып баруыгыз сизелә...

— Карап, күзәтеп килөм: әдәбиятта яшь алмаш үстерүгә зур игътибар бирелә. Мәсьәлә бездә дә шулай куелган: колхозның киләчәге — яшьләр кулында, дибез. Яшь буынның шәхесен, дөньяга карашын формалаштыруда әдәбият ифрат зур роль уйный. Шуңа күрә авылның яшьлеге, бүгенге көне турында әсәрләр күбрәк кирәк. Яшьләр турындагы әсәрне яшьләр язарга тиеш. Ринат Мөхәммәдиевнең «Беренче умырзая», Мансур Вәлиевнең «Дулкын» повестьлары дөньяга чыгу әнә шуны раслый. Әдәбияттагы бу юнәлеш киләчәктә үсәр, тирәнәер дип өметләнәм мин.

Теләк шул: яшьләр прозасында авылдан идиллия эзләү яки аны берьяклы тәнкыйтьләү кәчәеп китә күрмәсен.

— Сез әдәбиятның яшьләрне тәрбияләүдәге ролен әйтеп киттегез. В. Распутин, Н. Думбадзе әсәрләрен, татардан Ә. Еники, М. Юныс прозасын, Х. Туфан һәм С. Хәким поэзиясен һ. б. искә төшерик. Иҗатлары көчле, тәэсир итә. Иҗаттагы кыюлык, күтәрелгән мәсьәләләрнең актуальлеге зур икән, әдәбиятның тормышка тәэсире дә шулкадәр көчлерәк була. Яшьләрнең китаплар белән дуслыгы мәсьәләсе ничек тора сездә? Авылда

кызлар яки егетләр проблемасы юкмы? Гомумән, авыл яшьләре ни укый, ни белән мавыга?

— Беркөн китапханәче белән сөйләшеп торган идем, шунда картотекага игътибар иттем. Баксаң, китапханә активының 60-70 проценты яшьләр һәм мәктәп укучылары икән! Укыйлар, тышлыгы тузганчы укыйлар китапны. Башка якларда ничектер, бездә гармун тавышының, кичке уеннарның үзешчәннәр хәрәкәтенең тынып торганы юк. Колхозның җыр һәм бию ансамбле үзенең осталыгын районда гына түгел, Польша Халык Республикасында да күрсәтте. Без моны һәрвакыт горурлык белән сөйлибез.

Авылда яшьләр теләп кала. Мәсәлән, узган ел мәктәпне тәмамлаган 36 укучының 16 сы колхозда калды, шуларның өчесе авыл хуҗалыгы институтына укырга китте. Дөресен әйткәндә, кызлар «проблемасы» бар. Каядыр читкә киткән кызларның байтагы авылда төпләнгән егетләргә кияүгә чыга. Колхозга кире кайтуның бер юлы шулайрак хәл ителә. Кызларны авылда калдыруны күздә тотып, күптән түгел колхоз үзәгендә «Спартак» (Казан) аяк киемнәре берләшмәсенең филиалын ачылды. Хәзер биредә яшьләрдән 30 кеше эшне башлап җибәрделәр. Шунысы куанычлы, читкә китүчеләр арасыннан филиалга эшкә кайтырга теләк белдерүчеләр дә бар. Бу инде әйбәт фал.

— Алда әйткәнебезчә, татар әдәбияты битләрендә авылның социаль үсеш-үзгәрешләр кардиограммасы, художестволы хроникасы язылып бара. Колхозлашу, сугыш вакыты, сугыштан соңгы еллар һәм, ниһаять, бүгенге авыл... Тарихи процессның тышкы панорамасы гына түгел, крестьянның дөньяга карашы, культура дәрәҗәсе, психологиясе, матди һәм рухи интереслары да үзгәрә. Әдәбият шуларның барысын да колачлый аламы? Сез ничек уйлыйсыз: бүгенге авылны сурәтләгәндә аның үткәнен һәм киләчәген, социаль тамырларны, мохитне, каршылыкларны нинди пропорциядә алырга кирәк соң? Безнең әдәбиятта авыл кешеләре, аларның хезмәте һәм язмышындагы кайбер яклар онытылып тора түгелме...

— Бик авыр һәм четерекле сораулар. Мин аларга, әлбәттә, хәлемнән килгәнчә, үзем аңлаганча җавап бирергә тырышам. Калганын тәнкыйтьчеләр әйтер.

Без барыбыз да әдәбият укып үскән кешеләр. Китаплар аша тарихны, революцион үзгәрешләрне, батырлык чыганакларын, кыскасы, тормышның үзен өйрәндек. Талантлы әсәр боларның барысын да колачлый. Конкретрак дисәгез, менә нәрсә әйтер идем мин. Авыл турында язылган әсәрләрдә аның үткәне белән бүгенгесен чагыштырып, янәшә куеп карау җитми. Бүгенге таза тормышлы колхозның беренче адымнары, беренче кешеләре нинди булган — кагыйдә буларак, бу мәсьәләгә язучы иптәшләр әйләнеп тә карамый диярлек. Әле бит колхозны оештырган, төзешкән кешеләрнең байтагы исән. Исән түгелләр икән, авылның хәтере бик яхшы, һич югы, хәтергә мөрәҗәгать итик.

Әдәбиятта тормышка нык бәйләнгән әйберләрнең күбәя баруы куандыра мине. Башында М. Горький торган социалистик реализм методы үзенең мөмкинлекләрен һаман саен ныграк раслый. Әмма, мәгълүм булганча, әдәби әсәр — тормыштагы хәлләрнең гап-гади күчермәсе генә түгел. Биредә язучының идеалы, иҗат фантазиясе, әдәби осталыгы дигән нәрсәләр дә килеп кушыла. Шушы җәһәттән килеп караганда, повесть һәм романнарда гыйбрәтле язмыш кешеләре, олы геройлар, тагын да төгәлрәк әйтсәк — шәхесләр җитенкерәми. Колхоз председателеме ул яки гап-гади колхозчымы — әсәрнең төп герое икән, ул инде шәхес булырга тиеш. Татар совет әдәбияты — бай традицияләре булган ныклы, перспективалы әдәбият. Киләчәктә әнә шундый геройлар белән очрашасыма тамчы да шикләнмим мин.

Әңгәмәне **Рәшат НИЗАМИЕВ** алып барды.

Казан утлары
АЭС
әдәби пост

# Марат Әмирханов

# ГАРИЗАЛАР

ОЧЕРК

Хасип Халиков музыкантларныкына охшаган озын бармакларын бөгә-бөгә санап китте:

— Виктор Вахламов, Салих Хәйруллин, Виниамин Калистратов... Ксеп куйган сварщиклар, чын рәссамнар иде. Ышанмыйсызмы? Әнә, карагыз!

Ул стенага эленгән рәсемнәргә күрсәтте. Хәер, будка ишеген ачуга ук күреп алган идем мин аларны. Гади рәсемнәр түгел болар, тимер чыбыкны эретеп-ябыштырып ясалганнар. Шуларның авторларын юксына өлкән мастер. Аны да аңларга була, әлбәттә. АЭСта төп корылманы күтәрә аның егетләре — җибәрү-резерв станциясен салалар. Ул шәһәрне һәм төзелеш индустриясе базасын җылылык белән тәэмин итеп торачак, атом электр станциясенең беренче блогы да шушы пар казаны ярдәмендә көйләп җибәреләчәк. Хәзергә исә су да, җылылык та вакытлы схема буенча төзелгән объектлардан килә. Шуңа күрә дәгъвалар күп. Вакытлыча дип салынган нәрсә ни дисәң дә, вакытлы инде.

Станция — катлаулы корылма, ул унөч объектны берләштерә, баш корпуста гына да бер миллион сумлык чамасы төзү-монтаж эшләре башкарырга кирәк.

Үткән елның җәе иде. Станция, план буенча, сафка басарга тиеш, ә анда әле эшнең очы да, кырые да күренми. Моңа кадәр котлован казыганнар, нигез койганнар. Хәзер иң четерекле, иң нәзберек эшләр калган. Чаннарны җыю — шуларның иң катлаулысы, моны чын осталар гына башкарып чыга ала. Ә осталар эштән азат итүне сорап гариза яза. Галкин бригадасында, әнә, 16 кешедән нибары алтысы калган.

Хасип ачу беләнрәк алдындагы кәгазьләрне өстәл тартмасына сыдырып төшерде. Каударлана мастер. Минем төпченеп утыруны да өнәп бетермәде. Идарәдә шелтә биреп кайтарганнар икән үзенә.

— Эшләмәгән кешене генә орышмыйлар,— дип юаткан булам.

— Ә-әй...— Халиков кулын гына селтәде:— «Колесный» акчаны киссәләр, тагын коргаксырга туры килмәгәе әле.

«Колесный» дигән сүз безнең төзүчеләр теленә АЭС төзелү уңаеннан керде кебек. КамАЗ чорында юк иде, нефтьчеләрдә дә колакка чалынмады. Көнбатыш Себергә йөреп эшләүчеләрдә генә булса инде. Кама Аланында исә аны шактый еш ишетергә туры килә.

Хикмәт шунда, бик күпләр монда ерактан килеп йөри: Зәйдән, Түбән Камадан, Брежневтан. Автобус китерә аларны, аннары алып китә һәм алар командировкада саналалар, ягъни тәгәрмәч өстендә. Кызык: үз өеңдә йокла, тор, ашә... һәм командировочный акча да ал. Бернинди кануннарга да сыймый кебек.

Әмма СССР Энергетика һәм электрлаштыру министрлыгы, тармак профсоюзы үзәк комитеты «колесный»га фатиха биргәннәр. Чөнки бу атом станциясе дә, яңа шәһәрчек тә бернинди материаль базасы, төзү оешмалары булмаган тын төбәктә корыла. КамАЗда бу кыенлыктан вакытлы поселоклар төзү юлы белән чыкканнар иде. Әмма вакытлы поселокларның үз авырлыклары, үз проблемалары булды. Әйтик, Чаллыда төзелеш никадәр зур, никадәр мәһабәт булмасын, ул вакытлы поселокларны фәкать 10—12 елдан соң гына бетерергә мөмкинлек туды. Алабуга трактор заводында да шулай ук вакытлы поселоклар кору күздә тотылмый, төзүчеләрнең бер өлеше, тиешле көнкүреш шартлары булдырылганчы, вахта алымы белән Брежневтан килеп-китеп йөриячәк.

Халиков исә «тәгәрмәч акчасы»ның тылсым көченә чын күңеленнән ышана. Хәер, аннан зуррак җитәкчеләрнең дә бу «коткару саламы»ннан коры калырга исәпләре юк.

Югыйсә, гаиләсе белән инде Кама Аланына күчеп килүчеләрнең дә иске гадәт буенча командировкада саналуын тагын ничек аңлатырга мөмкин?

Әмма төзүчеләрнең барысы да әлеге «буш» акчага атлыгып тормыйлар. Кайберәүләр хәтта моны гаделсезлек дип саныйлар. Димәк, «колесный» һич тә, кайбер җитәкчеләр уенча, тылсым түгел. Моны Халиков үзе дә таныды инде.

— Тәгәрмәчкә таяк тыгучы акыллы башлар җитәрлек,— диде ул офтангандай.

— Акчадан йөз чөерәләрмени?

— Дөреслек эзлиләр, югары оешмаларга дәгъва да белдергәннәр.

— Ә анда ни диләр?

— Планны контора кешеләре үтәми, ул безнең җилкәдә, менә...

Шул вакыт шыгырдап ишек ачылды. Бусагада кара тут йөзле, төз гәүдәле кеше күренде. Кылыч борын, юка иреннәр, ачык караш. Кыскасы, затлы кыяфәт.

— Дөреслек эзләүчеләрнең берсе менә шушы була инде,— диде Хасип керүченең күңеленә тиюдән курыкмыйча. Күрәсең, алар моңа кадәр дә бу хакта сөйләшкәннәр.— Әзһәр Хәбибуллин бу. Таныш булыгыз!

Әзһәрнең йөзеннән мыскыллы елмаю чаткылары йөгереп узды.

— Менә танышып чык! Нарядны җиде сумнан яптым!— диде өлкән мастер.

— Эшләгәч, язалар инде аны.

Хасип кесәсеннән кулларын алмыйча гына бүлмә буйлап йөрештереп килде, графиннан стаканга су агызды, әмма эчмәде, бер читкәрәк этеп куйды.

— Әзмәвердәй ир кешегә 160 сум акча чутмыни ул?

—«Аякларны юрганыңа карап сузасың инде.

Халиков, синең кебек кире кешегә тәмле сүзне әрәм иткәнче дигәндәй кулын селтәде һәм:

— Нинди йомышың бар соң?— диде.

Әзһәр кесәсеннән пөхтә генә итеп дүрткә бөкләнгән кәгазь кисәге чыгарып, өлкән мастер алдына китереп куйды.

Халиков аскы иренен тешләп бермәл сүзсез утырды. Аннан соң эчен тотып көләргә кереште.

— Дөреслек, хаклык пәрдәсенә ябынган була бит әле, менә чын йөзеңне ачтыңмы инде, дустым, шулай ул, берәүнең дә бушка эшлисе килми.

Хасипның йөзе тәмам яктырды, шелтә алуын да онытты, ахрысы. Үзенең сүзе өстен чыкканга (шулай уйлый иде булса кирәк) балаларча куана иде.

— Мин акча өчен китмим.

— Ә нәрсә?

— Квартира бирмисез ич.

— Монда синнән озаграк эшләүчеләр дә бар.

— Шуңа күрә сорамыйм да, фатирлы эш таптым.

— Ни дип буза куптарып йөрдең соң, алайса?

Хәбибуллинның кыйгач кашлары янә дугаланып алды, күзләреннән салкын нур сибелде.

— Сезне Хасип Сәлахович,— диде ул калтыранган тавыш белән,— план үтәү генә борчый. Кешегә ул гына җитми бит әле.

— Фәлсәфә кормыйк.— Халиков алдындагы кәгазьгә кул куйды.

— Тот гаризаңны, дүрт ягың кыйбла!

* * *

Әзһәр, ишекне шап итеп ябып, чыгып китте. Үпкәле иде ул Халиковка. Кая урнашасың, ярдәм кирәкмиме, дип сораса, теле корыр идемени? Белә ич аның нинди хәлдә калуын? Күңеле бушар иде ичмаса. Башында кырыкмаса кырык уй бит аның. Барын да әр-яңадан башларга туры килде.

Әзһәрнең исә тормышы көйләнгән иде. КамАЗда сигез ел эшләде. Башта гади төзүче, аннан мозаикачылар бригадиры булды. Культура йортлары, мәктәпләр, шифаханәләр бизәделәр. Бу биналар хәзер ялт итеп көлеп тора, сокланып туймаслык. Әлбәттә, рәсем-сурәтләрнең авторлары — дипломлы художниклар. Мозаикачы шул эскизларны вак ташлар, төсле пыялалар ярдәмендә гамәлгә ашыра, сәнгать әсәренә әверелдерә. Осталык белән бергә, игътибарлылык, саклык, төгәллек тә таләп итә бу һөнәр. Аз гына ялгыштыңмы, бөтен колоритны бозуың бар.

Яңа шәһәрдә балалар бакчасының уен залын бизәгәндә булды бу хәл. Ашыгыч иде. Тизрәк тә тизрәк! Бригадир булгангадыр инде, таякның авыр башы һаман Әзһәргә тиеште.

Бер як стенаны, ниһаять, бизәп бетерделәр. Җитәкчеләргә дә ошады эшнең темпы, премия дә яздылар. Ләкин бригадир канәгатьләнә алмады. Башкаруның сыйфатына тел-теш тидерерлек түгел, тик бизәлгән стена ямьсез иде. Балалар өчен бит бу!

Мин аңламыймдыр, рәссамнарның да башына тай типмәгән ләбаса, акны карадан аера беләләрдер, дип үзен юатырга тырышты ул.

Тынгысызлыкның сәбәбе кетелмәгәндә ачылды. Әлеге да баягы кызы ярдәм итте. Икәүләшеп бер кызыклы гына китапны актарып утыралар иде. Әзһәр сорап куйды:

— Кара әле, кызым, нинди матур болын! Әйеме?

— Юк, — диде Гөлназ, җилкәсен җыерып.— Салкын рәсем.

Әзһәр, әлбәттә, рәссамнар телендә дә «салкын», «җылы» дип йөртелгән төсләрне белә иде. Уйламаган гына. Балалар бакчасының стенасы да кызы әйтмешли, «салкын» булып чыккан.

Рәссам сакал-мыек җиткергән тар җилкәле бер кеше иде. Бөтен битен каплап торган зур күзләре аша бермәл сүзсез генә Әзһәргә карап торды да:

— Эш узган инде,— диде.

— Әле бер генә стенаны эшләдек бит.

— Кем сиңа худсоветның карарын бозарга рөхсәт итсен?

— Заказчы.

— Анысы минем эш түгел.

— Сез безгә төсләрне сайлашыгыз, калган ягын үзебез рәтләрбез.

Калган ягы тагын да авыррак булып чыкты. Бер кеше дә җаваплылыкны үз өстенә алырга теләмәде. Шәһәр советына ук барып җиттеләр, мәгариф бүлеге белән бергәләп тырыша торгач кына йөк урыныннан кузгалды.

Тик бу вакытта Әзһәрнең гаиләсендәге аңлашылмаучылыклар тирәнәя барды. Ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәт бер чатнадымы, аны җиңел генә сылап куеп булмый, стена түгел шул. Үзен дә акламый. Холкы корырак аның. Ихтимал, йомшак мөгамәлә, ихтирам да җитеп бетмәгәндер. Ничек кенә булмасын, хәл мөшкелләнде.

— Булмаса бераз аерым яшәп карыйк,— диде ул хатынына.— Бәлкем файдасы тияр.

Тегесе нәфис җилкәләрен генә сикертеп куйды, ихтыярың, янәсе. Әзһәр, шулай итеп, атом электр станциясе төзелешенә килеп төште. Ләкин аерым тору ике арадагы мөнәсәбәтне яхшыртмады, упкын киңәйде генә.

Ул әле дә бик еш уйлана: квартирын калдырып китеп дөрес эшләмәде, бәлки бүләргә кирәк булгандыр, башкалар шулай итә ич. Торырга урын юк, дип аптырап йөрмәс иде хәзер. Тик ул мәсьәләне, ирләрчә, вакланмыйча хәл итте. Үзенә нәтиҗә дә чыгарып куйды.

Бервакытта да хатын-кызларга якын килмәскә ант итте. Тик... кибеттә күзенә бер мөлаем йөз чалынып китте, үзе тагын шунда ук юк та булды, нәкъ әкияттәгечә.

«Кайда күргәнем бар иде соң бу кызыйны, таныш кебек.» Ирексездән шул уй кереп оялады Әзһәрнең башына. Юкка баш ватмыйм әле, дип тынычланырга да теләде ул, икенче сменага эшкә чыгасы иде, шунда элдертте.

Иртән уянуга күз алдына теге мөлаем йөз тагын килеп басты. Һич онытылмый.

Кама Аланында әлегә берничә йорт кына, шуңа күрә мөлаем йөзне очратуы авыр булмады аңа. Урта буйлы, нәфис гәүдәле, сылу ул кыз Әдилә исемле икән. Кинога барыйк диюгә, ризалашты. Очрашу урынына ул кәтүк кебек кенә бер кечкенә малай ияртеп килгән иде.

— Таныш булыгыз, минем улым,— диде Әзһәрнең күзләренә туп-туры карап.— Хәзергә әбисендә яши, кунакка алып килгән идем.

— Минем Гөлназым бераз зуррак инде,— диде Әзһәр.

Алар аңлаштылар. Яшерен хәл түгел: яңа төзелешләргә комсомол путевкасы белән генә килмиләр. Монда үз бәхетләрен эзләп йөрүче тол хатыннар, буйдак ирләр дә бар. Акча артыннан куучылар да очрый. Аларга туган ягына омтылучылар, фатир өмет итүчеләр кушыла. Шулардан туплана коллектив.

Баштарак Әзһәр белән Әдилә бер карчык өендә тордылар. Кызлары тугач, хәл авырлашты. Ике бала белән кеше өстендә ничек яшәмәк кирәк?! Һәм ул, барына да чик куярга тәвәккәлләп, гариза язды.

* * *

Мин шактый вакыт Халиковны да, Әзһәр Хәбибуллинны да күздән югалтып тордым. Әзһәр белән нигәдер һаман очрашасым килә иде. Яшермим, аның атом станциясе төзелешеннән китәргә сорап гариза язуы һич тә гаҗәпләндермәде, чөнки мин Әзһәрнең югары белемле укытучы, Казан дәүләт педагогия институтының физика-математика факультетын тәмамлаганын белә идем. Институттан соң Чаллы районының бер авылында укытты ул, аннан шәһәргә, төзелешкә килде.

Бер яктан караганда, төзелештән киткәч, мәктәпкә кайтырга тиеш иде. Һәм алгарак китеп әйтим, ул шулай эшләгән дә. АЭС белән янәшәдәге Иске Чишмә урта мәктәбенә урнашкан. Аңа фатир да биргәннәр, аерым йорт. Димәк, теләгенә ирешкән!

Без аның белән икенче мәртәбә җәй көне очраштык. Авылларны күчерү мәсьәләсен өйрәнеп (төзелеш зонасына эләккән Беляхча авылы турында сүз бара) йөрү иде. Бу авылны «Новошешминск» совхозының үзәгенә күчерәләр, дөресрәге, анда барлык уңайлыклары булган яңа поселок салалар.

Участок начальнигы Михаил Николашкин юл буе зарланып барды. Михаил Федоровичны җылыту мәсьәләсе аеруча борчый икән. Ник дисәң, йортларны үзәктән җылыту системасы ташкүмергә көйләнгән. Сезон саен дүрт мең тонна күмер кирәк булачак. Авыл өчен шактый мәшәкатьле эш бу, өстәвенә, кыйммәт. Төзелә торган атом электр станциясе дирекциясе башта бу мәсьәләгә, миннән киткәнче, иясенә җиткәнче, дип кенә караган, ахрысы. Хәзер менә котельныйны сыек ягулыкка көйләү турында бәхәсләшәләр. Бу билгесезлек төзүчеләрнең эшен тоткарлый.

Машина әле генә явып үткән яңгыр суларын пычтыр-пычтыр китереп кыр вагонының нәкъ ишеге турысына туктады. Ике-өч тактадан сукмак та әмәлләп куйганнар.

Безне юантык гәүдәле, ялтыр башлы бер кеше каршы алды.

— Николай Степановичка сәлам!— дип көлемсерәп кул суздьг аңа участок начальнигы.

Николай Степанович Шахов авыл советы председателе икән. Билгеле, төзелеш мәсьәләләре аны да кызыксындыра.

— Тагын ни уйлап таптыгыз инде?— диде Николашкин хәл-әхвәл белешкәннән соң.

— Һаман шул бер балык башы инде, мич хакында йөрибез.

— Пычаксыз суярга исәплисез инде, Николай Степанович, болай да план яна.

Шаховның киң ак маңгаенда вак сырлар хасил булды, канатланган кош кебек кулларын җәеп җибәрде:

— Үзең уйлап кара инде алайса: мичсез өй буламы, ә?

— Проектны алданрак карарга иде сезгә!

Авыл советы председателе аны тыңламый иде инде.

— Төзүчеләр каршы түгел бит. Владимир Майоров бригадасындагы партия группасы җитәкчесе үзем алынам, дип тора. Рөхсәт ит!

— Бу бит миннән генә тормый, Николай Степанович.

— Белештек инде без, каршы килүче булмаячак.

— Киңәшеп карыйк соң алайса.

Бераздан бүлмәгә бригадирлар, партгрупорг, мастерлар килеп керде.

Партгрупорг дигәнебез Әзһәр икән ләбаса!

— Әйе, мич чыгара беләм,— диде ул.— Бу һөнәргә башкаларны да өйрәтә алам. Шулай килештеләр.

— Әзһәр, сез ничек монда?— дип сорадым мин бүлмәдән кешеләр чыгып киткәч.

— Мин кайда булырга тиеш соң?

— Соң сез мәктәпкә күчкән идегез түгелме?

Хәбибуллинның аскы ирене әнисенә үпкәләгән баланыкы кебек бүлтәйде, күзләре дә ничектер моңсуланып киткәндәй булды.

— Кесәмдә педагог дипломы йөри, күңелем — төзелештә. Тагын килдем менә.

Монда Хәбибуллинның яңа гаризасын күрсәттеләр, фатир сорап язган, янә кеше өстендә яшиләр икән.

Ихтимал, ул үз гомерендә төрле гаризалар язгандыр, әмма миңа калса, төзелешкә кабат алуларын сораганы чын йөрәктән язылган. Атом станциясе төзелешендә ул үзенең чын оста икәнлеген, мөгаен, ахырынача раслап күрсәтер.

## Сәгыйть Хафизов

# ШАГЫЙРЬЛӘР ҺӘЙКӘЛЕ

Бөек Ватан сугышы чорының бай әдәби мирасындагы «Эх, шул килеш» исемле шигырь хәрби чынбарлыкны кителмәгәнчә тәвәккәллек, тирән мәгънә белән ачып сала. Анда фронтовик шагыйрь Шәрәф Мөдәррис сугыш гарасаты шашып шаулаган бер мәлдә, атаканың алгы сафында, полк байрагын күтәреп, тауга калыккан солдатны, татар солдатын җанландыра. Совет каһарманы пуля, ядрәләр җиле астында да тауда нык тора, байрак белән полкташларын алга чакыра, җиңүгә әйди. Мәһабәт, илаһи геройга сокланып, шагыйрь шунда мөкатдәс теләген әйтеп куя:

Эх, шул килеш кинәт җизгә катып,
Һәйкәл булып басып калсачы —
Туган җирен канга, тиргә батып
Яклый алган татар солдаты!

Шигырь Бөек Ватан сугышының тәүге елында, 1941 елда язылган булган. Бу чакта Шәрәф Мөдәррис совет солдаты алдында торган катлаулы юлны, ул үтәячәк тарихи миссияне әле бик үк тулы күзаллый алмый, билгеле. Әмма шагыйрь безнең солдатның бу канлы, зур көрәштә һәйкәл куярлык батырлыклар кылачагына ышана, моны тирәнтен тоя. Героик совет халкына һәм шуның бер вәкиле — татар халкына, батыр замандашларына дан җырлау, аларның героик сыннарын иҗат итү — бер Шәрәф Мөдәррискә генә түгел, ә барлык татар әдипләренә хас изге омтылыш иде. Вакыт, еллар агышы ныграк ышандыра бара: бу дәвернең үз замандашларына салган һәйкәле нык, мәгърур, гүзәл.

Илдә кан коюлы сугышның катлаулы шаукымы хөкем сөргән чакта кешеләр йөрәгенә ышанычлы юл салу гаять зур рухи энергия, тормыш хакыйкатенә чиксез тугрылык һәм оптимистик идея-эстетик концепцияләргә таяну исәбенә генә мөмкин. Сугыш чоры поэзиясе, шиксез, поэтик фикернең тынгысызлыктагы иң югары ноктасы ул. Шуңа күрә дә ул үз урынын яшәү белән үлем тарткалашкан иң хәтәр сызыкта — фронтта, партизан лагерьларында, төрмәләрдә, үлем концлагерьларында тапты. Бу — асылда солдат поэзиясе. Иң югары, патетик тойгылар да, борчулы хисләр дә, драматизм да шунда, конкрет кеше — солдат язмышы материалында ассоциативлашты.

* * *

Сугыш чыгу хәбәренә җавап реакциясе рәвешендә язылган күп шигырьләрдә патетика, кабатланган фразалар өстенлек алса да, бик кыска вакыт эчендә алар ихласлык, конкретлык белән алмашынды. Безнең карашыбызча, бу үзгәреш күп әдипләребезнең хәрби хезмәткә алыну, сугышка китеп, хәрби чынбарлыкны үзләре кичерүгә бәйле иде. Соры солдат шинеле кию кешегә җылы гына бирмәде, әйтерсең, аңардан тәнгә ата-бабадан килә торган йола таләбе, хис-тойгылар рәвеше дә сеңде. Шулай килә: күпме генә тыныч тормыш, хезмәт, иҗат кешесе булма, нишлисең — шинель киеп каеш буу — борынгыдан ир кеше вазифасы саналган. «Солдат мылтык аткан чакта Дары исе тарала. Ходай сабырлыклар бирсен, Сугыштагы балага»— дип, элек-электән җырлап килгән безнең халык. Тарих төпкеленнән килә торган халык уеның аерым чагылышлары аһәңнәр төсендә Бөек Ватан сугышы чоры шигырьләрендә еш яңгырап китә. Шәйхи Маннурның лирик герое солдат өлешенә тигәнне аеруча сабырлык, түземлелек белән кабул итә.

Ил өстендә дошман торган чакта
Солдат урыны сугыш кырында,

дигәндә дә:

Солдат яши туган иле өчен,
Солдат үлә туган җир өчен,

— дигәндә дә, аның авызыннан борынгы хакыйкатьнең үзен ишетәбез кебек. Тик бу кайнар пуля җилен дә чебен җилпенүе генә итеп тойган салкын акыллы карт солдатның шомарган афоризмы гына түгелме? Алай дисәң, бу чакта «Атаудагы хисләр» поэмасының авторы Әдип Маликов әле мыек кына кабартып килә торган солдат-шагыйрь. Әмма күпме сызлану-сыкрану кичермәсен, аның лирик герое да фәлсәфи уйчанланып, «Солдат юлы — изге, якты юл...» дип расларга көч таба.

Гали Хуҗиевның: «Мин — солдатың әле — һаман сафта, Бу — намуслы хезмәт итүем» дигән шигырь юлларында да, Шәрәф Мөдәрриснең «Без бу җирдә Ватан каршысында башкарабыз гадел бурычны» дип раславында да сугыш чоры поэзиясе салкын акыл, катгыйлык белән ир-егеткә изге Ватанны саклау фарыз икәнен аксиома итеп куя. Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, М. Ногман, Ә. Ерикәй, Гиз-әл Габид, М. Гаяз кебек шагыйрьләрнең тыныч, уйчан шигырьләрен укыганда да солдат кешенең образы конкретлаша төшә, уйлары, дөньясы ачыклана. Алардан халык әкиятләрендә макталган солдат — түземле, сабыр, акыллы, гайрәтле солдат калкып чыга сыман. Солдат кешегә бөтенесеннән дә бигрәк батырлык, үлем дигән чиркәнеч, коточкыч нәрсәдән дә курыкмау сыйфаты кирәк. Бу җәһәттән дә сугыш чоры поэзиясе турыдан-туры:

Тәкәббер бул үлем алдында,
Син курыкма, үлем куркысын!
(Ә. Фәйзи)

— дип, сыналган киңәшне бирә.

Бөек Ватан сугышы чоры татар поэзиясендә сизелгән бу тыенкы рационалистик агым кырыс чынбарлыкның олы ихтыяҗы иде. Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленин үз вакытында социалистик Ватанны дошманнан саклап калуга карата күп уйланган, киңәшләрен әйткән. Безнең карашка, ул фикерләрнең барысын да, фокустагы сыман, юлбашчының бер җөмләсе сыйдырган кебек: «Әгәр дә без үзебезне буш кычкырулардан, гаҗизлектән җиңдермәсәк, дошманнан җиңдермәбез»[1]. Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясендә кайнар, миңгерәткеч сугыш чынбарлыгына карата түземле, йөрәкле булырга чакырган сабыр акыл авазы, һичшиксез, юлбашчыбыз күрсәткән олы хакыйкатькә турыдан-туры җавап бирергә омтылудан, шулай ук, халыкчан шигъриятнең үз инстинктыннан килә иде.

Тик шулай да сугыш дәвере шагыйрьләре иҗатының төп поэтик кредосын икенче башлангыч, алдан ук чагыштырмас дәрәҗәдә көчле үсеп киткән ашкынулы, хиссиятле башлангыч тәшкил итте. Ул татар поэзиясе тарихында тиңе булмаганча бай юнәлеш буларак формалашты. Аның төп чыганагын ялкынлы революция һәм гражданнар сугышы чоры романтикасы хасил итә иде. Азатлык көрәше поэзиясе яңа тип каһарман солдатның героик, ярсулы образын алгы планга чыгарды. Йөрәге иҗтимагый ирек, перспектива сөенеченнән рухланып типкән һәм социалистик Ватаны өчен актык тамчы канын да кызганмаган кызыл көрәшчене революция шагыйрьләре ашкынып җырладылар.

Без курыкмыйбыз үлемнән, безгә ул берни түгел,
Безгә каршы кул күтәрү, уйла, ул уен түгел.
Без җиңәрбез, көл итәрбез алдагы дошман көчен,
Кан коярбыз, җан бирербез шул мөкатдәс эш өчен,

— дип язды солдат Ибраһим Йосфый. Ә Бөек Ватан сугышы чорындагы аерым шигъри юллар, әйтик: «Бу көннәрнең бөек эше өчен һич кызганыч түгел минем кан» (Исхак Закиров) яки: «Кызганмабыз данлы гомерне дә хезмәт халкы өчен көрәштә» (Гариф Галиев)— шул поэтик фикернең кайтавазы сыман булып яңгырыйлар. Болар үз чиратында тагын ерактагы үткәнне — «Кечкенә Җәлил»не искә төшерә. Революциянең иң яшь шагыйрьләреннән берсе булган Муса Җәлил азатлык көрәшендә корбан булуны «бәхет» дип атады. Җиңелми алга барганда, пуля килеп, күкрәгемне бишкә киссә, егылсам — бәхетлемен, дип фикерләде аның лирик герое.

Ләкин шагыйрьнең соңрак еллардагы сәнгатьчә фикерләвендә реаль социалистик яшәү принципларының йогынтылы тәэсире сизелә, иҗатында халыкчанлашу, баю тенденциясе бара. Бөек Ватан сугышы чорында язылган «Окоптан хат»ында шагыйрь ихластан:

Канат җәеп, үлем куркынычы
Торган саен окоп алдымда,
Мин көчлерәк тоям ирек тәмен,
Яшәү дәртен кайнар канымда,

— ди. Бу инде аның бәхетне яшәүдән, тормыштан табуы турында сөйли. Әйе, чын совет кешесенең асылы да шунда: ул тормышны, яшәүне ярата. Тормышны, яшәүне

[1] Ленин В. И. Полное собрание сочинений. Т. 35, изд. 5, М., 1974, стр. 407.

ныграк сөйгән саен, ул көчлерәк итеп кешеләрне, Илен, Ватанын ярата. Шул бөек, олы хис аны каны, хәтта гомере бәрабәренә эшләнгән батырлыкларга китерә... «Окоптан хат»ның лирик герое шулай фикерли, бөтен кузәнәге белән шуңа ышана. Беренче шигырьдә гуманизм стихияле булса, монда ул аңлы, социалистик гуманизм чагылышын ала. «Кечкенә Җәлил» язган «Бәхет» белән солдат Муса Җәлил иҗат иткән «Окоптан хат» шигырьләрендә стиль, тасвир, сурәттә зур аермалык булган шикелле, олы омтылыш, тойгы нисбәтендә дә алар арасына тулы тәңгәллек куеп булмый. Герой-шагыйрь М. Җәлил һәм Бөек Ватан сугышы чорындагы башка шагыйрьләрнең иҗатында кеше, Ватан азатлыгы өчен көрәш концепциясе татар совет поэзиясенең башлангыч еллары белән чагыштырганда, һичшиксез, икеләтә-өчләтә реалистик, сәнгатьчә көч белән гәүдәләнде. Ягъни шул дәрәҗәдә үк образлылык артты.

Әнә карагыз, саран гына бер сурәт-тасвир, гади бер мимика, деталь-елмаю. Ә сугыш поэзиясендә ул үзе белән пешереп ала торган информацион яңалык алып килә. Үлем каршында курку, чиркану, нәфрәт кичерергә яисә батыр булып калырга мөмкин. Тик менә көлү?!.

... Көлә беләм сугыш җирендә.
Көлә беләм,
Шаулап җырлый беләм,
Көрәшләрдә куңел ямь таба,
Күз алдымда каты үлем күрәм,
Җиңә беләм,
Җиңү — мәртәбә!

Фашистлар тарафыннан крематорий мичендә яндырылган шагыйрь Х. Мөҗәйнең лирик герое каты үлем каршында да елмайган килеш тора. Тик ул ялгыз түгел.

Елмаеп үлү — М. Җәлил лирик героеның да сугыштагы изге анты:

Мин түгелме шигырь утым белән
Ант итүче канлы сугышта?
Үлемгә дип, ачы нәфрәт белән
Елмаермын соңгы сулышта.

Тик шагыйрь әсирлеккә төшкәч тә язылган «Авыру сызмалар» шигырендә, кинәт үзгәреп:

Юкка чыкты бик күп теләкләргә,
Күп эшләргә булган өметләр.
Юкка яздым: «Көлеп үләрмен!»— дип,
Юк, үләсе килми, егетләр.

Парадокс кебек. Шагыйрь үлем каршында көләргә җыена, ситуация тугач, көлми. Мимика белән уйнау гына түгелдер бит? Юк, Җәлилнең бөек, чытык йөз белән үләсе килми — эш тик шунда. Көрәш юлына басып, ил каршында антын үтәгәч кенә ул елмаер. Үлемгә каршы елмаер!

М. Җәлилнең «Кыз үлеме» шигыре бу поэтик мимиканың төп асылын ачып сала. Шагыйрь мәңгегә тынып калган көрәшче кызның йөз халәтен дикъкать белән күздән кичерә:

Ярым ачык юка ал ирнендә
Катып калган тыныч елмаю.
Әйтерсең лә, нидер сөйли-сөйли,
Көлемсерәп аңын җуйган ул...

Кыз үлемгә каршы елмаер көч таба ала, чөнки ул, шагыйрь әйткәнчә: «Дошманнарга үлем, ә үзенә мәңге үлмәс яшәү китерде». Көлү — кешедәге шатлык, бәхет билгесе. Көлү — актив, югары әхлак халәте. Димәк, бөек, хак эш өчен көрәшкә өлешеңне салу, өлешеңнең барлыгына ышану көче көрәшчедә көлү-бәхет уята. Безнең сугыш чоры шагыйрьләре шуңа көлгәннәр. Муса Җәлил һәм аның унбер көрәшче иптәшенең башларын гильотинода кистерү шаһиты пастор Юрытконың «Татарлар елмаеп үлделәр» дигән сүзләре билгеле. Нинди рух бөеклеге! Совет поэзиясендә дә, чынбарлыгында да үлем каршында елмаю, бәхет тойгысын саклап калу факты бу!..

Сүз уңаенда әйтергә кирәк, сугыш чоры шагыйрьләре иҗатындагы поэтик рәсем мөмкинлекләрен күзәтү андагы реалистик сәнгать байлыгын тулырак ачарга ярдәм итәчәк.

Эзләнүчән, тынгысыз сугыш чоры татар поэзиясе халыктан, әдәби традицияләрдән килә торган казанышлар белән генә чикләнеп калмады. Үзенекен, яңаны да тапты һәм новаторларча формалаштырды. Эчкерсез, самими реалистик лирика — нәкъ менә шундый мөһим табышларның берсе булды. Яңа сыйфатлы лириканың идея-эстетик нигезен, һичшиксез, коммунистик партиялелек, социалистик гуманизм, патриотизм, интернационализм идеяләре йогынтысында формалашкан чынбарлыкка тыгыз мөнәсәбәт тәшкил итте. Лирика үсешенең хасияте турында фикерләүләр төрлечә булса да, асылда бер нәрсәдә карашлар якынлаша: шагыйрь йөрәгенең чынбарлык күренеше белән тирән дулкынлануы, көчле куңел реакциясе кирәк. Сибгат Хәкимнең бик мәгънәле бер фикере хәтергә килә: «Халыкта еш әйтелә торган сүз бар: Йөрәгеңә бик якын алма... Шагыйрь барысын да йөрәгенә бик якын ала». Барысын да йөрәк белән кичерү, бөтенесен дә йөрәккә якын алу — сугыш чоры әдипләренең характерлы билгесе иде.

Бөек Ватан сугышы чоры лирикасының аерым мәсьәләләре, бигрәк тә герой проблемасы бездә шактый тәфсилле тикшерелгән. Сугыш дәверендәге лирик герой — солдатның олы йөрәкле, чиксез бай тойгылы, хиссиятле булуы билгеләнә. Дошманына карата ул ничаклы үчле һәм нәфрәтле, кырыс һәм тәвәккәл, гайрәтле булса, дусларына, якыннарына карата аңарда мәхәббәт һәм сөю, нечкә хис һәм тойгылану шул кадәр үк көчле. Һәм шунысы да бик мөһим: шул катлаулы күңел дөньясын ул тирән самимилек, эчкерсезлек белән ачып сала:

Иң якын дустың икән ул —
Фронтта булган кешең.
Үз итеп аңа сөйлисең
Хәтта син күргән төшең.
(С. Хәким)

Болар шулай. Әмма тагын бар нәрсәне ныклап күңелгә сеңдерик: реаль гадәти кешегә хас булган табигыйлек ничаклы зур, тирән булмасын, бу әдәби герой гадәти түгел. Ул әдәби иҗаттагы чиксез кыйммәтле, бөек һәм бик оригиналь күренеш. Сугыш чоры поэзиясендәге лирик герой Ил, Ватан, халык язмышын хәл итүгә бәйле катлаулы ситуациядә сурәтләнде. Азатлык, бәйсезлек өчен корбан, гомер бирергә кирәктә ул кешегә хас булган йомшаклыклардан, хис-тойгылардан кинәт арына, югары күтәрелә алды, Ватаны алдында байрак үбеп биргән антына турылыклы булып җиңү китерердәй үлемгә дә ташланды. Бу әдәби геройның тирән патриотик, гуманистик асылы нәкъ менә шунда.

Тагын шунысы бик мөһим: сугыш елларындагы әдәби образ шагыйрь хыялы, фантазиясеннән бигрәк, чынбарлыктан килгән герой иде. Ул дистәләгән татар совет шагыйрьләренең үз язмышларында да реальләште. Әйтергә кирәк, лирик герой һәм шагыйрь берлеге сугыш чоры поэзиясенең гражданлык сыйфатын, тәрбияви әһәмиятен бермә-бер көчәйтә.

* * *

Бөек Ватан сугышы чорының әдәби героенда шул дәвер чынбарлыгының үз халәтен тәшкил иткән рухи күтәренкелек, кайнар ашкыну, патриотизм, мәхәббәт кебек олы хисләр гәүдәләнде, киеренке уйлар чагылыш тапты. Киеренкелек аеруча лирик геройга хас иде. Дәвер лирикасы үз замандашының катлаулы эчке дөньясына сизгер барометр булып кына калмый, ә актив, гуманистик сәнгать буларак, аны идеалга чакыручы сугышчан байрак ролен дә үти. Анда катлаулы идея-эстетик концепцияләр, поэтик фикерләүләрнең тынгысыз хәрәкәте күзәтелә.

Без шуларга игътибарлымы? Без сугыштагыларны тулысынча аңлыйбызмы, алар кичергәннәрне яхшы тоябызмы? Кызганыч, әмма шундыйлар очрый, сугыштагылар, янәсе, үлемгә күнегә, үлем алар өчен ботка ашау кебек көндәлеккә әверелә дип фәлсәфә сата. Хәтта күкрәге белән амбразура каплаган каһарман истәлеген мәсхәрәләүче адәм актыгы да табыла кайчак... Исән калу шансларын барлый, гомерне арзан бирүдә шелтәли. Мондыйлар үлем ярасыннан әрнеп кычкырган солдат тавышына да, әҗәл концлагерьларыннан, төрмәләрдән иңрәп чыккан әсир авазларына да битараф булып кала. Туң йөрәклелек, миһербансызлыкмы бу? Бәлки батырлык турында сөйли-сөйли, аны гадиләштереп, әзер схемага салып аңлатудан, батырлык иясенең үз, йөрәк тавышына тиешенчә колак салмыйча эш итүдән килә торган бер бәладер бу?

Көрәш кырындагыларда яшәү хисе тупасланмый. Юк бит, юк! Бу хис аларда тыныч-тагыга караганда күпкә көчлерәк, тирәндәрәк. Моны сугыш шагыйре йөрәк канына манчып яза. Тик ничек итеп яшәргә соң? Ничек итеп якты Җиңү көненә барып ирешергә? Бу сорауга сугыш шагыйре һич тә ансат җавап бирә алмый...

Сугышта яшәү мәсьәләсен Ф. Кәрим талантлы «Тимер һәм тимерче» балладасында, безнең карашка, фәлсәфи тирәнлек белән куя. Хәер, баллада һәрчак фәлсәфи, символик. Илле яшен тутырган колхоз тимерчесе Саттарга, илен саклап, яу кырына чыгарга туры килә. Күрә Саттар: каршы яктан җир калтыратып, үлем чәчеп, танк үрли. Көчле, бик куркыныч үлем-танк... Киңәш-табыш көтеп окопташына борылса, ул инде шәүлә булып артка йөгерә. Ватан юл бикләргә кушканда, дошманга капка ачучы куркакны Саттар үз кулы белән дөмектерә:

Вөҗдан рөхсәт итә атарга,
Ава җиргә куркак гәүдәсе —
Калмый эзе, калмый шәүләсе,
Һәм кабер дә булмас аңарга.

М. Җәлилнең («Кол»), Ф. Кәримнең («Куркак»), Х. Мөҗәйнең («Качкын») шигырьләрендә һәм башка фронтовик шагыйрьләрнең әсәрләрендә «каһәрләнгән кеше» иң җирәнгеч тойгылар белән тамгалана. Ул үлемнән качса да, халык нәфрәтеннән качып котыла алмый. Аңа бездә яшәү дә, тормыш та юк. Сугыш бетеп, байтак еллар узгач, М. Әмир

шундый качкынны Җәлилләрчә каһәрләп язган повестен «Җан көеге» дип атады. Үзләренең өй базында сугыштан, халык үченнән качып яткан Камәретдин — чын мәгънәсендә җансыз кеше. Аның җаныннан көек кенә калган...

Безнең поэзиядә дошманга карата нәфрәт тәрбияләү тенденциясе ике юнәлештә үсте. Бер яклап, фашистларның тиңсез ерткычлыгын ачкан «Партизан хатыны», «Гөлсем», «Вәхшәт», «Бүреләр» кебек драматик эчтәлекле әсәрләр язылды. Икенче яклап, лирик пландагы геройның уйлануларын ачкан шигырьләр күпләп иҗат ителде. Безнең карашка, бу мөнәсәбәттә аеруча мөһим факт булып Ф. Кәримнең «Мин — гуманист» дигән шигыре тора.

Әсәрнең лирик герое — солдат-шагыйрь. Ул үзен «мин — гуманист» дип атый.

Мин бер шагыйрь — тойгы, хис кешесе.
Яратам мин кошлар сайравын.
Мин гуманист — сөям дөньяны,
Акмасын дип, җирдә кеше каны.
Гуманизм — минем байрагым.

Ләкин шагыйрь-солдат төз аткан пулясы белән агач башыннан фашист снайперын чүкеп төшерә һәм, уйлары белән гамәле каршылыкка кергәндәй, әйтеп куя:

«Мин — гуманист»— дидем, үзем менә
Бу кешенең гомерен бетердем...

Ләкин геройның уйларында каршылык юк икән, чөнки:

...Кеше гомерен бетермәдем.
Сабыйларның канын суыручы,
Бәхет бакчаларын корытучы,
Иң әшәке кортны үтердем,

— ди шагыйрь.

Димәк, фашистларның чын кешелек белән аз гына да уртаклыклары юк. Алар кешелекнең явыз дошманы. Алай гынамы әле?! Фашист матурлык дошманы ул. Юлындагы бар нәрсәне ватып, яндырып көл итеп килүче дошман белән матурлык яраша алмый.

Әнә Әхмәт Исхакның «Чәчәк һәм үч» дигән шигырендә җылы, ямьле җәйге кичтә бер гөл чәчәк атарга җыена. Бу назлы гөлне табигать иркәли, тонык ай үбә...

Узып бара иде шул вакытта
Куаклыктан төнге юлына,
Кеше санлы, ләкин ерткыч бер җан,
Автоматын тотып кулына.
Котмәгәндә гүзәл бу чәчәккә,
Китереп басты аның итеге,
Сытылып калды чәчәк һәм югалды
Ай уйнаган дымның бөртеге...

Фашизм белән гуманизм, матурлык — килешмәс төшенчәләр. Ә. Исхакныкы кебек үк Х. Мөҗәйнең лирик герое да «Җирдә үскән һәрбер гөл өчен үч алырга диеп дошманның», ант итә.

Югарыдагы поэтик фикерне «Бездә яздыр» исемле шигырендә зур гомумиләштерү белән Ф. Кәрим болай дип раслый:

Фашист безгә үлем генә китерә,
Фашизмның таңы, язы юк.
Яшен уты белән күккә язып әйтәм,
Язы юкның яшәү хакы юк.

Менә шул поэтик идея нигезендә татар поэзиясе дошманны аяусыз фаш итә, аның маңгаена үлем мөһере басылганын һәр йөрәккә җиткерергә ашыга һәм яңа бер көч белән үчкә чакыра.

Әмма поэтик тойгы үтә дә сизгер. Шагыйрь инде нәфрәтенең «Нәфис чәчкә булып атканын» (Р. Саттар) ачык тоя. З. Мансурның лирик герое үч накалын төгәл билгеләгән прибор кебек, бу тойгының югары шкаласын да билгели:

Нәфрәт белән тулы бөтен дөнья,
Күзләрендә җирнең йокы юк.

Ә кайбер ярсу шагыйрьләрдә, әйтик, Ф. Кәримнең «Немец җирендә», «Кемне кызганыйм» кебек шигырьләрендә, исемнәреннән үк күренгәнчә, шкала критик дәрәҗәгә үк күтәрелеп килә. Шагыйрь күңелендә тәшвишле уйлар да кузгала. Туктаусыз үчкә, канга чакыру йөрәкләрне тупасландырмасмы, матурлыкны тою, мәхәббәт, сөю хисләрен җуймасмы? Алардан мәхрүм кеше — шулай ук, чын асылын җуйган кеше бит ул. Сугыш вакытлы нәрсә, әле дөнья котәсе бар...

Ш. Мөдәрриснең «Сукыр лампа» шигыре, мөгаен, шундый уйлар чагылышы булып дөньяга килгән. Тонык ут землянкага зәгыйфь яктылык сибеп кенә калмый, сугышта арган-талчыккан солдат күңеленә нур да бөрки, аны ямьли. Шигырьдә лампа алдагы ымсындыргыч киләчәккә ишарә булып ассоциативлаша. Солдатның лампага тартылуы — ямьле киләчәккә ашкынуы, сусавы ул. «Батист яулык», «Гөлбәдәр» шигырьләрендә дә Ш. Мөдәррис солдат һәм шәфкатьле күңел проблемасын нечкә тоеп гәүдәләндерә. «Сугыш күпме газап китермәсен, шул ук калды йөрәк ялкыным» яки «Ялтыр кылыч кебек мәхәббәтем тутыкларга һич тә күмелмәс» кебек юлларда лирик геройның сугыш гарасатында да хис-тойгы байлыгын саклавы күренә.

Ш. Маннурның «Чәчәкләр һәм снарядлар», М. Садриның «Ай хикәяте», Ф. Кәримнең «Бездә яздыр», Гиз-әл Габидның «Дүрт сүз» кебек шигырьләрендә чагылыш тапкан солдат күңеле проблемасына, мәхәббәт, туган җир, киләчәк мәсьәләсенә кагылган әсәрләр килеп өстәлә. Шулай итеп, сугыш чоры поэзиясендә тагын бер зур юнәлеш — мәхәббәт, шәфкатькә чакырган юнәлеш формалаша, үсә башлый. Борын-борыннан үз халкының күңел матурлыгын, мәхәббәт, хезмәт сөенечен, якты омтылышларын җырлап килгән татар поэзиясе туплар, ядрәләр шавы астында, канлы сугышта да үз асылын җуймый. Җуелса, аның бер вәкиле булган М. Җәлилнең ватанчылык һәм олы миһербанлылык белән совет кешеләрен генә түгел, немец халкы вәкилләрен дә тирән тетрәндергән «Алман иләндә» кебек әсәре иҗат ителә алмаган булыр иде.

Ватанчылык һәм миһербанлылык — Бөек Ватан сугышы чоры татар поэзиясенең төп сыйфатлары. Аларны без андагы һәр идея-эстетик концепциядә, поэтик фикердә күрәбез. Әйтик, сагыну тойгысына караш. Сугыштагы бу тойгы зур, сагышлы, читен. Солдатның сагынуы, шагыйрь йөрәге аркылы узып, шигырьгә, җырга күчә. Төш булып, саташу булып, ашмаслык хыял булып күчә. Әмма никадәр генә күзәтмә, аларда элекке җырдагы кебек:

Йөгереп китердәй булам ла
Кайтып җитәрдәй булам,
Күзгә ачы җилләрдә лә
Туган-үскән илләргә,

кебек сабырсыз ялгызлык мотивы ялгыш кына да чагылыш тапмый. Безнең солдат — шагыйрь йөрәге монда да үз эчке януын, сагышын тыя, аларга юнәлеш бирә белә. Адымы ныклы, карары катгый аның:

Кайту да юк, кавышу да,
Әгәр җиңмәсәк.
Җиңеп кайтырбыз, җиңүдә —
Бөтен киләчәк.
(Ф. Кәрим)

Әмма поэзия сагыну тойгысын һич кимсетми. Кайту юлы дошманның үз өне — Берлин аша дип, солдат күңеленә өмет үрләтә. Фрицны ерак куган саен өйгә юл якыная, дип сагынуны басу чарасын да күрсәтә, поход юлына мәгънә дә бирә ул:

Барган юллар ерак киткән саен,
Киткән саен кояш баешына,
Кайтыр юллар якын, алтынкаем,
Синең белән тиздән кавышуга.
(Ш. Маннур)

Сугыш чоры татар поэзиясендә кешенең иң яшерен, интим хисләренә дә игътибарлылык, аның шәхесен зурлау, олылау сыйфатлары анда конкрет, реаль яшәеш тапкан үлемсезлек концепциясендә аеруча ачык күренә. Бу концепция батырлык, геройлык актына нисбәттә шагыйрьләр иҗатында рухландыргыч, оптимистик аһәң булып еш яңгырап торды. Ватан, Яшәү, киләчәк хакына корбан булган көрәшче, каһарман үлми! Ул икенче, рухи гомер юлын башлый. Чәчәкләрдә, каннарда, хыялларда яши башлый. Буыннар белән киләчәккә күчә, һаман яшь, һаман матур булып, идеалга атлый... Әйе, тормышыбыз моңа шәһит, сугыштагыларның үлемсез җаннары тере, хәрәкәттә... Сугыштагылар, яу кырындагылар яшәү, гомер мәгънәсендә, һичшиксез, киңрәк, мәгънәлерәк, төплерәк караштa торганнар. Гомерләрен бик кыйммәткә биргәннәр, чөнки бу турыда рухи бөеклектә торып фикер йөрткәннәр алар. Бөек Ватан сугышы чоры татар поэзиясе — Совет Кешесенең шул рух бөеклегенә гүзәл һәйкәл ул!

**Зәйнәп Хәйруллина**

# ЖЫР ДА ЖИҢҮ ЯУЛАШТЫ

Мәскәүдә милли республикалар әдәбияты һәм сәнгате декадалары, ялгышмасам, 1935 елдан уздырыла башлый. Һәр декада моңарчы күрелмәгән олы бәйрәм, ил бәйрәме булып күңелдә калган. Декадалар барган көннәрдә игътибарны радио үзенә тарта. Кайда гына булмасын, кешеләр кара «түгәрәк тәлинкә» — репродуктор тирәсенә җыелалар. (Ул елларда әле телевидение юк. Әһәмиятле вакыйгалар, сәнгать яңалыклары белән иң элек радио һәм киножурналлар таныштыра иде.) Әнә Украинадан нинди җырчылар чыгыш ясый: П. Паторжинский (бас), М. Литвиненко-Вольгемут (сопрано)!.. Менә илебез беренче тапкыр казах җырчысы К. Байсәитова тавышын ишетә. Октябрь революциясенә кадәр профессиональ сәнгате булмаган казах халкының беренче операсы «Кыз-Жебек» радио буенча бөтен Союзга трансляцияләнә. Шул операда җырланган «Кәккүк» ариясен безнең җырчыларыбыз да опыт өлгергәннәр. Әйе, һәр декада моңарчы киң күләмдә ишетелмәгән гүзәл әсәрләр белән таныштырып, күңелле очрашулар бүләк итә, һәр декада күпмилләтле совет сәнгатенең киләчәктә тагы да зур казанышларга ирешүләренә инандыра, иҗатка рухландыра.

Башкалабызда иҗатыбызны күрсәтергә иде дип үзара хыялланып яшәгәндә безгә дә куанычлы хәбәр килде: Татарстан әдәбияты һәм сәнгате декадасын Мәскәүдә уздыру планлаштырылган! Башкалага бару 1941 елда булачак. Сәнгать бәйрәменә зур хәзерлек башланды.

Барлык иҗат коллективларында җан аямый, ару-талуны белмәстән эшләгәндә, күтәренке күңел белән иҗади хезмәттә янганда, инде Мәскәүгә бару вакыты менә җитә, менә җитә дип канатланганда... Сугыш... Көтелмәгән фаҗига. Явыз фашист гаскәрләре илебезгә һөҗүм башлаган. Барлык эш, бөтен тырышлык фронтка, илне дошман явыннан азат итүгә юнәлдерелде. Республикабызның иҗат оешмалары да үзләренең эшләрен бик тиз арада сугыш таләпләренә яраштырып, үзгәртеп кордылар.

Татарстан Композиторлар союзы, әле яңа гына туган иҗат коллективы (аның беренче гомуми җыелышы, Союзга членнар кабул итү җыелышы 1940 елның 2 февралендә генә уздырыла), үзенең актив эшчәнлеге белән көннән-көн зуррак хөрмәт казана бара һәм музыкаль культура фронтының алдынгы, әйдәүче отрядына әверелде. Иң беренче чиратта композиторлар туган илебезне канэчкеч фашизм яуларыннан азат итү өчен каһарманнарча сугышучы фронтовикларны рухландырырлык әсәрләр булдыруга керештеләр. Композиторларның саны әле дистәгә дә тулмаган чак: Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Мәрьям Рахманкулова, Василий һәм Юрий Виноградовлар, Заһид Хәбибуллин, Нәҗип Җиһанов, Җәүдәт Фәйзи, Фәрит Яруллин (Яруллин 27 июльдә инде армиягә китә)... Аларның күрелмәгән энтузиазм белән эшләүләрен бүген сокланып искә алам. Алар һәр көнне диярлек радиокомитетка яңа патриотик җырлар тәкъдим итәләр. Һәр композитор музыкаль сәхнә әсәре язуны үзенең мәҗбүри изге бурычы итеп саный иде. Әйтик, М. Мозаффаров «Зөлхәбирә» операсын (Әхмәт Фәйзи либреттосы) Октябрь революциясенең 25 еллыгына тәмамлый; С. Сәйдәшев Ленинградтан эвакуацияләнгән консерватория профессоры М. Юдин белән бергә Галиәсгар Камалның «Хафизаләм иркәм» драмасына музыка яза; Н. Җиһановның М. Җәлил белән бергә эшли башлаган «Илдар» операсы тәгәлләнә...

1942 елның беренче марты культурабыз тарихында татар музыкаль комедия жанрының туу көне дип искә алына. Ул көнне Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясе беренче тапкыр тамашачылар игътибарына тәкъдим ителә. Яңа әсәренең зур уңыш казануы белән канатланган композитор икенче музыкаль комедия — Әхмәт Фәйзи либреттосына «Акчарлаклар»ны язуга керешә. Аның премьерасы 1944 елның 26 нчы августында була. Җиңү якынлашканда Татарстанга багышланган кинофильм төшерелә башлый. Бу фильмга музыка язу А. Ключаревка тапшырыла. Композиторлар опера театры, филармония радионы художестволы музыкаль әсәрләр белән баеталар. Алар татар музыкасына яңа жанрлар алып керәләр. Шуны да искә алыйк: бу авыр сынау елларында композиторларыбыз иҗат эшләрен җаваплы дәүләт хезмәте белән бергә бәйләп алып баралар. Н. Җиһанов — опера театрының художество җитәкчесе, Җ. Фәйзи татар дәүләт филармониясенең художество җитәкчесе итеп билгеләнә, шулай ук адвокатлар коллегиясендә дә эшли. М. Мозаффаров — радиокомитетның музыкаль редакторы, А. Ключарев — халык иҗатын җыю һәм өйрәнү кабинеты директоры, С. Сәйдәшев — Татар дәүләт академия театрында музыка эшләре җитәкчесе. Фронттагы хәлләр яхшыга таба үзгәрә барган саен музыкаль тормыш та җанлана. Композиторларның эшчәнлеге киң колач җәя.

1943 елда, сугышчыларга бүләк итеп, «Фронтка концерт» исемле фильм эшләнә. Фильм-концертта мәшһүр гармунчы Фәйзулла Туишев, җырчылардан Гөлсем Сөләйманова, опера солистлары Мәрьям Рахманкулова, Галия Кайбицкая, Усман Әлмиев, һәм шулай ук Җәлал Садриҗиһанов җитәкчелегендәге симфоник оркестр катнаша. Кинотасмага төшерү төнлә, спектакльдән соң театр сәхнәсендә алып барылды. Режиссеры Марк Донской иде. Бу мәшһүр режиссерны татар музыкасы белән таныштыруда һәм оештыру эшләрендә пианистка Е. Домбаева-Верниковскаяның ярдәме зур булды.

Республика күләмендә үзешчән сәнгать көчләренә смотрны (1944) оештыруда, бигрәк тә йомгаклау концертын хәзерләүдә Александр Ключарев, Җәүдәт Фәйзи зур тырышлык куялар. Барлык авыл районнарының йөздән артык җырчы, биюче, гармунчы, нәфис сүз осталары җыела. Араларында өлкәннәр дә, сугыш инвалидлары да, колхозчы яшьләр дә байтак.

...Пәрдә ачыла. Залны кайнар алкышлар күмә. Сәхнәдә бөтен катнашучылар түгәрәк ясап утырганнар. Әйтерсең лә, сабан туена җыелганнар. Башкаручылар төрле милли киемнәрдән. Әнә чуваш кызлары кызыл, сары күлмәк кигәннәр. Уртада Балтач хоры. Аларның төрле төстәге күлмәкләре өстеннән киелгән ак алъяпкычлар ак чәчәкләрне хәтерләтә. Керәшен хатын-кызларының баш киемнәрен бизәгән таңкәләре ялт-йолт итеп балкыйлар. Сугыш елларында оештырылган бу беренче смотр халыкның сәнгатькә чиксез зур мәхәббәтен, рух күтәренкелеген чагылдырды.

Татар дәүләт филармониясенә дә сугышның беренче көненнән катлаулы бурычларны бик оператив хәл итәргә туры килде. Мәскәү, Ленинград, Минск шәһәрләреннән эвакуация белән килүче сәнгать эшлеклеләрен кабул итү, концерт эшчәнлеген дәвам иттерү,Татарстан артистларын фронтка җибәрү...

Җыр һәм бию ансамбле оештырылуның беренче көннәреннән үк солистка булып эшләгән җырчы, Татарстанның атказанган артисткасы Разия Тимерханова бу чорны түбәндәгечә күз алдына китерә:

«23 июньдә билгеләнгән план буенча Галимнәр йортына репетициягә килсәк, бер мизгелгә ишек төбендә аптырап калабыз. Галимнәр йорты бөтенләй үзгәргән: гадәттә, музыкантлар килүгә тезелеп куела торган пультлар да, урындыклар да юк. Аларны коридорга чыгарып, бер почмакка өеп куйганнар. Ул көнне без барлык бүлмәләрдән җиһазларны чыгару белән шөгыльләндек. Бина эвакуация белән килүчеләр өчен хәзерләнде.

Икенче көнне безне Татарстан Халык Комиссарлары Советы каршындагы Сәнгать эшләре идарәсенең приказы белән таныштырдылар. Бик күп ирләрнең армиягә чакырылуы сәбәпле, ансамбль составы нибары егерме кешелек булып, хатын-кызлар җыр һәм бию ансамбленә әверелә. Оркестрлар таратыла. Ансамбль авылларга, гастрольләргә җибәреләчәк, шуңа хәзерлек башлана.

Июльнең беренче көннәрендә без инде авылларда идек. Җитәкчебез — хормейстер И. Грекулов, баянчыбыз — Г. Халитов. Программабызда татар халык көйләре. Кайсы гына авылга барып кермик — йөрәк кысыла, күңел әрни. Урамнарда беркемне очратмыйбыз, йортларга керсәк — күз яше, һыгылыршу. Юлларда сугышка китеп баручы төркем-төркем ирләр, аларны озата баручылар, хатын-кызлар, балалар очрый.

— Ай, кайгы-хәсрәтле көннәрдә кем генә килер икән безнең концертларга? — дибез. Борчылабыз, уңайсызланабыз. Әмма кичләрен халык клубка җыела. Иң элек сәхнәгә колхоз, авыл Советы җитәкчеләре күтәрелә. Алар дулкынланып халыкка мөрәҗәгать итәләр: «Һичбер төрле икеләнүнең булуы мөмкин түгел. Илебез көчле. Ул җиңәчәк. Җиңүне тизләтү өчен тырыш хезмәт, ныклык, сабырлык кирәк. Бертугандай, бөтен көчне туплап бергә эшлик». Концерт башлана. Безнең чыгышларны концерт-митинг дип атыйсым килә. Әнә шундый

өндәү-концертларыбыз сентябрьгә кадәр дәвам итте. Дүрт ел буе без җәен дә, кышын да авылларга гастрольләргә чыктык. Көндезләрен гел эштә булдык. Бәрәңге дә утырттык, аны җыярга да булыштык. Печән җыярга да ярдәм иттек, иген дә җыештык. Ә кышларын авыл яшьләренә репертуарларыбыздагы җырларны өйрәттек. Хорлар оештырдык. Биючеләребез биюләр дә куйдылар.

Ә Казанга кайткан араларда көннәребез госпитальләрдә үтә иде. Кай көнне безне унберәр, уникешәр госпитальгә җибәрәләр, кай көнне бер-ике госпитальдә генә концерт бирсәк тә хәлдән таеп кайтабыз. Каты яраланганнар белән очрашу безне тетрәтә, хәлләребезне ала иде. Һич оныта алмыйм: көннәрнең берендә без Казан авыл хуҗалыгы институтына урнашкан госпитальгә килдек. Беренче булып сәхнәгә мин чыктым. Җырлый башладым. Күзем беренче сафта утыручыларга төште. Башым әйләнеп китте. Күз алларым караңгыланды. Җырлый алмыйча, сәхнәдән елап чыгып китәргә мәҗбүр булдым... Бу — башлары, битләре каты яраланган сугышчыларны туплаган махсус госпиталь булган, күрәсең. Берсенең дә йөзе күренми. Марля белән башлары уралган. Кайсысының борыны беләк тиресенә тоташтырылган. Кул ничектер табигый булмаган хәлдә күтәрелеп тора. Кайсысының борыны колагына ялганган... Бу фаҗигале күренеш минем аңымны алды. Дүрт ел буена госпитальләрдә авыр кичерешләрне, әйтеп бетергесез бәхетсезлекләрне күп күрергә туры килде.

Авыллардан йөреп кайтуга, яңа программа хәзерләдек тә, Калинин фронтына юл тоттык. Салкын кышның бик суык көне. Вокзалга җыелдык. Өс киемнәребез бу күрелмәгән салкынга чыдарлык түгел. Аякларыбызда — резин боталар. Кемнең әмере булгандыр, безгә Кукмара киез итекләрен китерделәр. Вагоныбызга кереп утырдык. Уртада тимер мич. Як-якта ике катлы сәндерәләр. Өстебездәге киемнәрне, киез итекләрне салмыйча йокларга яттык. Салкын. Иртән уянсам, урынымнан кузгала алмыйм. Нәрсә булган? Аркамны стенага терәп ятканмын. Пальто исә тән җылысы белән вагон стенасына ябышып каткан. Иптәшләр мине тарткалый торгач, шатыр-шотыр итеп пальто стенадан куба башлады...

Җиңү көне. Филармония сугыш елларында Куйбышев урамындагы 22 нче йортта, хәзерге Сәүдә работниклары культура сарае бинасында эшләде. 9 май көнне иртән филармониягә җыелдык. Ике грузовик безне көтеп тора. Борт такталары төшерелгән. Барыбыз да грузовикларга урнаштык. Машиналар акрын гына Бауман урамына таба юнәлделәр. Урам уртасында ике машинаны янәшә куеп, концерт бирәбез: җырлыйбыз, биибез. Халык арасыннан, машинага сикереп менеп, безнең биюләргә кушылып биючеләр аз булмады. Ә халык шул кадәр күп. Әгәр машинадан туп-туры адым ясасаң, аягың җиргә тимичә, халык өстеннән баруың бик мөмкин. Кичкә кадәр шулай халык шатлыгы диңгезендә йөздек».

Татар дәүләт опера һәм балет театры сугышның беренче көннәрендә әле үзенең спектакльләрен билгеләнгәнчә алып барды. Тик артистларга яңа эш өстәлде: 23 июньнән башлап һәр солист, һәр музыкант көненә 5 — 6 концертта катнаша. Хәрби частьларда, армиягә озату пунктларында концертлар иртә-кичен оештырылалар. Июль аенда декадага хәзерләнгән ике спектакль тамашачылар хөкеменә тәкъдим ителә. Аларның берсе — Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ы, Музыкасын Җәүдәт Фәйзи язган. Төп рольләрне драма артистлары Хәлил Әбҗәлилов, Гөлсем Болгарская, Хөсәен Уразиков, Мәҗит Илдар уйнады. Ә музыкалы рольләрне опера һәм балет театры солистлары Нияз Даутов, Галия Кайбицкая, Мөнирә Булатова башкарды.

Композитор Нәҗип Җиһановның Муса Җәлил белән бергә иҗат иткән «Алтынчәч» операсы белән казанлылар беренче тапкыр 12 июльдә таныштылар. Әлеге опера дәһшәтле көннәрдә ил кичергән вакыйгаларга бик тә аваздаш иде. «Алтынчәч»тә, билгеле булганча, Ватанны илбасарлардан азат итүчеләргә, халык батырлыгына дан җырлана. Тугзак ана балаларын көрәшкә чакыра:

Ук, җәяңне ал, улым!
Яуга каршы бар, улым!..

«Алтынчәч» спектаклен киң җәмәгатьчелек кайнар алкышлады. Татар совет культурасының күренекле эшлеклеләре аның турында үзләренең беренче фикер-тәэсирләрен дә әйтергә өлгерделәр. Мәсәлән, күренекле язучыбыз Шәриф Камал болай дип язды: «Алтынчәч» операсы миндә гүзәл һәм көчле тәэсир калдырды. Монда халыкның ирек сөючәнлек, батырлык һәм күмәк омтылучанлык кебек матур сыйфатлары тамашачыларга музыка аркылы җанландырылып бирелә... Уңышлы иҗат җимешләре белән композитор Н. Җиһанов һәм либретто авторы М. Җәлил иптәшләр мактау һәм котлауга лаеклылар дип беләм».

Сугыш елларында бер генә спектакль дә буш залда бармады. Моның сәбәбе нәрсәдә? Минем фикеремчә, сәнгать кешеләрне берләштерде, сәнгать кайгыны да, шатлыкны да, авырлыкларны да бергә кичерергә өндәде. Тамашачы сәхнәдә сурәтләнгән вакыйгаларны заман белән, Ватаныбыз кичергән хәлләр белән бәйләп кабул итте. Һич онытырлык түгел.

Кичләрен Казан урамнары дөм караңгылыкка күмелә. Трамвайлар сирәк йөри. Шул караңгы кичләрдә — яңгырмы, буранмы — барыбер халык театрга агыла. Сәхнәдәге тормышны бирелеп карый, күңеле белән шул тормыш эчендә кайный. Геройлар белән бергә яши. Хәтеремә уелып кергән бер спектакльне сөйлисем килә. Сәхнәдә Н. Җиһановның Муса Җәлил белән соңгы тапкыр бергә эшләгән «Илдар» операсы бара. Композиторның әлеге операсы Бөек Ватан сугышы батырлары турында сөйли. Операның икенче өлешендәге вакыйгалар колхоз клубында бара. Авылдашлар фронтка китүчеләрне озаталар. Һәркем үзенең хөрмәтен, яратуын белдереп бүләк китергән. Җылы оекбашлар, перчаткалар. Менә колхоз карты Гыймади (Л. Верниковский уйный) киез итекләр тапшыра. Шушы күренеш барышында сәхнә һәм тамаша залы бергә кушылган төсле тоелды. Әйтерсең лә, сәхнә юк, әйтерсең лә барлык тамашачылар фронтовикларны озатырга, зур залга җыелганнар. Сәхнәдәге һәр хәрәкәткә алар үзләренең мөнәсәбәтләрен сиздерәләр. Спектакль күтәренке бара, һәр солист ихлас күңелдән, зур ышандыру көче белән уйный. Пәрдә төшә. Алкышлар озакка сузыла. Тамашачы әле шактый вакыт үзен колхоз клубына җыелган озатучылар арасында итеп сизә.

Татар дәүләт опера һәм балет театры үзенең милли театр булуын һәм милли спектакльләр тудырырга тиешлеген бер генә сәгатькә дә онытмады. «Сугыш бетәр. Җиңү бәйрәме булыр. Якын дусларыбыз, туганнарыбыз сугыш кырыннан кайтырлар. «Я, без җиңү даулаганда, сез нишләдегез? Безнең кайтуыбызга нәрсә хәзерләдегез?» — дип сорасалар, аларга күңелле, күтәренке рухлы, рәхәтләнеп ләззәтләнеп тыңларлык әсәрләр тәкъдим итә алырлык булсын. Музыкаль комедия жанрында эшләвемнең сере шунда»,— дип еш кабатлый торган иде Җәүдәт Фәйзи. Сүзендә торды. Опера театры 1944 елның җәендә (26 август) Әхмәт Фәйзи либреттосына нигезләнгән «Акчарлаклар» музыкаль комедиясен казанлылар игътибарына тәкъдим итте. Менә инде кырык елдан артык «Акчарлаклар» музыкаль комедиясендәге җырлар, арияләр симфоник оркестр өчен номерлар безнең тормышыбызны бизәп киләләр.

Театрның 5 еллыгын билгеләп үтү бәйрәм төсен алды. Уңышлы узган спектакльләр, юбилей концертлары иҗат коллективын канатландыра. Һәркем тырышып эшли. «Шүрәле» балеты репетицияләре иртә-кич алып барыла. Бөек Җиңү көннәре якынлашканда театр патриотизм рухы белән сугарылган өч яңа спектакль өлгертте. 1945 елның 12 мартында, ниһаять, «Шүрәле» балеты күрсәтелде. Г. Тукай һәм Ф. Яруллин хыялында туган «Шүрәле»не беренче булып балет солисты Романюк гәүдәләндерә, кыю, зирәк авыл егете Былтырны Барый Әхтәмов, әкияттәге аккош һәм гүзәл Сөембикәне Анна Гацулина тудыра. Өчесе дә сокландыргыч гүзәл, тормышчан, милли образлар, онытылмаслык образлар иҗат итәләр.

Дәһшәтле елларда совет халкын патриотик рухта тәрбияләүдә, барлык рухи көчне явыз дошманга каршы көрәшкә туплауда радионың ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуы һәркемгә аңлашыладыр. Республикабызның музыкаль тормышында да Татарстан радиосының әһәмияте зур булды. Композиторларыбызның яңа әсәрләре беренче башлап радиода яңгырады. Радиода танылган җырчылар, музыкантлар, музыка эшлеклеләре концертларда чыгыш ясап кына чикләнмәделәр, бергәләп яңа әсәрләр тудыру, башкару осталыгын үстерү һәм музыка сәнгатенең киләчәгенә бәйле проблемаларны уртага салып хәл итү юнәлешендә игелекле эш башкардылар. Кыскасы, Татарстан радиокомитеты музыкаль үзәккә әверелде.

Сугыш елларында радиода Кави Нәҗми, Мирсәй Әмир, Гомәр Бәширов, Гариф Гобәйләр эшләде. «Концерт программаларын тирәнтен уйлап төзү — иҗади хезмәт»,— ди иде Кави ага. Мин Кави аганың һәр сүзенә колак салам. Буш арада Кави белән Мирсәй агалар эшләгән бүлмәгә, икенче катка менеп төшкәлим. Монда кыска гына, әмма ифрат күңелле һәм эчтәлекле сөйләшүләр булып ала. Ашыйсы килү дә беркадәр онытылып тора. Кави ага өеннән алып килгән бер-ике чи бәрәңгене кабыгы белән юка гына итеп турәкләп кисә дә, бүлмә уртасында торган тимер мич өстенә куеп, тоз сибеп кыздырып ала һәм безне, аның янына кергән кызларны, сыйлый. Кави абый темперамент белән сөйли. Мирсәй абый салмак кына, үзе һич елмаймастан, үткен, көлке репликалар әйтеп куя. Без шаркылдап көләбез. Күңел күтәрелеп китә.

9 май. Кояшлы иртә. Радиодан Юрий Левитан Җиңү хәбәрен әйтүгә, тиз генә киенеп, радиокомитетка йөгерәм. Урам тулы халык. Күзләрдә шатлык яше. Кешеләр бер-берсен кочаклыйлар. Академия театры алдында — Фуат Халитов, Хәким Сәлимҗанов, Салих Сәйдәшев һәм тагын кемнәрдер. Җиңү белән котлап, мине радиога кадәр озаталар. Гөлсем Сөләйманова, Гайшә Камаева, Мөхәммәт Сафин, Рокыя Ибраһимова инде килеп тә җиткәннәр. Репетиция ясыйлар. Җиңү көненә концерт программасы алдан хәзерләнгән иде. Менә диктор К. Саттарова Җиңү турында татар телендә хәбәр итә. Аннан С. Сәйдәшевнең К. Нәҗми сүзләренә язылган «Җиңү җыры» белән концерт башлана.

Концерт барышын эш булмамда тыңлап утырганда, Мөхәммәт Сафинның матур, көчле тенор тавышы ничектер тоныкь, төссез ишетелә төсле тоелды. Йөгереп мендем икенче катка. Студиядән тапшыру барган вакытта кереп-чыгып йөрергә катгый тыелса да, Мөхәммәт абый студиядән чыкты да минем җилкәгә башын куеп: «Йөрәгем, йөрәгем, үләм...» — дип бер-ике сүз әйтә алды... Ул арада кабинетыннан Гариф Гобәй атылып чыкты. Мөхәммәт Сафинны Гариф абый кабинетына алып кереп яткырдык... Байтак кына ятканнан соң, «Хәлем яхшырды», дип, Мөхәммәт абый өенә юл тотты. Сәгать 4 тә госпитальгә концертка барырга вәгъдәләшеп өйләребезгә таралдык.

Менә сәгать 4 тә радиога җыелдык. Телефон шалтырый: «Мөхәммәт Сафинны концертка көтмәгез, моннан бер сәгать элек ул үлде...»

...Сугыш кырыннан җиңүчеләр кайта башлады. Радиода язучы Әмирхан Еники, Гамир Насрый эшкә керештe. Әле шинельләрен дә салырга өлгермәгән шагыйрьләр Сибгат Хәким, Мостафа Ногман бик тиз арада композиторларыбыз, җырчыларыбыз белән дуслашып өлгерәләр. Яңа җырлар, яңа зур күләмле музыкаль әсәрләр туа. Татар совет музыкасы үз тарихында яңа сәхифәне ача башлый.

*Укучыбыз яза*

## БАТЫРЛАР ОНЫТЫЛМАСЫН

Хөрмәтле редакция! «Казан утлары» журналының 1982 елгы 12 санында Нигъмәт Иксановның «Сөрген батыры» исемле очеркы дөнья күргән иде. Анда Октябрь революциясенә кадәр патша хөкүмәте Якутиягә сөргән татарлар һәм аларның Гражданнар сугышы елларында партизан отрядлары төзеп Совет властен урнаштыру өчен көрәшләрдә актив катнашулары хакында сөйләнә.

Безнең гаилә озак еллар буе Якутиядә яшәде һәм очеркта тасвирланган кешеләр безгә яхшы таныш. Шуңа күрә әлеге очеркны Якутскида яшәүче кардәшләребез дә бик кызыксынып укыганнар.

Безнең гаиләдә сигез партизан бергә төшкән тарихи фоторәсем саклана. Алар арасында үзенең ике бертуганы белән минем этием — Хаҗи Фәтхуллов та бар. Ә «Сөрген батыры» исемле очерк белән бергә басылган фоторәсемдә сурәтләнгән обелискта Фәтхулловлар фамилиясе дүрт юл алып тора. Фәтхулловлар биш бертуган булганнар, аларның бишенчесе — Нургали Гыйззәтулла улы Фәтхуллов СССР Верховный Советы депутаты һәм Якутия АССРның Халык Комиссарлары Советы Председателе булып эшләде. Ул 1925 елда партия сафларына керә. Революция һәм Гражданнар сугышы елларында рус-татар интернациональ партизан отрядын оештыра һәм, бертуганнары белән бергәләп, Колчакка каршы сугышларда, Якутск шәһәрен акгвардиячеләрдән саклауда катнаша. Гражданнар сугышыннан соң бик күп җаваплы постларда эшләде.

Халкыбызның революцион үткәненә кагылышлы материалларга зур урын бирелү — «Казан утлары»ның матур традициясе. Әйе, якты көнебез өчен фидакарь көрәшчеләрнең берсе дә онытылмаска тиеш! Партиянең тугрылыклы солдаты, кайнар йөрәкле большевик Нургали Фәтхуллов турында да илебезнең барлык почмакларында көтеп алына торган «Казан утлары» журналы битләрендә тулырак язма күрәсе килә.

Рәисә **ФӘТХУЛЛОВА**,
Татарстан, Саба районы, Байлар Сабасы авылы.

**Редакциядән: Халкыбызның революцион тарихын, Совет властен урнаштыруда актив катнашкан якташларыбыз язмышын яктырткан язмаларны киләчәктә дә бирep бару күздә тотыла.**

**Әбрар Кәримуллин,**
филология фәннәре докторы

# ТАТАР КИТАПЛАРЫ КАЙДА САКЛАНА?

*Халык кулындагы китап — аның рухи һәм мәтди азатлыгы өчен көрәштә иң көчле корал.*

Ромен Роллан.

Язу, китап уйлап табу — кешелек тәҗрибәсен киләчәк буыннарга югалтмыйча саклап калу һәм тапшыру өчен гаять камил форма. Алар уйлап табылгач тарих тәгәрмәче тизрәк әйләнә башлаган.

Китапны юкка гына кешелекнең, халыкларның хәтере димиләр. Ул халыкның хәтере дә, аның тарихының елъязмасы да. Шул ук вакытта китап халыкларның үзара танышу, аралашу чарасы да. Ерак гасырлар белән хәзергене бәйләүче, тоташтыручы, заманнар, дәверләр, гасырлар һәм язмышлар чылбыры да ул. Китап шул ук вакытта мәңгелекнең юлдашы да.

Китап — халык хәтерен саклауның иң камил формасы. Ә халыкның хәтере, рухи мирасы гаять зур байлык. Шуңа күрә һәр цивилизацияле халык үзенең рухи мирасын, аны теркәгән язма, басма сүзне кадерләп саклый, җыя, өйрәнә, пропагандалый. Замандашыбыз, академик С. Р. Микулинский халыкның рухи мирасы аның бетмәс-төкәнмәс байлыгы, без аны җыярга, сакларга өйрәнергә тиешбез, үткәнен оныта башлаган халыкның киләчәге юк. Халыкның мәдәни дәрәҗәсе үзенең рухи мирасына карашы белән билгеләнә, ди галим.[1] Вакытында А. С. Пушкин да үткән мираска игътибарсызлыкны кыргыйлыкка кире кайту дип бәяләгән.

Һәр мәдәни халык үзенең мирасын барларга, җыярга, сакларга, өйрәнергә күп көч сарыф итә. Менә шуңа күрә дә язу, китап барлыкка килү белән шул мирасны туплау, саклау өчен китапханәләр килеп чыккан. Аларның төп функциясе — китапларны барлау, җыю, аларда тупланган байлык белән яңа буыннарны таныштыру. Китап барлыкка килү белән, китап сөючеләр дә килеп чыккан. Дәүләт тарафыннан оештырыла торган китапханәләр белән бай, гаять уникаль шәхси китап фондлары да барлыкка килгән. Аларның тырышлыгы нәтиҗәсендә борынгы заманнардан шактый бай кульязма һәм басма китаплар сакланып калган. Кызганычка каршы, бик күпләре югалган, тузган, янган, яндырылган, һәм алар белән кешелек тарихы тудырган күп кенә рухи байлык та, ачышлар да юкка чыккан.

Язу уйлап табудан алып шрифтлар-литерлар кулланып, китап басуны уйлап чыгарганчы, 40 мең елдан артык вакыт узган. Шушы дәверләрдә кулдан язылган китаплар гына булган. Теге яки бу әсәр нигездә бер генә данәдә язылган. Еш кулланудан ул бик тиз тузган, юкка чыккан. (Борынгы кульязма китапларның аз саклануының башка сәбәпләре дә җитәрлек, бу турыда биредә махсус тукталуның кирәге юк.)

Заманнар узу, кешелекнең алга китә баруы белән кешеләрдә белемгә дә мохтаҗлык үсә барган, бу инде укый-яза белүнең үсүенә дә сәбәп булган. Шулай итеп, китапка булган ихтыяҗ да үскән. Менә шушы шартлар нигезендә кешеләр китапны күбәйтүдә җиңелрәк ысул, күчмә хәрефләрдән сүзләр җыеп китап басу юлын уйлап тапканнар.

Бу ачыштан соң инде бер әсәрне күп данә басарга мөмкин була, ә бу үз чиратында, ул әсәрнең озак саклануы өчен дә мөмкинлекләр ача. Китап басу барлыкка килгәч, китапханәләр саны бик тиз арта, аларның китап фондлары тиз үсә башлый. Дәүләт китапханәләрендә илдә басылган барлык китапларны җыю һәм саклау эшенә дә зур әһәмият бирелә. Илдә басыла торган һәр китапны җыю, туплау, саклау йөзеннән «обяза-

тельный экземпляр» кертелә. Мондый «мәҗбүри данә» — положениесе буенча илдә чыгарыла торган һәр басма әсәрнең бер данәсе мәңгегә саклау өчен махсус яки бер дәүләт китапханәсенә мәҗбүри рәвештә җибәрелергә тиеш була. Китапханәгә алынган бу «мәҗбүри данә» анда архив берәмлеге, документ буларак теркәлә. Шушы «мәҗбүри данә» положениесе буенча килә торган басмалар нигезендә илдә басылган китапларның саны, тиражы исәпкә алына.

Басылган һәр китапның бер данәсен мәҗбүри рәвештә аерым китапханәдә туплау беренче мәртәбә Франциядә 1537 елда кертелә. Сыйнфый җәмгыятьләрдә мәҗбүри данә кертү цензура максатларыннан чыгып та эшләнгән, әлбәттә. Ләкин, ничек кенә булмасын, мәҗбүри данә системасын оештыруның прогрессив ягын да танырга кирәк. Мәҗбүри данә кертү илдә басыла торган барлык матбугат әсәрләрен тулысынча туплауга мөмкинлек ачу белән бергә, аның статистикасын тудыруга, шул ук вакытта дәүләт регистрацион библиографиясен алып барырга да мөмкинлек ачкан.

Россиядә мәҗбүри данә 1783 елда кертелә. Шушы елдан башлап һәр басмаханә үзендә басылган китапның бер данәсен бушлай, мәҗбүри рәвештә Петербург фәннәр академиясенә җибәреп тора башлый. 1810 елның азагыннан башлап мәҗбүри данә положениесе белән Петербург публичный китапханәсе дә (хәзерге көндә М. Е. Салтыков-Щедрин исемендәге Ленинградтагы публичный китапханә) Россиянең һәр басмаханәсендә чыккан китапның бер данәсен бушлай ала башлый. 1862 елдан мәҗбүри данә Румянцев музее китапханәсенә җибәрелә (хәзер В. И. Ленин исемендәге СССР дәүләт китапханәсе, Мәскәүдә). Шушы положение буенча мәҗбүри данә алучылар арасында без Гельсингфорс университеты китапханәсен дә күрәбез.

Менә шушылардан чыгып, революциягә кадәр татар телендә чыккан китапларның кайда тупланууын күзалларга мөмкин. Ләкин моңа тулырак, төгәлрәк җавап бирү өчен кайсы китапханәгә мәҗбүри данәнең кайсы еллардан башлап килеп торуын гына түгел, мәҗбүри данә буенча төрле китапларның җибәрелү тәртибен, аларның китапханә фондларына ни дәрәҗәдә алынуын, саклануын да белергә кирәк.

Инде әйтеп үткәнчә, бездә мәҗбүри данәне Петербург фәннәр академиясе (ул Россия фәннәр академиясе дип тә йөртелгән) китапханәсе беренче буларак ала башлаган. Хәзер СССР фәннәр академиясенең Ленинградтагы фәнни китапханәсен тәшкил иткән бу учреждение революциягә хәтле иң бай китапханәгә әверелгән. Анда китаплар белән бергә әттән кульязма китаплар, шул исәптән шәрык телләрендәге язма һәм басма китаплар туплау буенча даими эшләп килгәннәр. Бу китапханәгә мәҗбүри данә буларак татар телендә чыккан китаплар һәм илдә гарәп, фарсы, төрек, башка телләрдә басылган китаплар да килеп торган. Соңыннан бу китаплар Академиянең Азиат музее китапханәсенә күчерелә. Шушы музейның директоры, академик Б. А. Дорн тарафыннан 1866 елда чыгарылган библиографиядә 1801—1866 елларда Казанда басылган барлык китаплар диярлек теркәлгән, шуның өстенә Мәскәү, Петербург, Әстерхан типографияләрендә басылган татар китаплары да искә алынган. Бу китапханә Октябрьдан соң да СССРда басылган һәр телдәге китапларның мәҗбүри данәсен алып килә.

Соңыннан Фәннәр академиясенең шәрык, шулай ук татар китаплары һәм кульязмалары СССР фәннәр академиясенең Көнчыгыш институтының Ленинград бүлегенә күчә. Бу институт китапханәсендәге татар китапларыннан башкала университеты галимнәре, студентлары шактый киң файдаланган, аларның каталогы да төзелгән була. Бу китапханә татар телендә басылган китапларны чагыштырмача тулы туплаган иң бай китапханә булды, анда татар телендә чыккан беренче китаплар да тупланган иде. 50 елларның ахырында бу китапханәдә саклана торган татар, шулай ук кайбер башка шәрык телләрендәге басма китапларны тарату башланды. Бу китапханәдән СССР фәннәр академиясе Казан филиалы китапханәсенә дә өлеш чыкты: аңа ун меңгә якын татар телендәге китаплар җибәрелде. Бу басмаларның күпчелеге революциядән соң басылган китаплар булып чыкты, араларында революциягә хәтле чыккан басмалар да барын бар, ләкин андый китаплар аз иде. Соңыннан беленде: революциягә хәтле чыккан татар китапларының күп өлешен Казахстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Әзербайҗан фәннәр академиясе һәм СССР фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы алдан сайлап алган булып чыкты.

Казан филиалы китапханәсенә алынган басмаларның бер-ике меңе фондка кертелә, бер өлеше Татарстан дәүләт китап палатасына тапшырыла, бер өлеше (6 мең чамасы) служебный фонд сыман аерым саклана. Соңгылары ачык каталогларда чагылмаган. Татар китапларының бер өлеше Ленинградта, академиянең Көнчыгышны өйрәнү институты китапханәсендә дә калган, кайбер басмаларны Институт чит илләр белән китап алышу өчен алмашу фондына күчергән. Нәтиҗәдә татар китапларының иң бай тупланган хәзинәсе шулай таркала.

Татар китапларының хәзер иң тулы сакланган урыны — Ленинградтагы М. Е. Салты-

ков-Щедрин исемендәге фәнни китапханә. Бу китапханәгә татар басмалары 1811 елдан башлап хәзерге көнгә кадәр мәҗбүри данә буларак килеп торалар. Татар китаплары мәҗбүри данә буларак 1862 елдан бирле В. И. Ленин исемендәге СССР дәүләт китапханәсенә дә алынып тора.

Мәҗбүри данә системасының нәрсә икәнен белгәч, бу система нигезендә татар китаплары кайсы еллардан кайсы китапханәләрдә туплануын ачыклагач, аларда татар китаплары, газета-журналларының никадәр тулы җыелуын да күзаллап үтик. Башта ук шуны әйтик: мәҗбүри данә килгән бу китапханәләрдә татар басмалары бөтен тулылыгы белән тупланмаган. Эшнең сере шунда — цензура законы буенча һәр басмаханә үзендә чыккан китапның берничә данәсен цензурага җибәрергә тиеш булган. Китапны дөньяга чыгарырга рөхсәт биргән очракта, цензура басмаханәләрдән килгән китапның аерым данәләрен мәҗбүри данә алучы китапханәләргә тараткан. XIX йөзнең 70 еллар уртасына хәтле татар китабы цензурасы Казанда була. Бу цензура Казанда чыккан татар китапларын даими рәвештә мәҗбүри данә алучы китапханәләргә җибәреп тора. Шуңа күрә булса кирәк, бу елларга хәтле чыккан татар китаплары ул китапханәләрдә баерак тупланган. 1874 елдан башлап татар китабы цензурасы Санкт-Петербург цензура комитетына күчерелә. Бу татар китабы цензурасын тагын да көчәйтү йөзеннән эшләнә. Татар китабы цензурасы бирегә күчерелгәч, аның мәҗбүри данәсен китапханәләргә җибәрүдә дә аерым үзгәрешләр килеп чыга. Татар китабы цензорының сүзләренә караганда, ул дөньяга чыгарырга рөхсәт биргән китапның цензурага килгән данәләрен ике айдан алып ярты елга хәтле тиешле китапханәләргә җибәрми торган була. Әгәр шушы вакыт эчендә ул рөхсәт иткән китап өстеннән шикаятьләр килмәсә, аларны мәҗбүри данә буенча китапханәләргә җибәрә башлаганнар. Бу очракта да дөньяга чыгарга рөхсәт ителгән һәр татар китабы мәҗбүри данә буларак китапханәләргә җибәрелмәгән. Цензор В. Смирнов үзе басарга рөхсәт иткән, инде дөньяга чыккан татар китапларының кайберләрен «рус китапханәләрендә саклау»ның кирәге юк дип, мәҗбүри данә өчен җибәрелгән данәләрне юкка чыгарып барган. Менә шуңа күрә татар китапларының барысы да мәҗбүри данә буларак күрсәтелгән китапханәләргә барып җитмәгән.

Мәҗбүри данә рәвешендә китапханәләргә барып җиткән һәр татар китабы да китапханәдә сакланмаган, аның төп фондларына кертелмәгән, каталогларында чагылмаган. Мәҗбүри данә алучы китапханәләрнең ишекләре татарлар өчен ябык булган. Ул китапханәләрдә татар һәм көнчыгыш телләрен белүче китапханәчеләр, библиографлар да булмаган. (Петербург фәннәр академиясендә андый белгечләр булган, шуңа күрә андагы татар китаплары фондка да алынган, аларга каталоглар да төзелгән.) Дөрес, XIX йөзнең ахырларында Петербургтагы Публичный китапханәгә мәҗбүри данә буенча алынган татар һәм башка шәрык телләрендәге китапларны эшкәртүгә керешү билгеле. Бу эшкә атаклы Кавказ Шамиленең улы Заһид Шамил тотынган. Ләкин революциягә хәтле шушы һәм Румянцев музеена килгән татар басмаларының күпчелеге эшкәртелмичә, каталогларга кертелмичә әрдәнә кебек өемнәрдә ята биргән. Бу китапларны Ленинградтагы Публичный китапханәдә һәм Мәскәүдәге хәзерге В. И. Ленин исемендәге Дәүләт китапханәсендә революциядән соң гына эшкәрттеләр, каталогларда чагылдырдылар һәм Совет власте чорында гына алар укучыларга барып җиттеләр.

Революциягә хәтле Хельсинки университетына мәҗбүри данә рәвешендә килгән татар китаплары, газета һәм журналлары да эшкәртелмичә ята килгәннәр. Бу университетның профессоры Гомәр әфәнде Таһир соңгы тапкыр Казанга килгән вакытында, биредәге татар китапларын соңгы елларда каталоглаштыруга керештеләр дип сөйләгән иде. Анда күпме татар матбугаты әсәрләре тупланган, аларның сакланышы ничек икәнлеген без ачык белмибез.

Революциягә хәтле чыккан татар басма сүзенең мәҗбүри данә тәртибендә китапханәләргә керүе һәм аларның сакланышы менә шулай тора.

Октябрь революциясеннән соң халыкның рухи байлыгы булган китапны саклауга зур әһәмият бирелә. Совет властеның беренче көннәрендә үк матбугат турында В. И. Ленин кул куйган декрет кабул ителү әнә шул турыда сөйли. Китап байлыгын социалистик төзелештә киң файдалану, басма сүз әсәрләрен туплау, саклау, исәпкә алу өлкәсендә Октябрь революциясеннән соң яңа этап башланды. Матбугат, китап эше тулысынча дәүләт эшенә әйләнде.

Бу өлкәдә иң әһәмиятле булган дәүләт документларының берсе 1920 елның 20 июнендә кабул ителә. В. И. Ленин кул куйган «РСФСРда Библиография эшен Дәүләт нәшриятына тапшыру турында Халык Комиссарлары Советы Декреты» ул. Шушы Декрет нигезендә 1917 елның 10 мартында оештырылган «Россия китап палатасы» РСФСР Наркомпросы карамагына күчә. (Бу палата төрле елларда Үзәк китап палатасы, РСФСРның Үзәк китап палатасы исеме белән дә билгеле.) 1936 елны ул «Бөтенсоюз китап палатасы» итеп үзгәртеп корыла.

Шушы декреттан соң Советлар Россиясендә яңа шартларда мәҗбүри данә системасы торгызыла. Мәҗбүри данә белән илдәге 20 дән артык китапханә тәэмин ителә башлый. СССРдагы һәр басмаханәдә чыккан китапның 25 данәсе Үзәк китап палатасына җибәрелә. Шушы вакыттан башлап китап палатасы илдә чыккан һәр басманы архив берәмлеге итеп мәңгегә саклау өчен үзендә туплый, мәҗбүри данә нигезендә илдә басылган һәр басманың хисабын, матбагачылык статистикасын алып бара башлый. Шул ук вакытта аңа ил күләмендә дәүләт регистрацион библиографиясен төзү бурычы да йөкләнә. Ил матбугатын исәпкә алучы бу библиография «Китап елъязмасы» һәм башка төрле елъязмаларда даими басылып килә. Үзәк китап палатасы аерым китапханәне мәҗбүри данә белән тәэмин итүче үзәккә дә әйләнә.

1922 елны мәҗбүри данә белән китапханәләрне тәэмин итү мәсьәләсе яңадан карала, аның географиясе дә шактый киңәя. Шушы елдан башлап Казан университеты китапханәсенә дә РСФСРда чыккан һәр басма мәҗбүри килә башлый. СССР ЦИК һәм СНКның 1928 ел 26 май карары нигезендә бу китапханәгә РСФСР күләмендә чыккан барлык басмалар, ә 1933 елның 13 сентябрь карары нигезендә СССР күләмендә чыккан барлык басмалар мәҗбүри данә тәртибендә килеп тора.

Менә шушыннан чыгып, Казан университетының Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә 1922 елдан башлап татар телендә чыккан басмаларның нигездә тулысынча тупланауын әйтә алабыз.

Гарәп, латин графикасында басылган китапларның каталогын рус графикасы нигезендә рекаталогизацияләгәндә мин университет китапханәсендә XX йөз башында, хәтта XIX йөзнең төрле елларында басылып чыккан һәр татар китабы белән танышып чыктым. Инде белүебез буенча, бу китапханә революциягә хәтле татар китабын мәҗбүри данә буенча алмаган. Университет татар китапларын үзенең китапханәсенә туплау буенча да эшләмәгән. 1855 елны университетның шәрык разряды Петербургка күчеп киткәндә, университетның китапханәсендә туплана башлаган татар кульъязма китаплары да башкалага күчкән. Бу разряд күчкәч, университетта шәрыкны өйрәнү бик озакка туктап кала. Менә шуңа булса кирәк, университет китапханәсенә революциягә хәтле чыккан бер китап та сатып алынмаган. Бу патша самодержавиесенең татарларга карата тоткан изү, чукындыру политикасы белән дә бик нык бәйләнгән. Билгеле булганча, XIX йөзгә хәтле Казанда татар китапларын басу белән иң күп шөгыльләнгән басмаханә — университет типографиясе. Татар китабының цензоры булып Казанда университет профессорлары эшләгән. Менә шундый шартларда да аның китапханәсенә университет типографиясендә басыла торган бер генә китапның да алынмавы — гаҗәеп күренеш.

1894 елны Н. Ф. Катанов Казан университетына килгәч факультатив рәвештә төркитатар теле, әдәбияты, тарихы буенча лекцияләр укый башлый. Университетның китапханәсендә татар китаплары булмау аркасында, үзенең фәнни һәм педагогик эшчәнлеге өчен кирәк булган татар басмаларын кешеләрдән эзли, җыя, сатып ала башлый. 1907 елда Н. Ф. Катанов Казанда яңадан ачылган цензура комитетына татар китабы цензоры булып урнаша, һәм шул елдан башлап цензор буларак һәр татар китабын бушлай алып бара башлый, шул исәптән басарга килгән күп кенә татар әдипләренең кульъязмалары да аның кулында калгалый. Татарстан дәүләт архивында сакланган документлардан күренгәнчә, Н. Ф. Катанов 1801 елдан алып XX йөз башына хәтле Казанда чыккан китапларның исемлеген төзегән. Анда бу чорда чыккан басмаларның күпчелеге чагылган. Димәк, аларны Н. Ф. Катанов тапкан, үз китапханәсенә җыйган. Миссионерлар, шовинистлар һөҗүме аркасында рухы сүнә башлаган Н. Ф. Катанов гаять бай шәхси китапханәсен сатарга була. Аны ул киләчәктә шәрыкны өйрәнүгә юл тотар дип уйлаган Иркутск институтына тәкъдим итә, аннан Ташкент университетына мөрәҗәгать итеп карый. Ләкин патша хөкүмәте бу китапханәне алырга бер тиен дә акча бирми. Аннан Н. Ф. Катанов китапларын Лейпциг университетына тәкъдим итә. Лейпцигтан бу китапханәне сатып алабыз дигән хәбәр дә килә. Бу вакытта Төркиянең премьер-министры сәяхәт белән Казанга килеп чыга һәм шушы китапханә турында ишетә. Н. Ф. Катанов китапханәсенең нигездә шәрык телендәге китаплардан торган кыйммәтле җыелма икәнен аңлаган Гыльми паша аны шунда ук сатып ала да Төркиягә озата. Шулай итеп Н. Ф. Катановның бай шәрык китапханәсе Истамбул университеты китапханәсенә барып керә. Соңыннан бу китапханәне Төркиягә барып чыккан татар язучысы М. Акъегет эшкәртеп чыга, каталогын төзи. Бу китапханәнең хәзерге көндәге язмышы безгә билгеле түгел.

Революциягә хәтле Казан университеты үзенең китапханәсе өчен бер генә татар китабы да сатып алмаган, аны туплау буенча да берни дә эшләмәгән. Шулай булса да революциягә хәтле университет китапханәсенә составында татар китаплары да булган бер шәхси китапханә килеп кергән. Ул Казан университетының шәрык разрядында про-

фессор булып эшләгән И. Ф. Готвальд (1813—1897) китапханәсе. Үзе исән вакытта, XIX йөзнең 90 еллары башында ук университетка бүләк итеп тапшырылган бу китапханә ун елга якын эшкәртелмичә ята биргән. Бу китапханәне Н. Ф. Катанов һичбер түләүсез, эштән соң, ике ел дәвамында эшкәртеп чыга, аның каталогларын төзи һәм үз хисабына 1900 елда аерым китап итеп бастырып та чыгара. Готвальдның университетка бүләк иткән китапханәсендә рус, европа һәм шәрык халыклары телләрендә 4000 ләп китап һәм 300 чамасы татар кулъязмалары була. Бу китапларны һәм кулъязмаларны Готвальд Казанга килеп төшү белән җыя башлаган. Аның китапханәсендә XIX йөзнең икенче яртысында чыккан татар китаплары гаять бай, тулы тупланган дияргә була. Моның сәбәбе дә аңлашыла. Шәрык разряды Петербургка күчкәндә, шул разряд профессоры булган Готвальд Казанны ташлап китми. Университетта гарәп теле, гомумән шәрыкны өйрәнү тукталгач, И. Ф. Готвальд университет типографиясе начальнигы, тиздән шул эш белән бергә татар китабы цензоры булып та эшли. Дистәләрчә еллар шушы урыннарда эшләве аңа татар китапларын җыярга киң мөмкинлекләр биргән, шул исәптән ул басарга дип цензурага килгән кулъязмаларны соңыннан Петербург цензурасы тарафыннан тыелган китапларны да җыю белән шөгыльләнгән. Бу китапханә аркылы университет фондына бердәнбер данәдә сакланган татар китаплары, уникаль кулъязмалар килеп кергән. Готвальд китапханәсе аркылы кергән китапларга 50 еллар азагында рекаталогизация үткәрелде. Алар хәзер университет китапханәсенең генераль каталогында, шулай ук татар китаплары каталогында китерелгәннәр. Бу фондка кергән китап карточкалары индексы алдында «Готв» дигән билге куелган.

Университет китапханәсенә революциягә хәтле чыккан татар китаплары шулай итеп, беренче мәртәбә И. Ф. Готвальдның шәхси китапханәсе аркылы килеп кергән. Университет китапханәсенә революциягә хәтле чыккан китапларның калган өлеше инде 1917 елдан соң алынган. Аның кыскача тарихы түбәндәгечә. Революциядән соң патша заманындагы учреждениеләр, байларның китапханәләрен конфисковать итү, национализация башлана. Бу китапханәләрнең бер өлеше төрле совет оешмалары каршында оештырылган китапханәләргә бирелә, эшчеләр, солдатлар, крестьяннар өчен оештырылган уку йортларына тапшырыла. Күптән китап басу һәм, гомумән, фән, культура үзәге булган Казанда китаплар күп була. Национализацияләнгән китаплардан Казанда Китап Сарае оештыру турында да уйлыйлар. Бу эшкә шулкадәр рухланып тотыналар, аның өчен хәтта университет китапханәсеннән олау-олау китаплар ташый башлыйлар. Реаль чынбарлык белән аз бәйләнгән бу эш проект булудан ары үтә алмый. Бу планның реаль булмавын аңлагач, Татарстанның директив органнары 1931 елда Татарстанда бердәм үзәк фәнни китапханә төзү турында карар кабул итәләр. Бу карар нигезендә Казан университеты китапханәсенә «Татарстан республика фәнни китапханәсе»н кушу күздә тотыла. Бу «фәнни китапханә» әнә шул Китап сарае оештыруга дип национализацияләнгән китапханәләрдән торган китаплар җыелмасы була. Бу «Республика фәнни китапханәсе» дип атала башлаган китапханә составында Татар мәдәнияты йорты китап фонды, Үзәк шәрык китапханәсе, Татарстан китап палатасы, археология, тарих һәм этнография һәм башка җәмгыятьләрнең китап фондлары, Татарстан экономик гыйльми тикшерену институты, Казан уку округы һәм губернадагы урта уку йортлары һәм башка оешмаларның китап фондлары кергән була. Аерым шәхесләрнең конфискацияләнгән фондлары да шулар арасында булган. Казан университеты китапханәсенә кушылыр алдыннан «Республика фәнни китапханәсе» дип аталган бу фондта «миллионнан артык китап тупланган булса да, алар нигездә бернинди тәртипсез өелгән китап чүмәләләре, асылда китап складын гына хәтерләткән»[1]. Шушы «ике» китапханәне кушу нәтиҗәсендә «Казан университеты каршында Татреспублика фәнни китапханәсе» оештырыла. 1934 елдан башлап аңа фәнни тикшерену институты статусы бирелә һәм ул РСФСР Мәгариф Халык Комиссариатының китапханәләр баш идарәсе карамагына күчерелә, махсус балансы булган учреждениегә әверелә.

Менә шул вакыттан башлап Казан университеты китапханәсе «Татреспублика фәнни китапханәсе» исеме астында университет студентлары һәм галимнәре белән бергә стахановчыларга һәм инженер-техник персоналга, укытучылар һәм врачларга, барлык югары уку йортларына, совет һәм профсоюз хезмәткәрләренә хезмәт күрсәтергә тиеш була.

Ашыгып, реаль мөмкинлекләрне искә алмыйча оештырылган «Казан университеты янындагы Татреспублика фәнни китапханәсе» үзенә йөкләтелгән зур бурычларны үти алмады.

---

[1] Романов Я. С. Краткий очерк истории научной библиотеки Татреспублики при Казанском государственном университете: 1804—1939. Казань, 1940, 25 б.

«Татарстан фәнни китапханәсе»н университет китапханәсенә кушудан ике миллионга якын эшкәртелмәгән китап фонды университет китапханәсе исеменә күчерелә. Бу фондны Гостиный дворның Бауман урамына караган ярымподвал цоколь этажына китереп өяләр. Татарстан дәүләт китап палатасы һәм Үзәк мөселман китапханәсенең татар һәм шәрык китаплары фонды 30 елларда ук эшкәртелә башлаган.

Калган фондлар бары 60 еллар уртасында гына тәртипкә салынды, каталогларга алынды. Шуннан соң бу фонд китапханәнең төп фонды белән тикшерелде, төп фондта булмаган китаплар сайлап алынып, Университет китапханәсенең гамәлдәге фондына кертелде. Калган китаплардан ике миллионга якын китапны «обменно-дублетный» фонд барлыкка килде. Бу фондтагы китапларны 60 еллардан башлап ярдәм итү йөзеннән яки китап алмашу тәртибендә илебездә ачылган яңа уку йортларына, фәнни учреждениеләргә тарату башланды. Шулай итеп аның китап фонды бары тик өлешчә генә Казан университеты фондына алынды.

Университет китапханәсе ике хуҗаның хезмәтчесе булып озак яши алмады. Аның төп хуҗасы булып Казан университеты калды һәм бюджеты да Казан университеты ихтыяҗларына карап билгеләнде. Китапханәне «Татреспублика фәнни китапханәсе» дип үзгәртү аның штатын, бюджетын арттыруда да чагылыш тапмаган. Кыскасы, Казан университеты китапханәсе бик тиз арада үзенең иске статусына кайткан — университет галимнәренә һәм студентларына хезмәт күрсәтүче китапханә булып калган. Дөрес, бу китапханә уку залларында буш урын булганда төрле вуз укытучылары, завод-фабрика, фәнни-тикшеренү институтлары хезмәткәрләренә үзенең ишекләрен һәрвакыт ачарга тырышты. Хәзер, китапханә өчен яңа бина төзелгәч, биредә вузлар аша ярдәмләшү нигезендә Казан галимнәренә хезмәт күрсәтү үсә төште. Китапханә абонементы аркылы Казанның гына түгел, илебезнең йөзләгән китапханәләре файдаланып киләләр.

1931 елгы берләштерү вакытында Казан университеты китапханәсенә кушылган фондлар арасында революциягә хәтле чыккан китаплар да шактый күп булган. Менә шул китаплар хисабына биредә революциягә хәтле чыккан татар китапларының шактый бай фонды барлыкка килгән. Ләкин бу фондта революциягә хәтле чыккан татар китаплары тулы түгел, укучылар моны исләрендә тотарга тиеш.

1959 елның октябреннан Казан университеты китапханәсе мәҗбүри данә китап алудан туктады. Хәзер университет китапханәсенә татар телендә чыккан китаплар бары аның татар теле һәм әдәбияты кафедраларының укыту планы профиленнән чыгып кына комплектлаштырыла. Димәк, бу китапханәдә татар телендә чыккан китаплар 1922—1958 еллар өчен генә тулы китерелгән. Монда тагын шуны искә алырга кирәк: 1930 елларга хәтле мәҗбүри данә тәртибендә килеп торган татар китаплары бары 1934 елдан соң гына каталоглаштырыла башлаган. Моңа хәтле аларның бер өлеше юкка да чыккан. Университет китапханәсендә татар китаплары фондының ни хәтле тулы китерелүен һәм ничек тупланууын белгән хәлдә, анда нәрсә табарга мөмкинлеген күзаллау җиңелрәк. Ул — Татарстанда татар китаплары тупланган иң бай китапханә. Аннан кала Татарстанда татар китаплары бай тупланган урын — Татарстан дәүләт китап палатасы.

Партия һәм совет хөкүмәтенең милли культуралар турында кайгыртуы нәтиҗәсендә Октябрьдан соң китап палаталары милли районнарда да оештырыла башлады. Аларны ачудан төп максат — республикада басылган матбугатны җыю, документлаштыру, саклау, хисапка алу, милли телдә башка урыннарда чыккан китапларны барлау һәм аларның библиографик регистрациясен, статистикасын алып бару. Икенче төрле әйткәндә, Үзәк китап палатасы Союз күләмендә алып бара торган эшләрне җирле китап палатасы милли район һәм милли китап нигезендә алып барырга тиеш була. Татарстан китап палатасын оештыру милли районнарда беренче булып башлана. Бу өлкәдә беренче адымнар 1921 ел башында ук ясала. Шушы вакытта РСФСР дәүләт нәшриятының Татарстан бүлеге — Татгосиздат янында «Китап палатасы һәм библиография бүлеге» ачыла[1]. Бу китап палатасын Казан университеты шәкерте булган, соңыннан РСФСР Үзәк китап палатасында озак еллар эшләп килгән, «Китап елъязмасы»ның баш редакторы, совет китап беләме һәм библиографиясе өлкәсендә атаклы галим Е. Шамурин оештыра. Аның истәлекләреннән күренгәнчә, ул оештырган китап палатасының бурычы «Татарстан республикасында чыгучы барлык, бөтен Россиядә басыла торган татар телендәге басмаларны барлау, җыю, тасвирлау, аларның «Китап елъязмасын» төзү, матбугат статистикасын оештыру», китап пропагандалау өлкәсендә төрле эшләр алып бару була[2].

---

[1] Шамурин Е. Организация библиографического дела в РСФСР: (1917—1927 гг.)— В кн.: Библиография в СССР и книжные палаты. Харьков, 1928, 26 б.

[2] Шамурин Е. Күрсәтелгән хезмәт, 27 б.

Бу китап палатасы 1917 елдан Казанда һәм губернада чыккан барлык китапларны туплау, аларның библиографиясен төзү эшенә керешә. Ул вакытларда республиканың материаль хәле авыр булганлыктан китап палатасына ярдәм булмый һәм ул эшләүдән туктап кала.

Соңыннан Татарстанда чыккан барлык басмаларны, республикадан тыш басылган татар китапларын туплау һәм тасвирлау белән Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк тә шөгыльләнеп карый. 1923 елда «Татарны өйрәнү гыйльми җәмгыяте» оештырылгач, бу җәмгыять тә татар басмаларын барлау, аның библиографиясен төзү эшенә керешә. 1928 елны «Татарстанны өйрәнү җәмгыяте» оештырыла, аның каршында «Библиография бюросы» төзелә. Аңа «Татарны өйрәнү гыйльми җәмгыяте» эшли башлаган татар китапларының библиографиясен төзү бурычы да йөкләнә. Ләкин әлеге ике фәнни җәмгыять тә бу өлкәдә даими эш алып бармыйлар. Ирекле фәнни җәмгыять булган бу оешмаларның материаль мөмкинлекләре дә гаять авыр булган.

РСФСР Үзәк китап палатасы һәм Казан университеты фәнни китапханәсе мәҗбүри данә буенча татар телендә чыккан китапларны алып барсалар да, аларда бу басмаларны исәпкә алу, фондка беркетү, «Китап елъязмасы»нда чагылдыру оештырылмаган була. РСФСР Үзәк китап палатасына килгән СССР халыклары телләрендәге китаплар, беренче чиратта гарәп графикасында басылганнары эшкәртелмичә, исәпкә алынмыйча ята биргәннәр[1]. Үзәк китап палатасында татар китаплары бары 1928 елдан башлап кына исәпкә алына, фондка кертелә, «Китап елъязмасы»нда чагыла башлый. Илдә китап продукциясен күрсәткән, РСФСР Үзәк китап палатасы чыгарган статистик материалларда 1928 елга хәтле чыккан татар басмалары чагылыш тапмаган.

Менә шушы шартларда Казанда республика китап палатасын торгызу буенча эш башлана. Ниһаять, 1926 елның 21 декабрендә Татарстан Халык Комиссарлары Советы «Татарстан китап палатасы турында положение»не раслый. Шушы положение нигезендә «Татарстан АССР дәүләт китап палатасы» оештырыла. Татарстанда барлык телләрдә һәм татар телендә илдә чыга торган барлык басмаларны туплап бару, аларның регистрацион библиографиясен төзү, китап статистикасын оештыру белән бергәттән, китап палатасына революциягә хәтле басылган барлык китапларны җыю, туплау, аларның җыелма библиографиясен чыгару бурычы да йөкләтелә. Шулар белән бергәттән Татарстан турында башка телләрдә, чит илләрдә чыккан материалларны барлау, «Татарико» библиографиясен алып бару бурычы да өстәлә. 1929 елдан «Татарстан үзәк китап палатасы» исеме алган бу палатаның башлангыч китап фондын «Үзәк мөселман китапханәсе» фонды тәшкил итә. Бу китапханә Казан шәһәр китапханәсенең «Мөселман бүлеге» нигезендә барлыкка килә. «Мөселман бүлеге» дигән китапханә 1905 елгы революция нәтиҗәсендә казна хисабына Казан шәһәр китапханәсе каршында ачыла. Революциягә хәтле татар китапханәләре турында сүз алып барганда җирле тарихны өйрәнүчеләр татарларда Октябрьга хәтле бер генә китапханә булган дип әнә шул китапханә турында сүз алып баралар. Чыннан да, казна хисабына Казанда шушы бер генә татар китапханәсе булган. Ләкин бу әле революциягә хәтле татарларда бер генә китапханә булган дигән нәтиҗә ясарга нигез була алмый. Хөкүмәтнең тиешле органнары тарафыннан танылган, аерым оешмалар исеменнән эшләргә рөхсәт ителгән татар китапханәләренең саны революциягә хәтле йөзгә якынлаша. Боларга мәдрәсәләрдә оештырылган китапханәләр керми.

Революциядән соң Казан шәһәр китапханәсе янындагы «Мөселман бүлеге»н аерып алып аннан «Мулланур Вахитов исемендәге шәрык китапханәсе» ясыйлар, аннан ул «Үзәк мөселман китапханәсенә» әйләнә, соңыннан Татар мәдәнияты йорты ачылгач, аны «Татарстан фәнни китапханәсе» дип тә йөртә башлыйлар. Китап палатасына тапшырылган вакытта бу «Үзәк мөселман китапханәсе» фондында 20 меңнән артык татар китабы тупланган була. Аларның абсолют күпчелеге революциягә хәтле чыккан басмалар. Фондта бераз рус телендә шәрыкны, татарларны өйрәнүгә караган басмалар да булган. Революциягә хәтле бу китапханәдә тупланган китапларның исемлеге дә басылып чыккан[2].

Революциядән соң барлыкка килгән төрле ирекле фәнни оешмаларны, фәнни һәм культура учреждениеләрен, шулай ук вузларның, фәнни-тикшеренү институтларының эшчәнлеген берләштерү йөзеннән ТАССР Халык Комиссарлары Советының 1927 ел 11 январь карары нигезендә Татар мәдәнияты йорты төзү турында карар кабул ителә. Аның составына «Татарстанны өйрәнү җәмгыяте», «Татарны өйрәнү гыйльми җәмгыяте», «Яңалиф җәмгыяте», Татарстан экономик гыйльми тикшеренү институты, Татарстан

---

[1] Кара: Фуад. Учет национальной литературы.— Книгоноша, 1924; № 43, 12 б.

[2] Биккулов Г. Әсами кәтеп. Казан шәһәр китапханәсенең мөселманнар өчен ачылган шөгъбәсендәге китаплар фиһресте. Казан, «Өмед», 1913, 80 б.

китап палатасы, Алласызлар җәмгыяте, Татарстан Үзәк музее, «Татар академия китапханәсе» (бу Үзәк мөселман китапханәсенең яңа исеме), вузлар каршындагы фәнни түгәрәкләр, Татарстан пролетариат язучылары ассоциациясе, яшь язучылар җәмгыяте һәм башка оешмалар кертелә. Киләчәктә «Татар фәннәр академиясе» булачак, дип күз алдына китерелгән бу Татар мәдәнияты йорты бик тиз таркала, дәресрәге ул оешып җитә дә алмый. Татар мәдәнияты йорты янында мөстәкыйль яшәгән Татарстан китап палатасы 1929 елда татар басма китабын регистрацияләү буенча беренче хезмәтен дә бастырып чыгара. С. Таһирова төзегән, Татарстан китап палатасының беренче директоры Г. Ашмасов кереш сүзе белән чыккан бу «Гыйльми библиография»дә 1925 елда бөтен ил күләмендә татар телендә чыккан 414 китап һәм 36 исемдәге газета һәм журнал исәпкә алынган. 1930 һәм 1931 елларда ул «Матбугат елъязмасы» исеме астында өч кисәктән торган яңа регистрацион библиография чыгарып өлгерә. Анда 1930 елның беренче өч кварталында чыккан татар китаплары исемлеге теркәлгән була.

Төрле ведомстволарга буйсынган китапханә һәм библиографик учреждениеләрне берләштерү процессы башлану сәбәпле, китап палатасы мөстәкыйльлеген югалта, ул башта Академүзәк каршында төзелгән Татарстан фәнни китапханәсе составына керә, соңыннан Казан университеты китапханәсе бүлегенә әверелә. Шуннан соң татар басмаларын, җирле матбугатны барлау, теркәү, статистикасын алып бару туктап кала. Бу хәл 1938 елга хәтле дәвам итә. Җәмәгатьчелекнең соравы буенча Татарстан хөкүмәте 1938 елның 22 февралендә яңадан китап палатасын торгызу турында карар кабул итә[2].

Татарстан китап палатасының Казан университетында эшләгән ике кешесе яңа оештырылган китап палатасына кире кайтарыла. Университет китапханәсенә күчкән Татарстан китап палатасы китаплары да, аңа бирелгән Үзәк мөселман (Татар академия китапханәсе) китапханәсе дә университет китапханәсе фондында калалар. Бу китап палатасында 1926 елдан башлап эшләп килгән, аның белән университет китапханәсенә күчкән, аннан кире, 1938 елда китап палатасына кайткан күренекле библиограф Мәсхүдә ханым Бурнашева университет китапханәсеннән татар китапларының беразын китап палатасына бүлеп бирүләрен әйтә торган иде. Ләкин бу фондның күләме һәм нинди китаплардан торуы билгеле түгел. Документларда бу турыда бер сүз дә юк. Безнеңчә, бу Казан университетына шәхси татар китапханәләреннән алынган, әле 1938 елга каталоглаштырылмаган фонд булырга тиеш.

Китап палатасы мәҗбүри данәне Татарстан хөкүмәтенең 1927 ел 20 сентябрь карары нигезендә, 1928 елдан даими ала башлый. Бу җирле мәҗбүри данә Китап палатасы Казан университетына күчсәләр дә аңа килеп торган. Шулай итеп Казан университеты китапханәсе 1931—1938 елларда Татарстанда чыккан басмаларны икешәр данәдә алып килгән. 1938 елны Китап палатасы яңадан торгызылгач җирле мәҗбүри данә Казан китап палатасына күчә, университет китапханәсе РСФСРда чыга торган мәҗбүри данәне алып тора. Бу мәҗбүри данә юлы белән университет китапханәсенә Татарстанда гына түгел РСФСРның башка шәһәрләрендә чыккан татар телендәге басмалар да килеп тора. Ә Татарстан китап палатасына мәҗбүри данә белән Татарстаннан тыш чыккан китаплар җибәрелми, ул андый басмаларны үзе эзләп, сатып яки китап алмашу тәртибендә тупларга тиеш була. Икенче төрле әйткәндә, бу елларда Казан университеты китапханәсенә татар телендәге басмалар тулырак килә.

Татарстан китап палатасында 1938 елдан башлап Татарстанда чыккан барлык басмалар тулы тупланган булырга тиеш. Шул ук вакытта китап палатасы элек басылган китапларны эзләү, туплау буенча да эшли башлый. Татарстан турында төрле телләрдә чыккан китапларны да җыярга тырыша. Хәзер Татарстан дәүләт китап палатасында 930 мең данә тирәсе саклау берәмлеге бар. Алар арасында XX йөзнең башында, өлешчә XIX йөздә чыккан татар китаплары да очрый. 1979 елда Татарстан китап палатасы 1917—1929 елларда чыккан татар китапларының библиографиясен әзерләп чыгарды. Анда 4 меңнән артык татар китабы регистрацияләнгән. Шуларның яртысыннан артыгы китап палатасында тупланмаган. Димәк, татар китабының хәтта 1917—1938 елларда чыкканнарының да китап палатасында нибары яртысы гына диярлек тупланган. Ә аңа хәтле чыкканнары тагын да аз җыелган. Татарстан китап палатасы иске татар китапларын җыю буенча эшләп килә, үзләренең шәхси китапханәсендә 1938 елга хәтле чыккан китаплары булган иптәшләр палатага аларны бүләк итеп, татар китабының тулы фондын булдыруда ярдәм итә алырлар иде.

Республикада татар китаплары Фәннәр академиясенең Казан филиалы китапханәсендә

---

[1] Кара: Мухсинов З. Дом татарской культуры.— В кн.: Труды Дома татарской культуры. Т. 1. Казан, 1930, 8 б.

[2] Кара: Сорок лет советской государственной библиографии: (1920—1960). М.-Л., 1960, 255 б.

дә тупланган. Китапханәнең татар китаплары фонды барлыкка килү 1939 елда Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты каршында (кайбер иптәшләр аны Татарстан Халык Комиссарлары Советы янында оештырылган дип ялгыш күрсәтәләр) ачылган Татарстан Тел, әдәбият һәм тарих институтына бәйләнгән. Бу — латин шрифтыннан рус графикасына күчкән еллар. Китапханәләрне латин шрифтында басылган китаплардан чистарту еллары. Яңа ачылган Институт үзенең татар теле, әдәбияты һәм тарихын өйрәнү юлында әнә шул китапларга мохтаҗ. Менә шуңа күрә Институт андый китапларны эзләргә мәҗбүр була. Институт китапханәсе өчен атаклы галим, күренекле җәмәгать эшлеклесе Мөхетдин Корбангалиевнең, нигездә гарәп шрифтында басылган китаплардан торган бай китапханәсе сатып алына. Аннан күренекле фольклорист, тел белгече Җамал Вәлиди китапханәсе Институтка бүләк тәртибендә килеп керә. Тел белгече, атаклы фонетист Галимҗан Шәрәф тә үзенең бай китапханәсен бүләк итә. Институт җитәкчеләре әле списать итеп өлгерелмәгән гарәп шрифтындагы татар китапларын да табалар. Әнә шундыйлар арасында Алабугадагы бер техникум китапханәсенең татар китаплары фонды да булган. Менә шулардан хәзерге Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты китапханәсенең татар фонды барлыкка килә. Сугыштан соң бу китапханә иске шрифтлар белән басылган, институт профиленә караган китапларны халык арасыннан җыю буенча да эшләп килде. Институтның тематикасына караган яңа китапларны да бирәдә даими алып баралар. Югарыда искә алынганча, 1969 елны бу китапханәгә СССР Фәннәр академиясе Көнчыгыш институтының Ленинград бүлегеннән 10 меңгә якын татар китабы килеп төште.

Шулай итеп бирәдә шактый гына бай татар китаплары, газета һәм журналлар фонды хасил булды. Алар арасында уникаль, Казандагы башка китапханәләрдә сакланмаган басмалар да очрый. Ләкин ни хәтле генә китап җыелмасын, бу китапханәдә аерым еллар, чорлар буенча татар китаплары тулы тупланмаган.

Үзенең статусы буенча республикабызның үзәк китапханәсе булган — В. И. Ленин исемендәге ТАССР республика фәнни китапханәсе турында да әйтми үтү ярамас. Исеменнән күренгәнчә, ул Татарстанның төп үзәк фәнни китапханәсе. Ул югарыда искә алынган Казан шәһәр китапханәсенең дәвамы. Үзенең положениесе буенча күрше республика фәнни китапханәләре кебек үк крайда чыккан барлык китапларны тулысынча туплап, җыеп баручы китапханә булырга тиеш. Шул ук вакытта Татарстаннан тыш басылган татар китапларын җыю, барлау да бу китапханәнең бурычына керә. Башкортстан, Удмуртия, Чувашия һәм башка барлык автономияле республикаларның фәнни китапханәләре нәкъ менә шул планда эшлиләр. Бу уңайдан шуны искә алып үтәргә кирәк: Н. К. Крупская исемендәге Башкортстан республика фәнни китапханәсе башкорт телендә чыккан барлык китаплар белән беррәттән, революциягә хәтле чыккан татар китапларын үзенә туплау өстендә дә даими эшләп килә. Бирәдә гаять бай иске татар китаплары фонды тупланган, һәм аны тулыландыру өстендә әле дә өзлексез эш алып барыла.

Әйтеп үтелгәнчә, революциядән соң Казан шәһәр китапханәсенең «мөселман бүлеге» аннан аерып алынды. Казан шәһәр китапханәсе фонды нигезендә барлыкка килгән Татарстан республика китапханәсе шулай итеп татар китапларыннан мәхрүм булды. Татарстан китап палатасы белән беррәттән тагын икенче китапханәләрнең университет китапханәсенә кушылуы, аның «Казан университеты янындагы Татреспублика фәнни китапханәсе» исеме алуы да күрсәтелгән китапханәдә татар китапларын туплау, җыюга ярдәм итмәгән. Чөнки аның функцияләре университет китапханәсенә тапшырылган булып чыга.

1934 елда В. И. Ленин исемендәге Үзәк китапханәгә — ул бу елларны шулай исемләнгән — Татарстанның гыйльми библиографиясен төзү буенча оештырылган Библиографик бюро кушыла. «Татарны өйрәнү гыйльми җәмгыяте» каршында 1923 елда оештырылган бу бюро Татарстан турында басылган хезмәтләрне исәпкә алу, аларның библиографиясен төзү буенча үзенә күрә шактый гына хезмәт башкара. Аның В. И. Ленин исемендәге Татарстан үзәк китапханәсенә күчерелүе — киләчәктә Татарстан турында басылган һәм басыла торган материалларны исәпкә алу, аларның күрсәткечләрен чыгарып бару эшен шушы Үзәк китапханәгә тапшыру йөзеннән эшләнә. Димәк, бу бюро белән Үзәк китапханәгә татар китаплары да килеп кергән [1].

1929 елдан башлап В. И. Ленин исемендәге бу китапханәгә мәҗбүри данә рәвешендә Татарстанда чыккан барлык басмалар, шул исәптән татар телендә чыккан китап, журнал, газеталар да килә башлый. (1948—1958 елларда җирле мәҗбүри данә бу китапханәгә

---

[1] Бу бюро Үзәк китапханәгә кушылганчы 1917—1927 елларда Татарстанда чыккан һәм Татарстан турындагы басмаларны эченә алган рус һәм татар китаплары нигезендә инде библиографик күрсәткечләр дә төзегән була. Кара: Тагиров Р. Ш. Библиография Татарстана.— Казань, 1930, 1 б.

килмәгән дип әйттеләр. Моның ни дәрәҗәдә дөреслеккә туры килүен әлегә ачыклый алмадык)

Хәзерге көндә В. И. Ленин исемендәге Татарстан АССР республика фәнни китапханәсендә нибары мең ярым — ике мең гарәп һәм латин шрифтлары белән басылган татар китаплары бар. Алар да эшкәртелмәгән көе, бер почмакка өеп куелганнар. Күпчелеге 1920—1940 елларда чыккан басмалардан торган бу фонд татар китаплары каталогында да чагылмаган. Алар арасында В. И. Ленинның үзе исән вакытта татар телендә чыккан беренче басмалары, партия съездларының стенограммалары, Г. Тукай, М. Гафури, К. Нәҗми, Г. Камал, һ. Такташ һәм башка татар язучылары, рус әдипләренең татар телендә чыккан китаплары һәм бүтән басмалар бар.

Бу китаплар арасында революциягә хәтле чыккан татар китаплары да очрый. Шулай ук «Аң», «Шура», «Ак юл» кебек революциягә хәтле чыккан журналларның аерым саннары бар. Бу фактлар китапханәгә революциядән соң да татар китаплары алынуы турында сөйли. Татарстан Үзәк китапханәсе иseme астында эшләп килгән елларда бу китапханәгә җирле мәҗбүри данә юлы белән дә, шулай ук башка юллар белән дә гарәп, латин графикасында чыккан китаплар алынган. Ләкин алар соңыннан юкка чыкканнар.

Татарстанда китапханәләр берләштерү буенча үткәрелгән төрле мавыгулар белән танышкач, ни өчен В. И. Ленин исемендәге Татарстан үзәк китапханәсенең республика күләмендә татар басма китабының бай үзәгенә әверелми калуын аңлавы кыен түгел.

Хәзер, Казан университеты китапханәсе бары вуз китапханәсе генә булып, 1959 елдан башлап, аның фондына мәҗбүри данә буенча татар басмалары килми башлагач, татар китапларын туплау эше тулысынча В. И. Ленин исемендәге ТАССР республика фәнни китапханәсе өстендә калды. Татарстан китап палатасы белән бу китапханә республикабызда татар китабының үзәге булырга тиеш. Аларның статусы шундый. Бу өлкәдә Татарстан дәүләт китап палатасы тырышып эшләп килә, ә В. И. Ленин исемендәге ТАССР республика фәнни китапханәсе исә бу эштән читтә кала бирә.

Татар китапларының кайда, ни күләмдә туплануы, саклануы турында менә шуны әйтә алабыз. Дөрес, революциядән соң мәҗбүри данә алучы китапханәләр дистәләп санала. Алар арасында һәр союздаш һәм күп кенә автономияле республикалар, илебезнең зур китапханәләре бар. Күпчелеге СССР халыклары телләрендәге китапларны, шул исәптән татар телендәге китапларны да алып торганнар. Без мәҗбүри данә алып торган Казахстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан публичный китапханәләренең фондлары белән таныштык. Ләкин аларның каталогларында мәҗбүри данә буенча кергән татар китапларын очратмадык. Мәҗбүри данә алган бу китапханәләрнең эшкәртелмәгән фондлары арасында шул елларны басылган татар китаплары әле дә сакланып ятуы мөмкин.

библиография

# ТАТАР ФОЛЬКЛОРИСТИКАСЫНЫҢ ЯҢА КАЗАНЫШЫ

Һәрьим бер фәннең үз объекты булган кебек, аның үсү, камилләшү законнары, шул законнарның үз юнәлеше дә була. Икенчерәк итеп әйткәндә, теге яки бу фән үзе өйрәнә торган объект фактларын барлау, аларның санын ишәйтүдән тыш, үзенең методикасын — тикшерү, өйрәнү алымнарын эзлекле ревизияләргә, шулай үз-үзен анализлау нәтиҗәсеннән чыгып төзәтенә, хаҗәте булса, үзгәрә барырга тиеш дигән сүз. Шуннан башка аның дөрес һәм нәтиҗәле үсүе мөмкин түгел.

Бер карaганда, мондый максаттан чыгып язылган махсус хезмәтләр билгеле фәннең үз эчендә генә, хәтта «арткы чоланында» казынуы кебегрәк тоелыр. Теоретик әзерлексез укучыларда (кайбер очракларда консерватив фикер йөртүче яисә күнегелгән традиция кысаларыннан чыкмыйча гына гамәл кылырга өйрәнгән белгечләрдә дә!) андый тикшеренүләр хакында: «Моның ише укучылар даирәсе тар хезмәтләрнең кемгә кирәге бар?» — дигән шикелле сорауларның тууы ихтимал. Бу мәсьәләне, нигезсезлеге хәзер ап-ачык күренеп тора торган «иске» бәхәсне кабат хәтерләп тору очраклы түгел. Чөнки бездә кайчандыр «кибернетика ул буржуаз мода», яисә фәндә «структураль, формаль ысуллар белән шөгыльләнү ул идеалистик сазлыкка бату» ише «күсәкле хөкемнәр» аз яңгырамады. Нәтиҗәдә гуманитар фәннәребезнең кайбер махсус тармаклары гадәти фактлар туплау, яисә җыелган фактларны тасвирый рәвештә җиңелчә анализлау, чын теоретик анализны исә ашык-пошык кына оештырылган социологик схематизм белән алмаштыруга кайтып кала язды. Чын сәнгать әсәрләрен читтә калдырып, урта кул декларатив әсәрләрне күккә чөеп мактаулар менә шушы тенденциянең бер гәүдәләнеше иде. Фольклористикабызда да бу күренеш үзен сиздереп килде. Мондый хәлнең бер тискәре нәтиҗәсе итеп, халык авыз иҗаты әсәрләрен классификацияләүдә яшәп килгән буталчыклыкларны, мәсәлән, язма әдәбият әсәрләрен халык иҗатыннан аера алмау, бер төркемгә караган текстларны бөтенләй башка жанр кысаларына кертүләрне, ниһаять алдан әзерләп куелган хөкемнәргә җайлы мисаллар гына чүпләү белән чикләнүне күрсәтергә мөмкин. Бу очракта классификация мәсьәләсендәге кимчелекләрне мисал итеп алу һич тә очраклы түгел: фольклористикадагы классификация ул, кайберәүләр уйлаганча, формаль мәсьәләләр белән булашу түгел, бәлки теге яки бу текстның фольклор истәлекләре системасындагы һәм тарихи-иҗтимагый, һәм жанр-типологик урынын дөрес билгеләү, шуннан чыгып, һәр текстның сәнгатьчә, димәк, тормышча кыйммәтен гадел ачыклау дигән сүз.

Әмма, бәхеткә каршы, мондый берьяклылыкларга вакытында чик куелды. Бигрәк тә соңгы унбиш-егерме ел эчендә гомум совет филологиясендә, җөмләдән татар әдәбияты белеме һәм фольклористикасында да, халык авыз иҗаты әсәрләрен әтрафлап өйрәнү, фактларны эзлекле рәвештә туплау, текстларның күләмен ишәйтү, аларның социаль-иҗтимагый кыйммәтләрен төрле яклап ачу, чын сәнгать әсәрләрен пропагандалау белән бергә әлеге истәлекләрнең кайбер төрләрен структураль, типологик хәлдә һәм, өйрәнелә торган материалларның барысын бергә җыеп дигәндәй, система рәвешендә тикшерү тернәкләнеп, җанланып, хәтта гөрләп үсеп китте. Консерватив фикер йөртүчеләрнең «бу мода гына» дип сукрануларына, «тиздән бетәчәк ул!» — дип юрап килүләренә карамастан, әлеге тенденция көчәйгәннән көчәя, нәтиҗәләре дә ишәя, саллылана барды. Тора-бара ул тенденция үзәктән перифериягә дә күчте. Безнең конкрет чынбарлыкта исә бу күренеш Казан университетының филология факультеты каршында СССР Фәннәр академиясе тарафыннан әдәбият белеменең кайбер фәнни алымнарын тәртипкә салу, җөмләдән әдәбият белеме өлкәсендә системалы тикшеренүләр башкару буенча махсус төркем оештырылуда чагылды (аның җитәкчесе профессор Йолдыз Нигъмәтуллина). Соңгы елларда бу төркемгә кергән галимнәрнең кайбер тикшеренүләре дә күренә башлады. Шундый хезмәтләрнең берсе сый-

фатында филология фәннәре кандидаты Альберт Яхинның «Татар фольклорының системасы» исемле күләмле монографиясен күрсәтергә мөмкин[1].

Совет фольклористикасының бай традициясенә таянып язылган бу хезмәттә автор үз алдына төп бурыч итеп, фольклорыбыз истәлекләрен өйрәнүдә яңа тикшерену алымнарын эзләүне, шуларны конкрет тәҗрибәдә сынап карау, шул тәҗрибә нигезендә татар халык авыз иҗаты әсәрләренең төп төрләрен билгеләүне, аларның барлыкка килү һәм үсү үзенчәлекләрен, үзара мөнәсәбәтләрен ачыклауны куя. Һәм, әйтергә кирәк, автор үзалдына куелган катлаулы, җаваплы бурычларга тулысынча диярлек ирешә ала.

Авторның абстракт фикерләү алымына һәвәслеге, җитмәсә төрле фәлсәфи, гносеологик категорияләргә, кайбер төгәл фәннәргә генә хас төшенчәләргә, атамаларга еш мөрәҗәгать итүе уку процессын чыннан да катлауландыра төшә. Китапны башка ачмаска дип ябып куярга җыенучылар, хәтта шулай ябып үк куючылар да булгандыр, ихтимал. Әмма сабыр туплап, әсәрнең эченә, «тукымасына» керә башлагач, әлеге «ят» сүзләрнең, «коры» төшенчәләрнең «җанлана» төшеп, мәгънәләре ачыла, автор теләгенең дә калкурак гәүдәләнә баруы күренә. Тагын бераз узгач, безнең алда әллә нинди ят, аңлаешсыз проблемалар түгел, бәлки халык авыз иҗатының үзе шикелле үк һәм гадәти, һәм катлаулы, шунысы белән үзенә һәрвакыт тартып тора торган, ләкин барыбер ахыргача тәмам ачылып бетмәгән (ихтимал, бетмәячәк...) күптәнге таныш мәсьәләләр икәнлеген беләсең.

Хезмәтнең урта һәм ахыр өлешләрендә исә аннан аерыла алмау, авторның үз дәрәҗәсенә күтәрелеп аның белән актив килешә бару, яисә кайбер мәсьәләләрдә бәхәсләшә башлау хәленә төшүеңне дә тоясың. Син инде баштагы кебек «китапны укыргамы, ябаргамы» — дип икеләнгән пассив укучы түгел, юк — син яки актив тарафдар, яки позицияле оппонент... Шул рәвешчә, үзең дә сизмәстән диярлек, билгеле бер объектны системалы рәвештә өйрәнүнең фән өчен перспективасын — өметле якларын да, четерекле, авыр җәһәтләрен дә танып беләсең.

Системалы тикшерену дигәч тә, аны әллә нинди бер өр-яңа, бөтенләй ят алым икән дип уйларга ярамый. Чөнки, гади итеп әйткәндә, система ул бер күренешне башка күренешләр белән тыгыз мөнәсәбәттә — эчке һәм тышкы бәйләнештә,— шул ук вакытта әлеге күренешнең өлешләрен, кисәкләрен дә, үз нәүбәтендә, үзара бердәмлектә, органик оешканлыкта, диалектик каршылыкта, ягъни өзлексез хәрәкәттә карау, шулай аңлау һәм аңлату дигән сүз. Эчке һәм тышкы бәйләнешларга, органик бердәмлек һәм диалектик каршылыкка кагылу исә форма белән эчтәлекнең үзара мөнәсәбәтләренә, күренешләрнең барлыкка килү, оешу, үсү, камилләшү яисә сүрелү, сүнү һәм үлү мәсьәләләренә төрле яклап тукталу мөмкинлеге тудыра. Монда инде күренешләрнең бер сыйфатын гына уртага куеп, калганнарын читкә ташлап фикер йөртергә ярамый. Шуңа күрә тикшерүчене фольклор текстларының яисә социаль-иҗтимагый, идея-эстетик эчтәлеге (мәгънәсе) яки гел тышкы гәүдәләнеше, формасы, ул форманың (яшәеш рәвешенең!) аерым сыйфатлары гына түгел, бәлки шуларның һәммәсе бербөтен организм буларак кызыксындыра. Димәк, өйрәнү, тикшерү сүзнең чын мәгънәсендәге комплекслык кыяфәтен ала. Дөрес аңлаганда, системалы өйрәнүдән төп максат менә шуннан гыйбарәт. А. Яхин алдында да шундый катлаулы һәм мавыктыргыч мәсьәләләр торган.

Һәм шунысы күңелле, автор, бурычның аерым бер өлеше белән генә мавыгып, фәнни танып-белүнең төп максаты булган иҗтимагыятьлекне читләтеп узмый, бәлки әледән-әле кайтып, тикшерелә торган әсәрләрнең социаль эчтәлегенә, тормыштагы функциясенә мөрәҗәгать итә. Чөнки галим дөрес аңлый: системалы, структураль анализ дигән нәрсә — ул өйрәнү процессының үзмаксаты да, аның соңгы чиге дә түгел, бәлки бер этабы, хәтта чарасы гына. Шуңа күрә автор хезмәтенең беренче бүлегендә фольклорның гомум-социаль — иҗтимагый структурадагы урынын, аның башка төр сәнгать әсәрләре белән функциональ бәйләнешын, ниһаять, халык авыз иҗатын аңлаудагы хосусиятләргә, димәк, аның эстетик үзенчәлекләрен билгеләү мәсьәләләренә туктала.

Фольклор әсәрләрен классификацияләү — фәнни төркемләү, жанрларга бүлү, кайсы жанрның нинди функция үтәүгә буйсынуын, димәк, аның социаль-иҗтимагый бурычын ышанычлы рәвештә билгеләү мөмкинлеге туа. Китапның икенче бүлеге, кыскача итеп әйткәндә, менә шушы мәсьәләләргә багышланган.

Автор татар фольклоры текстларына гына ябышып ятмый, бәлки бөтен совет, хәтта дөнья фольклористикасы ирешкән казанышлар югарылыгында торып, татар фольклорының системасы хакында гомумтеоретик планда хөкем йөртә, шуңа күрә зур фәнни категорияләр белән гамәл кылып, чын гыйльми теория югарылыгындагы нәтиҗәләргә, гомумиләштерүләргә ирешә ала. Теоретик алымда ирешелгән казанышлар исә үз нәүбәтендә татар фольклорының кайбер

[1] Яхин А. Г. Система татарского фольклора. Казань, 1984, 200 б.

төрләрен квалификацияле рәвештә анализлау (тасвирлау гына түгел, бәлки текстларның эченә кереп җентекләп тикшерү!) мөмкинлеген тудыра. Китапның өченче һәм дүртенче бүлекләре шул ысулда татар фольклорының аерым жанрларын өйрәнүгә багышланган.

Мәсьәләгә системалы рәвештә якын килүче автор жанрларны үзара тыгыз мөнәсәбәттә — аларның үзара якынлыгын, ераклыгын истә тотып гамәл кыла, шуңа күрә элек хөкем сөргән кайбер алымнардан, күзаллаулардан хаклы рәвештә баш тарта. Мәсәлән, аның фикеренчә, әйтем һәм мәкальләрне Аглый белән Таглый шикелле бергә, гел янәшә түгел, ә аерым-аерым карарга кирәк икән. Чөнки, тышкы охшашлыкны ясисә кайбер генетик уртаклыкны исәпкә алмаганда, тормышка мөнәсәбәте һәм андагы функцияләре буенча, алар төрле дәрәҗәдә торып, төрлечә иҗтимагый бурыч үтәгән, үти торган үзара бөтенләй башка-башка жанрлар икән. Бу — кечкенә нәтиҗә түгел, минемчә, чөнки монда яңа алымның отышлы яклары да, аның фән өчен перспективасы да ярылып ята.

Альберт Яхинның табышмаклар, кыска җырлар, мәкальләр хакындагы күзәтүләре, фикерләре дә үзенчәлекле һәм дәлилле. Кыска җырлардагы янәшә икеюллыкларның үзара мәгънәви бәйләнгән ясисә бәйләнмәгән булуы мәсьәләсе моңарчы төрле бәхәсләргә сәбәп иде. Шул кыска җыр дигән хикмәтнең табигате, тормыштагы функцияләре, аерым төр һәм төркемчәләре хакында әйтелгән яңа фикерләр дә фольклор белемебезгә лаеклы өлеш дип бәяләрлек. Әлбәттә, кыска җырларга караган мәсьәләләрнең барысы да хәл кылынган дип әйтергә булмый әле, автор үзе дә моны дәгъва кылмый, чөнки күләме-саны ягыннан иксез-чиксез булган кыска җыр диңгезенең төбенә төшәр өчен күп тырышырга кирәк. Шулай да кыска җырлар эчендә автор билгеләгән дүрт төркем, ул төркемнәрнең үзара мөнәсәбәтләре хакындагы аның күзәтүләре, минемчә, аерата игътибарга лаек.

Дүртенче бүлек мәзәк һәм мәзәкчәләр жанрына багышланган. Көлкеле сюжетка корылган һәм «хикәячек» кебек нәрсәнең мәзәк (анекдот) булып җитә алмавы хакындагы фикер белән килешмичә мөмкин түгел: бездә, кызганычка каршы, һәр көлкеле вакыйганы, аның табигатенә кереп тормыйча, мәзәк-анекдот дип аңлау һәм аңлату, хәтта притча шикелле бөтенләй мөстәкыйльле жанрны да мәзәк кысаларына куып керту гадәткә әйләнә язды. Шуңа күрә А. Яхин тәкъдим иткән жанрны билгеләү алымнары, минемчә, фольклор белгечләренең игътибарыннан читтә калмаска тиеш.

Жанрның структурасын ачыклап, аның иҗтимагый функциясен, барлыкка килү һәм үсү, жанр буларак чарлану үзенчәлекләрен, ниһаять, татар мәзәкләренең милли хосусиятләрен күзәтүгә багышланган сәхифәләрендә дә төптән уйланып әйтелгән фикерләр шактый. Мәзәкләрнең генезисы хакындагы күзәтүләр аерата игътибарга лаек дип әйтерлек. Аларның социаль-иҗтимагый функцияләре турындагы фикерләр дә кабул ителерлек. Тик, кызганыч ки, татарларда феодалларга каршы юнәлтелгән мәзәкләр ни өчен юк дәрәҗәсендә аз ясисә бөтенләй сакланмаган дигән сорауга бирелгән җавап — аңлатма кирәгенчә төгәл һәм әтрафлы килеп чыкмаган. А. Яхинның фикеренчә, Казан ханлыгы чорында халыкның күпчелеген ясаклы кешеләр тәшкил иткән һәм аларның җәмәгатьчелеге (общиналары) зуррак мөстәкыйльлеккә, ягъни автономиягә ия булып, феодалларга карата үзләрен ирекләрәк тоткан (183 б.). Чынлыкта мәсьәлә күпкә катлаулы. Беренчедән, Казан ханлыгы чорында да, аннан соң да татар игенчеләре һәм аларның аксакаллары әллә ни көчкә дә, җәмәгатьчелек «автономиясенә» дә ия булмаганнар. Икенчедән, татарларда феодалларга каршы рухтагы мәзәкләрнең аз булуы (бу чыннан да шулай!) ул Казан ханлыгы чорындагы җәмгыять төзелешенең үзенчәлегеннән килеп чыккан сыйфат түгел, ә соңгырак дәвер, ягъни XVII—XVIII, хәтта XIX йөзләрдәге иҗтимагый үзгәрешләрнең нәтиҗәсе. Башкачарак итеп әйткәндә, XV—XVI гасырларда туган, яшәгән антифеодаль татар анекдотлары соңгы өч гасыр дәвамында онытылып беткән. Чөнки, Казан ханлыгы җиңелгәч, бу якларда патша хөкүмәте алып барган эзлекле политика дәвамында, татар феодалларының төп һәм көчле, оешкан, оештыру куәтенә ия булган катламнары бөлеп бетә ясисә, христианлашып, милли җирлектән аерыла, шуңа күрә татар дөньяви феодалларының социаль изүче буларак функцияләре кими, кайбер төбәкләрдә һәм билгеле бер чорларда бөтенләй юкка чыга яза (бу хакта минем «XVII—XVIII гасыр татар тарихи чыганаклары» исемле китабымның 25—32 битләрендә махсус язылган иде инде). Шушы фундаменталь сәбәп аркасында XVIII—XIX йөзләрдә һәм XX гасыр башында татар мужигы (антифеодаль әсәрләренең төп авторы!) өчен татар җәмгыятендә зур роль уйнамаган алпавытлар турында авыз чайкап утырырга артык ихтыяҗ калмаган.

Ләкин, бу әйтелгәннәрдән чыгып, XVIII—XIX йөзләрдә татар крестьяннары феодаль изүдән дә арынган икән дигән кебек берьяклы, хәтта принципиаль ялгыш

нәтиҗә ясарга да ярамый. Чынлыкта экономик зәгыйфьләнеп, оешканлык ягыннан тәмам чәрдәкләнеп беткән, димәк, сыйнфый диктаторлык сыйфатын югалткан милли феодаллардан бушаган урын вакуумга да әверелмәгән — социаль-иҗтимагый структурада барлыкка килә башлаган мондый «бушлык» шунда ук тутырыла барган. Аны, беренчедән, царизм йөзендә конкрет һәм персональ феодалы нык ышеренгән (патша власте авторитеты артына кереп оялаган) дәүләт крестьянлыгы халәте каплап барса, икенчедән, дөньяви феодаллардан бушый барган урынга рухани феодаллар сырышкан. Нәкъ менә шул «үз» муллаларыбыз тулаемы белән «үз мужигын» эксплуатацияләгән. Шул рәвешчә, дөньяви феодалларның урыннарын рухани феодаллар били бару аркасында, кайбер икенчел дәрәҗәдәге үзгәрүләр — өскорма үзгәрүләре — барлыкка килүгә карамастан, татар чынбарлыгындагы сыйнфый, социаль структураның антогонистик нигезе — базисы принципта элеккечә үк кала биргән (бу хакта карагыз: Усманов М. Заветная мечта Хусаина Фаизханова. Казань, 1980, 182—184 бб.) Шуның өчен дә А. Яхин тәкъдим иткән аңлатманың әле анализланган беренче өлешенә караганда икенче өлеше — татарларда руханиларга каршы юнәлгән мәзәкләр гаять киң таралган дигән нәтиҗәсе күпкә дөресрәк (183 б.). Авторны аныклап, тулыландырып, шуны өстисе килә: татарларда руханиларга каршы мәзәкләрнең күбәюе дә аларның элек-электән килгән милли үзенчәлеге түгел, һәм ул да соңгырак дәверләрнең күренеше. Димәк, галим күтәреп чыккан бу мәсьәлә киләчәктә җентекләп тикшерүне сорый дигән сүз. һәм монда ашыкмыйча, кабаланмыйча фикер йөртергә кирәк.

Бу төзәтмәне мин А. Яхинны татар феодаль сыйныфының тарихын әтрафлап яктырта алмавында гаепләр өчен китермим (андый мәсьәләне төгәл хәл кылу ахыр чиктә фольклор белгеченең бурычы да түгел — бу өлкәдә без, тарихчылар, җаваплырак). Минем фикер икенчерәк: системалы алым белән эзлекле рәвештә өйрәнгәндә, фольклор әсәрләренең социаль-иҗтимагый сыйфатлары, аларның туу, үсү һәм яшәү закончалыклары калкурак ачылып, безнең танып-белү мөмкинлекләребез киңәя, камилләшә төшә икән.

Рецензияләнә торган китапта кайбер башка характердагы кимчелекләр дә юк түгел. Мәсәлән, мин андагы библиографик исемлекнең җитәрлек дәрәҗәдә эшкәртелеп, тиешле тәртипкә салынып бетмәвен ашыгу нәтиҗәсе дип бәяләр идем. Шулай ук хезмәтнең күп өлешендә анализ мисалларының җитәрлек дәрәҗәдә китерелеп бетмәве дә текстка вакыт-вакыт коры, саран тезис кыяфәтен биреп куя. Ләкин, бәхеткә каршы, мондый җитешсезлекләр күп түгел һәм алар яңа хезмәт хакындагы гомум уңай бәяне үзгәртә алмыйлар. Бәянең сөземтәсе исә шуннан гыйбарәт: Альберт Яхинның бер концепциягә буйсынып, эзлекле алым белән язылган бу хезмәте фольклористикабызның соңгы казанышларыннан булу өстенә аның киләчәгенә яңа юнәлеш башлап җибәрергә сәләтле тәмамланган махсус тикшеренүләрнең беренчеләреннән һәм бүгенгә иң соңгысы дип әйтергә лаек. Бу хәл исә авторга яңа җаваплы бурычлар өсти: ул үзенең позициясен тагы да ныгытырга, димәк, эзләнүләрен системалы рәвештә дәвам итәр, әз үз эшчәнлеге белән генә чикләнмичә, шәкертләр дә тәрбияләргә тиеш.

**Миркасыйм ГОСМАНОВ,**
тарих фәннәре докторы,
профессор.

# ГҮЗӘЛЛЕК НИЧЕК ТУА

Ленинградтагы «Художник РСФСР» нәшриятында күренекле совет рәссамы Харис Габдрахманович Якупов иҗатына багышланган монография дөнья күрде. Китапның авторы Светлана Червонная Татарстан сынлы сәнгате үсеше проблемалары белән күп еллардан бирле шөгыльләнә. Башка автономияле республикалардагы сәнгать торышы белән дә яхшы таныш булган галим монографик анализ ясау өчен Х. Якупов иҗатын милли сынлы сәнгатьнең сугыштан соңгы үсешенә зур йогынты ясаган иҗат буларак сайлаган. Шул ук вакытта С. Червонная мондый китап илебез халыкларының күпмилләтле культурасы тормышындагы иң мөһим проблемаларны күтәреп чыгарга һәм карап тикшерергә мөмкинлек бирер дип санаган.

Китап зур кызыксыну белән укыла, күп төрле фикерләр уята, сораулар тудыра. Бу сорауларга шунда ук бирелгән җаваплар белән килешергә дә мөмкин, кайсыбер җаваплар исә бәхәсле фикерләр дә кузгата. Китапның шактый өлешен тәшкил иткән төсле репродукцияләр нәтиҗәләр ясау өчен нигез булып торалар. Әлеге хезмәт рәссамның кырык

еллык иҗади эзләнүләре нәтиҗәсен яңача күрергә һәм аңа бәя бирергә, иҗатының, шәхес буларак формалашу һәм үсү этапларын эзлекле өйрәнергә, һәр әсәрендәге шәхес һәм иҗат бердәмлеген тоярга, иҗат остаханәсенә күз салырга, шулар ярдәмендә аны яхшырак аңларга мөмкинлек бирә.

Әле генә Казан художество училищесын тәмамлаган Харис Якупов сугышның беренче көннәреннән ук фронтка китә. Аның «университетлары» нәкъ менә шунда — алгы сызыкта башлана. Рәссам, гражданин, кызыклы иҗади шәхес буларак, ул менә шул вакытта — авыр, рәхимсез сугыш елларында формалаша. «Минем ул вакыттагы рәсемнәрем — үзенә күрә фронт көндәлеге,— дип сөйли рәссам.— Шуңа күрә мин, нинди авыр шартлар булуга карамастан, беркайчан да, беркайда да рәсем ясавымнан туктамадым... Бу эшне профессиональ бурычым дип санадым... Никадәр арыган булсам да, никадәр куркыныч булса да, бу эшем хәрби хезмәтем кебек әһәмиятле дип санап эшләргә тырыштым».

«Профессиональ бурычым»— бу сүзләрдә Х. Якуповның тормышка һәм иҗатка мөнәсәбәте ачык күренә. Гражданин буларак ил алдындагы изге бурычын тоеп эшләү сыйфаты аның иҗат шәхесендә елдан-ел зурая бара. Ул сәнгатьтә җиңел юллар эзләми, һәрвакыт төп юнәлешне сайлый. Ә бу юл, гадәттә, иң авыр юл.

Сугыш чорында ясалган рәсемнәргә кайтыйк. Монографиядә рәссам иҗаты белән танышу нәкъ менә шундый рәсемнәрдән башлана. «Вакыт узудан саргаеп беткән кәгазь битләрендәге бу рәсемнәр... чорыбызның чагыштыргысыз кыйммәтле тарихи истәлекләре,— дип бәяли аларны автор.— Аларда — кырыс һәм изге, фаҗигале һәм героик сугыш чынбарлыгы».

Харис Якуповның сугыштан соңгы иҗатын автор нигезле рәвештә өч этапка бүлә. Беренчесен —1946 елдан 1957 елга кадәр — С. Червонная «утраклык» чоры дип атый. Әмма, автор әйтүенчә, бу чорның аталышы шартлы, термин рәссамның иҗтимагый позициясен түгел, бары тик табигать белән аралашмыйча, күбрәк үз остаханәсендә генә эшләвен күрсәтә. Икенче этап — «Питрәч чоры» (1958—1965 елларны эченә ала). Бу чорда иҗат ителгән әсәрләрнең күбесе Питрәч районының М. Вахитов исемендәге колхозы хезмәтчәннәренә багышланган. Әлеге картиналарда берничә ел остаханәдә «бикләнеп» эшләгәннән соң дөньяга чыгу сизелә. Өченче чор — уйланулар чоры — алтмышынчы елларның икенче яртысыннан башлана. Бу чорны шундый исем белән атауның сәбәбе бар. Ул елларда эшләнгән картиналарда тарихи һәм хәзерге заман процессларын тирәнтен аңларга, вакыйгаларның һәм фактларның асылын ачыкларга, аларны логик теземгә берләштерергә омтылу сизелә.

Китапның һәр этапка багышлап язылган бүлекләренә игътибар итик. «Хезмәт, хезмәт һәм янадан хезмәт» дип исемләнгән бүлектә тасвирланган чорда яшь рәссам берничә ел эчендә бөтен илгә танылган художник булып үсеп җитә. Бу чорда «Кунаклар белән сөйләшү», «Хөкем алдыннан», Л. Фәттахов белән берлектә «В. И. Ленинның Татарстан АССР оештырылу турындагы Декретка кул куюы» кебек картиналар иҗат ителә. Рәссам китаплар өчен, «Чаян» журналы өчен рәсемнәр ясый. Кыскасы, бүлектә күп төрле кызыклы мәгълүматлар китерелгән. Әмма шунысын әйтергә кирәк: бу бүлектә автор «Бүген инде сугыштан соңгы беренче елларда иҗат ителгән шома, акылга нигезләнеп төзелгән тематик картиналар белән ул еллардагы матур этюдлар арасындагы сыйфат аермалыгын күрү авыр түгел», дип, рәссам иҗатын анализлаудан бераз читләшкән. Минемчә, әгәр С. Червонная рәссамның бу беренче картиналарында ук күренә башлаган иҗат үзенчәлекләренә ныграк басым ясаган булса, китап тагын да баерак булыр, кызыксыныбрак укылыр иде.

«Җанлану» дип исемләнгән «Питрәч чоры» турындагы бүлек, һичшиксез, китапның иң яхшы өлеше буларак кабул ителә. Рәссамның иҗат эшчәнлеге совет сынлы сәнгатенең шул вакыттагы үсеше белән ничек бәйләнгән? Бу сорауга С. Червонная Х. Якупов иҗатында барлыкка килгән яңа үзенчәлекләргә кайнар соклану хисе белән шунда ук үзе җавап та бирә.

Районга барып кайту рәссамда тирән тәэсир калдыра, ул анда күпсанлы этюдлар ясый. «Әлеге этюдларда табигый булмаган бернәрсә дә юк: һәр очракта да кәгазь битендә авыл күренешләре тормыштагыча, бернинди өстәмә буяуларсыз, күзгедәге кебек дөрес чагылдырылган,— дип яза автор.— Нәкъ менә шул табигыйлектә, беркадәр көтмәгәндә, рәссам үзе өчен зур шигърият чишмәсе ача, тормышчан, гүзәл картиналар иҗат итү юлын таба». Бу этюдларны художник иҗатында яңа этап башлап җибәргән «кечкенә эпизод» төсендә карап, С. Червонная рәссамның иҗат үсешендәге бик мөһим бер моментны билгеләп үтә: «Билгеле, Якупов иҗатындагы үзгәрешләр нигезендә авылга барып кайту, кышкы табигать кочагында эшләү генә ятмый. Бөтен совет сәнгатенә хас үзгәрешләр заман сулышын тоеп яшәгән рәссам иҗатына да йогынты ясамый калмый. Бу чорда совет рәссамнарының күбесенең иҗаты үзгәреш кичерде, яңа яклары белән ачылды...»

Харис Якупов тормышта дисеңме, сәнгатьтә дисеңме — яңалыкка гаять сизгер кеше. Минем аны күргәзмәләрдә куелган картиналарны, яңа басылып чыккан китаплардагы

төсле рәсемнәрне игътибар белән, тирәнтен уйланып, бирелеп караган вакытында күзәткәнем бар. Ул иптәшләренең һәр табышына, һәр уңышына чын күңелдән сөенә, һәр этапның иң алдынгы тенденцияләрен күреп ала белә, аңа гына хас булган юл белән бара.

«Питрәч» циклының һәр картинасы турында китапта сокланып сөйләнә. Чыннан да, бик яхшы эшләнгән төсле кучермәләр югары бәяләүнең дәреслеген раслыйлар. Рәсемнәрне караганда текст авторы аларны тирәнрәк аңларга, «рәссамның чынбарлыкны, тормыш дәреслеген соклану, ярату, шатлыклы гаҗәпләнү белән ничек аерылгысыз берләштерүен» тоярга ярдәм итә. М. Вахитов исемендәге колхозның алдынгы дуңгыз караучысы М. Галиуллина портретының совет портрет сәнгатенең «алтын фонды»на кертелүенең, ул картинадан репродукцияләрне совет сәнгатенә караган зур басмаларда очратуыбызның серен без шунда аңлыйбыз.

«Питрәч чоры»нда эзләнүләрнең иң югары ноктасы булып ике әсәр тора: «Көчле кешеләр» һәм «Алдынгы терлекчеләр». Аларда алтмышынчы еллар уртасында татар сынлы сәнгатенең нинди югары дәрәҗәгә күтәрелүе бик ачык чагыла. Бу картиналарда көчле, сабыр һәм батыр рухлы халык характеры концепциясе, кеше белән җир бердәмлеге тирән һәм эзлекле ачыла. Менә шундый булган ул бернечә елларга сузылган бәхетле иҗат мизгеле һәм үз халкының хезмәт тормышындагы моңарчы билгеле булмаган эстетик һәм рухи байлыкларны ачу чоры,— дип яза автор, Питрәч этабына йомгак ясап.

Рәссамны алда нәрсә көтте? Бу сорауга җавап монографиянең «Уйлану», «Казан студентлары» дип исемләнгән соңгы бүлекләрендә һәм альбом ахырындагы репродукцияләрдә бирелә. Монда этюдлар да, хезмәт халкының матурлыгына, Татарстан нефтьчеләренә һәм КамАЗ төзүчеләренә дан җырлаучы композицияләр дә, 1887 елда Казан студентлары сходкасында катнашкан В. Ульянов образын гәүдәләндерү юнәлешендә эзләнү нәтиҗәсе булган зур тематик картиналар да бар. Әлеге картиналарны беренче тапкыр күргән көннәр әле дә булса хәтердә. Башта «Уйлану», «Терелəр һәм үләләр», аннан соңрак «Пролог», М. П. Девятаев батырлыгына багышланган «Азатлыкка очу», «Татарстан алтыны» һәм «Чаллы гүзәлләре», «Пролог» темасының «Казан студентлары. 1887 ел» исемле монументаль композициядә яңача бирелүе...

Монографиянең соңгы бүлекләрендә әлеге картиналарны иҗат итү турында җентекле сөйләнә, тирән анализ бирелә. Әмма, минем карашымча, рәссамның бөтен иҗатын берләштерүче гаять кызыклы бер фикер аеруча игътибарга лаеклы. Х. Якуповның 1960 елларның икенче яртысындагы иҗатын,— дип яза С. Червонная,—«Инкарьне инкарь итү» диалектика законы яшәешенә үрнәк итеп куярга мөмкин. Илленче еллар ахырында аның иҗатында тормышны, табигатьне, кешене — рәссамның күзенә чалынган бар нәрсәне гади генә, дөрес итеп, ниндидер ясалма бизәкләрдән башка турыдан-туры тасвирлау хакына һәрберсенә үз роле бирелгән катнашучылары булган сюжетлы-тематик композицияләрнең, әдәби-тарихи композицияләрнең инде күнегеп бетелгән эталоннарын инкарь итү процессы барды. Алтмышынчы елларның икенче яртысында исә картинаның философик эчтәлеген тирәнәйтү өчен, әйләнәтирәдәге дөньяны чагылдырып кына калмыйча, аны дөрес аңлатуга, аның иҗтимагый, политик һәм әхлакый төзелеше турында фикер йөртүгә омтылу һәм әлеге уй-фикерләрне сынлы сәнгать формаларында чагылдыру өчен Якупов үзенең элекке хезмәтләрендәге эчке сиземләүгә нигезләнгән табигыйлекне күпмедер инкарь итә. Шул ук вакытта икенче инкарь итү беренчесенә тиң түгел; монысы иҗади үсешнең элекке этаплардагы бар яхшы якларны үзенә алган югарырак баскычы... Аның тормыш турында борчулы яки шатлыклы уйларын чагылдырган яңа әсәрләрендә инде иҗат дөньясына табигать кочагында «онытылып» эшләгәндә үтеп кергән яктылык һәм сафлык мул бирелгән...

Синтезлаштыру белән кушылган диалектик инкарь итү Х. Якупов иҗатындагы заманча эзләнүләрнең төп юнәлеше булуы китапта бик дөрес билгеләнә. Бәлки «Питрәч чоры»на күчү закончалыгына да шул күзлектән карарга, аның алдагы чорда ирешелгәннәр белән эзерләнгән булуын күрсәтергә кирәк булгандыр?! Тирәнтен анализ ясау осталыгына ия булган авторга аның асылын «шомалыкка», «әдәби уйлап чыгаруга» гына кайтарып калдыру килешеп бетми.

Әмма бу очраклы хәл дип аңларга кирәк. Тулаем алганда, китап кызыклы язылган, оста каләм белән язылган. Аны игътибар белән укып чыгу гүзәллек тудыру могҗизасы белән таныштыра, шуның белән бергә, татар сынлы сәнгатенең иң күренекле вәкилләреннән булган рәссамның иҗатын тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

**Леонид ЕЛЬКОВИЧ,**
сәнгать фәннәре кандидаты.

# ДАВЫЛЛЫ ЧОР ҖЫРЧЫСЫ



Күренекле әдип, журналист һәм публицист Шакир Мөхәммәтша улы Мөхәммәдев 1865 елның 20 маенда Буа шәһәрендә туа. 14 яшенә кадәр шәһәр мәдрәсәсендә укый, ләкин тормыш кысынкылыгы аркасында укуын ташлап, эш эзләп читкә китәргә мәҗбүр була. Язмыш 14 яшьлек үсмерне Оренбургка илтеп ташлый. Ул анда байга хезмәтче булып яллана, тормышның әчесен-төчесен татый. Зирәк малай, зур кыенлыклар, җәбер-кимсетүләргә карамастан, үзлегеннән укый, беркадәр русчага да өйрәнә. 1884 елда Ш. Мөхәммәдев Оренбургның бер бае конторасында эшли, аннары, бәхет эзләп Мәскәүгә юнәлә. 1900 елда булачак каләм остасы инде Маньчжуриядә. 1900—1901 елларда ул Харбин шәһәрендә яши һәм шунда иҗат эшчәнлеген башлап җибәрә. Ш. Мөхәммәдевнең беренче хикәясе «Җәһаләт яхут Галиәкбәр агай» шул чакта языла һәм 1901 елда Казанда басылып чыга. Язучы бу әсәрендә бөтен кәсепләрен алдау, талауга корган татар байларының типик образын иҗат иткән. Шул ук елны «Яфрак асты яки Мәкәрҗә ярминкәсе» исемле икенче хикәясе Оренбургта дөнья күрә. 1902 елда язучы туган якларына кайта һәм тиздән Оренбургта төрле байларның конторaларында эшли. Шул еллардан башлап, ул хикәяләр язу белән беррәттән тезмә әсәрләр дә иҗат итә («Яңа бәдәвам», «Урал буе — татар туе» һ. б.), көндәлек матбугатта актив катнаша башлый. Тифлис шәһәрендә әзербайҗан телендә чыккан «Шәркы рус» газетасында ул «Татар угылы» имзасы белән халыкны мәгърифәткә, прогресска өндәгән мәкаләләре белән катнаша. 1906—1907 елларда язучының демократик рух белән сугарылган мәкаләләре даими рәвештә «Вакыт», «Казан мөхбире» газеталарында, «Әлгасрел-җәдит» журналында басылып килә. 1906 елдан Ш. Мөхәммәдев татар демократик матбугатының иң алдынгы органнарыннан берсе булган «Карчыга» журналын чыгара башлый (9 саны чыгып, 1907 елда ябыла). Аның «Күз яшьләре», «Сигез сәгать эш вакыты», «Пермьнан», «Җир кирәк», «Дума членнарына» һ. б. шигырьләре революцион көрәшне пропагандалый, азатлыкны җырлый. Шундый ук рухта язылган публицистик әсәрләре дә («Максат», «Хәзерге хәлләр», «Хәсрәтле көннәр», «Эшче халыкка», «Безнең кулаклар» һ. б.) иске тормышка каршы көрәш авазын куәтли. Бу әсәрләре белән Ш. Мөхәммәдев татар революцион публицистикасының гүзәл үрнәкләрен бирә, революцион-демократик фикер үсешенә бәрәкәтле йогынты ясый.

Әдип Бөек Октябрь социалистик революциясен шатланып каршы ала, Оренбургның совет учреждениеләрендә зур тырышлык куеп эшли. Сәламәтлеге какшаган язучы үпкә авыруыннан 1923 елның 10 ноябрендә Оренбург шәһәрендә вафат була.

Түбәндә Ш. Мөхәммәдевнең революцион демократик рухтагы «Карчыга» журналы битләрендә басылган кайбер әсәрләреннән үрнәкләр китерелә. Алар «Кайгылы», «Эшче», «Авыл кешесе» псевдонимнары белән яки имзасыз басылган. Гомумән, «Карчыга» — да әдип ике дистәдән артык псевдоним куллана, ә бик күп парчалар, публицистик әсәрләре имзасыз бирелгән.

Текстларда Ш. Мөхәммәдевнең башлыча үз теле һәм орфографиясе саклапды, фәкать кайбер сүзләр генә, мәсәлән, «көннәремез», «телләремез», бүгенге орфография кагыйдәләренә буйсындырылып, «көннәребез», «телләребез» формасында бирелде.

**Равил ӘМИРХАНОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

# Максат




«Карчыга»ның башлыча максаты: эшче халыкны хайван дәрәҗәсенә дә күрмәенчә, җәһәннәм чокыры кебек караңгы, сасы, һавасы бозык фабрикаларда, заводларда сасыган итләр, күгәргән икмәкләр илә ачлытуклы асрап, суткасына уналтышар сәгать каторжный хезмәт иттереп, приказчик, конторщикларына кояш чыкканнан төнге сәгать унга, уникегә кадәр җигеп, кибеттә, подвалда әллә ниндәй былчырак эшләргә кушып, юк кына нәрсә өчен ата-анасы илә сүгеп, актык тамчы каннарын эчеп, тиешле жалованиеләрен кысып, аларның кул көче аркасында кесәләрен тутырган, корсагын үстергән надан, тәкәббер, залим, ач күзле капиталистлар илә сугышмак, кадәри хәл приказчик, конторщик һәм эшче халыкның файдасына каләм йөртмәктер.

Ничә йөз еллардан бирле хөкүмәткә әллә ниткән тиешле-тиешсез налоглар түләп йөдәгән, ачлыктан аптыраган, хокуксызлыктан гаҗиз калган җирсез, сусыз авыл халкының тормышыннан, дахили вә хариҗи сәяси эшләрдән, мәктәп-мәдрәсәләрдән вә гайре нәрсәләрдән бәхәс итеп, тиешсез һәм килешмәгән эшләрне көлке тарикы илә язып, рәсемнәре һәм күрсәтеләчәктер.

«Карчыга», 1906, 1 сан, 1 б.

---

Кадәри хәл — хәл кадәренчә, мөмкин булганча.
Дахили вә хариҗи — эчке һәм тышкы.
Тарикы илә — юлы белән, ысулы белән.

# Хәсрәтле көннәр

Русия өстендәге кара болытлар көннән-көн куера, дөнья йөзе көннән-көн караңгылана барадыр; бу көн үз ихтыярында йөргән кеше иртәгә төрмәгә кермәвеннән, Якутскига җибәрелмәвеннән, яхуд полевой суд буенча хөкем кылынып асылмавыннан һич имин түгел; һәркемнең җаны-тәне кыл өстендә генә йөридер. Гөнаһлы бәндә, җәһәннәмдә ята-ята, җәһәннәм газабына да күнә, имеш; шуның шикелле Руссиядәге золым астында изелгән халык та полевой судларга, гомерлек каторгаларга, егерме дүрт сәгать эчендә дар агачына асылуларга күнә башлады; бюрократия көннән-көн куәтләнә бара, хөррият өчен йөрүчеләр, хәзерге хөкүмәттән разый булмаган кешеләр һәр көнне төрмәләргә, крепостьларга тутырылалар, Сибириягә озатылалар; хөррият собраниеләр, хөррият союзлар тәмам бетте, хөррият матбугатның да исеме генә калып бара.

Үткән ел октябрь 17 манифестыннан бирле Русия танымаслык бер хәлгә керде: Русиянең һәр җирендә, һәр шәһәрендә ничә йөз еллардан бирле ирек вә җиргә мохтаҗ авыл халкы, бер кисәк икмәк, ял итәр өчен бернинчә сәгать вакытка сусаган эшче халык үзләренең тормышын яхшыртыр өчен, үз праваларын алыр өчен капитализм илә сугышып кан елгасына батты; ничә вә ничә яшь егетләр халык файдасы артыннан йөреп корбан булдылар, никадәр аталар, ничә-ничә аналар үзләренең күз карасы кебек газиз угылларыннан аерылды; никадәр бала-чага анасыннан аерылып, ятим булып калдылар. һәр җирдә елгалар кебек күз яшьләре агадыр, һәр җирдә кыямәт көне кебек аһ-ваһ итеп елау, хәсрәт, ничә йөз еллардан бирле эшче, фәкыйрь халыкны үзләре теләгәнчә җигеп, аларның ярлылыгыннан файдаланып, аларны ачтан үлмәслек кенә хак илә бер минут күзләрен ачарга, хәл алырга вакыт бирелми, әллә нинди каты вә авыр хезмәтләр кылдырып, каннарын эчеп кесәләрен юанайткан байлар, эш вакытын киметеп, хак арттырырга сораган өчен, «хуҗага каршы киләләр, бунт чыгаралар, законны бозалар, фәлән» дип ничә меңнәр гөнаһсыз эшче халыкны урыннарыннан куып, бала-чагасы илә урамнарга ташлап, ач-ялангач калдырдылар һәм бик күбесен «котыртучылар» дип шпионлык кылып, төрмәләргә яптырдылар, Сибириягә җибәрттеләр. Үзенең

хайван түгел икәнлеген вә башка кешеләр кебек ук дөньяда адәм шикелле торырга аның да хакы барлыгын аңлап, үз правасын требовать иткән эшче халык капиталистлар һәм хөкүмәт каршысында «бунтовщик» булып күренде! Коллык зынҗырыннан азат булып, хөррият өчен үзләренең газиз җаннарын фида кылырга хәзер алдагы сафта укыган яшьләр, фабрик-заводларда хезмәт итүче эшчеләр булды. Аз жалованьега күп хезмәт биреп, һәртөрле мәшәкать, җәфа вә кыенлыкларга чыдап, дөнья яктысын күрми золым, җәбер астында изелгән түбән дәрәҗәдәге түрәләр, приказчиклар, эшчеләр һәркайда бастовать итеп, бөтен Русияне астын өстенә китерделәр.

Ялгыз капиталистлар, юан корсаклы байлар илә аена әллә ничәшәр мең жалованье алып, һич эш эшләми, клубларда карта уйнап гомер үткәрүче бюрократлар гына «болганчык суда балык тоту асат» икәнен бик яхшы белгәнлектән, иске тормышны максат, хөррият теләүчеләргә теш-тырнаклары илә каршы тордылар. Чөнки аларның дөньялары түгәрәк, һәрнәрсәләре җитешкән, ашаганнары, кара халык әйтмешли, бал да май; киеммәтле туннар кияләр, меңәр сумлык аргамакларны резин шинлы коляскаларга җигеп, кататься итәләр, көненә унбишәр сәгать йоклап, корсаклары шартлаганчы ашыйлар, эт булганчы эчеп... кебек исерәләр, дөньядагы барлык кабахәт эшләрне кылалар, хезмәтчене, приказчикны һич тиешсез урында эт урынына сүгәләр, налог түли-түли йөдәгән авыл халкының актык тиресен туныйлар, болай булгач, әлбәттә, болар өчен иске тормыш яхшы. Әмма бу иске тормышның нигезе хәзер тәмам чергән, бүгенме-иртәгәме егылачак. Хаклык һәрвакыт өстен булачагында һич шөбһә юктыр. Хәзергә кадәр аяк астында изелгән эшче халык илә җирсезлектән аптыраган авыл халкы да, әлбәттә, бер көн моратларына ирешеп, дөнья яктысы күрәчәкләр.

«Карчыга», 1906, 2 сан, 2—3 бб.

---

Ялгыз — биредә: фәкать, бары тик мәгънәсендә.

# Күз яшьләре

### ЙОСЫФ КИТАБЫ КӨЕ ИЛӘ

Русия эчендә ниләр булгай,
һәр җирдә стражник һәм казак тулгай,
Хөррият өчен күп кешеләр сугылгай,
Куркынычлы көннәребез алда имди.

Бюрократ һәм байларның карны туктыр,
Алар кулында төрле-төрле корал күптер,
Бичара эшче халыкка икмәк юктыр,
Авыл халкы җирсезлектән кырылыр имди.

Кара халык ачлыктан үлеп бара,
Боларны туйдырырга юктыр парә,
һәркем эзләр иде үзе чара,
Мәгәр нагайкадан куркыр имди.

Кыенлыкка калып бара көннәребез,
Зынҗыр белән беркетелде телләребез,
Аһ-ваһ илә үтәдер һәм төннәребез,
һәр җирдә полевой судлар тулды имди.

Кара болыт яктылыкны янә каплыйдыр,
Бюрократлар иске тормышны мактыйдыр,
Буржуалар капиталны үзендә саклыйдыр,
Бүлешергә һич ниятләре юктыр имди.

Күбәйде һәр җирдә асылу һәм атылу,
Хисап юк яндыру һәм ватылу,
Мода булды сары алтынга сатылу,
Болар бар да Столыпин ысулы имди.

Ышаныч юк һәм киләчәк Думага,
Карагруһлар сәҗдә кыладыр сумага,
Әйләнеп бара бөтен Русия чумага,
Күрәчәк кыенлыклар алда имди.

Кара халык ачлыктан күзен ача алмый,
Болай булса, ашлыкларын да сачә алмый,
Казакларның камчысыннан һич кача алмый,
Төркем-төркем Сибириягә җибәрделәр имди.

Дума таратылгач, бюрократлар куәт алды,
Хөррият тарафларны төрмәгә салды,
Бала-чага ата-анадан ятим калды,
Моннан артык кыенлыклар булмас имди.

Болай булса, хараптыр эшләребез,
Корбан булды күп кирәкле кешеләребез,
Анларсыз без, куркаклар, ни эшләрбез,
Озакламый выборлар булачак имди.

Караңгы төн никадәр озын булмасын,
Җир йөзе золым илә һәм тулмасын,
Арысланнар Себергә күпме куылмасын,
Ниһаять, бер таң атмый калмас имди.

«Карчыга», 1906, 2 сан, 2—3 бб.

---

Парә — акча.
Зынҗыр — чылбыр, богау.

# Эшче халыкка

Әгәр дә без үзебезнең кул көчебез, үзебезнең маңгай тиребез берлән тамак туйдыручы эшчеләр үз кирәкләребезне үзебез сорамасак, үзебезнең ачлы-туклы тормышыбызны яхшыртыр өчен үзебез иҗтиһад кылмасак, хода бигрәк байларга бирсен, «аларда булса, без ач булмабыз әле» дип һәмишә шул искечә ризыгыбызны байлардан көтеп, аларның «фатиха»сына гына алданып йөрсәк, безнең көнебез дә, тормышыбыз да яхшыланмаячак, кадерле булган бәйрәм көннәребездә дә ял итәргә, хатын-кыз, балачагабыз берлән туйганчы чөкердәшеп сөйләшеп чәй эчәргә, аш ашарга форсат бирелмәячәк, суткасына унсигезәр сәгать эшләп алган акчабыз һәмишә шулай балаларыбызны тәрбия кылырга җитмәячәк, балаларыбыз һәмишә шулай надан калачак, хатыннарыбыз һәмишә байларның былчырак керләрен, шакшы иdәннәрен юудан, помойларын түгүдән бушамаячаклар; ул хөрмәтсез байлардан хәер көтмәк, шайтаннан иман өмит итмәк берлән бердер, алар ничек тә булса безнең җилкәбезгә атланып, актык тамчы каныбызны эчәргә тырышачаклар; алар әүвәлдә безнең җелегебезне күп суырдылар, ә хәзер, мөмкин булса, бөтенләй җаныбызны алырга тырышачаклар, чөнки бу соңгы еллар эшче халык та алар кебек үк дөньяда торырга хакы барлыгын аңлап, үз правасын требовать итә башлагач, аларның бөтенләй каннары куерды.

Әй, иптәшләр! Выбор вакытлары якынлашадыр[1], әгәр дә дөньяда адәм кебек яшисебез килсә, дөнья яктысын күрәсебез, балаларыбызны адәм кебек тәрбия кылып, укытасыбыз килсә, эш вакытын кыскартып, хезмәт хакын арттырасыбыз килсә, выбор вакытларында йоклап калмаска кирәк; избирательлек правасы булганнарыбыз выборга катнашып, үз эчебездән эшче халык файдасына тырышучы, эшче халыкның кирәген яхшы белүче ышанычлы фидакарь адәмнәргә тавыш биреп, выборщик сайлап, һич булмаса, Оренбургтан берәр эшчедән Думага депутат җибәреп, үз кирәкләребезне требовать итәргә кирәк. Юкса без эшчеләрнең кирәген алпавытлар, байлар кайгыртмаячак, чөнки һәркемнең бармагы үзенә таба бөгелә, үз файдасын күзли, безнең адәм кебек яшәвебезгә алар һич разый түгел. Теләсә мөселман, теләсә урыс, яки яһүди, поляк булсын, без эшче халык өчен тырыша торган, эшче халыкның кирәген белгән адәмнәргә тавыш бирергә тиеш. Чөнки урыс эшчесе илә мөселман эшчесенең хаҗәте бердер.

«Карчыга», 1906, 3 сан, 14б.

---

Форсат — җай, уңайлы очрак.

[1] II Дәүләт думасына сайлаулар 1907 елның январь–февраль аенда үткәрелә.

# МОҢ ТАМЫРСЫЗ БУЛМЫЙ



Иҗат почеркы үзенчәлексез була алмый. Һәрбер художник башка иҗатчылардан үзенчә аерылып тора. Берәүләрдә иҗат үзенчәлекләре алай ук күзгә бәрелми, ә икенчеләрдә... Композитор Алмаз Монасыйпов, мөгаен, икенчеләр рәтенә керәдер. Көчле дәрәҗәдә индивидуальләшкән катлаулы иҗат почеркы, табигый ки, гомум хорда аны шундук танып алырга булыша. Композитор әсәрләренең бик үк гадәти яңгырашлы булмавы музыкаль җәмәгатьчелектә еш кына бәхәсләр дә кузгата. Мондый иҗат почеркының тамырлары каян килә? Аларны шәхеснең үзеннән эзләргә кирәктер.

Композитор А. Монасыйповның автобиографик белешмәсендә мондый юллар бар: «... 1925 елның 11 июлендә Казанда туганмын; гомуми белем һәм музыка мәктәпләрен тәмамлагач, 1940 елда музыка училищесының виолончель классына укырга кердем; 1943—1945 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт иттем; 1945—1956 елларда Казан консерваториясен ике тапкыр тәмамладым: виолончель (доцент А. Броун) һәм композиция (профессор А. Леман) класслары буенча; профессор И. Шерман классында ассистентура-стажировка үтеп, Татар дәүләт опера һәм балет театрында озак еллар дирижер булып эшләдем; консерваториядә композиция классы да алып бардым...»

Белем һәм хезмәт биографиясендәге күпкырлылык композиторның иҗатында да сизелерлек чагылыш таба. Скрипка һәм фортепиано өчен соната, симфоник оркестр өчен балет сюитасы, скрипка, виолончель һәм фортепиано өчен камера-инструменталь әсәрләр, скрипка һәм оркестр өчен концертино-серенада, дүрт симфония, «Тукай аһәңнәре» вокаль-симфоник поэмасы... Әлеге төрлелек иҗатның бөтенлегенә һич тә зыян китерми. Шунысын да әйтергә кирәк: композитор нинди генә әсәр өстендә эшләмәсен, үзенең яраткан жанры — җыр өлкәсендә эзләнүләрен беркайчан да туктатмый. Татар, рус һәм башка милләт шагыйрьләре текстларына ул бик күп җырлар һәм романслар язды. Аларны Валентина Толкунова кебек илкүләм танылган җырчылар да яратып башкара. Алмаз Монасыйпов җырлары... Мондый төр әсәрләрдә композиторның кабатланмас стилен камилләштерү юнәлешендәге эзләнүләре дә күренә, тегәлрәк әйткәндә, осталыкның ни дәрәҗәдә үсүе җырның музыкаль гәүдәләнешендә шундук күзгә ташлана. Шулай ук җыр зуррак музыкаль идеяләрнең ялалуына, аерым алганда, катлаулы симфоник партитуралар («Тукай аһәңнәре» вокаль-симфоник поэмасы, «Муса Җәлил» симфония-поэмасы) драматургиясенең формалашуына да сизелерлек уңай йогынты ясый.

Искәртеп үтелгәнчә, А. Монасыйповның иҗат почеркы, татар музыкасы традицияләренә мөнәсәбәттә, шактый бәхәсләр кузгатты. Композитор иҗатында Урта Азия, Кавказ халыкларының музыкаль культурасы йогынтысын да күрүчеләр булгалады. Ә менә күз алдындагы чыганак — Урта Идел татарларының төрле этник группалары музыкасының шифалы йогынтысы тиешенчә игътибарга алынмады. Композитор үзенең эзләнүләрендә лад һәм структура ягыннан да, интонация һәм метроритмика ягыннан да нәкъ менә милли музыкаль фольклор үзенчәлекләренә таяна. Аның күп кенә җырлары һәм романслары казан татарлары һәм татар-мишәрләрнең озын көйләре традицияләре җирлегендә иҗат ителгән. Озын көйләрнең бай мелизматикасыннан автор бик оста файдалана, аларның пентатоник структурасына яңа бизәкләр өсти.

Композитор җырлары һәм романсларының интонацион-конструктив яктан халык иҗаты үрнәкләренә якынлыгы М. Җәлил сүзләренә язылган «Соңгы җыр»ның мелодик үстерелешендә аеруча ачык күренә. Үзенең драматизмы белән күңелләрне тетрәндерүче бу җыр тексты, белгәнебезчә, халык иҗаты үрнәгендә, шигъри параллельлек алымыннан файдаланып язылган.

Җир йөзе шундый киң,
Күңелле һәм якты!
Тик төрмәм караңгы,
Ишеге йозаклы!
. . . . . . . . .
Мин беләм: бик татлы
Да яшәү тойгысы!
Тик инде мин үләм,
Бу җырым — соңгысы!...

Интонацион яктан карагaнда, «Соңгы җыр»дагы көй агышы күпмедер дәрәҗәдә «Туган тел»не хәтерләтә. Шигырьнең беренче җөмләсенә туры килгән мелодик үстерелеш өченче һәм дүртенче юлларда түбәнге интонацион ноктага җиткерелә. Көйнең мондый драматургиясе җырның эчтәлегенә — якты һәм караңгы төсләр контрастына бик тә туры килеп тора.

«Хыяллар»... Эстрада өчен шактый еллар элек язылган бу лирик җыр (Ә. Ерикәй шигыре) тамашачы тарафыннан хәзер дә яратып тыңлана. Көйнең беренче өлешендә «Ак калфак», «Кәрия-Зәкәрия» кебек татар халык җырлары аһәңнәре яңгыраган төсле тоела. Икенче өлештәге отышлы модуляция көйнең дулкын төсле кабатланып торуын тәэмин итә, бертөрлелектән котылып, төрле вариацияләр ясарга мөмкинлек бирә. Әсәрнең күп кенә джаз коллективларын җәлеп итүе, мөгаен, менә шундый үзенчәлекләр белән аңлатыладыр.

Композитор А. Монасыйпов иҗаты турында сөйләгәндә, ритм мәсьәләләренә тукталмыйча ярамастыр. Ритм иҗатчы стилен тудыруда җитди роль уйный. Яңадан халык иҗатына кайтыйк. Күзәтүләр күрсәткәнчә, халкыбызның җыр сәнгатендәге күп кенә жанрлар катлаулы метроритмикага корылулары белән аерылып торалар. Әлеге үзенчәлек халык иҗаты үрнәкләренә таянып язылган әсәрләрдә дә югалмый. Әйтик, традицион 5/8 һәм 7/8 ритмик үлчәмнәре А. Монасыйповның вокаль лирикасында, «Тукай аһәңнәре» вокаль-симфоник поэмасының аерым өлешләрендә еш очрый. Композитор шушы ритмик төркемнәрнең төрлечә үзгәртелгәннәреннән дә уңышлы файдалана (фортепиано өчен пьесалар циклы, скрипка белән оркестр өчен концертино-серенада һ. б.) Гадәти үлчәмдә язылган әсәрләрдә дә вокаль партия ритмик яктан шактый катлаулы. Көй тау елгасы шикелләрәк ага — кочәя, салмаклана, тынып калгандай була. Шулай да көй тотрыклы ага, ритмик бөтенлеген җуймый.

Татар җыр сәнгатенең бер казанышы буларак кабул ителгән «Зөһрә» җыры (1965 ел) шулай ук Монасыйповча үзенчәлекле булуы белән игътибарны тартып тора. Әсәр ритмик яктан да кызыклы. Лирик җырның гади генә язылган тексты (М. Хәсәен шигыре) психологик тирәнлеккә дәгъва итми, шулай да ул композитор күңелендә төрле-төрле төсләр белән җемелдәүче балкыш тудырган. Көйнең кереш өлешендә импровизационлык сизелә. Күп бизәкле картина күз алдына килә: кояшлы иртә, үзенең матур киләчәге турында хыялланучы кыз... Җай гына агылган көйгә 5/8 үлчәмле фортепиано аккордлары килеп керә. Җырда контрастлык барлыкка килә. Халык көйләренә хас булган мондый үлчәм, әйтик, бишек җырларының салмак агышында тынычландыргыч тәэсир тудыра, ә менә кызу темпта ул, киресенчә, йокымсыраган җанны да уятып җибәрә, күңелләргә канат куя. Композитор очынып торучы Зөһрәне әнә шулай сурәтли һәм бер җыр кысаларында, темп һәм фактураны үзгәртү юлы белән, бер-берсенә капма-каршы рухи халәт тудыруга ирешә.

Шунысын да әйтеп үтик: «Зөһрә» җыры көенең беренче өлеше борынгы «Бәдәвам» китабы текстларын көен хәтерләтә. Китапларны көйләп уку традициясенең бер гәүдәләнеше булган бу көйдә казан татарлары җыр сәнгатенең борынгы катламнары шактый ачык күзаллана. Безгә аның авторы мәгълүм түгел. Китап үзе, белгәнебезчә, 1846 елда Казанда басылган. Ә аңарчы ул кулъязма төсендә таралган. Тарихчы Ш. Мәрҗани һәм башкалар фикеренчә, «Бәдәвам» Болгар заманнарында ук иҗат ителгән. Татар мәдрәсәләрендә дәреслек буларак хезмәт иткән әлеге китаптагы шигъри юлларны шәкертләр көйләп ятлаганнар, шулай итеп, аларны буыннан-буынга тапшырганнар.

«Тукай аһәңнәре» вокаль-симфоник поэмасының өченче бүлеге — композитор А. Монасыйповның вокаль миниатюралар өлкәсендәге иң күренекле казанышы. Циклның

лирик үзәген «Туган авыл» исемле җыр билгели. Күпмедер дәрәҗәдә бишек җырын хәтерләткән гап-гади көйдә татар халык иҗатының якты моңны сеңдергән тирән катламнары ачылып китә шикелле. Көйнең агышы пентатоника чикләреннән чыкмый, һәм моны классик үрнәккә әверелгән шигырь үзе таләп итә. Барысы да табигый рәвештә көй агышына буйсынган. Һәм нәтиҗәдә... Сөекле шагыйребез Г. Тукайның шигъри юллары һәркемнең «үзәгенә үтәрлек» булып яңгырый, җырның кайтавазы күңелләрдә тирән мәгънәви төсмерләр уята.

Күздән кичерелгән шушы әсәрләр буенча гына да шуны ышанып әйтергә мөмкин: композитор Алмаз Монасыйпов иҗаты лад һәм структура ягыннан да, ритмика һәм мелодик үстерелеш ягыннан да халкыбызның җыр культурасы традицияләренә таяна. Иҗатының башлангыч чорында ул армый-талмый белем офыкларын киңәйтә, табигый интуиция һәм «йөрәк кушуына» бирелеп, төрле жанр һәм стильләрдә көчен сынап, үзенә генә хас кабатланмас язу алымын камилләштерү юнәлешендә туктаусыз эзләнә. Үзендә ныклы ышаныч тугач һәм сайлаган юлның дөреслегенә инангач, композитор, музыкадагы милли башлангычны чиксез олылаган хәлдә, иҗатын тирәнлек буенча да, киңлек буенча да өзлексез камилләштерә башлый. Бүгенге көндә исә Алмаз Закирович Монасыйпов профессиональ осталыкның югары баскычына күтәрелде, һәм без әлеге тәҗрибәле композитордан татар музыка сәнгатен баетырлык яңадан-яңа һәм тагын да үзенчәлеклерәк әсәрләр көтәргә хаклыбыз.

**Наилә ШӘРИФУЛЛИННА,**
Казан дәүләт консерваториясе укытучысы.

# ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВ ХАТЛАРЫ

Язучы Габдрахман Әпсәләмов мирасы татар совет әдәбиятының горурлыгына әверелде, аның бай иҗаты укучылар күңелендә үз урынын тапты. Әнә шуңа күрә, гомеренең соңгы көннәренә кадәр язу өстәлен ташламаган фидакарь әдипнең тормышына, иҗат юлына яңалык өстәгән һәр факт һәм документ безнең өчен кадерле. Бу очракта исә сүз аның Бөек Ватан сугышы фронтыннан язган ике хаты турында барачак. Аларны безгә әдипнең дусты Рәхмәтулла ага Гайфуллин китереп тапшырды. Бу хатлар әдипнең Бөек Ватан сугышы вакытындагы тормышын тулырак күз алдына китерергә ярдәм итәләр.

Хатларны китерүче Рәхмәтулла ага үзе 1907 елда Алтай краенда туган. Ата-анасы чыгышы белән Татарстанның хәзерге Зеленодольск районындагы Акъегет авылыннан. Ачлык елны алар бәхет эзләп ерак Алтайга күчеп китәргә мәҗбүр булганнар. Рәхмәтулла Гайфуллин — үз тырышлыгы аркасында белем алган, киң дөньяга чыккан кеше. Заманында ул төрле җаваплы урыннарда эшләгән. Ә 1936 елда аны, партия эшләрендә чыныккан кадр буларак, Татарстан китап нәшриятына эшкә җибәрәләр. Шушы вакыттан алып Рәхмәтулла ага татар язучылары белән аралашып, алар белән тыгыз элемтәдә яши. Г. Әпсәләмов белән ул 1939 елны эшләгәндә таныша. Әдип бу вакытта Мәскәүнең М. Горький исемендәге Әдәбият институтында укый һәм институтка татарлардан укучылар оештыру өчен Казанга килә. Шул вакыт Рәхмәтулла ага үзенең әле генә тәмамлаган повестен укыта. Г. Әпсәләмов әсәрне Мәскәүгә, институтның кабул итү комиссиясенә алып китә. Әлеге повесте белән Рәхмәтулла ага Әдәбият институтына кабул ителә.

Бөек Ватан сугышы башлангач, бу ике дусның юллары вакытлыча аерыла. Әмма 1942 елны Рәхмәтулла ага, Кызыл Армия частьларын мобилизацияләү һәм оештыру буенча махсус задание үтәп, Мәскәүгә кайтып төшә һәм Г. Әпсәләмов гаиләсенең авыр хәлдә калуын, әдипнең абыйсы һәм ике энесе һәлак булуын белеп, СССР Язучылар союзы председателе А. А. Фадеев янына керә. Әдипнең гаиләсенә туклану карточкалары бирүне җайга сала. Бу вакытта әдип үзе Карелия фронтында миномет расчетының командиры булып хезмәт итә. Бер бәрелеш вакытында яралана, госпитальдә ята. Рәхмәтулла ага аның әнисе аркылы әдипнең хәлләрен белешеп тора. Бервакыт махсус задание белән аны да әдип сугышкан Карелия фронтына җибәрәләр. Ул анда Г. Әпсәләмовны эзләп таба, армия политбүлегендә аның сәләтле татар язучысы булуын, армия газетасында эшләп зур файда китерәчәген әйтә. Күпмедер вакыттан соң әдипне чыннан да рус-ча чыга торган газетага әдәби хезмәткәр итеп күчерәләр. Соңрак ул Карелия фронтында татар телендә чыга башлаган газетага күчә, бу вакытта аңа кече лейтенант званиесе дә бирелә.

Биредә әдипнең фронттан Рәхмәтулла ага Гайфуллинга язган ике хатын урнаштырабыз.

Гайфи дус!

Көтмәгәндә синнән хат килеп төште. Мине онытмавың өчен зур рәхмәт...

Үзем турында нәрсә языйм соң? Госпитальдән чыккач, күп тапкырлар разведкада булдым, үзем өчен хәрби счет ачтым, бәрелешләрдә катнаштым. Һәм һаман да исән-сау. Аз-маз армия газетасына язгалыйм. Хәзер безнең фронтта татар телендә газета чыга. Анда әдәби хезмәткәр булып эшләргә иде дә, юк, мөмкин түгел! Монысы бит миннән тормый. Язучылар союзы мине бөтенләй онытты. Ә хатлар язып кына ни майтарып булсын. Син якында булсаң, бәлки ярдәм дә итәр идең.

Мин сиңа көнләшеп тә куям. Күп йөрисең, күпне күрәсең. Без, язучылар өстендә тагын бер зур бурыч ята — без халыкка, киләчәк буыннарга бүгенге бөек көрәш турында сөйләргә тиешбез. Син дә каләм тибрәтүче кеше, бу турыда син дә язарга тиешсең!

...Яхшы әсәрләрне Матбугат йортының 5 нче катында утыручылар түгел, ә тормышның үзендә кайнаучылар язачак! Монысы минем өчен ачык! Ә минем үземә килгәндә, темалар туып кына тора, материал да байтак, күпне күрдем һәм кичердем! Бик тә язасы килә, әмма мөмкинлек кенә юк.

Сиңа Мәһинурдан сәлам. Җавап көтәм. *Сәлам белән Габдрахман.*

*Полевая почта 774 384 часть. 27/II—43.*

Кадерле Гайфи дус!

Бүген синең 1943 елның 9 маенда язган хатыңны алдым. Ул миңа шактый соңарып килде, чөнки бу араларда еш күчендем, адресым да үзгәреп торды...

Барыннан да элек безнең гаиләнең кайгысын уртаклашуың өчен сиңа зур рәхмәт. Мин бертуганнарымның һәлак булуын бик авыр кичерәм. Үзем дә күп тапкырлар ут эчендә булдым. Минометым утны һәрвакыт беренче булып ача иде. Мин хәтта юк ителгән фашистларның санын да алып бардым. Әмма болар гына барыбер аз. Бу кабахәт фашистлар белән акфиннарга карата миндә нинди нәфрәт уты кайнаганын белсәң иде!

Синең рекомендацияң буенча мине редакция эшенә тарттылар. Һәр юлны кара белән түгел, каным белән язам. Гади сугышчыларның тануы кыен булган кечкенә генә язмаларын эшкәрткәндә аларга үземнең бөтен ярсуымны һәм нәфрәтемне салырга тырышам, сугышчыларда да шундый ук хисләр уятсын дим. Үзем дә бит ике елга якын алар арасында сугыштым.

Әнкәйне кайгыртуың өчен нинди генә рәхмәтләр әйтим? Солдат буларак, шуны гына әйтә алам — исән калсам, гомердә дә онытачак түгелмен!

Миңа эшләгән изгелекләрең өчен дә сиңа зур рәхмәт. Редакциядә мин үз урынымны табачакмын, әлбәттә. Монысы өчен тыныч бул. Ләкин монда бу эшкә әзерлексез кешеләр дә бар. Алар үзләре әйбәт кешеләр, ләкин каләмнәре юк. Сүзнең төсмерләрен, тирән мәгънәсен, көчен аңлап җиткермиләр.

Хәзер мин бик күп язам. Ләкин бастырырга урын юк. Үзебезнең газетага русча язганны гына бастырып була. Ә татарчадан яхшы тәрҗемә итүче кеше монда юк. Казанның үзендә дә хәлләр шәптән түгел. Журнал да бик акрын кыймылдый.

Апрель аенда Советлар Союзы Герое Илдар Маннанов янында булдым. Аның турында очерк язам. Политуправление аны татар һәм рус телләрендә бастырып чыгару өчен Казанга җибәрде. Шулай да, барлап торучы булмагач, ул хәрәкәтсез ятар, дип куркам. Ә аны тиз арада бастырып чыгару яхшы булыр иде, аерым китапчык булып чыкса бигрәк тә шәп (кулъязмада 20 бит). Иң кулае Воениздатка тапшыру. Анда эшне тиз тоталар.

Аннан соң минем фронтта язган хикәяләремне дә бастырасым килә. Аларның саны 10 нан артты инде. Ләкин Казан белән һич тә уртак тел табып булмый.

Син җибәргән китаплар килеп җитмәделәр. Бик кызганыч, миндә хәзер әдәбиятка мохтаҗлык бик көчле. Ә кәгазь мәсьәләсе хәл ителде. Мине монда даими эшкә калдыру-калдырмаулары әлегә билгеле түгел. Минем звание штатка туры килми бит.

Хат көтәм. Сиңа сәламәтлек һәм ныклык телим.

*Сәлам белән синең Габдрахманың.*
*Полевая почта 68331 Д 25/VI—43*

## ӘДӘБИЯТТА ТУКАЙ ОБРАЗЫ

Татарстан язучыларының проза, поэзия һәм драматургия секцияләренең 11 апрельдә узган берләштерелгән утырышы әнә шул темага багышланды.

Утырышны проза секциясе җитәкчесе М. Мәһдиев алып барды. Фикер алышуларда язучылар Г. Бәширов, Ә. Еники, Н. Арсланов, И. Нуруллин, тарих фәннәре докторы, профессор Р. Нәфиков, Р. Даутов, Р. Кәрами, Л. Хәмидуллин, Ә. Рәшитов һәм башка иптәшләр чыгыш ясады. Тукайның тулырак, җентеклерәк биографиясен булдыру, тагын да ачыклый төшү кирәклеге, шагыйрьнең халык күңелендә тоткан урынына лаеклы әсәрләрнең аз булуы әйтелде.

## БАШКАЛА КҮРГӘЗМӘСЕНДӘ

Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышланган 1600 сынлы сәнгать, графика, скульптура, декорация һәм гамәли сәнгать әсәрен берләштергән Бөтенроссия сәнгать күргәзмәсендә Татарстан рәссамнары һәм скульпторлары да катнашты. СССРның халык художнигы Х. Якуповның «Рәссам. Фронт зарисовкалары» исемле картинасы мәскәүлеләрдә зур кызыксыну уятты. Скульптор А. Әбдрәшитов, театр рәссамнары Ә. Тимергалиев һәм А. Чудайкинның эшләрен дә тамашачылар яратып карадылар.

## М. ҖӘЛИЛ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Әстерхан шәһәрендә Муса Җәлил исемен йөрткән урам бар. Май аенда шул урамда урнашкан балалар китапханәсе бинасына мемориаль такта куелды. Бу уңайдан тантаналы митинг уздырылды.

## ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

17 майда Казанның Төзүчеләр культура сараенда күренекле язучы Вакыйф Нуруллинга 50 яшь тулу хөрмәтенә аның иҗат кичәсе үткәрелде.

Кичәне Татарстан Язучылар союзының партия оешмасы секретаре язучы Р. Мөхәммәдиев алып барды.

Әдипнең иҗат юлы турында тәнкыйтьче Р. Мостафин сөйләде.

Кичәдә катнашучылардан Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, РСФСР Язучылар союзы консультанты шагыйрь Г. Рәхим, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры профессор Я. Абдуллин, Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире А. Әхмәдуллин, Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Шәрәфетдинов, Татарстан телевидениесенең баш редакторы шагыйрь Р. Миңнуллин һ. б. популяр әдипнең әсәрләренә югары бәя бирделәр.

Кичәдә катнашучылар өчен республикабыз башкаласы сәнгать осталары көче белән зур концерт бирелде.

12 апрельдә язучыларның Тукай клубында шагыйрь Роберт Әхмәтҗановка 50 яшь тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Аны шагыйрь Р. Гатауллин алып барды.

Язучылар союзы идарәсе исеменнән шагыйрьне идарә председателе Т. Миңнуллин котлады. Р. Әхмәтҗановның иҗат юлы турында шагыйрь Р. Харис сөйләде. Кичәдә шулай ук шагыйрьнең каләмдәшләре Р. Мингалимов, М. Әгъләмов, Ф. Сафин һ. б. чыгыш ясады.

Соңыннан РСФСРның халык артисты И. Шакиров, Татарстанның халык артистлары Х. Бигичев, Р. Ибраһимова, Татарстанның атказанган артистлары Р. Сәхәбиев, Х. Җәләлев, җырчы Х. Шәйдуллин катнашында зур концерт булды.

26 апрельдә Казанның Актерлар йортында Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Илдус Әхмәтҗановның иҗат кичәсе булды. Габдулла Тукайның 100 еллыгына багышланган әлеге кичәне кереш сүз белән шагыйрь Р. Харис ачты. Аннары И. Әхмәтҗанов башкаруында Г. Тукайның «Кисекбаш», С. Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә» һәм бөек шагыйрьгә багышлап язылган башка әсәрләр яңгырады. Шулай ук кичәдә Татарстанның халык артистлары З. Сәхәбиева, Х. Бигичев һ. б. чыгыш ясады.

## БРЕЖНЕВ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

17 февральдә Брежнев язучылар оешмасының чираттагы утырышында прозаик Газиз Кашаповның иҗат отчеты тыңланды. Г. Кашапов бүгенге көннәрдә нинди әсәрләр язуы, якын киләчәктәге планнары белән таныштырды. Фикер алышуларда филология фәннәре кандидаты Ә. Шәрипов, прозаиклар Ф. Дунай, Р. Сәлимҗанов, драматург Р. Хәмид, шагыйрьләр Н. Мадъяров, К. Сибгатуллин, Я. Игәнәй һәм башкалар Г. Кашаповның иҗатына нигездә яхшы бәя бирделәр, кайбер кимчелекләрен күрсәтеп үттеләр.

23 мартта язучылар оешмасының чираттагы утырышы Түбән Камада үтте. Ул яшь прозаик-

лар Таһир Нәбиуллин, Фәтхулла Абдуллин, яшь шагыйрь Михаил Федосенко иҗатлары турында сөйләшүгә багышланды. Фикер алышуларда катнашкан Р. Хәмид, Г. Кашапов, Р. Сәлимҗанов, Н. Алешков, Р. Хисмәтуллин һәм башка иптәшләр бу авторларның иҗатын уңай бәяләделәр.

13 апрельдә язучылар оешмасының чираттагы утырышы Алабуга шәһәрендә үтте. Ул шушы төбәктә яшәп иҗат итүче «Чулман» әдәби берләшмәсе членнарының иҗаты турында сөйләшүгә багышланды. Утырышта М. Гимазетдинов, Л. Абдуллина, Ф. Шаехов, Ф. Хуҗин, И. Абдуллин, М. Хәлиуллова әсәрләренә тирән анализ ясалды. Фикер алышуларда Брежнев язучылар оешмасыннан Р. Хәмид, Н. Мадъяров, К. Сибгатуллин, «Чулман» әдәби берләшмәсе җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Ә. Шәрипов, әдәби берләшмә членнары катнашты.

Шушы ук утырышта Алабугада рус телендә язучы иптәшләрнең иҗатын активлаштыру максатында яңа әдәби берләшмә булдыру мәсьәләсе каралды, берләшмә оештырылды. Яңа берләшмәгә «Лира» дигән исем кушылды, җитәкчесе итеп М. Абзянов сайланды.

Яшь язучыларның соравы буенча, ике әдәби берләшмәнең дә эшчәнлеген даими күзәтеп, ярдәм итеп тору өчен аларга шефлар итеп Брежнев язучылар оешмасыннан Н. Мадъяров һәм И. Лимонова билгеләнде.

28 мартта Мәскәүдәге дөнья әдәбияты институтында М. Горький исемендәге Бөтенсоюз әдәби конкурсында җиңүчеләргә дипломнар тапшырылды.

Җиңүчеләр арасында прозаик Әхәт Гаффар да бар. Ул бу бүләккә Мәскәүнең «Современник» нәшриятында чыккан «Долг» («Әҗәт») дигән китабы өчен лаек булды.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Совет сынлы сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен түбәндәге иптәшләргә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 15 апрель Указы белән «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде:

Әхмәдиев Илдар Каюмовичка — художник-график, СССР Художниклар союзы члены.

Зарипов Эрот Якубовичка — художник-график, СССР Художниклар союзы члены.

## ХЕЗМӘТЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет кинематографиясе өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм 50 яшь тулу уңаеннан Казан кинохроника студиясенең документаль кино режиссеры Харис Фәсхиевич Фәхретдинов КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

# УРАЛТАУ ЭРГӘСЕНДӘ

Иҗаттагы озын гомерлелек санаулы шәхесләргә генә биреләдер. Татар сынлы сәнгате аксакалы Бакый Урманче — әнә шундый бәхетле осталарның берсе. Ярты гасырдан артып киткән иҗат эшчәнлеге аңа һәрьяктан да югары камиллек баскычына күтәрелергә ярдәм итә. Нәгышь, скульптура, графика, сәхнә бизәү һәм көнкүреш сәнгатьләре, художестволы проектлаштыру... Иҗаттагы озын гомерлелек рәссамнан күпкырлы осталык таләп итүче менә нинди тармакларны колачлый. Һәрбер әсәр бөтен чылбырның табигый бер буынын билгели. Әсәрләреннән күренгәнчә, Б. Урманче Европа, рус һәм шулай ук Көнчыгыш сәнгатьләре традицияләрен яхшы белә, әмма аның сәнгатьчә фикерләү нигезе милли культура казанышларын гаять дәрәҗәдә нечкәләп аңлау-өйрәнүгә, милли традицияләрне заманча югарылыкта интернациональ баетуга корылган.

Рәссамның гаять киң колачлы иҗатыннан «Истә калганнар» сериясенә (1979—1980) генә тукталыйк. Дүрт картинаны берләштергән әлеге серия үткән һәм бүгенге турында уйланулар буларак кабул ителә. Яшәү мәгънәсе... Төрле уйлар кузгатучы фикер җепләре менә шундый бер төенгә җыйнала. Әсәрләргә балачак хатирәләре нигез итеп алына. Әмма рәссам үткәннәргә бүгенге күзлек аша карый, истәлекләргә хәзерге тәэсирләрен «кушып җибәрә»...

«Зәңгәр чиләк матур була, су белән тулса гына...» Уралтау эргәсендәге елгага су алырга төшкән кызларны күргәч, мәгълүм халык җырының әнә шундый сүзләре хәтергә килә. Кайтыр якка борылган зифа буйлы кызның бизәкле чиләкләре бәхеттәй мөлдерәп торалар. Бер читтә атлар чемченеп йөри. Тагын да ерактарак ике атлы үтеп бара. Казлар да елгага төшкән. Һәр тарафта аклык-пакьлек тантана итә. «Бәрхеттәй йомшак» буяулар, нечкә декоратив бизәкләр белән эшләнгән «Уралтау эргәсендә» картинасы иҗатында һаман яшь булып калучы аксакал рәссамыбыз Бакый Урманченың яшәү мәгънәсен тыныч тормыштагы хезмәт ләззәтен татуда, җирдәге матурлыкны саклап ишәйтүдә күрүен тагын бер мәртәбә ачык итеп раслый.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казан дәүләт консерваториясенең кыллы квартеты — ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Шамил Монасыйпов (сулда), Марат Зарипов, Альберт Әсәдуллин, Камил Монасыйпов.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотолары.

## Укучыларыбыз игътибарына

Илебездәге газета-журналларга киләсе ел өчен язылу кампаниясе башланырга аз вакыт калып бара. Шуңа бәйле рәвештә укучыларыбыздан «Казан утлары» журналына подписка тәртибе турында күпсанлы сораулар килә.

Соңгы еллардагы практика раслаганча һәм алынган хатлардан күренгәнчә, «Казан утлары» журналына язылуның иң уңайлы вакыты — подписка башлангач беренче унбиш көн. Моны бигрәк тә Татарстаннан читтә яшәүче иптәшләрнең исенә төшерәсе килә.

Журналның Бөтенсоюз каталогындагы индексы — 73210. Бер елга язылу хакы — 10 сум 80 тиен.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)